Данил Салихов
Таш сандык
***Пьесалар***

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
С18

**Салихов Д.Х.**

Таш сандык: пьесалар / Данил Салихов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 320 б. — 3000 д. — ISBN 978–5–298–01770–1

Бу китапка Данил Салиховның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре тупланды.
«Хиромантлар» пьесасы «Уч төбендә өч егет» исеме астында Минзәлә татар дәүләт драма театрында тамашачыга тәкъдим ителде. «Булмас димә, дөнья бу» комедиясе ике ел Әлмәт татар дәүләт театрында уңыш белән бара.

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
ISBN 978–5–298–01770–1

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Салихов Д.Х., 2008

# ХИРОМАНТЛАР

*Комедия ике пәрдәдә, өч картинада, ун күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Рамил — авыл хуҗалыгы академиясенең соңгы курс студенты. Баянчы.
Тәскирә — Рамилнең сөйгән кызы, Сәнгать институты студенткасы.
Шамил — авыл хуҗалыгы академиясенең соңгы курс студенты. Рамилнең бүлмәдәше. Баянчы.
Җәмилә — медицина институты студенткасы. Шамилнең сөйгәне.
Камил — авыл хуҗалыгы академиясенең соңгы курс студенты. Гитарада уйный.
Сәлимә — финанс-икътисад институты студенткасы. Камилнең мәхәббәте.

Вакыйга бүгенге көннәрдә студентлар тулай торагының һәм шәһәр фатирының бер бүлмәсендә бара. Рамил, Шамил һәм Камил бергә яшиләр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### *БЕРЕНЧЕ КАРТИНА*

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл хуҗалыгы академиясе тулай торагының егетләр яши торган бүлмәсендә өстенә төрле сурәтләр төшерелгән футболка, джинса кигән Рамил өстәл янында җыр язып утыра. Караватта, аякларын бөкләп, Шамил «За рулем» журналы актара. Футболка, шортиктан. Бүлмә буйлап арлы-бирле Камил йөри. Өстендә кыска җиңле күлмәк, джинса.

Шамил. Егетләр, нинди иномарка алыйм икән?
Камил. «Мерседес» ал, бетле тавык! Ач-ялангач хәерче! Ничек тә, акча төртеп булса да, дипломыңны алырга тырыш инде. Таралган колхозыңа кайтып, бабаңнан калган ДТ-75 тракторын җыярсың. Институтны бетерергә ярты ел вакыт калды. Авылыңа кайтып нишләмәкче буласыңдыр?

Шамил. Кайтып буйдаклар армиясенә язылам. Безнең авылда, Пескәйдә, егерме сигез өйләнмәгән ир-егет бар. Шуларның иң яшенә утыз җиде, иң картына җитмеш җиде, ә миңа егерме җиде. Иң яше мин булам.

Камил. Нәрсә дә булса уйларга кирәк, егетләр! Минем әни карт. Миңа өйләнергә кирәк. Авылга инженер булып кайтып сыер имчәге тартыр хәлем юк. Менә син, Шамил, авылга кайтып, чиләк өстенә утырып, сыер имчәге тартырга ризамы?

Шамил. Юк. Ими тотсам, дәртем уяна. Син минем өчен кайгырма. Үзең турында кайгырт.

Камил. Синең турында да кайгыртырга туры килә шул. Җәмиләңне бабаңнан калган ДТ тракторы белән сөйрәтеп тә алып кайтара алмаячаксың.

Шамил. Әнә Рамил Җәмиләгә атап җыр гына язып бетерсен. Баянымда уйнап, шул җырны Җәмиләгә өздереп җырлап җибәрәчәкмен, көрпә салынган чиләккә сыер ничек иярсә, Җәмилә дә шул моң артыннан авылга кадәр ияреп кайтачак.

Рамил. Булды бу, егетләр! Килеп чыкты бу. Тыңлап карыйсызмы?

Шамил. Йә, йә, Рамай!..

Рамил *(баяны белән торып баса).* Так. Значит, болайрак. Рамил абыегыз сүзләре һәм музыкасы. «Җәмилә». *(Җырлый.)*

Салкын сулар сибеп кенә
Үстерәм гөлләремне.
Серләремне сөйләр идем,
Тыңласаң серләремне.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Гөлләремнең ал чәчәге
Таң нурында балкыды.
Мәңге сүнмәс, һич сүрелмәс
Сөюемнең ялкыны.

Тәрәзәгә үреләсең,
Гөлләргә күмеләсең;
Гөлгә карыйм, сиңа карыйм,
Син матур күренәсең.

Йә ничек, егетләр?

Шамил. Прелесть! Шәп, Рамил! Браво! Булдыргансың, молодец!

Рамил. «...Гөлгә карыйм, сиңа карыйм, Син матур күренәсең». Шәп бит! Көйгә сүзләр рәхәтләнеп мәтәлчек атып ята.

Камил *(караватына барып утыра)*. Ерунда. Син миңа язып бирдең бит инде. Сәлимәнең тәрәз төбенә барып җырлаган идем, помой суы белән коендырып җибәрде.

Шамил. Синдә бит моң юк, ахир. Моң юк.

Рамил. Синең колагыңа аю басканга мин гаепле түгел.

Камил. Каян килгән Поваroттий да Басков. Хренников, несчастный! Син шагыйрь дә, композитор да түгел! Беләсеңме син кем?

Рамил. Кем?

Камил. Шарлатан!

Шамил. Ул музыкада бернәрсә дә аңламый. Борчылма, Рамай. Сиңа авыл хуҗалыгы академиясенә түгел, консерваториягә укырга керәсе калган.

Камил. Нинди аяныч. Татар халкы нинди композиторын, нинди шагыйрен югалткан.

Рамил. Борчылма. Барысы да алда. Шамил, бүген үк кызыл почмакка керербез дә өйрәнербез.

Камил *(Шамилгә)*. Баяныңны күтәреп, Җәмилә тәрәзәсе янына барып бу җырны җырлый күрмә. Бөтен медицина институты студентларын көлдерәчәксең. Җәмиләне оятыннан бауга менгерәсең. Баян — узган гасыр, искелек калдыгы. Алтмышынчы, җитмешенче еллар. Гитарада уйнап, җырлап та мәсхәрәгә калдым әле.

Шамил. Икедән гайре башка аккорд белмәгәч, каласың, билгеле.

Камил. Минме?! Әбиеңә кайтып сөйлә. Өч ел рәттән студентларның смотр концертында унбишенче, егерме өченче, егерме җиденче урыннарны алдым.

Шамил. Ул концертларда утыз гына номер иде шул.

Рамил. Да, егетләр, сезнең эшләр бик шәптән түгел. Озакламый диплом, аннары — авыл, ә кызларыгыз — Җәмилә белән Сәлимә — авылга кайтырга ашкынып тормыйлар.

Камил *(урыныннан тора, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри).* Кирәк бит, ә, кирәк бит. Әтисе җирле үзидарә җитәкчесе рәисе. Кызына шәһәрдә эш эзли диген. Ә мине, котыртып, энем Камил, авыл хуҗалыгы академиясенә бар, авылны сездәй егетләр генә аякка бастырса бастыра, дип, шәһәргә укырга озатты. Кирәк бит, ә, кирәк бит, егетләр!

Шамил. Аның урынында булсам, мин дә шулай эшләр идем.

Камил. Нигә?

Шамил. Син имгәктән котылырга. Ә мин үзем борчылмыйм. Җәмилә җыр-моң өчен егылып китә. Менә, Җәмиләкәй, кара кашкай, сиңа атап, төн йокымны калдырып җыр яздым, дип җырлап җибәрүем булачак, Җәмиләкәй, күз яшьләренә чыланып, иңсәмә башын куеп үксеп-үксеп елап җибәрәчәк.

Рамил. Дөрес, Шамил. Ирләр — имән тамыры, кызлар — бодай камыры!

Камил. Камыр шул. Бер ташый башласалар, тотып тыяр хәл юк.

Рамил. Мин барда борчылмагыз, егетләр! Минем башка ышаныгыз. Егетнең уе — үбешү дә кавышу, кызның уе — кияүгә чыгу.

Камил. Әкият! Әнә Сәлимә ике ай инде миннән качып йөри. Свиданиегә дә чыкканы юк.

Шамил. Чыкмаса. Минеке дә чыкмый. Күпме бүлмәләрен саклап утырырлар дип уйлыйсың.

Рамил. Чыгарлар. Дәрт ирләрдә бер өлеш, ә кызларда җиде өлеш. Кара әле, Камил, уйлаган булып, эч пошырып, идән пычратып, тузан туздырып, баш әйләндереп тудыйм-судыйм йөрмәле! Мокытым, наданкаем, аңгыракаем, ул башыңны күпме генә уйлатсаң да, барыбер трактор, комбайннан гайре бернәрсәнең дә очына чыгалмаячак. Сезнең икегезнең дә ул башкайларыгыз шөреп, гайка борырга гына җайланган. Ә кызлар, кызлар алар катлаулы техника. Аларга аерым подход, аерым ачкыч кирәк. *(Үз башына сугып.)* Менә, менә ул кызлар душасына ачкыч таба торган баш! Баш түгел, домсовет! Худсовет та педсовет! Өстәвенә Госсовет! Булды, суламый торыгыз! Башка идея килде. Кызларыгызның бер-берсен күргәннәре бармы?

Шамил. Юк. Камил Сәлимәсенең өеннән чыкканы юк бит аның. Профессор булырга җыена. Шуңа күрә әтисе дә кызын шәһәрдә калдырмакчы була. Дөрес эшли. Мин дә шулай эшләр идем. Нигә әле мин профессор буласы кызымны, майга каткан бер инженер аламасына биреп, авылга кайтарып сыер имчәге тарттырыйм.

Камил *(үртәлеп).* Бер авылда үсеп, бер мәктәптә укып, бер партада ун ел утырып, сигез ел артыннан чапкан кыз да, әтисе сүзенә карап, синең сүзеңне аяк астына салып таптагач, билгеле, авыл бетә. Авыл беткәч, тел бетә, тел беткәч, милләт бетә.

Рамил. Борчылма, җайларбыз. Кызы күрергә матур, акылга такыр. Ничего! Алтын йөзекләр сынмас, дәртле егетләр тынмас! Шамил, син үзеңнең Җәмиләңне Камилгә бирәсең.

Шамил. Нәрсә?! Тоттырганнар ди Камилгә Җәмиләне. Аңа ул борылып та карамаячак. Бакча карачкысына!

Камил. Нәрсә сөйли ул шүрәле?! Нәрсә сөйләгән була ул кар кешесе?! Синең Җәмиләңнең миңа майга, балга манып бирсәң дә хаҗәте сукыр бер тиен!

Рамил. Егетләр, башка юл юк. Нишлисең, аңлыйм хәлегезне. Ике якта ике гүзәл, берсен бирсәң, берсе җәл. Ә син, Камил, Сәлимәңне Шамилгә бирәсең.

Камил. Алсын. Бөтен приданныйлары белән бирәм. Мин жадный түгел. *(Тамашачыга.)* Күрмәгәнен күрсәтеп кайтарсын.

Шамил. Шуннан нәрсә килеп чыга инде?

Рамил. Шуннан шул, Шамил дускай, аклы ситсы кем кимәс, кемнәр ярын кем сөймәс. Син — Сәхипкә, мин — зәгыйфькә, дип, эшне башлыйбыз.

Камил. Юк, син безгә планыңның серен аңлат.

Рамил. Ашыкма. Тәртә — чана белән, һәрбер эш — чама белән. *(Камилгә.)* Син Сәлимәнең җен ачуын чыгардың, шулаймы?

Камил. Шулай булмый ни.

Рамил *(Шамилгә).* Ә син Җәмиләнең?

Шамил. Авылга кайтмыйм дип киреләнә бит.

Рамил. Ат киреләнсә, тәртә арасына кертермен дип уйлама. Сез үпкәләп йөргән арада, аларга икенче егетләр кармак салып куймасыннар.

Камил.
Шамил. Чыннан да.

Рамил. Бар әйбернең җае бар, чыпчыкның да каны бар. Ачулары басылганчы вакыт уздырырга кирәк.

Камил. Юк, синең бу планың барып чыкмаячак. Алар дивана түгел.

Рамил. Дөрес, алар — акыллы, син — дивана. Син кызларны белмисең. Эт — өреп, егет — йөреп, кыз көтеп картая. Башларын әйләндерергә кирәк. Болганчык суда балык тоту уңайлы.

Шамил. Ну молодец та инде үзең, Рамай! Чыннан да, синдә баш түгел, Дума, малай.

Рамил. Хәзер, икене икегә кушып, биш чыгарабыз. Камил, хәзер син Шамилгә Сәлимә турында чәчми-түкми барысын да сөйлисең. Ә син, Шамил, Камилгә Җәмилә хакында. Шамил, син — «Сәлимә» җырын, ә син, Камил, «Җәмилә»не өйрәнәсең. Аңлашылдымы, егетләр?! Сезгә өч көн вакыт. Өч көннән соң, кызларыгыз белән танышып алгач та, Камил, без сине сөйгәнең Җәмилә белән Тәскирәләрдә чәй өстәле артында кабул итәрбез. Чәе, мәе, сый-хөрмәте — сездән, суы — бездән.

Шамил. Ә безне?

Рамил. Камилләрне сәгать өчтә. Кабатлап әйтәм, пятнадцать ноль-нольдә. Ышан сезгә, такыр башка. Иртәнге өчтә килә күрмәгез. Ә сез, многоуважаемый, без пяти минут будущий инженер иптәш, восемнадцать ноль-нольдә, ягъни кичке алтыда. Бер чынаяк чәй, үзегезнең сый белән башлы-күзле итәрбез. Булды бу. Камил — гитара, Шамил — баян. Ә мин, Рамай Шакировский, башлап җырлаучы. Егетләр, инструментларыгызны алыгыз! *(Егетләр инструментларын алалар.)* Безнең гимн! Раз, два, три! И... начали!

Рамил
Шамил
Камил (*җырлыйлар*).

Алмагачта алма күп,
Матур кызда хәйлә күп,
Матур кызда хәйлә булса,
Яшь егеткә файда юк.

Егет — гөлнең былбылы,
Кызлар — былбылның гөле.
Гөл былбылны сагыныр,
Былбыл гөлгә багыныр.

Егет ата киекне,
Кызлар сөя егетне.
Кызлар сөя шул егетне —
Бирсәң алтын йөзекне.

Музыка көчәя, ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук картина. Төн. Егетләр йоклыйлар. Камил караватыннан тора да, аяк очларына басып кына, Шамил янына килә.

Камил *(пышылдап)*. Шамил, Шамил, Җәмилә нindирәк соң ул, чибәрме?

Шамил. Аһ, анаңның баш баласы! Йоклыйсыңмы, юкмы син! Өченче тапкыр йокыдан уятасың. Сәгатькә кара. Төн уртасы. *(Сикереп урыныннан тора.)* Рамил, әйт әле шушы бабникка, үтерә бит инде. Төне буе йокы бирмәде.

Рамил. Нишлисең, мәхәббәт! Суык — колактан, сылу йөрәктән алыр. *(Әйләнеп ята.)*

Шамил. Философ!

Камил. Беләсе килә бит. Ә вдруг мин аңа өйләнермен.

Шамил. Нәрсә?! Син?! Аңа?! Саташасыңмы әллә? Утны сүндер! *(Юрганын бөркәнә.)*

Камил. Кемгә кирәк, шул сүндерер. *(Караватына таба китә.)*

Шамил, урыныннан торып, ут сүндерергә бара.

Шамил *(Камилгә)*. Белеп тор, егет, кызлар чырае күрмичә картайсам, исемем Шамил булмасын!

Шамил утны сүндерә. Музыка. Әкрен генә таң сызыла. Бүлмә эчен сыек кына зәңгәрлек каплый. Камилнең ятагын прожектор яктырта.

Камил *(саташа)*. Сәлимәм... Сәлимәкәем, зинһар, миңа рәнҗемә. Мин Җәмиләгә өйләнәм инде. Ул минем белән авылга кайтырга вәгъдә бирде. *(Мыгырдап ала да янәдән гырлый башлый. Тагын саташа.)* Җәмилә, Җәмиләкәем, чалгыңны кибәнгә када. Балалар киселмәсен. Җәмилә, Җәмилә!..

Шамил белән Рамил торып утыралар. Прожектор алар ягына борыла.

Шамил. Әй Ходаем, хараплар булдык.

Рамил. Нишләмәк кирәк, сыерга — тоз, тинтәккә кыз күрсәтмә. Саташа, бичара.

Камил *(саташуын дәвам итеп)*. Сәлимәм, әй лә, Җәмиләм!..

Рамил. Саташа.

Шамил. Саташу гына түгел бу, җенләнә!
Рамил. Юк, бастырыла.
Камил *(саташа).* Сәлимәкәем, Җәмиләкәем, телисезме, сезгә атап язган җырымны җырлыйм.
Рамил. Буталып беткән, бахыр.
Шамил. Ну нәфсе кешедә... *(Мендәрен Камилгә ыргыта.)* Тор, имгәк! Саташасың бит, дивана!
Камил *(сискәнеп уяна да торып утыра).* Ә?! Нәрсә булды, егетләр? Нигә йокламыйсыз?
Шамил. Йокларсың синең белән.
Камил. Нигә торып утырдыгыз?
Рамил. Кызык булганга.
Шамил. Киен әйдә.
Камил. Нигә?
Шамил. Психбольницага барабыз.
Камил. Нигә?
Рамил. Сине күрсәтергә.
Камил. Мине?! Нигә?
Шамил. Җенләнә башладың бит, дивана!
Камил. Ә, теге ни бит... *(Үз-үзеннән оялып.)* Төш күреп ята идем.
Шамил. Күрә идең шул. Жмут! Крахабор!
Рамил. Йә, сөйләп кара, нинди төш күрдең?
Камил. Янәсе, анатомиядән имтихан бирәм...
Шамил. Ниндирәк сорау эләкте инде?
Камил. Җир өстендә яшәүче тереклек.
Рамил. Нәрсә?! Синең өчен җир өстендә яшәүче тереклек Җәмилә белән Сәлимә генәмени?
Шамил. Безне кая куясың?
Камил. Әй, бәйләнмәгез әле. Йокларга кирәк. Иртәгә экзамен бирәсем бар.
Рамил. Төне буе әзерләндең бит.
Шамил. Болай булгач, бирәсең инде.
Рамил *(юрганы белән мендәрен алып).* Юк, егетләр, сез галимнәр белән бергә, бу бүлмәдә, йокы эләкмәс. Коридорда йоклау хәерлерәк булыр. Сәламәтлекне сакларга кирәк. Егет чаклар бервакыт чәчәк булып коела. Минем өйләнәсе дә бар бит әле. Булачак хатынга нәрсә дип аңлатырмын.

Рамил чыгып китә. Шамил, юрганына төренеп, Камил янына килә.

Шамил. Камил, Камил туганкаем, теге философ чыгып китте. Әйт әле, Сәлимә чибәрме?
Камил. Әйе. Менә хәзер мин сиңа таң сызылып килгәндә Сәлимә турында сөйләп утырырмын. Ычкын янымнан! Иртәгә экзамен бирәсем бар. Утны сүндер!
Шамил. Псих! Сиңа кирәк, син сүндер! Минем иртәгә экзамен бирәсем юк. Көндезге икегә кадәр йоклый алам. *(Урынына барып ята.)*
Камил. Сездән көт яхшылык, алырсың яманлык.
Шамил. Ямаулык сорасаң да бирмим. Сүндер утны!
Камил. Өйрәтмә. *(Утны сүндерә.)*

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук картина.

Ут янганда, бүлмәдә Шамил, Рамил һәм Тәскирә. Камил кайтып керә.

Шамил. О, Камил туган!..
Рамил. Котларга буламы?
Камил. Була, пычагым! Профессор Асия Гарифовнага өч тапкыр Җәмилә Сәлимовна дип эндәшкән идем, бар, энем, йокыңны туйдырып кил, дип куып чыгарды. Неврологка күренсәң дә зыян итмәс, дигән була, җен корткасы.
Шамил. Нигә төшеңне сөйләмәдең соң?
Камил. Телеңә салынып утырма, синең аркада төне буе йоклый алмадым.
Тәскирә. Җитәрегез инде, егетләр! Кеше экзаменын бирә алмаган. Борчыла. Ә сез...
Рамил. Борчылма. Өйләнеп, тынычлангач...
Шамил. Саташмый, бастырылмый...
Рамил. Йоклый башлагач бирерсең әле.
Шамил. Өйләнә алсаң.
Рамил. Өйләнә, нишләп өйләнмәсен. Мин башлаган эшемне җиренә җиткерми туктамыйм. Билгеле инде, безгә Тәскирә ярдәм итсә. Тәскирә, ярдәм итәрсең бит?!

Тәскирә. Нинди ярдәм хакында сөйлисездер бит? Уйлап карарга булыр.

Рамил. Ерунда. Менә шушы ике асыл егетне өйләндереп, башлы-күзле итеп авылларына озатырга иде.

Тәскирә. Шаяртмагыз, егетләр! Шамилнең — Җәмиләсе, Камилнең Сәлимәсе барын бик яхшы беләм мин.

Рамил. Каян беләсең?

Тәскирә. Үзең сөйләдең.

Рамил. Белгәч, бик яхшы.

Тәскирә. Кайда яшәгәннәрен, кайда укыганнарын гына белмим.

Рамил. Ялгышмасам, Җәмилә — медицинскийда, ә Сәлимә финансовыйда иде бугай. Кайда яшәүләре хакында егетләр үзләре әйтә инде.

Шамил. Җәмилә Лобачевский урамы, сигезенче йорт, җитмеш өченче фатирда хатын аерган бер исеректә өч кыз белән яши.

Рамил. Ишетәсеңме, Тәскирә матурым, Лобачевский, сигез, фатиры җитмеш өч.

Камил. Сәлимә — Тукай урамы, дүртенче йорт, бишенче фатирда. Дөресен генә әйткәндә, җимерелә язган бер баракта.

Рамил. Баракта... Тукай, дүрт, фатир биш. Танышасың киләме?

Тәскирә. Әлбәттә, килә.

Рамил. Танышасың килсә, үз яныңа торырга аласың инде. Ничек инде шундый гүзәл затларны баракта, йә булмаса, бер исерекбашта тотасың.

Тәскирә. Риза булсалар, шатланып. Минем белән яшәгән кызлар соңгы практикаларына киттеләр. Практикадан соң диплом алалар да күчеп китәләр.

Камил *(җитдиләнеп).* Авылга кайтмыйлармы?

Тәскирә. Юк, шәһәрдә калалар.

Шамил. Кызганыч...

Камил. Бик тә кызганыч.

Тәскирә. Тик шунысы бар: алар риза булмаслар. Мин торган фатирның хуҗасы бик күп сорый шул.

Рамил. Күпмерәк инде, әйтеп карале?!

Тәскирә. Кеше башына өч мең!

Шамил. Имәндә икән чикләвек!

Камил. Әбиең сызгыра беләме диярсең.

Шамил. Моңа безнең кәҗә сауган әнкәйләрнең генә акчасы җитми икән шул.

Рамил. Ерунда! Чепуха! Нишлисең, ат алсаң, арба кирәк, кыз алсаң, акча кирәк. Икегез дә эшләп торасыз, сынатмагыз.

Камил. Өчебез дә диген.

Рамил. Әй, минем эшләү инде ул, ташка үлчим, мәчегә сөт салырга да җитми.

Камил. Кара моны, Шамил, нәрсә сөйли!

Шамил. Жмут!

Рамил. Сынатмагыз, егетләр, атның юргасын, кызның уңганын алырга уйласагыз, ай саен кызларыгызга мең ярымыгызны жәлләмәгез.

Камил.

Шамил. Ә үзең?

Рамил. Ә мин нәрсә?! Минем кызым бар. Каршыгызда басып тора.

Камил. Юк инде. Аш салсаң, авылың белән, кыз алсаң, кавемең белән.

Рамил. Кара, син дә остарып киләсең түгелме?!

Тәскирә. Юк инде, Рамай, барып чыкмас!

Шамил. Кызык кеше син, Рамай.

Тәскирә. Җәмилә белән Сәлимә мең ярым түлиләр, ә Тәскирә өчне түли. Барып чыкмый.

Камил. Егетләрчә түгел.

Шамил. Юк, юк, Рамай, джентльменнарча түгел.

Рамил. Ничек егетләрчә түгел? Синнән мең ярым, аннан мең ярым, кушкач өч мең була. Шул өч меңне өч кызга бүлгәч, берәр мең була. Өч мең квартплатадан бер меңне алгач, кызларыгызга ике мең кала. Кызларыгыз ике мең түләргә риза булырлар дип уйлыйм. Ә мин кем өчен тырышып йөрим соң? Сезнең өчен! Сездән миңа гонорар тиештер бит инде.

Камил. Бик кыйммәткә төшмәссеңме?..

Рамил. Нигә? Бүре дә тук, кәҗә дә исән.

Тәскирә. Кәҗә хәлендә — Шамил белән Камил, ә син — бүре. Шулаймы?

Рамил. Тәскирә, телеңне тый. Характерымны беләсең. Кияүгә чыгасыңны онытма.

Тәскирә. Куркыттың. Исем китте. Алдымда өрлектәй ике егет басып тора. Мин аларның теләсә кайсы белән җир читенә китәргә дә риза.

Камил.
Шамил.    Авылга дамы?
Тәскирә. Каторгага да!
Камил. Өрмәгән урындыкка да утыртмам.
Шамил. Уч төбемдә генә саклармын.
Рамил. Ә менә мин сезне өченче этаждан ыргытырмын. Кара боларны! Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, диләр.
Тәскирә *(кычкырып көлеп).* Ярый, ярый, булды, егетләр! Җитте. Тезелеп басыгыз.

Кабалана-кабалана тезелеп басалар.

Камил.
Шамил.
Рамил. Нигә?
Тәскирә. Хәрәмләшмәгез! Буй озынлыгына карап тезелегез! *(Беренче — Шамил, икенче — Камил, өченче булып Рамил баса.)* Хи-хи-хи... *(Тамашачыга.)* Кәҗә тәкәсе! *(Рамилгә.)* Борчылма, үсәселәрең алда әле!
Рамил. Хикмәт буйда түгел, хикмәт... *(Паузадан соң, күкрәгенә сугып.)* Менә монда — душада!
Тәскирә. Ну-ка, егетләр, егетлегегезне күрсәтегез әле! Кайсыгыз кызлар өчен җан ата?!
Шамил. Мин!
Камил. Юк, мин!
Рамил *(тавышын калынайтып, ике мускулын кабартып).* Мин!
Тәскирә. Кайсыгыз юмарт, мин шуның белән авылга китәм. Минем өчен кайсыгыз күпмерәк түли?
Камил *(Тәскирәнең алдына тезләнеп, уң кулын күкрәгенә куеп).* Бер мең!
Шамил *(шул ук хәрәкәтне кабатлап).* Мең ярым!
Тәскирә. Йә, йә, кайсыгыз? Сынатмагыз, егетләр!
Рамил *(теләр-теләмәс кенә тезләнеп, Шамил белән Камилгә озак кына карап торганнан соң).* Ике мең ярым!
Тәскирә. Молодец, Рамил, булдырдың! Егет икәнсең! Сынатмадың! Мин — синеке, син — минеке! Сездән, егетләр, меңәр ярым, сөйгәнемнән ике ярым!
Шамил.
Камил.
Рамил.     Биш мең ярым?!
Тәскирә. Әйе, егетләр! Биш мең ярым!
Рамил. Чукынды марҗа калачка!
Шамил. Имәндә икән чикләвек.
Камил. Әкәләле имән ауды.

Өчесе дә, аңнарын җыя алмыйча, идәнгә утыралар.

Тәскирә. Сезнең теләгегез үтәлде. Иртәгәдән кызларыгызны үз култык астыма җыярмын.

Егетләр, идәндә утырган хәлдә, бер-берсенә пышылдап.

Камил *(Рамилгә).* Син безгә кемне алып килдең?..
Рамил *(аңына килә алмыйча).* Тәскирәне.
Шамил. Чегәннәр дә татар исеме кушалармыни?
Рамил. Кушалар икән шул.
Тәскирә. Сез, егетләр, ризамы?
Шамил.
Камил.
Рамил.     Риза булмый нишлисең?!
Тәскирә. Җавап көтәм, егетләр?!
Шамил.
Камил.
Рамил.     Риза инде, риза!

Музыка. Ут сүнә.

ИКЕНЧЕ КАРТИНА

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, гади генә җиһазландырылган Тәскирә яшәгән фатирның бер бүлмәсе. Ике якта ике ишек. Диван. Ике якта ике караватУртада — өстәл. Бүлмәгә Тәскирә, Җәмилә һәм Сәлимә керәләр.

Тәскирә. Рәхим итегез, кызлар! Бүгеннән башлап бу фатирда бергәләп яшәрбез. Диван — минеке, ике карават — сезнеке. Уңдагы ишек — кухня, сулдагы ишек — ванна.

Сәлимә. Рәхмәт, Тәскирә!

Җәмилә. Күңел ышанмый.

Сәлимә. Ничек инде шушындый затлы бүлмәгә нибары биш йөз сум гына түләргә...

Җәмилә. Мин туалетсыз, ваннасыз бүлмәгә өч мең түләп тордым.

Тәскирә. Борчылмагыз, кызлар! Бу однакомнатканы миңа бертуган абыем бүләк итте. Ул дальный плаваниедә эшли. Елга бер генә тапкыр кайтып китә. Бу хакта хәтта Рамил дә белми. Дүрт ел кешедән кешегә, фатирдан фатирга йөреп җаным чыкты. Фатирлы булу бәхетенә ирешсәм, үзем кебек газап чиккән студент халкына ярдәм итәрмен дигән сүзем бар иде. Сездән алган биш йөз сум шушы фатирның коммуналь түләүләре өчен кирәк.

Җәмилә. Әйт әле, Тәскирә, син безне каян эзләп таптың да һәм ни өчен именно безне?

Тәскирә. Ашыкмагыз, кызлар! Барысына да чират җитәр. *(Сумкасыннан акча чыгара.)* Менә монда биш мең дә биш йөз сум акча. Бу безнең расходлар өчен. Без хәзер сезнең белән гособеспечениедәге персональ студенткалар.

Сәлимә. Биш мең ярым?!

Җәмилә. Безгә?! Ай саенмы?

Тәскирә. Ай саен мин алган акчаларны кухнядагы комодта торган вазага салып куям. Чәй, шикәр, тоз, ипи, кер юу порошогы, сабын, кавын һәм дә бүтән кирәк-яраклар кирәк булса, шуннан алырсыз. *(Акчасын тотып кухняга кереп китә.)*

Җәмилә. Сәлимә, син берәр нәрсә аңладыңмы?

Сәлимә. Юк, ә син?

Җәмилә. Аңладым. Аферистка, йә булмаса, маньячка!

Сәлимә. Афера дип уйлыйсың?..

Җәмилә. Афера гына түгел. Монда ниндидер бик куркыныч сер ята.

Сәлимә. Сер?..

Җәмилә. Әйе, сер!

Сәлимә. Шулай шул. Мин дә шикләнәм. Ни өчен әле ул безне барлы-юклы биш йөзгә фатирына кертте.

Җәмилә. Эзләп табып кертте.

Сәлимә. Именно безне.

Җәмилә. Бу бүлмәгә биш йөзгә керергә теләүчеләр чират тора.

Сәлимә. Сез хәзер персональ студенткалар, диме?

Җәмилә. Әйе. Башта персональ, ә соңыннан...

Сәлимә. Раблар, ягъни коллар!

Җәмилә. Точно, афера! Исән чакта башны алып качыйк.

Сәлимә белән Җәмилә тиз-тиз чыгып китмәкче булалар, кухнядан,
ике пычакның йөзен бер-берсенә кайрап, Тәскирә чыга.

Тәскирә. Ит яратам, кызлар!

Җәмилә *(калтыранган хәлдә)*. Бетте, суя! *(Аңын югалтып егыла.)*

Тәскирә *(Сәлимәгә)*. Нәрсә карап каттың?! Бар, тизрәк кухнядан су алып чык, үлә бит!

Сәлимә *(куркуыннан тотлыга-тотлыга).* Миңа гына тия күрмә. Нәрсә телисең, нәрсә кушасың, барысын да үтим.

Тәскирә. Бар инде тизрәк, бар! Үлә бит!

Сәлимә. Хәзер.

Сәлимә йөгереп кухняга кереп китә. Кухняда дөбер-шатыр коелган савыт-саба тавышлары ишетелә. Тәскирә, елый-елый, Җәмиләне
яңаклый.

Тәскирә. Хараплар булдым, хараплар булдым. Үз башыма, үз башыма... Уян, уян, Җәмилә! Уян, җанкисәгем!.. *(Сәлимәгә.)* Син кая олактың?! Син кая олактың дим! Тизрәк бул! Су, су кирәк!

Кухнядан атылып Сәлимә чыга.

Тәскирә. Суың кая?

Сәлимә *(бармагы белән авызына төртеп күрсәтеп).* Стакан табалмадым, авызда!

Тәскирә. Тиз бул! Сиңа әйтәм, тиз бул, су китер!

Сәлимә. Хараплар гына булдым, ялгыш суымны йоттым. Мин хәзер, хәзер! *(Кабаттан кухняга кереп югала.)*

Тәскирә. Җәмилә, матурым, ач күзеңне! Зинһар, күзләреңне ач!

Җәмилә күзләрен ача. Куркуыннан сикереп тора да икенче почмакка сикерә.

Җәмилә *(куркуыннан тотлыга-тотлыга елап).* Сәлимә, Сәлимәне нишләттең? Сәлимә кая?

Кухнядан, чиләк белән су күтәреп, Сәлимә чыга.

Сәлимә *(тотлыга-тотлыга).* Мин монда, мин монда. *(Җәмилә янына бара һәм аны кочаклый.)* Мин әлегә исән, мин әлегә исән.

Тәскирә *(утырган җиреннән үксеп).* Котымны алдыгыз бит, кызлар, котымны алдыгыз.

Сәлимә *(Җәмиләгә пышылдап).* Афера!..

Тәскирә *(тынычлана төшеп).* Афера?.. Монда бернинди дә афера юк.

Сәлимә.

Җәмилә. Зинһар, зинһар, безгә генә тия күрмә. Нәрсә кирәк, нәрсә сорыйсың, нәрсә эшләргә кушасың, барысын да эшлибез.

Тәскирә *(тынычланып).* Утырыгыз әле, кызлар, мин кеше ашаучыга охшаганмынмы?!

Җәмилә. Юк, юк, охшамагансың. Тик...

Сәлимә. Безне генә...

Тәскирә. Сәлимә, синең йөргән егетең бармы?

Сәлимә *(куркуыннан тотлыгып, өстәвенә шикләнеп).* Юк. Минем егетем юк.

Тәскирә. Алдашма! Синең егетең бар! Исемен әйтергәме?!

Сәлимә *(шул ук халәтендә).* Юк. Минем егетем юк.

Тәскирә. Синең егетеңнең исеме — Камил!

Җәмилә *(Сәлимәнең колагына пышылдый).* Точно! Нәкъ үзе! Килеп каптык!

Сәлимә *(Җәмиләгә пышылдап).* Нишлибез?

Җәмилә. Дөресен сөйлә. Барыбер барысын да белә.

Сәлимә *(Тәскирәгә).* Юк, минем аның белән хәзер очрашканым юк. Кирәк булса, үзеңә ал!

Тәскирә. Ә синең, Җәмилә?

Җәмилә. Бар иде, хәзер юк.

Тәскирә. Хәзер мине тыңлагыз, кызлар! Синең Камилең, минем Рамилем, Җәмиләнең Шамиле сельхозның общагасында бер бүлмәдә яшиләр.

Сәлимә.

Җәмилә. Ничек бер бүлмәдә?

Тәскирә. Әйе. Дүртенче общаганың ике йөз дә туксан җиденче бүлмәсендә.

Җәмилә. Шулай шул. Шамил сельхозның дүртенче общагасының ике йөз дә туксан җиденче бүлмәсендә яши.

Сәлимә. Хак! Минем Камил дә шул бүлмәдә яши.

Тәскирә. Минем Рамай да шул бүлмәдә яши.

Сәлимә. Тәскирә, ә син кайда укыйсың?

Тәскирә. Минме? Мин культура институтында, массавик булырга җыенам.

Җәмилә. Ә мин — медицинскийда. Ә син, Сәлимә?

Сәлимә. Мин — финансовыйда.

Тәскирә. Менә таныштык та. Егетләребез бер бүлмәдә торып та, бер-беребезне белми яшәгәнбез. Кызлар, алар сезнең икегезне дә кызык итмәкче булалар. Мин сезгә серне ачмый булдыра алмыйм. Ни әйтсәң дә, мин дә сезнең кебек кыз.

Сәлимә. Кызык итмәкче булалар дисең инде?

Җәмилә *(аптырап).* Шамил белән Камил?!

Тәскирә. Һәм дә Рамил! Көннәрдән бер көнне синең Камилең — Җәмилә артыннан, ә Шамил — синең арттан, Сәлимә артыннан киләчәк.

Сәлимә. Менә сиңа мә! Вәт сиңа Камил. Век живи, век учись! Мыштым тәре! Күрсәтәм әле мин сиңа где раки зимуют! Бер авылда үсеп, бер класста укып, сигез ел арттан йөгереп...

Җәмилә. Аңлашылды. Авылга кайтмавымның үчен алмакчы була.

Тәскирә. Ничего, без аларның үзләрен кызык итәбез. Ат кибәннән өрекмәс, хәйләкәр кыз егеттән көлдермәс. Мин сезгә күрсәткән биш мең дә биш йөз сум акча — аларның ай саен безгә түли торган ясаклары.

Сәлимә. Шулай да мин аңлап җиткермим әле!

Җәмилә. Нәрсәсен аңламыйсың? Көннәрдән бер көнне урам чатында минем Шамилем сине көтеп ала да, нихәл, Сәлимәкәй, әтиең фәлән абзый, әниеңнең чын исеме белән, исән-саулармы, сеңлең, йә булмаса, энеңнең шулай ук исеме белән, ул ничегрәк укый, ул бит әле фәләненче класста, әниең, Камил өйрәткән буенча, фәлән апа һаман да шул эшендәме, дип сүз башлаячак. Син авызыңны күтәреп

шаккатып калачаксың. Каян мине белә икән бу дип. Синең хакта Камилең Шамилгә сөйләп торачак, ул шуны сиңа тукып торачак. Танышканыңны сизми дә калачаксың.

Тәскирә. Дөрес аңлагансың, Җәмилә!

Сәлимә. Ә минеке синекенә сөйләячәк.

Тәскирә. Иртәгә бирегә сәгать өчтә Сәлимә янына Рамил Камилне алып киләчәк. Рамай хәйлә табып чыгып качачак, ә Шамил синең белән танышу юлларын эзләячәк.

Җәмилә. Монда таныштырып торасы юк. Белмәсәң, бу очракта син дә, мин дә мәче тырнагындагы тычкан.

Тәскирә. Кызлар, зинһар, сынатмагыз, сер бирмәгез! Танышыгыз! Үзләрен кызык итәбез.

Сәлимә. Әгәр шул Камилне урынына утыртмасам, исемем Сәлимә булмасын!

Тәскирә. Ничего, бер күктә ике ай була алмаган кебек, бер кешедә ике мәхәббәт булалмый. Ә без киң күңелле. Берничә айга түзәрбез. Ике гыйшыкны бергә сыйдырырбыз. Ә инде кичке алтыда Шамил Сәлимә янына киләчәк. Кызлар, карточкаларыгыз бармы?

Сәлимә.

Җәмилә. Булмыйча. Бар, билгеле.

Тәскирә. Карточкаларыгызны үз караватларыгыз янына стенага элегез.

Сәлимә.

Җәмилә. Нигә?

Тәскирә. Кирәк. Минем планым бар. Барысы да уйланылган. Үзем дә сизмәстән, йөргән егетләрегезнең ачылмаган талантларын ачтым. Сезнең егетләрегез беләсезме кемнәр?

Җәмилә. Кемнәр?

Тәскирә. Вакыты җитәр. Үзегез әйтерсез.

Җәмилә. Һични аңламыйм.

Сәлимә. Мин дә...

Тәскирә. Вакыты җитәр, аңларсыз. Кызлар, димәк, кызык итәбез!

Сәлимә. Итәбез!

Җәмилә. Ничек кенә итәбез!

Тәскирә. Бер-берегезнең егетләрен ныклап, секундына йөрәкләре ничә тапкыр типкәннәренә кадәр өйрәнегез. Нәрсә яраталар, нинди аш, нинди кием, нинди прическа, нинди хушбуй һәм башкалар, һәм башкалар. Син, Җәмилә, Сәлимәгә — Шамилеңне, ә син, Сәлимә, Җәмиләгә Камилеңне сөйлә. Ә, шунысын әйтергә онытканмын, Рамил сезнең икегезгә дә багышлап җыр язган. Берсе баяны, икенчесе гитарасы белән сезнең алдыгызда тезләнеп җырлаганда, зинһар, көлеп җибәрмәгез.

Сәлимә.

Җәмилә. Түзәрбез!

Тәскирә. Йә, кызлар, Аллага тапшырып, башлыйбыз!

Сәлимә.

Җәмил. Башлыйбыз!

Сәлимә.

Җәмилә.

Тәскирә. *(җырлыйлар).*

Тал агачы, тал агачы,
Тал агачы — инештә.
Безнең ярлар безгә булыр,
Алдатмабыз ничек тә.

Ал да була, гөл дә була,
Су өсләре тын була.
Әгәр кызлар кирәк тапса,
Егетләр дә сал була.

Тал бөресе, тал бөресе,
Тал бөресе песиле.
Сездә ничек, бездә шулай —
Бездә кызлар сиземле.

Бүлмәгә Рамил керә.

Рамил. Сәлам кызларга! Нәрсә Берлинны алган кебек җырлыйсыз?

Тәскирә. Әллә алмаслар дип уйлыйсыңмы?

Музыка. Кызлар заманча бии башлыйлар. Көй тәмамлануга, барысы биюдән туктый.

Рамил *(көчкә-көчкә сулыш алып).* Ышан сезгә! Арба дуласа, атны уза. Йә, Тәскирәкәй, чибәркәйләрең белән таныштыр инде.

Тәскирә**.** Таныш бул, Сәлимә! Финанс-икътисад институтында экономика факультетының соңгы курс студенткасы.

Рамил. Исәнме, матурым! *(Кулын сузып күрешә.)* Рамил абыең Бәхтигәрәев булырмын. Күркәм йөзең — күзем өчен, күркәм буең — күңелем өчен.

Сәлимә. Егет сүзгә кеше кесәсенә керә торганнардан түгел.

Тәскирә**.** Җәмилә! Медицина институтының бишенче курс студенткасы.

Рамил. Да, могҗиза! *(Кул биреп.)* Авырткан җирдән кул китмәс, бу сылудан күз китмәс.

Җәмилә. Чудо!

Тәскирә**.** Кызлар, язгы бозны кар ашый, кызлар башын тел ашый.

Рамил. Бозга таянма, кызга ышанма! Егетләрегез белән кайчан танышабыз инде, кызлар?

Җәмилә. Егетләр тапкач.

Рамил. Әллә шушындый асыл затларның егетләре дә юкмы?..

Сәлимә. Бар иде, уплыли.

Рамил. Сер булмаса, ераккамы?

Җәмилә. Мәңгелек томаннар артына.

Рамил. Борчылмагыз. Яңаларын табарбыз.

Сәлимә.
Җәмилә. Бирсен Ходай!

Тәскирә**.** Синең ярдәм белән инде.

Рамил. Җәмилә, сиңа егетнең ниндие ошый?

Җәмилә. Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын! Егет булып җебегән булса, күз алдымнан юк булсын!

Рамил. Йөргән егетең җебегән идемени?

Җәмилә. Не то слово! Се-лә-гәй! Ничә ел гомеремне әрәм иттем. Капкабыз төбендә баян тартып чинаганы әле дә булса колагымда чыңлый. Шул тавышны ишетеп төннәрен куркып уянам.

Сәлимә. Нигә алай дисең, Җәмилә? Капка төбендә баян тартып җырлап торучылар булсын иде әле ул... Иртәгә үк институтымны ташлап авылга кайтып китәр идем. Минә гитарадан Аллам сакласын! *(Гитарада уйнаган кыяфәт ясап.)* Ляң-ляң-ляң! Төннәр буе, көннәр буе шул өч аккорд! Сигез ел йөрдек. Биш елга биш аккорд өйрәнә алмады. Баян баян инде ул. Гармунчы булсын иркәң, дип тиккә генә җырламыйлар.

Җәмилә. Сөйләмә юкны. Баян да булдымы инструмент! Искелек калдыгы. Гитара — современность!

Рамил. Баян бәгъреңә тигән икән, Җәмилә.

Җәмилә. Баяны кадалып китсен. Үзе саран, җитмәсә, әти-әнисе сүзеннән чыгалмый. Адым саен «авыл» дип теңкәмне корытты. Киенә дә белми, өтәчке! Ничә ел йөреп муеныма берәр алтын чылбыр таккан булса, йөгерә-йөгерә аңа ияреп авылга кайтыр идем ләбаса.

Сәлимә. Ә минеке... Камилне әйтәм, кулыма берәр алтын йөзек кидерсә, кыз күңеле — бер сатин... Ул нәрсә әйтсә, шул була иде.

Тәскирә**.** Анысы хак, кызлар. Йөргән чагында да саран булгач, тора башлагач нишләр. Минә минем Рамилем биш ел инде акча җыя. Диплом алуга, үзеңне алтын-көмешкә күмәм, ди. Шулай бит, матурым, Рамай?

Рамил *(тамашачыга).* Рамай, Рамай, трамвайга да акча юк шул, малай. *(Тәскирәгә.)* Булыр! Авылга гына кайт, булыр!

Сәлимә. Кызлар, сезгә әйтәм, Рамил, син тыңла. Тәмәке тарта. Күпме әйттем, йә — мин, йә — тәмәке, дип. Юк, ташламады. Әз-мәз генә тоткалый да. Ташла, дидем, тыңламады. Минә хәзер үзенә үпкәләсен.

Рамил. Борчылма, Сәлимә. Аракы эчми, тәмәке тартмый, баянда сыздырып уйный торган бик юмарт егет табып бирермен.

Җәмилә. Әле синеке затлы сигарет тартадыр. Ә минеке иң арзанлы, сасы сигарет. Аракы исенә түгел, пиво исенә дә түзеп булмый. Үземнекенә күпмеләр әйттем. Алма пиво, ал мороженое. Юк, тыңламады.

Тәскирә**.** Сөйләмәгез, кызлар! Ике мең ярым акча өчен күз яше белән елаган егетләрне дә күргән бар. Ә сез, алтын чылбыр, алтын йөзек, дисез. Хәзер андый егетләрне чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый.

Рамил *(тамашачыга).* Сылу — күңел аздырыр, алтын — юлдан яздырыр. *(Тәскирәгә.)* Рәхмәт инде, рәхмәт! Бетсен малың, чыксын җаның, минем кебек кыз белән диясең килә инде. Алырбыз. Әйттем бит инде, алырбыз!

Тәскирә**.** Менә шулай, Рамай, сиңа ике-өч көн вакыт. Шушы асыл затларга шундый шәп егетләр тап!..

Җәмилә. Уңган булсын, булган булсын, кесәсендә акчасы, шоколады, конфеты... Буе буй булсын, сүзе сүз булсын, үзе бай булсын, сөйгәне дә бер булсын! Гитарасын сыздырсын, үзе шуңа кушылып үзәк өзгеч итеп җырласын. Мин шул вакытта ризамын. Ә инде Шамил кебек булыр-булмас, әтрәк-әләм егет булса, күз алдымнан юк булсын!

Рамил. Булыр! Сезнең заказ буенча булыр! Ә сиңа, Сәлимә?..

Сәлимә. Мин Җәмиләгә кушылып шуны өстим: баян булсын кулында, алтын булсын уенда. Тәмәкене гафу итмим, аракыны, пивоны өйгә кертмим.

Рамил. Булыр! Сез уйлаган кавалер кичке алтыда биредә булыр.

Сәлимә.
Җәмилә. Сельхозданмы?

Рамил, шикләнеп, Тәскирәгә карый.

Тәскирә *(каушап)***.** Юк... Теге... Ни бит... Мин кызларга сине сельхозда укый, дөнья бәясе дус егетләре бар, үзем дә шуларга чүт-чүт кенә гашыйк булмый түзәм, дигән идем.

Рамил. Алтын тагарак көтеп, тишек тагаракка атланып калма! Ярый, кызлар, мин киттем. Алда зур эшләр көтә. Пока, кызлар!

Рамил чыгып китә.

Сәлимә.
Җәмилә.
Тәскирә. Әй, бичара!..
Тәскирә**.** Мескенем минем.

Музыка. Ут сүнә.

БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Шамил, баянында уйнап, «Сәлимәкәй», Камил исә,
гитарасын чиертеп, «Җәмилә» җырын өйрәнә.

Камил.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Шамил.
Сәлимәкәй суга барган чакта,
Җилләр сыйпап сөя башыннан,
Җилләр сыйпап сөя башыннан.

Камил.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Шамил.
Сәлимәкәй төнлә йоклаганда,
Ай сокланып үбә кашыннан,
Ай сокланып үбә кашыннан.

Камил. Юк. Булмый бу болай. Прямо колакка басасың. Кычкыртып уйнама әле?!

Шамил. Үзең соң, үзең, ни көең, ни моңың юк! Гурла! Акырасың да акырасың.

Камил. Миндә поставленный тавыш булганга мин гаеплемени?

Шамил *(Камил булып җырлап).*
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...
Ни көеңнең, ни сүзләреңнең ата-анасы юк.

Камил. Синеке әйбәт инде. Матәм маршы җырлап утырасың. Булмый бу, ахир, бар, коридорга чыгып өйрән.

Шамил. Чыгарсың, бар... Кичә дә комендант куып кертте. Сәлимәң янына озатам мин сине, ди.

Камил. Алайса, читальный залга чык.

Шамил. Аннан да кудылар. Нигә кирәк булды?! Хәзер мине общагада «Сәлимә» дип йөртәләр.
Камил. Исең китмәсен. Миңа да әйтәләр. Көнләшәләр. Үзеңә җыр өйрәнергә берәр почмак тап инде.
Шамил. Каян?! Юк инде, ахир, тыныч урын кирәк булса, үзең эзлә. Миңа монда да бик ошый. Мин монда да өйрәнә алам. Бик беләсең килсә, бу минем соңгы шанс. Сәлимә алдында сынатыр хәлем юк. Аннары кайтырсың авылыңа хатынсыз. Безнең авылдан кызлар кача. Урам буе өере белән буйдаклар гына йөри.
Камил. Бездә дә шул хәл инде ул.
Шамил. Эх, ахир, авылда көтүе белән кызлар йөрсеннәр иде ул. Төкерер идем Җәмиләсенә, Сәлимәсенә. Утыр инде экзаменга әзерләнәсе урынга «Сәлимәкәй» диеп баян акыртып, җыр өйрәнгән булып.
Камил. Сөйлисе юк. Өйләнмәс борын ай саен мең ярымышар алимент түләп.
Шамил. Тегене әйтәм, Рамилне, безнең башны бутады да үзе чыгып югалды.
Камил. Берүзенә ышанып өч кыз биреп җибәргәч.
Шамил. Башны харап итте инде.
Камил. Ыштансыз калдырды.
Шамил. Кәбестә янына кәҗә җибәрәләрме?
Камил. Теле телгә йокмый. Любой кызны үзенеке итә ала.
Шамил. Ну Тәскирә үзен кызык итте. Ике мең ярымны кычкыртып талады.
Камил. Сөйләп торган булма. Үзең соң, биш минуттан югары белемле инженер булырга торган башың белән, мең ярым, мең ярым, дип тезләнә-тезләнә, Тәскирә каршында биедең түгелме соң?!
Шамил. Син тезләнмәгән булсаң, орып бирә идем мин аны.
Камил. Мин, мең генә сум, дидем. Ә син... Уздыра, имеш. Мең ярым, мең ярым! Каян килгән миллионер! Менә хәзер түлә, җаның чыксын! Кадалып кит! Шартла!
Шамил. Ярар, булды! Җитте! Сөен! Ярый әле өчебезне дә пластунский шуыштырмады.
Камил. Кирәк бит, ә! Төне буе лычма суга батып мойкада машина юган акчаңны ниндидер бер кызга биреп чыгар инде.
Шамил. Әле ул синеке буламы-юкмы, билгесез.
Камил. Эч пошырып сөйләп тормасаңчы. Каравылда йоклап кайткан акчаңны акчага санап.
Шамил. Әйе, син генә эшлисең. Юсаң, зато чумара күрисең!
Камил. Борчылма, әнә Сәлимә белән генә танышып ал, сиңа да чумара күрергә туры килер.
Шамил. Тәки кайтмый.
Камил. Кара әле, Шамил, болар, Тәскирә белән сүз куешып, хәйлә белән безне саварга план кормадылар микән?
Шамил. Шулай дисеңме?.. Юктыр.
Камил. Хотя, Рамайны белмибезме?! Биш ел бер бүлмәдә яшибез. Булмас. Рамай — душа егет! *(Гитарасын алып җырлый башлый.)*

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Шамил *(баянына кушылып).*

Су буена төшкән идем, Сәлимәкәй,
Яфрак яргàн тал-тирәк шул, тал-тирәк.
Яна дисәң, ялкыны юк,
Ялкынсыз яна йөрәк.

Камил.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли...

Җырны бүлеп Рамил кайтып керә.

Рамил. Әй сез, Җәмилә белән Сәлимә, нишлисез?!
Камил
Шамил *(җырлауларыннан туктап).* Җыр өйрәнәбез.
Рамил. Аңгыракайларым, сез җыр өйрәнмисез, сез ботка пешерәсез. Бер бүлмәдә ике кеше ике төрле җыр өйрәнә аламыни?
Камил.
Шамил. Без өйрәнәбез.
Шамил. Ә кая өйрәник?!
Камил. Әйе, кая өйрәник?!

Шамил. Коридордан кудылар.
Камил. Читальныйдан кудылар.
Шамил.
Камил. Бүлмәдән дә куабыз, диделәр. Йә, булдымы?
Рамил. Булды. Ну кызлары, кызлары!..
Шамил. Матурлармы?
Рамил. Матур кыз — күз өчен, акыллы кыз — тормыш итәр өчен. Кызлар бик акыллы!
Камил. Чибәрләрме?
Рамил. Ташла! Чибәрлек — көн өчен, акыл — гомер өчен. Хикмәт чибәрлектәмени? Сез бит аларга өйләнергә җыенасыз. Гомер итәр өчен чибәрлек түгел, акыл кирәк. Акыл кирәк, егетләр!
Шамил. Алай димә, өйләнгәч, аны бит әле кочаклап та ятасы була.
Камил. Сәлимәне күрдеңме? Йә, ничек, чибәрме?
Рамил. Ничегрәк дип әйтим... Шадра бите — каз ите, шома бите — бот ите.
Шамил. Ничек?! Шадрамыни? Юк, мин уеннан чыгам. Миңа шадра кыз кирәкми. *(Камилгә.)* Сәлимәң үзеңә булсын.
Рамил *(Камилгә)*. Ул сине яратмый.
Камил. Ничек яратмый?!
Рамил. Шулай. Яратмый. Ул сине беркайчан да яратмаган.
Камил. Әкиятеңне әбиеңә кайтып сөйлә.
Рамил. Ул саран тәренең гитарасын тезгә куеп сындырырлык хәлгә килдем мин, ди. Синең кушаматың бар икән бит.
Камил. Нинди кушамат?!
Рамил. Сигез ел — биш аккорд!
Шамил *(шаркылдап көлеп)*. Шәп! Биш ел — өч аккорд!
Рамил. Син дә ыржайма! Пиво бүчкәсе! Саран тәре! Ничә еллар йөргән кызыңа бер алтын муенса гына алып таккан булсаң, менә хәзер Җәмилә урынына Сәлимә дип җыр өйрәнеп утырмас идең.
Камил. Жадность губит фрайера!
Рамил. Тик утыр, алкаш! Җәмиләгә алтын чылбыр алырга акчаңны әзерлә!
Камил. Бетемне тотсын! Миндә әндри казнасы юк!
Рамил. Алырсың! Авылга чибәр, югары белемле кәләш белән кайтасың килсә, йөзеген дә, алкасын да, балдагын да алырсың! Егет басмаган җир булмас, атсыз егет ир булмас. Малсыз егет — сансыз егет, чибәр кызга тиң булмас. Уен уен белән, егетләр, чыннан да, кызлары чибәр!
Камил. Җәмилә чибәрме?
Рамил. Андый чибәр кызны табулары, ох-хо-хой! Ул күзләре!..
Шамил. Егетләр, мин уеннан чыгам. Миңа мең ярымымны кире кайтарыгыз.
Камил. Күзләре нинди?
Рамил. Мәченеке кебек.
Камил. Нәрсә?!
Шамил. Мин уемнан кире кайтам.
Рамил. Янып торалар.
Камил. Чынлапмы?
Рамил. Чынлап.
Шамил. Мең ярымымны әзерләгез.
Камил. Рәхмәт, Рамай! Рәхмәт!
Шамил. Җәмиләмне берәүгә дә бирмим.
Камил *(Шамилгә)*. Тик кенә тор әле. Синнән сорап торалар ди. Саран тәре! Ул сине яратмый һәм яратмаган да диделәр бит инде.
Рамил. Өч кыз арасында иң чибәре — Сәлимә!
Камил. Ничек Сәлимә?
Рамил. Ул билләре, ул билләре, мин сиңайтим!
Шамил. Ну, ну...
Рамил. Көянтә белән тартасы килә.
Шамил. Нигә?
Камил *(кычкырып көлеп)*. Турайтырга.
Шамил. Уеннан чыгам, росходы күп.
Камил *(Шамилгә)*. Ышанма аңа, алдый ул. Аның билләре умарта кортыныкыдай. Ә гәүдәсе скрипка кебек. Аның чәчләре, тау башыннан агып төшкән чишмә кебек, бөтен гәүдәсенә хуҗа булып, билләренә кадәр сузылган. Аның күзләре... Аның энҗедәй тешләре... Аның кызарып пешкән чиядәй иреннәре... Сулышы җәйге урман аланы. Эх, егетләр, тиккә мин аның артыннан сигез ел йөгердеммени?

Шамил. Ә Җәмилә — калку күкрәк, тыгыз тән, киң җилкә, кәкре...
Камил. Нәрсә?! Киң җилкә дисеңме?!
Шамил. Бүлдермә! Кәкре аяк, җәлпәк борын, олы корсак, мул муен...
Камил. Җитте, җитте, булды. Үзеңә булсын.
Шамил. Җитте, җитте... Скрипка, имеш. Нигә бик тиз генә приданныйлары белән миңа бирергә ризалаштың? Алырсың синнән — эттән сөяк. Минем Җәмиләм кбек чибәр әле тумаган. Үзе тегә, үзе бәйли, үзе чигә, үзе тәмле пешерә, үзе җырлый, үзе бии. Тагын саныйммы?!
Камил. Ә минем Сәлимәм бу эшләрне берьюлы эшли.
Шамил. Ничек?
Камил. Йоклап!
Рамил. Тәк, егетләр, эшләр болайрак, иртәгә син, Камил, иртән-иртүк «Яхонт» кибетенә чиратка бас.
Камил. Нигә?
Шамил. Минем Җәмиләмә алтын чылбыр алырга.
Камил. Нәрсә?! Әйттерәсең әллә ни...
Рамил. Шунсыз булмый, Камил, өйләнү, кыз сайлау кеше гомерендә бер генә тапкыр була. Расходсыз гына булмый.
Камил. Акча каян алыйм?
Шамил. Үзем әҗәткә биреп торырмын.
Рамил. Ашыкма. Синең алтын йөзек аласың була.
Шамил. Бриллиант кашлысын түгелме?!
Рамил. Үз теләгең. Нишлисең, чибәр кызлар мал дауласа, егет матур яр сайлый.
Шамил. Юк инде. Мондый ук матур яр кирәкмәс иде.
Рамил. Иртәгә сәгать өчтә, син, Шамил, матур итеп киенеп, куен кесәңә алтын йөзек салып, баяныңны култык астына кыстырып, уң кулыңа розалар букеты (Кстати, букет алырга онытма!) тотып минем белән кызлар яши торган фатирга барасың. Ишекне ачып җибәрәбез, син чәчәкләреңне асыл зат Сәлимәгә бирәсең. «Күзләреңне йом» дисең. Ул күзләрен йомуга, бармагына йөзек кидерәсең.
Шамил. Аннары?
Рамил. Аннары, күңелең булганчы, күңеле тулганчы, аның алдына тезләнеп, «Сәлимәкәй»не сыздырасың.
Шамил *(Рамилгә)*. Ә син үзең нишлисең?
Рамил. Мин шул вакыт шыпырт кына чыгып таям. Сез икәүдән-икәү генә каласыз.
Камил. Кара, бу кызлар белән танышуның бер кыенлыгы да юк икән. Тезләнәсең дә торасың, тезләнәсең дә торасың.
Шамил. Ашыкма. Миннән соң син тезләнәсең.
Камил *(Шамилгә)*. Әйдә җырлап кара әле?!
Шамил. Әйе, җырлаган ди. Әллә мин дуракмы?
Камил. Акыллы да түгел инде.
Шамил. Ертык тишектән көлә.
Камил. Әйдә җырла!
Шамил. Җырлаган диярләр.
Рамил. Шансыгызны ычкындырмагыз, егетләр! Егет күңеле кызларда, кызлар күңеле кемнәрдә? Әлегә билгесез. Кызлар сезне ошатырлармы, юкмы? Кызлар бит кызарып пешкән кура җиләге. Башка егетләр өзеп капмасын.
Шамил. Ярар. Кадалып китсен акчасы. Аның янына баргач җырлармын.
Рамил. Менә молодец! Ә инде Камил белән кичке алтыда барырбыз.
Шамил. Алтын чылбыр алганда, кулонын алырга онытма. Ышан син саранга. Аның кулоны да юк. Кулоның өч тиенлек таш булмасын. Минем Җәмилә бик нәзберек ул. Күңелен төшерә күрмә. Әйдә җырла!
Камил. Әллә синең алда сер биреп торырмынмы?! Алырмын. Бриллиант кашлысын алырмын. *(Гитарасын ала.)*
Шамил *(тамашачыга).* Диваналарны чәчеп үстермиләр шул. Күз алдында шытып чыгалар. *(Камилгә.)* Җырла инде, җырла, нәрсә карап каттың?
Камил *(җырлый)*.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли...

Рамил *(Камилне бүлдерә)*. Булды, булды, җитте. Тукта. Бөтен общаганы аякка бастырасың. Син нәрсә?! Нишләвең бу?! Болай җырласаң, Җәмилә тәрәзәдән сикерәчәк. Егетләр, болай булмый. Инструментларыгызны алыгыз. Немедленно репетиция!

Камил — гитарасын, Шамил баянын алып җырлый башлыйлар. Рамил дирижерлык итә.

Камил.

Ай-ли, Җәмилә...

Шамил.

Саргайды ла йөзем, ай, саргайды...

Камил.

Җәй көннәре ямьле лә...

Шамил.

Сәлимәкәй, сине күп уйлап...

Камил.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Ут сүнә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*ИКЕНЧЕ КАРТИНА*

### АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Сәлимә үзе генә. Бүлмәдә звонок шылтырый.

Сәлимә. Керегез, кер, ишек ачык.

Бүлмәгә, кулына чәчәк бәйләме тотып, Рамил, баян күтәргән Шамил керәләр.

Шамил *(җырлый).*

Сәлимәкәй суга барган чакта,
Җилләр сыйпап сөя башыннан,
Җилләр сыйпап сөя башыннан.
Сәлимәкәй төнлә йоклаганда,
Ай сокланып үбә кашыннан,
Ай сокланып үбә кашыннан.

Иртән генә торып бер карасам,
Сәлимәкәй килә су буйлап,
Сәлимәкәй килә су буйлап.
Саргайды ла йөзем, ай, саргайды,
Сәлимәкәй, сине күп уйлап,
Сәлимәкәй, сине күп уйлап.

Сәлимә *(кул чаба).* Браво, браво, афәрин, бис!

Рамил. Гүзәл зат, Сәлимә! Минем сиңа дип атап алып килгән бүләгемне кабул итеп ал! *(Розалар букетын суза.)*

Шамил. Ничек синең?.. М-м-ми-и-нем...

Рамил. Әйе, чәчәкләрне Шамил сайлашты.

Шамил *(кыен хәлгә калганын сизеп).* Әйе, мин сайлаштым.

Рамил. Таныш бул, Сәлимә, минем иң якын дустым Шамил!

Шамил. Рәхмәт, рәхмәт! Исәнмесез!

Сәлимә *(кулын сузып).* Сәлимә!

Шамил *(күрешеп).* Мин беләм!

Рамил. Үзе әйбәт, үзе юмарт, эчми, тартмый, кызлар белән йөрми.

Сәлимә *(чәчәкләрне иснәп).* Каян белеп мин яраткан роза чәчәкләрен алырга булдыгыз?

Шамил. Камил әйтте... Әй лә... Теге... Ни...

Сәлимә. Камил?..

Рамил *(Шамилгә пышылдап).* Тинтәк! Тити баш! *(Сәлимәгә.)* Нинди Камил, нинди Камил... Камил кызга камил чәчәкләр дип әйтәсе килә аның.

Шамил. Әйе, әйе, камил чәчәкләр. *(Тамашачыга.)* Уф, тирләп чыктым.

Сәлимә *(Шамилгә).* Әллә бик эссеме? Тирләп чыктыгыз.

Шамил. Юк. Теге... Ни бит...

Рамил. Кызлар күрсә, тирли ул. Ярый, яшьләр! Ит — сүлле, егет җилле була. Ашыгам. Сәгать дүрттә экзамен. Пока! Мин очтым!

Рамил чыгып китә.

Сәлимә. Нигә ишек төбендә торасыз, түргә узыгыз.
Шамил. Рәхмәт, Сәлимә. Күзегезне йомсагыз иде.
Сәлимә. Бик теләп. *(Кулын суза. Күзен йома.)*

Шамил Сәлимәгә йөзек кидерә.

Шамил. Күзегезне ачыгыз.
Сәлимә *(күзләрен ачып, кулындагы йөзегенә карап).* Прелесть! Кирәкмәс иде инде, кирәкмәс иде. Мәшәкатьләнгәнсез.
Шамил. Бу минем сезгә бүләгем.
Сәлимә. Кирәкмәс иде инде. Салып бирер идем дә, үпкәләтермен дип куркам.
Шамил. Үпкәләмим.
Сәлимә. Юк, юк, үпкәләрсез. Беренче тапкыр күргән кызга шушындый бүләкләр өләшкәч, сез инде йөргән кызыгызны алтынга күмәсездер.
Шамил. Алай ук дип әйтмәс идем.
Сәлимә. Өстәвенә әле сез скромный да икәнсез. Миңа скромный егетләр ошый. Әйдәгез инде, әйдәгез, түргә узыгыз!
Шамил. Рәхмәт! *(Диванга барып утыра.)*
Сәлимә. Сезнең янга утырырга мөмкинме?
Шамил. Сорап торасыз. Алдыма утырсагыз да каршы түгелмен.
Сәлимә. Рәхмәт. *(Йөзеген күрсәтеп.)* Килешәме?
Шамил. Әйтерсең лә нәкъ сезнең өчен ясаганнар.
Сәлимә. Минем үземә алтын алкалар да бик килешә, диләр. Ә менә алкаларым гына юк.
Шамил *(тамашачыга).* Саргайта әле бу мине, көзге кырау! *(Сәлимәгә.)* Булыр!
Сәлимә. Нәкъ минем размер. Каян белеп алдыгыз?
Шамил. Камил инде... Камил булсын диеп алдым. *(Тамашачыга.)* Сөйләшә белмәгән телдән... Әйттерерсең әллә ни!
Сәлимә *(тамашачыга).* Мескенем... *(Шамилгә.)* Рәхмәт инде.
Шамил *(тамашачыга).* Рәхмәт белән тамак туймый шул. *(Сәлимәгә.)* Сәламәт булыгыз!
Сәлимә. Берәр нәрсә сөйләгез инде?
Шамил. Әтиең Рәкыйп абый исән-саумы?
Сәлимә *(гаҗәпләнгән булып).* Нәрсә?! Сез минем әтине каян беләсез?
Шамил *(тамашачыга).* Ай бу телне! Бу телне ярып, тоз сибәргә. *(Сәлимәгә.)* Юк... Теге... Ни бит... Уч төбегездән укыдым.
Сәлимә. Әллә сез хиромантмы?
Шамил. Хиромантмы дип инде, әз-мәз генә шөгыльләнгән булам шунда. *(Тамашачыга.)* Уф, котылдым! Миңа ул нәселдән, әни ягыннан килә.
Сәлимә *(тамашачыга).* Әбиеңнән түгелме! *(Шамилгә.)* Ну-ка, ну-ка, тагын нәрсәләр әйтә аласыз?
Шамил *(Сәлимәнең кулын тотып).* Сез — студентка. Финансовый институтның экономический факультетында соңгы курста укыйсыз.
Сәлимә *(тамашачыга).* Күзгә карап төтен җибәрә, сволочь! *(Шамилгә.)* Тагын ниләр күрәсез?
Шамил. Йөргән егетегез булган.
Сәлимә. Егет дисәң, хәтере калыр. Егет түгел, арыш боламыгы.
Шамил. Исеме — Камил.
Сәлимә. Сез бит настоящий хиромант!
Шамил. Ул сезне ярата.
Сәлимә. Яратадыр да бит, мин башканы сөям шул.
Шамил. Энең — Ильяс, сеңлең Гөлназ бар икән.
Сәлимә. Чудо!
Шамил. Әбиең узган ел, бабаң өч ел элек үлгән.
Сәлимә. Ә син әбиемнең әбисе кайчан үлгәнен әйтә алмыйсыңмы?
Шамил. Юк.
Сәлимә. Жалко.
Шамил. Мин алай ук тирәнгә керә алмыйм. Әтиең Рәкыйп абый авылыгызның хуҗасы икән. Әниең...

Сәлимә. Шамил җаным, укуыңны ташла! Сиңа нигә кирәк авыл хуҗалыгы академиясе. Син бит хиромант! Ач үзеңнең делоңны, кооператив. Синең ишек төбеңнән кеше өзелмәячәк. Исключительный бизнес! Мине дә үзеңә бухгалтер итеп алырсың.

Шамил. Юк, юк, син нәрсә, булмаганны.

Сәлимә. Нигә?

Шамил. Иртәрәк. Бераздан авылда ачарга җыенам.

Сәлимә. Мине дә үзең белән аласыңмы?

Шамил. Авылгамы?

Сәлимә. Хет җәһәннәм читенә.

Шамил. Син ризамы?

Сәлимә. Әлбәттә, риза.

Шамил. Их, Сәлимә! Мин бит синең янга шул теләк белән килдем. *(Баянын тартып уйнап җырлый башлый.)*

Су буена төшкән идем, Сәлимәкәй,
Яфрак ярган тал-тирәк шул, тал-тирәк.
Яна дисәң, ялкыны юк,
Ялкынсыз яна йөрәк.
Сикереп-сикереп агадыр кар суы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы?

Җырга Сәлимә дә кушыла.

Шамил.
Сәлимә.
Безнең авыл аркылы, Сәлимәкәй, Шамилкәем,
Ага суның салкыны шул, салкыны.
Су сипсәң дә басылмыйдыр
Янган йөрәк ялкыны.
Агып китте, агып китте, Сәлимәкәй, Шамилкәем...

Шамил.
Яулыгың кар суына шул.

Сәлимә.
Яулыгым кар суына.

Шамил
Сәлимә *(җырны дәвам итәләр).*
Аһ җаным, чыдый алмыйм
Йөрәгем ярсуына.
Сикереп-сикереп агадыр кар суы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы?

Сәлимә *(җырлап бетергәч).* Бигрәк матур җырлыйсыз.

Шамил. Җырлыйсыз түгел, җырлыйсың. Читләтмә мине, Сәлимә. Сез-безләрне бетерик. Син «син» дип дәш. Көен дә, сүзләрен дә үзем яздым.

Сәлимә. Татар халык җыры «Тәскирәкәй»гә кушылыпмы?

Шамил *(тамашачыга).* Ну, Рамай, подлец! *(Сәлимәгә.)* Гафу ит! Үземне тикшереп карамакчы идем. Кая, кулыңны бир әле? *(Уч төбен карап.)* Да, конечно. Менә бит сызылып ята. Менә бу сызык, кешенең күпкырлы икәнлеген күрсәтә. Синең ул ярылып ята. Син күп укыйсың, күп беләсең.

Сәлимә *(тамашачыга).* Белә, пычагым. Рамай йөз сиксән сигез тапкыр шушы җырны җырлап тинтерәтмәсә... *(Шамилгә.)* Тырышабыз инде, тырышабыз. Сез дә тырышасыз, без дә тырышабыз.

Шамилнең күз карашы стенага эленгән Җәмиләнең карточкасына төшә,
сискәнеп китә.

Сәлимә. Сиңа нәрсә булды? Сискәнеп куйдың. Йөзең агарды.

Шамил. Юк, болай гына.

Сәлимә. Ә-ә, ул минем иптәш кызым Җәмилә. Әллә танышыңмы?

Шамил. Юк, каян килеп таныш булсын ди.

Сәлимә. Сискәнеп киттең.

Шамил. Карашы йөрәгемә ярамый, авыр.

Сәлимә *(карточканы алып килә).* Минем иң якын подругам.

Шамил. Кирәкми. Кирәкми, урынына илтеп эл. Кире ягы белән элсәң, бигрәк тә яхшы булыр.

Сәлимә. Нигә?

Шамил. Аурасы йөрәгемә ярамый.

Сәлимә. Аурасы...

Шамил. Әйе, аурасы авыр.

Сәлимә. Бәлки, аның аурасы миңа да тәэсир итәдер.

Шамил. Юк, юк, син нәрсә?! Сезнең аураларыгыз туры килә.

Сәлимә. Шәп кыз.

Шамил *(карточканы кулына ала, тамашачыга).* Сөйгәненеңнең сурәтен тотып, башкага мәхәббәт аңлатып утыр инде. *(Сәлимәгә.)* Егете бармы?

Сәлимә. Сөйләвенә караганда, бар иде, ди, бер бозау. Между прочем, Шамил исемле иде, ди. Бер саран, хәерче, селәгәй иде, ди.

Шамил. Ташлаганмы, әллә егете китеп барганмы?

Сәлимә. Үзе ташлаган.

Шамил *(тамашачыга).* Юха елан! Кәрлә! *(Сәлимәгә.)* Зинһар өчен, алып куй бу фотоны. Күңелемә ярамый.

Сәлимә. Ташлаганыма сөенеп бетә алмыйм, аңа кияүгә чыгып, авылга кайтып, бот төбеннән резин итек киеп, сыер имчәге тартыр хәлем юк әле, ди.

Шамил. Әйтәм бит, аурасы авыр. Ялкаулыгы йөзенә чыккан. Алып куй, алып куй бу карточканы. Моның аурасы мине бесит!

Сәлимә. Насыйп яр табылыр әле, ди.

Шамил. Һичкайчан. Әйт үзенә. Ташлаган егетеңнән дә яхшыракны таба алмаячаксың, диген. Пескәй авылыннан икән.

Сәлимә. Каян?

Шамил. Пескәйдән. Әтисе — Гыйльфан, әнисе — Сания, абыйсы — Илшат, сеңлесе — Илһамия.

Сәлимә. Әбисе?.. Әбисе кайчан үлгән?

Шамил. Мәһрүрә әбиме? Биш ел элек.

Сәлимә. Бабасын беләсеңме?

Шамил. Габдрәхим бабайнымы? Белмичә. Күрше...

Сәлимә. Күрше?!

Шамил *(тамашачыга).* Чукынды, Шәрәфи ат кәҗәли! *(Сәлимәгә.)* Нинди күрше, нинди күрше? Күрешкәнем булмаса да, менә бу кызның фотосыннан, йөзеннән укып беләм дим.

Сәлимә. Шамил, син бит әрәм булып ятасың. Син хиромант кына түгел, син күрәзәче дә икәнсең бит!

Шамил. Юк, юк, мин күрәзәче түгел. Күрәзәчелек — әбиләр эше. Мин — хиромант! Шамилен сагынмый, димәк.

Сәлимә. Уйлап та бирми. Төшемә дә кереп карамый, сигез ел гомеремне суга салганмын, ди.

Шамил. Җәмиләме? *(Тамашачыга.)* Бу минем авызда тел түгел...

Сәлимә. Син аның исемен каян беләсең?

Шамил. Үзең әйттең бит, Җәмилә иптәш кызым, дидең.

Сәлимә. Что-то хәтерләмим.

Шамил. Бу минем иптәш кызым Җәмиләнең карточкасы, дидең. «Егетем чибәр иде» димиме соң?

Сәлимә. Куркырлык түгел иде, ди. Баянның өч төймәсенә басып, бераз гына татар халык җырларын уйнагандай итә иде, ди.

Шамил. Үзе кая соң әле?

Сәлимә. Ярты сәгатьтән кайтып җитәр. Рамил аны бер симпатичный егет белән таныштырам, диде. Рамил бит ул кешеләргә бәхет өләшеп йөрүче. Җитте, Җәмилә, сигез ел бер дурак, дундук, саран, авыл гыйбады белән йөргәнсең, җитте. Сиңа да настоящий уңган, булган, юмарт, гитарада сыздырып уйный, җырлый торган егет алып киләм. Ул тинтәгеңне башыңнан чыгарып ат, диде.

Шамил. Камил диме?!

Сәлимә. Каян белдең?

Шамил. Кемне?

Сәлимә. Камилне...

Шамил. Син нәрсә инде?! Камил егет белән таныштырамы дим. *(Тамашачыга.)* Килеп капканчы, таярга кирәк.

Сәлимә *(тамашачыга).* Шулай дип котыл. *(Шамилгә.)* Юк, хиромант булгач, әллә син барысын да беләсеңме дип уйладым.

Шамил. Белмим дә, беләсем дә килми.

Сәлимә *(тамашачыга).* Белсәң дә, белә алмыйсың шул. *(Шамилгә.)* Әйе, ул егетнең исеме дә Камил, үзе дә камил.

Шамилнең кесә телефоны шылтырый. Телефонын колагына куя.

Шамил. Алло, алло! Әйе, тыңлыйм. Аңлашылды. *(Сәлимәгә.)* Сәлимә матурым, минем вакытым чыкты.

Сәлимә. Ничек вакытың чыкты?

Шамил. Смена, смена, аңлыйсыңмы?!

Сәлимә. Ничек смена?..

Шамил. Онытылып киткәнмен. Ярты сәгатьтән смена!

Сәлимә. Эшкәмени?

Шамил. Әйе, эшкә.

Сәлимә. Чәй эчкән булыр идек.

Шамил. Башка вакытта.

Сәлимә. Иртәгә китәм. Ничәдә килә аласың?

Шамил. Ничәдә дип?.. Смена ничек туры килә бит.

Сәлимә. Иртәгә син төштән соң инде.

Шамил. Каян беләсең?

Сәлимә. Тәскирә әйтте.

Шамил. Тәскирә?! Тәскирә әйтсә, хак әйтә. Димәк, кичке якта.

Сәлимә. Шамил, ишетсен колагың, әгәр дә иртәгә, моның колагында алтын алкасы да юк инде дип, алтын алка күтәреп килсәң, бел, үпкәләтәсең.

Шамил. Рәхмәт инде. Һич кенә дә сине үпкәләтергә уемда юк. Ярый, матурым, сау булып тор. Иртәгә күрешкәнчегә кадәр.

Ашыгып чыгып китә. Икенче бүлмәдән Тәскирә белән Җәмилә чыгалар.

Тәскирә**.** Браво, Сәлимә, молодец! Булдырдың!

Җәмилә. Артыграк, артыграк килеп чыкты. Башка килмәслек иттең. Әле дә ачлы-туклы көн-төн эшләп, укып, кабыргага калган, син тагын алтын алка сөйлисең.

Сәлимә. Борчылма. Без уйлап тапкан уен түгел, үзләре. Без аларны чит-ят кызларга карамаслык итәргә тиешбез.

Тәскирә**.** Дөрес, Сәлимә! Ничу! Аларны сыгарга кирәк. Үз кызларының кадерләрен белсеннәр.

Сәлимә *(Җәмиләгә)*. Кая, бармагыңны суз! Менә бу йөзек синең сөйгәнеңнең туй бүләге булыр.

Җәмиләнең бармагына йөзек кидертә.

Җәмилә. Рәхмәт, рәхмәт, Шамилкаем!

Сәлимә. Кара бу тилене, Тәскирә! Мин алып бирдем, ә ул, Шамил, ди.

Җәмилә. Килешәме, кызлар?

Сәлимә.

Тәскирә. Килешә.

Җәмилә. Килешмичә, Шамилем бүләге бит!

Ишектә звонок шылтырый.

Тәскирә**.** Сәлимә, сыздык күрше бүлмәгә. Килеп җиттеләр.

Тәскирә белән Сәлимә икенче бүлмәгә кереп китәләр. Ишек төбенә кадәр ачыла, гитарада уйнап-җырлап, Камил белән Рамил керәләр.
Рамилнең кулында розалар букеты.

Камил *(уйнап җырлый)*.

Салкын сулар сибеп кенә
Үстерәм гөлләремне.
Серләремне сөйләр идем,
Тыңласаң серләремне.

Рамил.

Камил**.**

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Камил.

Гөлләремнең ал чәчәге
Таң нурында балкыды.
Мәңге сүнмәс, һич сүрелмәс
Сөюемнең ялкыны.

Рамил.

Камил.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Камил.

Тәрәзәгә үреләсең...

Җәмилә.

Тәрәзәгә үреләмен.

Камил.

Гөлләргә күмеләсең...

Җәмилә.

Гөлләргә күмеләмен.

Камил.

Җәмилә.

Гөлгә карыйм, сиңа карыйм,
Син матур күренәсең.

Рамил.

Камил.

Җәмилә.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.
Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Камил *(җыр беткәч).* Камил Солтанов көе һәм...

Җәмилә. Татар халык җыры.

Камил *(Рамилгә пышылдап).* Татар халык җыры?.. Ничек? Ә син?

Рамил *(пышылдап).* Мин дә шул халыкның бер улы!

Камил. Улы түгел, жулигы!

Камил Рамил кулындагы чәчәкләргә үрелә. Рамил чәчәкләрне
Җәмиләгә бирә.

Рамил. Алыгыз! Мондый гүзәлләр янына чәчкәсез килә алмыйм.

Камил. Ә мин?..

Рамил. Ә син — Камил! Таныш бул, Җәмилә, бу камил егет Камил була.

Җәмилә *(Камилгә кулын суза).* Җәмилә!

Камил *(кулын үбеп).* Камил!

Рамил. Гафу итегез, җәмәгать, ашыгам. Им-ти-хан! Чау, господа!

Рамил чыгып китә.

Камил. Җәмилә, җәй көннәре ямьле лә, күзләрегезне йомыгыз!

Җәмилә. Нигә?

Камил. Курыкмагыз, пәп итмим.

Җәмилә күзен йома, Камил аңа муенса кидерә.

Җәмилә *(муенсаны тотып).* Миңа?.. Муенса?.. Алтын?..

Камил. Күзләрегезне ачыгыз!

Җәмилә. Куркам. *(Күзен ачып тамашачыга.)* Фикер тупларга кирәк.

Камил. Кулонының ташын бриллиантлыны алырмын дигән идем дә, кибетегез хәерче икән.

Җәмилә. Борчылмагыз, киләчәктә алырсыз.

Камил *(тамашачыга).* Бик кыйммәткә төшмәссеңме?! *(Җәмиләгә.)* Алла боерса...

Җәмилә. Әйдәгез, түргә узыгыз. Диванга утырыгыз! Чәй куяр идем дә, бриллиант белән эш йөрткән егетләргә безнең өстәл бик кысыр күренер шул.

Камил *(тамашачыга).* Хәерче студентка берәр стакан чәй мешать итмәс иде. *(Җәмиләгә.)* Зыян юк. Рестораннан гына кузгалдым. *(Җәмилә алдына тезләнә.)* Җәмилә, мин сезнең белән танышырга дип килдем.

Җәмилә. Сез нәрсә?! Торыгыз! Әкиятегезне сөйләмәгез. Сездәй бай егетнең кызы булмас инде!

Камил. Күз атучылар, арттан йөрүчеләр күп, күңелгә охшаганнары юк.

Җәмилә. Ышанмыйм.

Камил. Бар иде, ташладым.

Җәмилә. Ни өчен?

Камил. Гитарада уйнаганымны яратмады. *(Гитарасын ала.)* Ә мин гитарасыз яши алмыйм. *(Җырлый.)*

Әй сез, матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын
Ник аңламыйсыз?
Ник аңламыйсыз?

Җәмилә. Кем инде ул сезнең йөрәкне яндыручы?

Камил. Сез! Сез ул минем йөрәгемне яндыручы.

Җәмилә. Ә бәлки, элек йөргән кызыгыздыр.

Камил. Сәлимәме?! Прошлый этап. Үзе минем өчен саргайсын!

Җәмилә. Сәлимә дисезме?!

Камил. Сез нәрсә, үткәннәргә сәлам дә бирмим дим. *(Стенадагы Сәлимә карточкасына күзе төшә.)* Стенада кем фотосы ул?

Җәмилә. Бүлмәдәш кызым Сәлимәнеке.

Камил. Сәлимәнеке?! Ну-ка, бирегә алып килегез әле! *(Җәмилә карточканы алып килә.)* Кая, бир әле?! Явыз кыз! Күрәсең, күзләренә чыккан. Әллә бу Сәлимәләр барысы да явыз микән? Өстәвенә куркак! Авылдан качкан. Берүк син аңа минем исемемне, минем белән танышканыңны әйтә күрмә. Ул синнән көнләшә.

Җәмилә. Да?..

Камил. Да!

Җәмилә. Аның хакында тагын нәрсәләр әйтә аласың?

Камил. Бик шәп егете булган. Әти-әнисе күркәм кешеләр. Нәрсә, медичка булырга җыенамы?

Җәмилә. Сез боларны каян беләсез? Сез — күрәзәче!

Камил. Юк, мин — хиромант! Ну-ка, уң кулыгызны бирегез әле? *(Җәмиләнең уч төбен карап.)* Исемегез билгеле. Сезгә егерме ике яшь. Сез Пескәй авылыннан. Әтиең — Гыйльфан, әниең — Сания, абыең — Илшат, сеңлең — Илһамия!

Җәмилә. Чудо! Сез бит настоящий багучы!

Камил. Юк. Мин багучы түгел, мин — хиромант!

Җәмилә. Сез — хиромант?! Сезгә үзегезнең кооперативыгызны ачарга кирәк.

Камил. Ә бәлки, ул минем бардыр...

Җәмилә. Авылда мастерскойдамы?

Камил. Көләсез?!

Җәмилә. Юк, сельхозда укыганыгызга күрә әйтәм.

Камил. Бу туташның егете бармы?

Җәмилә. Бар. Искитмәле уңган, булган, бик бай егете бар. Сыздырып баянда уйнап җибәрә... Ул җырлавы, ул җырлавы бәгырьләрне телгәли, үзәкне өзә. Сәлимә әйтә, җиде ел гомеремне гитара чәңгелдәве тыңлап суга салганмын, бүген өйләнәм дисә, иртәгә үк авылга ияреп кайтып китәм, ди.

Камил. Авылга?! Чынлапмы? Алдамыйсыңмы?

Җәмилә. Нигә гаҗәпләндегез?..

Камил. Гаҗәпләнерсең дә. *(Тамашачыга.)* Вот сасы көзән! Тәмам Сәлимәне гашыйк иткән. *(Җәмиләгә.)* Бүгенгесе көндә кызларның авылга кайтуы — зур сенсация! Зур батырлык! Ә син үзең кайтыр идеңме?

Җәмилә. Яраткан бай егеткә тормышка чыксам, нигә кайтмаска!

Камил. Менә мин инде ул син эзләгән егет!

Җәмилә. Белмим шул. Киләчәк күрсәтер. Беләм мин хәзерге егетләрне. Миңа унҗиде түгел. Егетләр алар танышканда муенса-алтын асалар да, аннары үзләре кызлар муенына асылыналар. Өйләнгәч, иңсәгә үк менеп кунаклыйлар. Гомерең буе төшерә алмый азапланасың.

Камил. Борчылма, матурым. Без андый сорттан түгел. Димәк, иптәш кызың элекке егетен сагынмый дисең инде.

Җәмилә. Юк. Исемә дә кереп карамый, ди. Күпме гомеремне жмут, саран белән үткәргәнмен, менә бу ичмасам егет, ди. Тартса — баяны, җырласа — моңы бар, кесәсе тулы акчасы, тартып ала, суырып үбә... Кеше арасында йөрергә төс-кыяфәте, буй-сыны бар. Өтәчке белән йөреп, җиде ел гомеремне суга салганмын, ди.

Камил *(тамашачыга)*. Вот юбалгы! Кызның башын әйләндергән! *(Җәмиләгә.)* Тагын нәрсәләр сөйли?

Җәмилә. Беренче свиданиедә үк колагыма алтын алка, бармагыма алтын йөзек кидерде, ди.

Камил. Нинди алка, нинди алка, алдый ул. Йөзек кидергәненә ышанам, ә алка хакында алдый.

Җәмилә. Син каян беләсең?

Камил. Кара карточкасына. Колагында тишеге дә юк.

Җәмилә. Тиштерер! Йөзеге нәкъ менә шушындый.

Камил *(тамашачыга).* Астан эш йөртә, сволочь! Миңа әйтми генә алка да алган. *(Җәмиләгә.)* Алка дисең инде?!

Җәмилә. Әйе, алка дим.

Камил. Алка нәрсә ул?.. Менә алтын беләзек...

Җәмилә. Беләзек беләзек инде ул.

Камил. Киләсе килүемдә кулыңда эт чылбыры кадәр алтын беләзек булыр.

Җәмилә. Әгәр ике кулыма да алсаң, бүтән минем янга киләсе булма. Син миңа сыңар беләзек бүләк итсәң дә ошыйсың.

Камил *(тамашачыга).* Ыштанны салдырасыларың алда икән әле! *(Җәмиләгә.)* Ә син миңа беләзексез дә ошыйсың. *(Тамашачыга.)* Ничего, без дә төшеп калганнардан түгел, сынатмабыз!

Җәмилә. Дөрес, мәхәббәтне алтын билгеләми. Ул йөрсен алтын алкаларын шалтыратып, йөзекләрен ялтыратып. Һәр кешегә дә бай егет насыйп булмый.

Камил *(тамашачыга).* Түз, йөрәгем, түз! *(Җәмиләгә.)* Борчылма, сынатмабыз!

Җәмилә. Камил, син ачуланма, минем иптәш кызларым кайтырга унбиш минут вакыт калып килә.

Камил. Унбиш минут?! *(Тамашачыга.)* Чукынды, харап булам! *(Җәмиләгә.)* Ярый әле сәгатьне искә төшердең, соңга кала язганмын. Җәмилә, мин китим инде.

Җәмилә. Әллә үпкәләдең инде? Ашыкма. Бергә кызлар белән чәй эчәрбез.

Камил. Юк, юк, рәхмәт. Смена!

Җәмилә. Тагын кайчан киләсең?

Камил. Смена кайчан туры килә инде.

Җәмилә. Иртәгә төшке ашка кадәр инде синең сменаң.

Камил. Каян беләсең?

Җәмилә. Тәскирә әйтте.

Камил. Тәскирә әйтсә, хак әйтә. Пока, Җәмиләм! *(Битеннән үбеп ала да чыгып йөгерә.)*

Җәмилә. Пока, хиромант!

Тәскирә белән Сәлимә чыгалар.

Сәлимә. Браво!

Тәскирә. Афәрин!

Сәлимә.

Тәскирә. Молодец, Җәмилә!

Җәмилә. Җәй көннәре ямьле лә... Уф, кызлар, үпкән җире һаман да янып тора.

Сәлимә. Син, кызый, чамалап. Башка бу эшеңә чик куй. Тирәнгә кереп китүегез бар. Без алай сөйләшмәдек. Ул минем үземнән дә артмый.

Җәмилә. Бик кирәге бар иде. Мә алтын чылбырыңны. Мин булмасам, гомереңдә дә күрми идең син моны.

Тәскирә**.** Ялгышасыз. Мин булмасам!.. Кызык бу егетләр, муенга чылбыр салып, үзләренә бәйләп куймакчы булалар.

Сәлимә. Әнә иртәгә Җәмиләнең беләгенә алтын богау салалар. Камилнең колы булмаса ярый инде.

Җәмилә. Курыкма инде, синең Камилең минем өчен сукыр бер тиен.

Сәлимә. Әй, кызлар, уен уйныйбыз дип, каш җимермәсәк ярый инде.

Җәмилә. Чыннан да, без аларны бирегә килмәслек иттек.

Тәскирә**.** Нигә?

Сәлимә. Менә минеке каян акча табып беләзек ала инде?

Җәмилә. Ә минеке алка?..

Тәскирә**.** Егет булса, җебеп тормас, җебеп торса, егет булмас! Алар пешергән ботка. Үзләре ашасын. *(Кесә телефонын алып номер җыя.)* Алло, алло! «Кулдан-кулга» газетасымы? Сезгә белдерү бирмәкче идем. Алло, язасызмы? Языгыз. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең дүртенче тулай торагының ике йөз дә туксан җиденче бүлмәсендә яшәүче Мәкерле районы Пескәй авылы егете Шамил һәм шул ук бүлмәдә яшәүче Шөгерле районы Кәкре Елга авылы егете Камил хиромантия буенча сеанслар үткәрә башлыйлар. Үз язмышлары, киләчәкләре кызыксындырган гражданнар иртәнге алтыдан кичке унга кадәр приемга килә алалар. Сеанслар бушлай. Адресы: Казан шәһәре, Тургай урамы, җиденче йорт, авыл хуҗалыгы академиясенең дүртенче тулай торагы, ике йөз дә туксан җиденче бүлмә. Кырык алтынчы, йөз дә туксан тугызынчы, туксан тугызынчы автобуслар белән Тургай бистәсенә кадәр бара аласыз. Яздыгызмы? Рәхмәт!

Җәмилә.

Сәлимә. Нишләвең бу, Тәскирә?

Тәскирә Уенны чынлап башлавым. Назад пути нет!

Музыка. Ут сүнә.

*БЕРЕНЧЕ КАРТИНА*

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Камил белән Шамил бүлмәләрендә йоклап яталар. Ишек каккан тавышка уянып китәләр. Коридорда бер төркем халыкның «Сәгать алты тулды. Ачыгыз, ач! Приемыгызны кайчан башлыйсыз?», «Чиратсыз керергә уйлый күрмә, башыңны сугып ярам.», «Бу әбигә нәрсә калган инде?», «Әй, балакаем, мин иртәнге дүрттән чират алдым инде.», «Алсаң, мин кичтән килеп кундым.», «Кто крайний?», «Бесполезно, молодой человек, все равно сегодня не попадете.», «Мин, сеңлем, йөз дә сиксән җиденче, син минем арттан, йөз дә сиксән сигезенче булып языларсың инде.», «Кая керәсең, кая?», «Акырма миңа. Миңа әнә теге хатын чират алды.», «Акырмам мин сиңа...», «Иптәшләр, тавышны бетерик әле!», «Кем азаккы?», «Бесполезно. Барыбер бүген эләгә алмыйсыз.», «Ишекне шакыгыз инде!», «Әйе, әйе, шакыгыз. Сәгать
җиденче китте» дигән тавышлар ишетелә.

Камил. Ни эшлиләр анда?
Шамил. Белмим.
Камил. Ишекне җимерәләр бит.
Шамил. Бар, ишекне ач!
Камил. Үзең ач!
Шамил. Нәрсә бар соң? Нигә алар безнең ишек төбенә өелгәннәр?
Камил. Этем белсен. Берни аңламыйм.

Коридорда Рамилнең ишек каккан һәм кычкырган тавышы ишетелә.

Рамил. Камил, Шамил, ачыгыз әле ишекне?!
Камил. Рамил тавышы түгелме?
Шамил. Рамил тавышы шул, бар, ач!
Камил. Юк, ачмыйм.
Шамил. Алайса, үзем ачам.
Камил. Ача күрмә. Коридордан халык агымы бирегә килеп кереп, безне таптап, изеп китәчәк.
Рамил. Егетләр! Шамил, Камил, ачыгыз, дим, ачыгыз, таптап үтерәләр.
Шамил. Камил, ачыйк булмаса.
Рамил. Ачыгыз, дим мин сезгә. Хәзер институттан ректор килә.
Камил. Нәрсә булды инде, нәрсә? Әйдә ачабыз!
Шамил. Әйдә.

Икесе бергә ишекне әкрен генә ачалар, бүлмәгә Рамил керә. Аның өс-
башы таушалган.

Рамил. Тизрәк, тизрәк дим, ишекне бикләгез! Ишеккә урындык аягы тыгыгыз! Ишекне карават белән терәгез!

Камил белән Шамил көч-хәл белән ишекне тотып торалар. Рамил ишеккә урындык аягы кыстыра. Тышкы яктан тавышлар ишетелә: «Оятсызлар! Алтыда прием диеп, җидедә дә ачмыйлар! Ректорларына шыл-
тыратыгыз. Кемдә телефон бар?»

Шамил. Анда нәрсә булган? Нинди мәхшәр?
Рамил. Нәрсә булган, нәрсә булган?! Мә, укыгыз! *(Куен кесәсеннән газета чыгарып, Камилгә ыргыта.)*
Камил. Нәрсә соң бу?
Рамил. Күзең чыкканмы әллә?! «Кулдан-кулга» газетасы!
Шамил. Күрәбез. Күзебез чыкмаган. Син юньләп аңлат.
Рамил. Дүртенче битен ачыгыз да укыгыз! Өстән өченче абзац.
Камил *(укый)*. «Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең дүртенче тулай торагының ике йөз дә туксан җиденче бүлмәсендә яшәүче Мәкерле районы Пескәй авылы егете Шамил һәм шул ук бүлмәдә яшәүче Шөгерле районы Кәкре Елга авылы егете Камил хиромантия буенча сеанслар үткәрә башлыйлар. Үз язмышлары, киләчәкләре кызыксындырган гражданнар иртәнге алтыдан кичке унга кадәр приемга килә алалар. Сеанслар бушлай. Адресы: Казан шәһәре, Тургай урамы, җиденче йорт, авыл хуҗалыгы академиясенең дүртенче тулай торагы, ике йөз дә туксан җиденче бүлмә. Кырык - алтынчы, йөз дә туксан тугызынчы, туксан тугызынчы автобуслар белән Тургай бистәсенә кадәр бара аласыз».
Шамил.
Камил. Хиромантлар?!
Рамил. Хиромантлар түгел сез, хреновый дуслар сез! Аферистлар! Иртәгә диплом алырга торганда академиядән кудырасыз.

Камил. Безнең нинди гаебебез бар?..
Рамил. Байыйсыгыз килде?! Җиңел кәсеп белән, кеше алдап баеп булмый ул.
Шамил. Тукта әле, без берни дә аңламыйбыз?!
Рамил. Аңламыйсыз?! Газетага кем белдерү бирде.
Камил.
Шамил. Без түгел.
Рамил. Әйе. Мин биргәнмендер. Әнә комендант Асия Кәримовнаны «скорый» белән алып киттеләр.
Шамил. Нигә?
Рамил. Нигә, нигә?! Приемга килгән бер психбольнойны кертмәгән дә, теге Асия Кәримовнаның сугып башын тишкән.
Камил. Кем эше булыр бу?.. Кем белдерүне биргән?
Шамил. Кем эше булсын?! Кем эше, билгеле, Сәлимә эше!
Камил. Юк инде, җаным, син минем Сәлимәгә не тронь! Бу — Җәмилә эше!
Шамил. Юк, Сәлимә эше!
Камил. Ә мин әйтәм, Җәмилә эше!
Шамил. Аһ, син шулай... *(Камилнең якасыннан ала. Сугыша башлыйлар.)*
Камил. Үтерәм, заразы!
Шамил. Ә мин карап торырмын.
Рамил. Җитте сезгә, көзге әтәчләр. *(Аралый.)*
Шамил.
Камил. *(сугышуларыннан туктап)*. Үзең, үзең
Камил. Үзең уйлап таптың.
Шамил. Син, син безне бутадың!

Коридорда янәдән тавышлар ишетелә: «Ишекләрен җимерегез!», «Дөрес, ишекләрен җимерергә кирәк!», «Җәмәгать, әйдәгез милиция чакыртыйк!», «Баламны, баламны сытып үтерәсез!», «Мине кысмагыз. Мин Икенче бөтендөнья сугышы инвалиды!», «Минем хатынга якын киләсе булмагыз, ул авырлы!», «Кем булуыгызга карамастан
бәреп үтерәм!..»

Камил.
Шамил. Нишлибез?!
Рамил. Теләсә нәрсә эшләгез! Мин сезнең белән түгел. Не был, не видел, не участвовал! Извините, егетләр, дипломсыз калыр хәлем юк.

Рамил караватындагы простыняларны бер-берсенә бәйли дә, бер очын
батареяга бәйләп, тәрәзәдән аска төшә башлый.

Камил. Юк инде, агай-эне, без дә синнән калмыйбыз. *(Ул да простыняларын батареяга бәйли.)*
Шамил. Бергә икән бергә! Өчәү башладык, азакка кадәр бергә! *(Простыняларын ул да батареяга бәйли. Коридордан тавышлар көчәя.)*

Ут сүнә.
*ИКЕНЧЕ КАРТИНА*

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Тәскирә бүлмәләрендә берүзе. Ишектә звонок.

Тәскирә**.** Кем бар анда?!
Шамил.
Камил. Без!
Тәскирә**.** Сезгә кем кирәк?
Камил. Кем кирәген ачкач белерсең.
Тәскирә**.** Кызлар өйдә юк.
Шамил. Зато үзең өйдә.
Тәскирә**.** Хәзер ачам. *(Ишекне ача.)* Исәнмесез, егетләр! Хәлләрегез ничек?
Шамил. Әбиеңнеке кебек!
Камил. Кая тегеләр?
Тәскирә**.** Сәлимә вокзалга китте.
Камил. Бездән качыпмы?!
Тәскирә**.** Синең әтиеңне каршы алырга.
Шамил. Җәмилә кая?

Тəскирə. Аэропортка китте.
Шамил. Нигə?
Тəскирə. Əниеңне каршы алырга.
Шамил.
Камил. Нигə?!
Тəскирə. Əти-əнилəрегезне ректорыгыз чакырткан.
Камил. Газетага рекламаны кайсыгыз бирде?
Тəскирə. Мин.
Камил.
Шамил. Ни өчен?!
Тəскирə. Сезне кызганып. Берегез төне буе машина юа, икенчегез каравылда тилмерə. Үзегез чыкылдап торган хиромантлар!
Камил. Көлəсең да?!
Шамил. Мыскыл итəсең?!
Тəскирə. Соң бит үзегез, без хиромантлар, дигəнсез. Кызлар ышанган. Мине дə ышандырдылар. Уйлаштык-уйлаштык та сезгə ярдəм итмəк, чын хиромант ясарга булдык.
Камил. Рəхмəт инде, булдыргансыз! Ишкəнсез ишəк чумарын.
Шамил. Газетага белдерү биргəнче, син безнең турыда уйладыңмы?
Тəскирə. Сезне уйлап бирдем бит инде.
Камил. Ул уйлаган... Безне академиядəн куалар, син шуны белəсеңме?
Шамил. Соңгы курстан.
Камил. Иртəгə диплом алабыз дип торганда.
Тəскирə. Егетлəр, барысы өчен дə сез һəм мин генə гаепле. Кызларның гаебе юк.
Камил. Нишлəп əле без гаепле?
Тəскирə. Сез башладыгыз, мин нокта куйдым.
Камил. Ул нокта куйган... Безне бетерергə.
Шамил. Нокта куярга ашыкма. Без сине...
Тəскирə. Егетлəр, телисезме, мин сезнең дə һəм үземнең дə хатамны төзəтəм.
Камил. Төзəтəсең?! Эш ректоратта!
Шамил. Əти-əнилəр приемда!
Тəскирə. Мин хатамны төзəтəм. Тик бер шартым бар.
Камил. Рамай белəн болгаттылар-болгаттылар да, əле, җитмəсə, ниндидер шарт куймакчы була.
Шамил. Сөйлəп кара.
Тəскирə. Ректорыгызга: «Белдерүне мин бирдем, егетлəрнең гаебе юк, мин гаепле», — диячəкмен.
Камил. Бездəн нəрсə талəп итəчəксең?
Тəскирə. Син, Камил, Җəмилəгə, ə син, Шамил, Сəлимəгə өйлəнəсең!
Шамил. Камил, нишлибез?
Камил. Өйлəнми нишлисең? Дипломсыз өйгə кайтсам, мине əткəй бəреп үтерə.
Шамил. Җəмилəсез ничек яшəрмен?
Камил. Ə мин — Сəлимəсез...
Тəскирə. Бер-берегезгə кунакка йөрешерсез.
Шамил. Дипломсыз ни йөзең белəн авылга кайтып керерсең?
Камил. Əткəй-əнкəйгə, туганнарга нəрсə дип җавап бирерсең?
Шамил. Ярар, нишлисең...
Камил. Язмыш...
Шамил. Язмыштан узмыш юк, дилəр.
Камил. Сагынып, саргаеп гомерлəр үтə икəн.
Шамил. Сезнең якка, Җəмилə яшəгəн якка карап сызармын, сулыгырмын инде.
Камил. Кызлар риза булырлармы?
Тəскирə. Җəмилəме? Җəмилə шатланып риза.
Камил. Ə Сəлимə?
Тəскирə. Шатлыгыннан түшəмгə сикерəчəк.
Камил.
Шамил. Предательлəр!
Камил. Алар безне саткан икəн.
Шамил.
Камил. Без дə риза!
Тəскирə. Алайса, иртəгə икегез дə паспортларыгызны алып бирегə килəсез. Ə мин бүген сезнең эшне җайлыйм.

Бүлмəгə Рамил керə.

Рамил. Нихәл, хиромантлар!
Шамил. Эч пошырма әле!
Камил. Бутау калагы.
Шамил. Безгә нинди ачуың бар иде?
Рамил. Әнә сезне бөтен академия эзли. Камил, синең әтиең Гарифҗан абзыйны күрдем. Ул, хиромантны ботыннан капка баганасына асам, ди. Урамга чыгарлыгымны калдырмады, ихатамның дүрт почмагына дүрт эт бәйләп куйдым, капка төбен җыен гарип-гораба, аксак-туксак, хатын чыкмаган ир-ат, кияү чырае күрмәгән хатын-кыз басты. Хиромант улың кайчан кайта, чиратка язылырга иде, диләр, ди.
Шамил. Минем әни күренмәдеме?
Рамил. Шунда. Ректорга керергә приемда утыра. Шамилне күрсәң, әйт, чиратка яза башладым, йөз дә җитмеш ике кеше язылды. Һәрберсеннән җиде йөз дә илле сум алам, Шамил азсынмас микән инде? Ул кайтуга коттедж салып өлгертәм, диде.
Камил. Булган бу.
Шамил. Авылга юл ябык.
Тәскирә. Мин ашыгам, егетләр! Эшне җайларга кирәк. Ә сезне иртәгә унда биредә көтәм.
Камил. Икебезне дәме?
Тәскирә. Икегезне дә.
Камил. Ә кызлар икесе дә өйдә булсалар?
Тәскирә. Борчылмагыз. Сәлимә — сине, Җәмилә Шамилне танымаячак.
Рамил. Син — Сәлимәне, Шамил — Җәмиләсен.
Камил.
Шамил. Кызык кешеләр сез.
Камил. Каян табышкансыз?
Рамил. Нишлисең, чиләгенә күрә капкачы.
Тәскирә. Сезнең өчен тырышып йөрүебез.
Шамил. Рәхмәт инде. Ничек кенә бәхилләтербез.

Музыка. Ут сүнә.

*ИКЕНЧЕ КАРТИНА*

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, бүлмәдә Сәлимә, Җәмилә, Тәскирә һәм Рамил.
Ишектә звонок.

Тәскирә. Керегез, кер, ишек ачык.

Бүлмәгә Камил керә.

Камил. Исәнмесез!
Җәмилә *(аның янына килә)*. Матурым, килеп җиттеңме?
Камил. Җиттем, асылым!

Ишектә тагын звонок шылтырый.

Тәскирә. Ишек ачык, керегез, кер!

Шамил килеп керә.

Шамил. Исәнмесез!
Сәлимә *(аның янына йөгереп килә дә битеннән үбеп ала)*. Килеп җиттеңме, алтыным?
Шамил. Килеп җиттем, бәгърем! *(Камилгә кулын суза.)* Исәнмесез! Сез кем буласыз?
Камил *(күрешеп)*. Камил булам.
Шамил. Ә мин — Шамил.
Камил. Бик шатмын. Мин сезне каядыр күргән төсле булам.
Шамил. Мин дә.
Камил. Сез сельхозда укымыйсызмы?
Шамил. Юк, мин авыл хуҗалыгы академиясендә.
Камил. Алай икән. Димәк, кем беләндер бутадым.
Рамил. Егетләр, түргә узыгыз.
Камил.
Шамил. Рәхмәт!
Шамил *(Сәлимәгә)*. Аппагым, бу туташ сезнең дустыгыз буламы?

Сәлимә. Әйе. Бу — Җәмилә.
Җәмилә *(кулын Шамилгә суза).* Таныш булыйк, Җәмилә!
Шамил *(күрешеп).* Мин Шамил булам. *(Диванга барып утыра.)*
Камил *(Җәмиләгә).* Җәмилүшкә, иптәш кызың белән таныштырмыйсыңмыни?
Җәмилә. Таныш бул, Камил, минем иң якын дусларымның берсе — Сәлимә!
Камил. Бик шатмын. *(Диванның икенче кырыена барып утыра.)*
Сәлимә *(Җәмиләгә).* Егетегез чыннан да күркәм икән.
Җәмилә. Сезнеке дә асыл! *(Шамил янына барып.)* Сезнең янга утырырга рөхсәтме?
Шамил *(пышылдап).* Утырып кал! Соңгы утыруыңдыр!
Җәмилә *(утыра).* Бар әле тегендәрәк, нигә җәелдең?!
Сәлимә *(Камил янына килә).* Миңа биредә генә урын калган икән. Мөмкинме сезнең янга утырырга?

Барысы да әкрен генә, пышылдап сөйләшәләр.

Камил. Утыр! Башка бик утырырга теләсәң дә, утыра алмассың.
Шамил. Кияүгә чыгам дисең инде?!
Сәлимә. Сиңа үч итеп.
Җәмилә. Өйләнергә уйладың?!
Камил. Әйе. Өйләнергә булдым әле.
Шамил. Үкенерсең, соң булыр!
Сәлимә. Терсәгеңне тешләрдәй булырсың, мин булмам.
Җәмилә. Миңа үч итепме?!
Камил. Беткә үч итеп!

Тәскирәнең кесә телефоны шылтырый.

Тәскирә *(телефонын колагына куеп).* Әйе, тыңлыйм. Рәхмәт! *(Егетләр белән кызларга.)* Кызлар, егетләр, таксилар килеп җитте. Хәзер без кеше гомерендә бер генә тапкыр була торган бәхетле минутлар кичерербез. Шамил һәм Сәлимә, Камил һәм Җәмиләнең законлы никахлашулары өчен загска гариза бирергә барабыз. Егетләр, сез чыннан да бәхетлеме?
Камил. Чересчур!
Шамил. Чыдать не возможно!
Тәскирә. Ә сез, кызлар?
Җәмилә. Шатлыктан баш әйләнә!
Сәлимә. Мәтәлчек атасы килә!
Тәскирә
Рамил (*ишекне ачалар).* Рәхим итегез! Сезне яңа тормыш көтә.

Музыка. Ут сүнә.
*ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА*

УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, сәхнәнең нәкъ уртасында ике якка ачыла торган ишекләр. Ишек өстендә пар балдаклар. Сул порталда туй киеменнән — Җәмилә белән Камил, ә уң порталда — Шамил белән Сәлимә. Мендельсон маршы яңгырый. Шаһитлар киеменнән Рамил белән Тәскирә чыгалар да ишекләрне төбенә кадәр ачалар. Репродуктордан килгән тавыш: «Хөрмәтле кәләш һәм кияү! Сезне бүгенге истәлекле көнегез белән котлыйбыз! Бүген, Җәмилә Гыйльфан кызы белән Шамил Шәкүр улының, Сәлимә Саттар кызы белән Камил Гарифҗан улының никах-
лары законлы рәвештә теркәлә».
Көй яңгырый.

Шамил. Ничек инде Камил-Сәлимә, Шамил-Җәмилә... Берни дә аңламыйм.
Камил. Бутап бетерде.
Тәскирә. Хөрмәтле дусларым! Сез Рамил белән мине, зинһар, гафу итегез!
Рамил. Без, без барысына да гаепле.
Тәскирә. Сезнең никахны законлы рәвештә теркәү өчен гариза бирергә баргач...
Рамил. Кәләшләрнең паспортларын бутап биргәнбез.
Тәскирә
Рамил *(башларын түбән иеп).* Кичерегез безне!
Тәскирә. Әгәр инде сөйгән ярларыгыз белән бергә калырга телисез икән...
Рамил. Бүгенге церемонияне әз генә срокка кичереп торырга туры киләчәк.
Шамил. Буталып йөрмә әле, Рамай!
Камил. Рамай, ат дагалаганда, бака ботын кыстырмый.
Шамил.
Камил. Буталып бик дөрес эшләгәнсез! Ки-чер-

мәс-кә!

Тәскирә. Ә сез, кәләшләр?..

Җәмилә. Мин каршы. *(Янында басып торган Камилгә.)* Нәрсә җебеп торасың? Бар, бар Сәлимәң янына, Сәлимәң янына бар дим.

Камил Сәлимә янына китә.

Сәлимә. Юк, юк, мин каршы.

Камил кире Җәмилә янына килә.

Сәлимә *(Шамилгә.)* Нәрсә терәлеп каттың?! Бар инде, бар Җәмиләң янына.
Җәмилә *(Камилгә)*. Бар инде, бар Сәлимәң янына.
Сәлимә *(Шамилгә)*. Бар диләр сиңа, Җәмиләң янына бар!

Камил белән Шамил капма-каршы киләләр дә маңгайга-маңгай бәреләләр.

Җәмилә. Ай, Шамилкәем, хараплар булдың!
Сәлимә. Бетте, бетте, Камилкәем!
Шамил.
Камил. Дөньялар яктырып китте.

Репродуктордан килгән тавыш: «Сез бүген бик җаваплы юлга басасыз. Үзегез һәм ата-аналар тарафыннан уйланылган гаилә төзү дигән җаваплылыкны үз иңсәгезгә аласыз. Гаилә кору ул — бер-береңә ышану, авыр чакларда бер-береңә терәк булу. Шатлыкта да, кайгыда да бер-береңә теләктәш булуда, бер-береңнең серләрен чит-ятларга чыгармыйча уртак хәл итүдә».

Музыка.

Репродуктордан килгән тавыш: «Актлар кәгазенә кул куюыгызны сорап, бирегә үтүегезне сорыйбыз».

Көчле фанфара яңгырый.

Кияү-кәләшләр ачык ишектән кереп китәләр. Рамил белән Тәскирә ишекләрне ябалар. Янәдән ишекләрне чак кына ачып, башларын чыгаралар.

Рамил
Тәскирә *(тамашачыларга)*. Сезне дә туй мәҗлесенә көтәбез. Рәхим итегез!

Ишекләр ябыла. Көчле музыка.

Пәрдә.

*Сентябрь, 2007*

# КОТКАРЫГЫЗ, КАРАВЫЛ!!!

*Комедия ике пәрдәдә, ике картинада, алты күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Мөкаддәс — утыз биш яшьләр тирәсендәге буйдак.
Миңҗиһан — буйга бик озын хатын.
Айгөл — Миңҗиһанның кызы, Мөкаддәснең сөйгәне.
Рушания — таза гәүдәле ханым, баш бухгалтер.
Исбах — Рушаниянең ире, гәүдәгә бик кечкенә.
Мөслих Мөслимович — җирле үзидарә рәисе.
Кави карт — колакка каты кеше.
Сәрмәдия — уйнашчы хатын.
Асыл Шәмгунович — тикшерүче.

Вакыйга җәй көне авылда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*БЕРЕНЧЕ КАРТИНА*

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл. Кибет каршындагы киң генә мәйданда прожектор эленгән багана. Баганага, хәвеф-хәтәр чыкса дип чаң кагар өчен, тимер юл шпалы һәм арба кендеге асылган. Кибет стенасындагы кызылга буялган тактага янгыннан саклану җиһазлары — төпсез чиләк, үтмәс балта, сапсыз көрәк куелган. Сәхнәдә тынлык. Кинәт, тынлыкны бозып, ерактан — сәхнә артыннан — ямьсез аваз ишетелә. Бу — Миңҗиһан тавышы.

Миңҗиһан. Каравыл! Коткарыгыз! Каравыл!!!

Миңҗиһан, эре-эре адымнар белән өч-дүрт кенә атлап, сәхнә уртасына чыгып баса. Кулында китмән. Китмәнгә зур размерлы ирләр трусигы эленгән. Янында кызы Айгөл.

Миңҗиһан *(көчкә-көчкә генә сулыш алып).* Хараплар булдык... Каравыл! Коткарыгыз!!!

Айгөл *(яңа туган сарык бәрәне кебек, нечкә генә тавыш белән).* Каравыл! Коткарыгыз!

Миңҗиһан. Каравыл!

Миңҗиһан эре адымнар белән сәхнәнең сул ягына чыгып китә. Аңа Айгөл дә иярә.

Айгөл *(сәхнә артыннан нечкә тавыш белән).* Каравыл! Коткарыгыз!

Озак та үтми, Миңҗиһан һәм Айгөл сәхнәнең уң ягыннан килеп керәләр.

Миңҗиһан. Бу авыл халкы кая дөмеккән? Каравыл! Коткарыгыз! Хараплар булдык!

Айгөл. Хараплар булдык!..

Миңҗиһан. Коткарыгыз!..

Айгөл. Коткарыгыз!..

Сәхнәгә халык җыела башлый.

Сәрмәдия. Ай Ходаем, нәрсә булды?

Миңҗиһан. Атаң башы!

Исбах. Кем яна?

Рушания. Әллә сугыш чыкканмы?

Миңҗиһан. Кая олактыгыз, авылыгыз белән көпә-көндез йоклыйсыз?! *(Китмән башындагы трусикны болгап.)* Менә бу нәрсә?!

Рушания *(Исбах өстенә килә).* Ах, сволочь! Тагын кемдә калдырып кайттың?!

Исбах. Карчык, карчык, дим, әнисе, нишләвең инде бу. Минем трусик кер бавыннан юып элгәч югалды бит.

Рушания. Әйе шул. Бу бит минем Исбахетдинемнең кер бавыннан юкка чыккан трусигы.

Сәрмәдия *(биленә таянып).* Булыр инде. Синең тилгән күтәреп алып китәрдәй Исбахетдинеңнеке булыр. Беләсегез килсә, бу безнең күмәк хуҗалык рәисе Мөслих Мөслимовичның кешелеккә генә кия торган трусигы!

Айгөл. Юк шул. Бу Мөкаддәснеке!

Сәрмәдия. Менә ичмасам! Әле Мөкаддәскә кияүгә чыгарга өлгермәгән, трусигын күрергә дә өлгергән. Ну булдыра хәзерге яшьләр, ну булдыралар!

Миңҗиһан. Борчылма. Сиңа җиткерә алмаслар.

Сәрмәдия. Кызыңның теленнән тартмадым. Үз теле белән әйтеп бирде.

Айгөл. Әйе. Син әйткән Мөслих Мөслимовичныкы инде алайса. Бу бит алагаем алтмыш дүртенче размер! Синең Мөслих Мөслимовичың моны кисә, башы белән чумачак бит.

Миңҗиһан. Кызым Айгөл, Сәрмәдия апаң белән сүз көрәштермә. Бу мәсьәләдә ул специалист!

Исбах. Анысы хак! Сәрмәдия бу мәсьәләдә зур белгеч!

Сәрмәдия. Тик кенә тор, ир аламасы! Ир булган, имеш. Арт санында утыз алтынчы размерлы ыштан тормый.

Исбах. Анысы хак. Менә Мөслихнең арт санында алтмыш дүртенче размерлы трусик торганын син каян белдең?!

Миңҗиһан.

Айгөл. Каян белдең?!

Сәрмәдия. Авылыгызда мунча ишеге эләрлек тә мужиклар булмагач, беләсең инде ул. Каян беләсең, каян беләсең?! Узган атнада Мөслих Мөслимович үземә мунча ишеге элде бит. Шунда тирләп чалбарын салган иде.

Рушания. Әйе шул, узган атнаның шимбәсендә, эңгер-меңгер төшеп килгәндә, бакча артлатып кына, култык астына балтасын кыстырып алан-йолан каранып, Мөслихетдин сезгә бара иде шул.

Сәрмәдия. Көндез аның вакыты юк. Хуҗалык эше.

Рушания. Юк, чәчрәп китим, бу минем Исбахетдинемнеке!

Исбах. Ярар инде, анасы, җәй көне трусикның нигә кирәге бар.

Миңҗиһан. Сездә трусик кайгысы. Тизрәк коткарырга кирәк!

Айгөл *(елап).* Хараплар гына булды, хараплар гына! Аяз көнне яшен сукты. Сез генә гаепле. Барысы өчен дә авылыгыз белән сез генә гаепле.

Кави карт. Туктагыз әле, авылдашлар! Акылыгызга килегез. Юньләп аңлатыгыз. Нәрсә булды соң? Безнең халык Үктәбер революциясеннән бирле аклар килсә, ак, кызыллар килсә, кызыл чүпрәк күтәреп тә туйган. Ә менә сезнең ирләр эчке киеме күтәрүегез нәрсәне аңлата?

Рушания. Син, Кави бабай, тик кенә утыр инде. Ишетер-ишетмәс алама колагың белән безнең эшкә тыгылма. Синең ул Николай вакытында күтәргән чүпрәкләреңне без хәтерләмибез дә, белмибез дә. Безнең чүпрәкне үзебезгә калдыр. Ирләребезнең эчке киемнәре берсеннән икенчесенә күчеп йөри башлаган икән...

Сәрмәдия. Монда революция генә түгел, канлы сугыш, чәчләрне йолкыш башлана әле.

Рушания. Әнә Сәрмәдия подпольный эшен башлаган инде.

Миңҗиһан. Мөслихне үз итәк астына алган.

Сәрмәдия. Сезнең ирләрегез ишек куялмаганга, мин гаепле түгел инде.

Рушания. Исбахетдин, ныклабрак кара әле, чынлап та бит синекенә охшаган.

Исбах. Минекенә охшавын охшаган, әмма ләкин бу бит юеш! Үзең беләсең, минем бит инде күптәннән «балык тотканым» юк.

Миңҗиһан. Менә, менә, юеш, ди. Ишетәсезме, юеш, ди. Каравыл!

Айгөл. Коткарыгыз!

Миңҗиһан. Коткарыгыз! Мөкаддәс суга батып үлгән!

Барысы бергә. Ничек батып үлгән?!

Айгөл. Авылыгыз белән котылдыгыз инде. Авылыгыз белән Мөкаддәсне күралмадыгыз. Гармунын уйный башласа, чырайларыгыз сытыла, тәрәзә пәрдәләрегез ябыла иде.

Миңҗиһан. Ярый, кызым Айгөл, елама. Үз-үзеңне сакла. Үлгән артыннан үлеп булмый. Тәкъдиренә шулай язылгандыр.

Айгөл. Барысына да син гаепле. Син генә гаепле. Юньле кеше гармун тартмый, юньле кеше җиң сызганып тормыш көтә дип, мине аңа кияүгә бирмәдең.

Сәрмәдия. Ярар, булды. Балавыз сыкма.

Рушания. Тавышың тавыш түгел.

Исбах. Йә, сөйлә инде, ничек батып үлгән?

Миңҗиһан. Менә кызым Айгөл белән, көн кыздыра башлагач, башка кояш сукмасын дип, чөгендер басуыннан өйгә кайтырга чыктык. Буа янына төшсәк, менә бу ята. Ә кешесе юк. Чөгендер басуына менеп карадык. Этле җан да юк. Янәдән трусик янына килдек. Кара әле, Айгөл, мин әйтәм, трусик ята, ә хуҗасы юк.

Исбах. Шуннан, шуннан...

Миңҗиһан. Әйләндереп-әйләндереп карыйбыз...

Сәрмәдия. Ә бәлки, ул авылга кайтып киткәндер?

Миңҗиһан. Ышанасызмы?!

Рушания. Таллар арасын карадыгызмы?

Миңҗиһан. Буа янында таллар үсәме соң?

Исбах. Ә камышлар арасын?..

Айгөл. Буа янында камышлар үсми.

Миңҗиһан. Мөкаддәс батып үлгән!

Кави карт. Ну егет икән! Молодец!

Айгөл. Нәрсә дисең, Кави бабай?

Кави карт. Ә?..

Айгөл. Нәрсә дисең димен?

Кави карт. Кычкырма колакка. Егет икән дим.

Сәрмәдия. Шуннан, шуннан...

Миңҗиһан. Шуннан шул. Китмән белән трусикны күтәреп карадым да шап иттереп арт саныма утырдым. Мөкаддәс батып үлгән!

Кави карт. Батып үлгән дисең инде. Вәт молодец! Егет икән!

Сәрмәдия. Чыннан да, безнең арада Мөкаддәс кенә юк.

Айгөл. Мөкаддәссез мин нишләрмен? Кем минем тәрәз төбемә килеп гармунын тартыр?

Сәрмәдия. Борчылма, кая китәрсең? Түзәрсең әле. Без түзәбез бит.

Миңҗиһан. Әй бала, бала! Капка төбенә, тәрәз төбенә килеп гармунын сыздырып җибәрер иде...

Сәрмәдия. Син, тәрәзәңне ачып, юынтык суыңны аның өстенә чаж иттереп сибәр идең.

Рушания. Ярый әле әнисе Мөлхәбирә түти үлеп котылды.

Исбах. Бу кайгыны күтәрә алмас иде.

Барысы бергә. Нишлибез?!

Айгөл. Буаны, җибәрәбез!

Рушания. Нәрсә белән?! Көрәк беләнме? Ул таш буаны җибәрергә авылыңда трактор, экскаваторың бармы?

Айгөл. Шлюзны ачабыз.

Сәрмәдия. Ачасың шлюзны... Мөслих Мөслимович аңа ат башы кадәрле өч йозак элде. Аны ачар өчен динамит кирәк.

Исбах. Нигә динамит?! Нигә шлюзны ачарга? Мин бар бит. Бывший сухопутный морской моряк! Бер генә чумам! Чумам да чәченнән тартып чыгарам.

Рушания. Син бит йөзә белмисең.

Исбах. Минме?.. Мин бывший сухопутный морской моряк! Мичман второго ранга!

Рушания *(биленә таянган хәлдә аның каршына килеп баса).* Чишен, мичман!

Исбах. Әллә чишенмәс дисеңме?!

Рушания. Ну-ка, тиз бул, чишен! Йөздерәм мин сине хәзер.

Исбах. Әллә чишенмәс дисеңме?! Чишенәм шул! *(Күлмәген сала. Чалбар каешын җибәрә.)* Карамагыз миңа. Мин оялам.

Рушания. Булдымы? Ник чалбарыңны салмыйсың?!

Исбах. Минем трусик юк икән...

Рушания. Әйдә алайса киттек!

Исбах. Кая?

Рушания. Йөзәргә!

Исбахны култык астына кыстыра да тау астына төшә башлый.

Исбах. Нишлисең?!

Рушания. Чумдырам!

Исбах. Булды, булды җитте, киенәм. Бир күлмәкне! *(Барысы да көләләр.)* Нигә ыржаясыз?! Суы салкын. Ә мине көзән җыера. Суы җылы булсамы... Шулай бит, әнисе Рушания?

Рушания. Шулай, шулай, шәһәрдә кияүләрдә ваннада батып үлә язган бәндә бит син.

Исбах. Син ванна белән буа суын бутама. Аңгыра син! Ваннада колач салып йөзеп булмый. Чумып та булмый. Миңа диңгез кирәк. Аңлыйсызмы, диңгез!

Айгөл. Җиттеме сезгә, юкмы?! Кәмит ясап утырасыз. Мөкаддәскәем су астында ята, ә сез?..

Сәрмәдия. Мөкаддәскәем, Мөкаддәскәем дигән була. Мөкаддәскәең булгач, шәһәргә ташлап качмыйлар аны. Батып та үлмәгән булыр иде.

Айгөл. Сез гаепле, әни гаепле. Гармунда уйнаганыннан көлдегез.

Миңҗиһан. Кави бабай, авылыбызда синнән дә сабыр, синнән дә мудрый кеше юк. Бир бер киңәш?!

Кави карт. Нәстә дисең?..

Исбах *(Кави картның колагына кычкырып).* Киңәш бир, ди.

Кави карт. Акырма колагыма. Әллә авылыгыз белән саңгыраuланып, чукракланып беткәнсез инде. Киләләр дә колакка акыралар, киләләр дә акыралар. Таптылар бер карт. Минем киңәш шул инде, кем, сеңлем Миңҗиһан. Эзләмәгез. Барыбер табалмыйсыз. Авылдан чыгып киткән моңны тотып та, табып та булмый аны.

Сәрмәдия. Таптыгыз киңәш сорар кеше. Үз сүзен үзе ишетмәгән саңгырау, аңгырайган карттан нәрсә өмет итәсездер?

Кави карт. Нәрсә дисең, Сәрмәдия кызым?

Сәрмәдия. Егет икансең, димен.

Кави карт. Ә-ә, Мөкаддәсне әйтәсеңме? Настоящий егет икән! Гомере буе эт типкесендә, кеше капкасы төбендә, гармунын да уйный алмыйча, күләгәдә яшәде дә көтмәгәндә авылының, тирә-юньнең нурын, авыл халкының рухын алып китте дә барды. Бөтен кешенең телендә бары тик Мөкаддәс!

Исбах. Нигә алай дисең әле син, Кави бабай? Минем өчен аннан да якын кеше, дус юк иде. Сигез ел бергә көтү көттек.

Рушания. Мөкаддәс атасыз үссә дә, юньсез булмады. Тәрбияле кеше иде.

Сәрмәдия. Мөкаддәснең бер начарлыгы тимәде. Ялгыз хатын дип тәрәзәмне шакымаган ир-ат калмады. Буйдак булса да, тәрәз төбемә килгәне булмады.

Миңҗиһан. Печән алып кайтсаң, сәнәген, утын алып кайтсаң, балтасын күтәреп керер иде.

Айгөл *(еламсырап).* Барысы өчен дә үзем гаепле. Шәһәргә авылны ташлап чыгып китмәгән булсам, бу хәл булмый иде.

Сәрмәдия. Үз-үзеңне бетереп елап утырма, сеңлем Айгөл. Синең бер гаебең дә юк. Барысы өчен дә анаң — Миңҗиһан апа гаепле.

Миңҗиһан. Нишләп әле мин гаепле булыйм ди?

Сәрмәдия. Шундый матур, уңган кыз тапмыйлар аны.

Миңҗиһан. Җитте, Сәрмәдия! Күзең каты, кызыма күз тидерәсең.

Сәрмәдия. Әйттем исә кайттым. Дөньялыкка шундый чибәр кыз тапмаган булсаң да ярар иде. Настоящее художественное произвидение! Музейга экспонат итеп кенә куясы бар.

Миңҗиһан. Сәрмәдия, ничә тапкыр кисәтергә була?! Баламның өстенә әйтмә, күз тидерәсең дип.

Сәрмәдия. Үзем дә шуннан куркам инде, Миңҗиһан апа. Үз сүзем түгел, Мөкаддәс мәрхүмнең сүзләре. Мөкаддәснең күзләре гел сездә иде бит. Шулай бервакыт Мөкаддәс үз капка төпләрендә, сыздырып-сыздырып, сагышлы көй уйнап утыра. Ник моңаясың, Мөкаддәс, димен. Айгөлне юксынам, Айгөлне, ди. Күзләре сезнең тәрәзәдә. Авылда кызлар бетмәгән, тот та берәрсенә өйлән, мин әйтәм. Менә мин дә свободный. Җир җимертеп яшәрбез, димен.

Миңҗиһан. Нишләп сиңа өйләнсен инде ул? Җитмеш җиде ирдән кайткан кешегә.

Сәрмәдия. Сөйлисе юк инде, сөйлисе юк. Җидегә чыктым, җидесеннән дә уңмадым. Сигезенчесе рәтле булмасмы дип өметләнәм әле.

Исбах. Минем исем китә инде сиңа, Сәрмәдия. Бу кадәр ирдәүкәлегең белән ничек сиңа ирләр кызыга икән?

Сәрмәдия. Үзем гаепле, үзем барысына да гаепле, Исбахетдин абый. Мин бит киң күңелле, үзең беләсең. Синең кебек, чит кеше тәрәзәмне кагуга, ишегемне ачам.

Исбах. Тфү, кабахәт! Телең тел түгел.

Сәрмәдия. Мөкаддәсне әйтәм... Их, Сәрмәдия апа, ди, Айгөлнең күзләренә генә кара син, күзләренә генә, ди. Тулган аймыни? Мәче башлы ябалаклар көнләшерлек, ди.

Айгөл. Үзең соң, үзең... Чепи күз!

Сәрмәдия. Сөйлисе юк инде. Әнкәйгә үпкәм зур. Чепи күзле итеп тапкан.

Миңҗиһан. Минем кызымның күзләре сөрмәле булганга авылыгыз белән көнләштегез инде.

Рушания. Ха-ха-ха... Сөрмәле диме?!

Исбах. Әйе, сөрмәле ди. Ха-ха-ха...

Рушания *(тамашачыга).* Акай!

Сәрмәдия. Ул күкрәкләре, ди, мәрхүм.

Миңҗиһан. Минем кызымның күкрәкләренә ни булган?!

Сәрмәдия. Булмаган. Имән чикләвеге кадәр булган.

Исбах. Ха-ха-ха... Имән чикләвеге, ди.

Рушания. Ха-ха-ха... *(Тамашачыга.)* Озакламый сугышалар!

Сәрмәдия. Ул аяклары, аяклары, Миңҗиһан апа, шундый сылулар, шундый нечкәләр, шундый кәкре, берьюлы җиде фәрештә очып чыгарлык. Их, Сәрмәдия апа, ди, мәрхүм Мөкаддәс, җиде бала таптырыр идем. Җиде балам, скакалка сикереп, аналарының аяк арасыннан сикерә-сикерә чыгып уйнарлар иде, ди, мәрхүм.

Айгөл. Кеше исәбенә кереп сөйләшеп тормасаңчы. Мирдән калган үләксә!

Сәрмәдия. Мирдән калсак та, бердән калмадык. Алланың биргәненә шөкер. Һәрнәрсәм урынында. Ул күкрәк дисеңме?! *(Куллары белән күкрәген күтәреп куя.)* Шулай, сеңлем, чикләвек кадәр күкрәк белән ерак китеп булмый ул. Ул билләр дисеңме?! *(Куллары белән билен кыса.)* Ул задный мост дисеңме?! *(Арт ягын уйнатып йөреп күрсәтә.)* Ул аяклар... булыр булмас Исбах кебек адәмнең өстенә салсаң, таң атканчы җаны чыга. Печән төялгән арбага бастырык итеп салырлык.

Рушания. Әй Ходаем, харап икән! Беләсең килсә...

Сәрмәдия. Синеке дә ничего, Рушания. Сәнәк сапларга була. Менә шулай, сеңлем Айгөл. Утыз җидедән соң — утыз сигезне, утыз сигездән соң утыз тугызны көтеп яшәргә генә кала. Ә без ул арада кырыкка чыгабыз. Кырыкка чыгабыз, уңганчы чыгабыз!

Миңҗиһан. Бик дөрес сөйлисең, Сәрмәдия сеңлем, бик дөрес сөйлисең. Унсигезең тулар-тулмас магазин төзергә килгән шабашникларга ияреп чыгып киткән идең, бөтен Рәсәйне әйләнеп, кырыкка кияүгә чыгып кайттың бугай инде.

Сәрмәдия. Дөрес әйтәсең, Миңҗиһан апа! Аллага шөкер, бөтен Рәсәйне күреп, аркылыга-буйга әйләнеп кайттым. Күрмәгән шәһәрем, күрмәгән авылым калмады. Хәтта Прибалтиканың да читен генә булса да күрдем. Әмма ләкин синең кызың кебек чибәр, сылу, асыл затны күрмәдем. Булдырсаң да булдырырсың икән. Кызыңның авызы бик кечкенә — уймак кына. Гомере буе борчак кына ашатырга уйлагансыңдыр инде.

Миңҗиһан. Синеке төсле силос базы түгел инде.

Сәрмәдия. Муены юк. Кирәк санамагансыңдыр инде.

Миңҗиһан. Торна муен!

Рушания *(Исбахка).* Хәзер, хәзер сугышалар.

Исбах. Сабыр, сабыр. Кызыгы алда.

Сәрмәдия. Такта күкрәк, гәрбил бил, ач яңак, пиштәр корсак, салам сыйрак!

Миңҗиһан *(җиңен сызгана).* Аһ, син шулай! Мин синеме, мин сине...

Исбах

Рушания *(кул чабалар).* Башланды!

Сәрмәдия. Полундра! *(Каратистлар шикелле баса.)* И-а! Ну-ка, ну-ка, кил әле! Бер-ике прием күрсәтәм.
Айгөл. Әни, син — арттан, мин — алдан!
Сәрмәдия. Юк. Анаң — сулдан, син — уңнан!
Кави карт. Җитте сезгә, оятсызлар! Мөкаддәстән үрнәк алыгыз!
Сәрмәдия. Мөкаддәстән үрнәк алабыз дип, су астына төшеп ятмабыз инде. Мешать итмә, Кави бабай. Җир өстендә яшәү өчен көрәш бара. Ә син су асты сөйлисең.
Исбах. Мешать итмә диләр сиңа, Кави абзый, мешать итмә. Хатын-кызның сугышканын карарга яратам мин.
Кави карт. Их, оятсызлар! Авылыбызның соңгы сандугачы арабыздан китте. Авылның соңгы моңы китте. Ә сез!..
Исбах. Анысы, Кави бабай, гармуны белән тәмам җилеккә төшкән иде инде. Иркенләп утырып бер ярты да салып булмый иде. Гармунына тәрегә баккан кебек береккән иде.
Миңҗиһан. Айгөлемне аңа кияүгә бирмәвемнең дә төп сәбәбе шул гармунда уйнавы булды.
Исбах. Керсәң, сөйләшеп булмас иде, понимаешь. Көне-төне шул гармунын тартыр иде.
Рушания. Тавыклар кунакчага кунаклый алмый иде инде.
Сәрмәдия. Ир-ат булып ир-атлар, төннәрен шуның гармун тавышыннан куркып, безнең очка килмәс булдылар.
Исбах. Арып-талып эштән кайтасың, понимаешь, ә ул гармун акырта.
Кави карт. Синең, Исбах энем, туганнан бирле берәр генә көн булса да эшләгәнең бармы соң ул?
Исбах. Төне буе синең тәрәз төбеңдә гармун акыртсыннар әле. Иртән торып эшкә барасың килер микән?
Айгөл. Гармун инде ул искелек калдыгы, Кави бабай. Татарның төпсез ыштаны төсле! Шәһәргә китүем дә шуның өчен. Аның гармунда уйнавыннан авыл яшьләре көлә иде.
Кави карт. Юксынырсыз әле. Үз моңыгызны эзләп-эзләп тә тапмагач, чәчелеп, сибелеп, бер-берегезнең телен аңламас хәлгә төшәрсез әле.
Исбах. Ә шулай да Мөкаддәсне табып җирләргә кирәк. Нишлибез?
Айгөл. Водолазлар чакыртырга кирәк.
Исбах. Водолазларга түләргә акчаң бармы соң?
Рушания. Милиция чакыртырга кирәк.
Исбах. Үзем барам.
Рушания. Кит әле, шүрәле! Аннары синең үзеңне районнан эзләп тап.
Сәрмәдия. Исбахетдин абзый, син бит районга китсәң, унбиш суткасыз кайтмыйсың.
Рушания. Районда унбиш суткада утыра-утыра, анда син себермәгән урам калмады.
Исбах. Мин бит чисталык яратам.
Миңҗиһан. Болай кул кушырып утырып булмый. Үзебезгә эзләргә кирәк.
Рушания. Буасын әйтәм, тирән микән?
Исбах. Алты дилбегә тирәнлеге.
Рушания. Әллә үлчәдең?
Исбах. Үлчәдем.
Миңҗиһан. Кайчан?
Исбах. Узган кыш.
Сәрмәдия. Чумыпмы?
Исбах. Чумып. То есть дилбегә салып.
Кави карт. Алты дилбегә каян алдың? Авылда өч ат, ике генә сбруй бар бит.
Исбах. Ә мин ике дилбегәне өч тапкыр салдым.
Рушания. Менә молодец! Булган да инде минем Исбахетдинем.
Сәрмәдия. Икене өчкә тапкырлый да сигез чыгара.
Исбах. Аңгыра син, Сәрмәдия. Икене өчкә тапкырлагач, сигез чыкмый инде, алты чыга, тити баш, миңгерәү!
Айгөл. Әнә авылның рәисе, то есть главасы, Мөслих Мөслимович килә.
Миңҗиһан. Ул тиз хәл итәр.
Кави карт. Ул тотынса итә инде. Ул...

Мөслих Мөслимович керә.

Мөслих Мөслимович. Сез нәрсә, авылыгыз белән чөгендер басуына бармый, сабан туе үткәреп ятасыз. Марш барыгыз да бала-чагаларыгыз белән басуга!
Рушания. Ни бит әле, иптәш Мөслих Мөслимович...
Исбах. Мөкаддәс...

Мөслих Мөслимович. Ишеттем. Көтүгә чыкмаган. Мин анымы?! Мин аны үз кулларым белән буага алып төшеп крещение ясыйм.

Миңҗиһан. Авылыбызда зур кайгы бит.

Мөслих Мөслимович. Нинди кайгы?! Әллә, Ходаем, погода бозыламы?

Айгөл. Юк ла...

Сәрмәдия. Мөкаддәс буага батып үлгән бит.

Кави карт. Ну егет икән!

Мөслих Мөслимович. Ничек батып үлгән?! Каян чыгып әйтәсез?

Миңҗиһан. Менә!

Исбах. Ыштаныннан, ягъни трусигыннан чыгып.

Мөслих Мөслимович. Син нәрсә, надан! Бу бит минем трусик!

Сәрмәдия. Юк шул. Бу синең трусик түгел. Бу...

Мөслих Мөслимович. Соң бит терлекчеләр слетында районның бөтен ирләренә бүләк иттеләр ич бу трусикларны. Менә ышанмасагыз карагыз! *(Чалбарын төшерә башлый.)*

Барысы бергә. Юк, юк, кирәкми. Ышанабыз.

Мөслих Мөслимович *(чалбарын әз генә төшереп).* Тукта әле, минеке үземдә икән бит.

Исбах. Ә минеке юк.

Рушания. Кер бавыннан урладылар.

Кави карт. Минеке сезнеке төсле түгел.

Мөслих Мөслимович *(Исбахка).* Китсәле, эт ялкавы! Ялганчы. Кер бавыннан урладылар, имеш. Сиңа безнеке кебек трусик каян килсен. Туганнан бирле бер көн колхоз эшенә чыкканың юк.

Кави карт. Мөслих энем, минеке дә андый түгел.

Мөслих Мөслимович. Димәк, хезмәтегез колхозга, то есть кооператив күмәк хуҗалыкка керткән өлешегез шулай гына.

Кави карт. Гомер буе, илле ел авылга хезмәт итеп, эшләгән эшеңне трусиклык та бәяләмәсеннәр инде.

Миңҗиһан. Йә, нишлибез, Мөслих Мөслимович?

Мөслих Мөслимович. Чөгендер басуына барабыз!

Айгөл. Мөкаддәс белән нишлибез?

Мөслих Мөслимович. Чөгендер түгел, чәчәк атмас! Үте сытылгач чыгар!

Айгөл. Юк инде, Мөслих Мөслимович, без аның үте сытылганын көтеп ята алмыйбыз!

Мөслих Мөслимович. Кара син моны ничек сөйләшә! Авылны ташлап, шәһәргә качканны онытккан. Берәүнең исенә төшкән, кияү кирәк булган. Кияү кирәк булгач, Мөкаддәсне ташлап китмиләр аны. Үзең гаепле! Чум да эзлә, чум да эзлә! Берүзеңә бер буа! *(Кулын селти-селти җырлый.)*

> Чума үрдәк, чума каз,
> Тирән күлне ярата, ярата,
> Саф һаваны ярата, ярата.

Сәрмәдия, Айгөл булып, оялчан кыяфәт ясап, бии-бии Мөслих Мөслимович янына килә.

Мөслих Мөслимович *(Сәрмәдияне җитәкләп биеп).*

> Айгөл үзенә кияү эзли,
> Айгөл үзенә кияү эзли.
> Мөкаддәсне ярата, ярата,
> Мөкаддәсне ярата, ярата.

Кави карт. Диваналар сез!

Айгөл. Өстәвенә тинтәкләр!

Сәрмәдия. Шулай шул. Әйе бит, Мөслих Мөслимович?! Дивана булмасак, авылда ятмас идек. Ачка койрык чәнчеп. Хак бит, Мөслих Мөслимович?!

Биюләреннән туктыйлар.

Мөслих Мөслимович. Хак! То есть нет! Менә сез ничек сөйләшә башлагансыз!.. Марш барыгыз да чөгендер басуына!

Миңҗиһан. Юк инде, без буаны...

Рушания. Буаны...

Исбах. Җибәрәбез!

Мөслих Мөслимович. Җибәртермен мин сезгә! Җибәрерсез буаны! Тотынып кына карагыз! Авылыгыз белән Себер җибәрермен!

Миңҗиһан. Нәрсә?! Авылдашыбызны суга салып калдырыйкмыни?

Барысы бергә. Җибәрәбез!

Мөслих Мөслимович. Сез нәрсә?! Үз акылыгыздамы?! Ә сез беләсезме, быел яз мин анда ничә центнер маймыч сатып алып җибәрдем?! Беләсезме?! Ике центнер карась малайлары сатып алып җибәргәнемне. Ә сез бик тиз генә, җиңел генә буаны җибәрмәкче буласыз. Бер маймыч айга күпме артым биргәнен беләсезме сез?! Белмисез! Белмисез шул. Бер маймыч айга ике йөз грамм артым, перевес бирә. Ә алты айга... Бер кило да ике йөз грамм була ул. Ә ике центнер маймычның ничә штук икәнен беләсегез киләме?! Без генә, совет чорында югары уку йортлары тәмамлаган бывший студентлар гына белә шул аны, наданкайларым! Без яшь чакта, студент чагында закускага, то есть тамак туйдырырга, кара икмәк белән йөз грамм килька гына ала идек. Йөз грамм милькага утыз алты штук килька туры килә, аңгыракайларым. Ә килька маймыч түгел, өч тапкыр кечерәк, миңгерәүләрем. Димәк, йөз граммга йөз дә сигез маймыч керә. Ә бер килограммга күпме маймыч керә?

Кави карт. Бер мең дә сиксән штук!

Мөслих Мөслимович. Хикмәт тә шунда шул. Бер килога бер мең дә сиксән штук карась малае кергәч, ике центнерга күпме керә?

Кави карт. Ике миллион йөз алтмыш мең маймыч!

Мөслих Мөслимович. Молодец! Саный беләсең, понимаешь ли, ә өйдә ятасың, понимаешь ли. *(Рушаниягә карап.)* Минем баш бухгалтерым икегә бишне кушалмый компьютер сорап утыра, понимаешь ли. Иртәгәдән үземә баш бухгалтер булып эшкә чыгасың! Һәр маймычның алты айлык артымын искә алып, уртача бер килода ике йөз граммнан алсак, безгә нишләргә кала?..

Рушания. Ике миллион йөз алтмыш мең балыкны бер кило да ике йөз граммга тапкырлыйсы була.

Мөслих Мөслимович. Тапкырла! Нәрсә авызыңны ачып каттың?

Исбах *(үпкәләп).* Әнә яңа баш бухгалтерың — Кави карт тапкырласын. Минем хатын Рушаниянең тапкырлавын ошатмыйсың бит.

Сәрмәдия *(Исбахка).* Күп тапкырладыгыз инде. *(Тамашачыга.)* Тапкырлый-тапкырлый череп баеп беттегез.

Кави карт. Ике миллион туксан ике мең килограмм.

Мөслих Мөслимович. Фантастика! Кеше, адәм ышанмаслык сан, цифр! Ике миллион туксан ике мең килограмм.

Кави карт. Шул ике миллион туксан ике мең кило балыкны кырык сумнан гына сатсаң да...

Мөслих Мөслимович. Бәяне төшермә, Кави абзый, бәяне төшермә. Илле сумнан! Йөз дә егерме тугыз миллион алты йөз мең чиста табыш! Җәмәгать, авылдашлар, кул чабулар, алкышлар кая?!

Барысы дәррәү кул чабалар.

Кави карт. Син, энем, Мөслих, санарга бик яратасың икән. Әйтәм җирле сине бер урында озак тотмыйлар, гел күчереп йөртәләр.

Айгөл. Буаны көрәк белән үзем ерам. Әмма Мөкаддәсне балыкларга ризык итмим.

Мөслих Мөслимович. Сеңлем, ачуланма, Мөкаддәс начар егет түгел иде, әмма гармуны белән җилегемә төшкән иде инде. Гармун тартып, көтү көтеп алга китеп булмый. Көтү — нерентабельно!

Барысы бергә. Дөрес анысы. Ул гармун тавышыннан туеп, күңел болгана иде инде.

Исбах. Нервлар бетүен бетте анысы.

Рушания. Ну бит авылдашны да су төбендә калдырып булмый.

Миңҗиһан. Кеше чөгендер утый, ә ул гармун тартып көтү көтә. Кая гаделлек?! Моны ничек аңларга?

Мөслих Мөслимович. Сыер биетеп кенә тормыш көтеп булмый әле ул, понимаешь ли.

Исбах. Йокларга гына ятасың, ә ул... Гармун тартып, чыбыркы шартлатып, авылга көтү алып кайта. Безобразие!

Айгөл. Юк инде. Сез эзләргә төшәсезме-юкмы, белмим, мин буага төшеп киттем.

Мөслих Мөслимович. Төшеп кенә кара! Балыкларның тынычлыгын гына бозып кара! Мин синең белән нишләргә кирәген белермен!

Айгөл. Нишләрсең?!

Мөслих Мөслимович. Күз күне буаны җибәргәндә, бер генә балыгым ун гына граммга ким булсын. Өстеңә налог салам!

Миңҗиһан. Салсаң салырсың инде. Әйдә, кызым!

Сәрмәдия. Әллә мине калыр дип уйлыйсызмы?

Кави карт. Әйдәгез, авылдашлар, мин дә сезнең белән. Авылның соңгы моңын, соңгы гармунчысын су төбендә калдырмыйк. Моң китә — авыл бетә. Авыл бетсә, гореф-гадәт, тел, милләт бетә! Әйдәгез, балалар, соңгы гармунчыбызны кадерләп, олылап туган җиребез куенына салыйк. Кем белә, бәлки, гасырлар узгач, кемдер аның каберенә тап булыр да, биредә татар дигән милләт яшәгән икән дип, үзенең тарих китабына язып куяр. Әйдәгез, балалар, әйдәгез, авылдашлар, кузгалыйк!

Барысы бергә. Безгә күптән кузгалырга вакыт!

Барысы бергә дәррәү кубып, кайсы багор, кайсы сәнәк, көрәк, балта, аркан тотып, тау астына, буага төшеп китәләр.

Мөслих Мөслимович *(мәйдан уртасында басып кала).* Күрсәтәм әле мин сезгә соңгы магиканны! Күрсәтәм әле мин сезгә соңгы моңны!

Музыка. Ут сүнә.

*ИКЕНЧЕ КАРТИНА*

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Мөслих Мөслимович үз кабинетында, аякларын өстәл өстенә куеп, җырлап утыра.

Мөслих Мөслимович.

Суда балык йөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер шул, сизәдер.
Авылыбызда тинтәкләр бар...
Күңелемне өзәдер лә, өзәдер.

Бүлмәгә милиция киеменнән тикшерүче Асыл Шәмгунович килеп керә.

Асыл Шәмгунович. Исәнмесез!

Мөслих Мөслимович *(урыныннан тора).* Исәнмесез!

Асыл Шәмгунович *(кулын сузып).* Таныш булыйк, милиция майоры, следователь Асыл Шәмгунович Шәмгунов!

Мөслих Мөслимович. Мөслих Мөслимович!

Асыл Шәмгунович. Карпов Еланти Крокодилович үзе кая?

Мөслих Мөслимович. Үзебез дип торабыз. Көләсез, иптәш следователь, көләсез.

Асыл Шәмгунович. Нигә көлим?

Мөслих Мөслимович. Әле яңа идеям авыздан чыгарга да өлгермәде, кушамат тагып та куйдыгыз.

Асыл Шәмгунович. Гафу итегез! Мин шәһәрдән. Сезнең район җитәкчеләрен белеп бетермим. Район эчке эшләр бүлеге начальнигы миңа сезне Карпов Еланти Крокодилович дип таныштырды. Сез чынлыкта кем буласыз инде?

Мөслих Мөслимович *(яңадан кулын сузып).* Мин — Мөслих Мөслимович Кирпичов, то есть Буранбаев булам.

Асыл Шәмгунович. Яхшы. Мин сезнең буага батып үлгән гражданин *(папкасын ачып)* Моңзаров Мөкаддәснең эшен тикшерергә килдем.

Мөслих Мөслимович. Аның эшен тикшерәсе юк инде, иптәш следователь. Аның хәле бик начар.

Асыл Шәмгунович. Таптыгызмыни?

Мөслих Мөслимович. Табарсың, бар. Бер атна эзлибез инде.

Асыл Шәмгунович. Күпме эзлисез?

Мөслих Мөслимович. Бер атнадан артык бугай инде.

Асыл Шәмгунович. Точнее.

Мөслих Мөслимович. Бүген сигезенче көн.

Асыл Шәмгунович. Авылыгызда сигез көн элек кеше батып үлә. Ә сез бу хакта район эчке эшләр бүлегенә кичә генә хәбәр итәсез. Моны ничек аңларга, иптәш Мөслих Мөслимович.

Мөслих Мөслимович. Сез мине теләсә ничек аңлагыз, иптәш следователь. Соңгы ике елда сигез эш урыны алыштырырга туры килде. Башымда гениальный план тууы була, тормышка ашыра алмыйм, бүтән эшкә күчерәләр.

Асыл Шәмгунович. Соңгы тапкыр кайда эшләдегез?

Мөслих Мөслимович. Кирпеч заводында директор вазифасын башкардым. Мин бит районыбызның кирпеч заводын яңа ысул белән эшләтә башлаган идем.

Асыл Шәмгунович *(делодан укып).* Шул идеягез аркасында ике ел условный срок алдыгызмы?

Мөслих Мөслимович. Ул вакытта минем югары постта эшләр өчен тәҗрибәм җитми иде. *(Өстәл тартмасыннан акт кәгазен чыгара.)* Менә акт! Суга кермәскә, балык тотмаска, җәтмә, ау салмаска! Барлык авыл кешеләренең куркынычсызлык актына куелган куллары тора. Бер авызың пешкәч, өреп кабасың икән ул. *(Актны кире өстәл тартмасына салып куя.)*

Асыл Шәмгунович. Ә кирпеч заводында ни булды?

Мөслих Мөслимович. Анда мин уйлап тапкан кирпеч астында калып өч кеше үлде. Әгәр шул вакыт мин аларга актка кул куйдырткан булсам, хәзер минем урыным биредә түгел, республиканың берәр

министрлыгында министр креслосында булыр иде. Нинди ысул, нинди кирпеч уйлап тапкан идем бит мин. Бер метрга бер метрлы кирпеч! Беренчедән, дүрт кирпечне берсе өстенә берсен өясең, күз ачып йомганчы, эт ботын күтәргәнче, дүрт метрлы стена әзер. Беренчедән, растворга эконом, икенчедән, кладчикларга. Бәяне ничек күтәрделәр бит?

Асыл Шәмгунович. Ә, әйе, исемә төште. Сез ул идеягез, ысулыгыз белән районыгызны гына түгел, республиканы шаулаткан идегез бугай.

Мөслих Мөслимович. Эш тәҗрибәмне күрүчеләр булмады. Киресенчә, ике елга условный срок бирделәр.

Асыл Шәмгунович. Ә хәзер нинди идеяләр белән яшисез?

Мөслих Мөслимович. Авыл хуҗалыгын күтәрергә кирәк, иптәш следователь, авыл хуҗалыгын. Авыл хуҗалыгын, иптәш Асыл Шәмгунович! Мал асрап, ит җитештереп, сыер савып алга җибәреп булмый, ГСМ кыйммәт. Горючий, смазочный материалны әйтәм. Техника — трактор, комбайн янына якын килерлек түгел. Балык үрчетергә кирәк, балык, иптәш следователь. Балыкка комбайн, трактор кирәкми. Балыкка печән, фураж кирәкми.

Асыл Шәмгунович. Беләм, конечно. Шуның өчен мине бирегә җибәрделәр дә.

Мөслих Мөслимович. Уже тиштеләр дә. Ну бу авыл халкы, ну бу авыл халкы, авызларында бер сүз тормый. *(Ишекне ачып, коридорны карый да, бикләп, форточканы яба. Пышылдап.)* Минем буа төбендә йөз дә егерме тугыз миллион алты йөз мең чиста табыш ята.

Асыл Шәмгунович. Һәм дә шушы авылның гражданины Мөкаддәс Моңзаров дигән кеше ята.

Мөслих Мөслимович. Гафу итегез *(өстәл тартмасыннан акт чыгарып),* менә акт! Суга кермәскә! Балык тотмаска, ау, җәтмә салмаска! Балыкларның тынычлыгын бозмаска! Менә Мөкаддәснең кулы тора. Менә ни өчен мин районның эчке эшләр бүлегенә хәбәр итмәдем. Хәбәр итсәм, буамны җибәртерләр дә, планым тормышка ашмый калыр дип курыктым. Үзегез беләсез, иген икмәгәч, мал асрамагач, күмәк хуҗалыкның акчасы юк. Акчасы булмагач, атназначно водолазлар да чакыртып булмый.

Асыл Шәмгунович. Ә бәлки, аны буага үтереп салганнардыр?

Мөслих Мөслимович. Кемне? Мөкаддәснеме?! Кемгә кирәк ул?!

Асыл Шәмгунович. Бәлки, аның үлеме кемгә дә булса кирәк булгандыр? Бәлки, ул кемгәдер комачаулагандыр?

Мөслих Мөслимович. Сез нәрсә инде, иптәш Асыл Шәмгунович?! Сез нәрсә? Анадан тума чишендерепме?

Асыл Шәмгунович. Ә нәрсә, сезнеңчә, Мөкаддәс, эчке киемнәрен салып, үзе батып үлгән булып чыгамыни? Ә ни өчен әле ул эчке киемен салган?!

Мөслих Мөслимович. Авыл бетте! Авылны бетерделәр! Авылны чишендерделәр! Авыл кешесенең алмаш трусигы да калмады.

Асыл Шәмгунович. Юк, иптәш Мөслих Мөслимович, юк! Бу — криминал! Яр читендәге трусик Мөкаддәс тарафыннан калдырылган бердәнбер дәлил, бердәнбер шаһит, бердәнбер зацепка! Аны үлемгә мәҗбүр иткәннәр. Үләсе кешегә трусик нигә?! Әгәр ул үзе теләп баткан булса, трусигы үзе белән булган булыр иде. Монда — криминал! Ә менә җинаятьче кем? Миңа шуны табарга кирәк.

Мөслих Мөслимович. Шулай дисезме?

Асыл Шәмгунович. Шулай димен. Мөкаддәснең начар гадәтләре бар идеме?

Мөслих Мөслимович. Бар иде. Көне-төне гармун уйнап, авыл халкының тәмам җилегенә төште. Бабасы, урманга керсә, кура сындырып, кура өрде, атасы, ат кылы тартып, думбра чиртте.

Асыл Шәмгунович *(ияк астына чиртеп).* Юк ла инде, үзе чиртми идеме?

Мөслих Мөслимович. Юк, юк, үзе чиртми иде. Ну атасы чиртергә мастер иде инде.

Асыл Шәмгунович. Юк ла инде, салмый идеме дим?

Мөслих Мөслимович. Салуын салмый иде, тартуын тарта иде.

Асыл Шәмгунович. Тарта иде, да?

Мөслих Мөслимович. О-о, ничек кенә тарта иде әле. Тирә-якта аңа җиткән тартучы юк иде.

Асыл Шәмгунович. Анашамы, әллә марихуанмы?

Мөслих Мөслимович. Анысын этем белсен. «Вараксин» идеме соң әле ул аның, әллә «Саратовский»мы?

Асыл Шәмгунович. Нигә? Әллә андыйлары да буламы?

Мөслих Мөслимович. Ну шул ике рәтлесе инде.

Асыл Шәмгунович. Һични аңламыйм.

Мөслих Мөслимович. Гармуннарда мин үзем берни дә аңламыйм. Миңа баян ни дә, тальян ни... Барысы да гармун.

Асыл Шәмгунович. Аңгыра син, Мөслих Мөслимович, аңгыра.

Мөслих Мөслимович. Аңгыра булмый, аңгыра, конечно. Минем гармун тартырга вакытым булмады. Ике кулым эштән бушамады.

Асыл Шәмгунович. Наркотик тартмый идеме дим мин сиңа?

Мөслих Мөслимович. Өзеп кенә әйтә алмыйм. Шикләнәм. Аек акыл белән кеше гармун тартмый.

Асыл Шәмгунович. Авылда шикле кешеләр юкмы?

Мөслих Мөслимович. Бар! Точно бар! Кави карт!

Асыл Шәмгунович. Ә ул кем?

Мөслих Мөслимович. Авылның бердәнбер карты. Мәет җирләп, мәет юып йөри.

Асыл Шәмгунович. Мәет җирләп дисең инде.

Мөслих Мөслимович. Авылда үлем-китем булса, зиратта ул иң беренче. Мәет күмүдән ләззәт таба. Шулкадәр үз эшен җиренә җиткереп эшли, хәтта аның артыннан күрше авыллар да килә. Шик юк түгел, шик бар.

Асыл Шәмгунович. Аңа ничә яшь?

Мөслих Мөслимович. Үзенең әйтүенә караганда, туксан бер яшь, ди.

Асыл Шәмгунович. Туксан бер дисең инде.

Мөслих Мөслимович. Әйе. Үзенең әйтүенә караганда, туксан бер. Ә минем сиксән җидедәге әбием әйтүенә карасаң, туксан җиде! Әби әйтә, мин кыз чакта ул инде бабай иде, ди. Аңа туксан бер генә түгел, туксан җиде, йә булмаса, туксан тугызлар булырга тиеш, ди.

Асыл Шәмгунович. Туксан тугыз яшьлек картка Мөкаддәс нигә кирәк булган инде?

Мөслих Мөслимович *(ишекне, форточканы тикшерә дә, пышылдап).* Мөкаддәснең гармунына кызыга иде.

Асыл Шәмгунович. Кызыга иде?..

Мөслих Мөслимович. Кызыга иде. Мөкаддәс капка төпләренә чыгып гармун тартса, ул да капка төпләренә чыга иде. Мөкаддәс гармун тартып көтүгә китсә, ул да көтүлеккә чаба иде. Ә үзенең кәҗәсе дә юк! Вәт!

Асыл Шәмгунович. Буага чит авыллардан килә иделәрме?

Мөслих Мөслимович. Килеп кенә карасыннар. Буаны ике ствол белән төнлә Исбах, көндез үзем саклый идем.

Асыл Шәмгунович. Буага ау, җәтмә салучылар бармы?

Мөслих Мөслимович. Юк! Өздереп әйтәм, юк!

Асыл Шәмгунович. Мөкаддәснең батып үлгәнен берәү дә күрмәгән инде.

Мөслих Мөслимович. Юк, күрмәгән. Но буаның үкергәнен үзем ишеттем.

Асыл Шәмгунович. Ничек үкергәнен?

Мөслих Мөслимович. Олы суларның елга бер тапкыр мәет сорап үкерә дигәнен әллә сезнең ишеткәнегез юкмы, иптәш следователь?

Асыл Шәмгунович. Юк, ишеткәнем юк. Тагын кемнән шикләнәсез?

Мөслих Мөслимович. Исбахтан!

Асыл Шәмгунович. Анысы кем тагын?

Мөслих Мөслимович. Тәкә шалтырамасы кадәрле генә бер адәм. Эшләми, сволочь! Эт ялкавы!

Асыл Шәмгунович. Нигә аннан шикләнәсез?

Мөслих Мөслимович. Безнең авылда Сәрмәдия дигән бер чибәр бар. Ә ул гомере буе Мөкаддәскә гыйшык тотып яшәде. Ә теге бүлтерек Исбах төннәрен барып Сәрмәдиянең тәрәзәсен каккалый.

Асыл Шәмгунович. Каян беләсең?

Мөслих Мөслимович. Нәрсәне?

Асыл Шәмгунович. Тәрәзәсен какканын.

Мөслих Мөслимович. Берничә тапкыр үзем куып җибәрдем.

Асыл Шәмгунович. Каян?

Мөслих Мөслимович. Тәрәзә төбеннән.

Асыл Шәмгунович. Ә син үзең анда нишләп йөрдең соң?

Мөслих Мөслимович. Сәрмәдиянең сыерын капкадан ачып кертим дип барган идем.

Асыл Шәмгунович. Аңлашылды. Сәрмәдия Мөкаддәскә гыйшык тотып яшәгән, төннәрен Сәрмәдиянең тәрәзәсен Исбах килеп шакыган, Исбахетдинне төннәрен Мөслих Мөслимович куып җибәргән дип протоколга язып куйыйк әле. *(Яза.)*

Мөслих Мөслимович. Куып җибәргән дип язмагыз, сыерын керткән дип языгыз, иптәш следователь, сыерын керткән дип. *(Тамашачыга.)* Себер җибәрә бу мине...

Асыл Шәмгунович. Ә Мөкаддәснең батып үлү хәбәрен авылга беренче булып кем хәбәр итте?

Мөслих Мөслимович. Миңҗиһан белән аның кызы — Мөкаддәснең мәхәббәте Айгөл.

Асыл Шәмгунович. Айгөл дисең инде.

Мөслих Мөслимович. Айгөл димен.

Асыл Шәмгунович. Айгөлгә ничә яшь?

Мөслих Мөслимович. Этем белсен. Ә-ә, шунысын әйтергә онытканмын, иптәш Асыл Шәмгунович. Теге картны әйтәм, теге картны — Кавины, странный ул. Мөкаддәс батып үлде, ә ул нәрсә ди, «Ну молодец, егет икән!» ди. Тора да шул сүзне кабатлый, тора да шул сүзне кабатлый. Сәер бит, ә?

Асыл Шәмгунович. Бик сәер. Хәзер миңа Миңҗиһан белән аның кызы Айгөлне чакырт. Аннары миңа берәр фатир да табарсың.

Мөслих Мөслимович. Фатир әзер. Сәрмәдиягә кертермен.

Асыл Шәмгунович. Аннары капкасын ачып сыерын кертергәме? Юк инде. Мине Мөкаддәс чакыртты...

Мөслих Мөслимович. Ничек Мөкаддәс чакыртты?! Үлгән Мөкаддәсме?

Асыл Шәмгунович. Нинди Мөкаддәс, нинди Мөкаддәс? Колагыңны чистарт, аңгырая башлагансың.

Мөслих Мөслимович *(тамашачыга).* Аңгыраерсың сезнең белән!

Асыл Шәмгунович. Мөкаддәс Моңзаров эше белән килдем. Мөкаддәс фатирына урнаштырырсың. Тынычлап, икәүдән-икәү генә калып алдагы планнарны корырбыз.

Мөслих Мөслимович. Кем белән?

Асыл Шәмгунович. Кем белән булсын инде?! Үлгән Мөкаддәс белән түгел, синең белән. Бар, бар, тиз, тиз бул, Мөслих Мөслимович. Обстоятельство көткәнне яратмый. Җинаятьче иректә йөри.

Мөслих Мөслимович. Шулай дисеңме?

Асыл Шәмгунович. Шулай димен.

Мөслих Мөслимович. Ярый алайса, мин киттем. Хәзер Миңҗиһан белән кызы килеп җитәрләр.

Мөслих Мөслимович чыгып китә. Асыл Шәмгунович телефоннан номер җыя.

Асыл Шәмгунович *(трубкасын колагына куя).* Алло, алло!.. Ни хәлләр? Рәхмәт! Мин килеп җиттем. Эшне... эшне башладым. Сөйләштем. Мөслих белән сөйләштем. Хәзерме, хәзер Миңҗиһан белән Айгөлне чакырттым. Борчылма! Кызын ник кияүгә бирмәгәненә үкендертәм әле мин аны.

Бүлмәгә Миңҗиһан белән Айгөл керәләр.

Айгөл. Мөмкинме?

Асыл Шәмгунович. Мөмкин, утырыгыз! *(Телефонга.)* Иртәрәк әле, иртәрәк. Шуннан, тау астыннан, буадан башлыйбыз инде. Дөрес, дөрес әйтәсең, хикмәт бит Мөкаддәснең югалуында түгел, хикмәт бит авылдан моң югалуда. Хикмәт бит милләт моңын югалтуда. Авыл халкын кыйбласына кайтармасам, моң эзләтеп пластунский шуыштырмасам, исемем Асыл булмасын. Пока! *(Трубканы куя.)* Йә, сеңлем, нишлибез, авылга моңны кайтарабызмы?

Айгөл. Моң нәрсә ул?

Миңҗиһан. Моңны тотып та, ашап та булмый.

Айгөл. Әй, абый җаным, әни булса да әйтим инде, моңны кочаклап ятып булмый. Син миңа Мөкаддәсне кайтарсаң иде, Мөкаддәсне!

Асыл Шәмгунович. Кочаклап ятып булмый дисең инде. Моң үзе адәм баласын кочаклый ул! Кирәк чакта елата, кирәк чакта көлдерә, кирәк чакта җырлата. Яшәргә дәрт-дәрман бирә, үткәнеңне, бүгенгеңне, киләчәгеңне барлый. Әйтегез әле, Моңзаров Мөкаддәснең суга батып үлү хәбәрен авылга сез алып кайттыгызмы? Ничегрәк авылга хәбәр иттегез инде?

Миңҗиһан. Доказательство белән. Китмән башына дәлил элеп.

Асыл Шәмгунович. Ә ул үлмәгән булса?

Айгөл. Кая соң ул?

Асыл Шәмгунович. Өендә!

Миңҗиһан. Сөйләп куя бу! Аңа — Мөкаддәскә — үлем турындагы ямьсез шаяру нигә кирәк соң?

Асыл Шәмгунович. Үзенең авылда иң кирәкле кеше икәнен белдертү өчен.

Миңҗиһан. Каян килгән кишер яфрагы?

Асыл Шәмгунович. Сиңа кирәкмәсә, авылга кирәк.

Миңҗиһан. Кирәк авылга. Авыл халкы ул юкка чыккач тыныч сулап куйды.

Асыл Шәмгунович. Синең кызың Айгөлгә кирәк.

Миңҗиһан. Аңа кирәк булса гына инде.

Айгөл. Әни! Гомерең буе шуны күпсендең инде. Синең алда гына шулай кылана ул, иптәш милиционер. Өйдә икәү генә калгач еламаган минутыбыз юк. Мөкаддәснең гармун тавышын сагынып елыйбыз.

Асыл Шәмгунович. Әйтегез әле, Мөкаддәс Моңзаров үзе батып үлде микән, әллә берәрсе булышты микән?

Миңҗиһан. Ни дип әйтергә дә белмим инде. Үзем, үзем гаепледер инде. Вакытында кызымны кияүгә биргән булсам, бәлки, бу хәл булмаган да булыр иде. *(Елый башлый.)*

Айгөл. Әни, елама. Синең гаебең юк. Барысы өчен дә Сәрмәдия тәре сыйрак гаепле. Шул, шул аның башына җитте.

Асыл Шәмгунович. Сәрмәдия?.. Ни өчен ул?

Миңҗиһан. Гомере буе баламнан көнләшеп, Айгөлемне бәхетсез итәргә тырышты.

Айгөл. Гомере буе Мөкаддәскә гыйшык тотып яшәде, карт тәре!

Миңҗиһан. Шул гына шабашниклар яллап суга батырды.

Айгөл. Үземнеке дә булалмады, Айгөлгә дә булмасын дип, күрше авылның сихерче Марусясыннан сихер яздырып алып, Мөкаддәсне бозды.

Асыл Шәмгунович. Дәлилли аласызмы?

Миңҗиһан. Өч кара халыкның, чеченнар булган, диделәр, авыл аркылы «Жигули»га утырып чыгып киткәннәрен күреп калганнар. Шул көнне Мөкаддәс юкка чыкты. Сәрмәдиянең чеченнары гына башына җитте.

Асыл Шәмгунович. Сәрмәдиянең чеченнары да бармыни?

Миңҗиһан. Булмыйча! Унсигез яшеннән шабашкага килгән кара халык белән аралаша башлаган иде. Гомере шулар белән үтте.

Айгөл. Юк инде, әни, юк! Марусяның бозымы харап итте аны, Марусяның бозымы. Мөкаддәс батып үләсе көнне Сәрмәдиянең, төенчек күтәреп, Мөкаддәс янына көтүлеккә менеп киткәнен авыл халкы күреп калган.

Асыл Шәмгунович. Минемчә, аны Кави карт үтергән.

Миңҗиһан.

Айгөл. Нигә?

Асыл Шәмгунович. Гармунына кызыгып.

Миңҗиһан.

Айгөл. Шулай дисезме?

Асыл Шәмгунович. Шулай дим.

Миңҗиһан. Булыр. Аны бит өч ел немец лагеренда, аннан качкан өчен биш ел совет төрмәсендә, җиде ел Колымада булган дип сөйлиләр.

Айгөл. Әйтәм җирле, гел мыек астыннан гына көлеп, «Ну молодец, егет икән!» дип көлеп утыра ул.

Миңҗиһан.

Айгөл. Вәт карт шайтан, карт шайтан!

Миңҗиһан. Әйтәм җирле, гомере буе Мөкаддәскә ияреп, селәгәен агызып йөрде ул. Гармунына кызыккан икән. Менә сиңа, бер авылда күрше була торып, бер-береңнең кем икәнен дә белми яшә.

Айгөл. Авылда игътибарсызлык көчәйде. Төнлә суеп чыксалар да, күрше хәлен күрше белми.

Миңҗиһан. Кешегә кеше керми. Ата —улны, ана кызны белми. Каян белдегез, иптәш следователь?

Асыл Шәмгунович. Бәлки, Исбахтыр?..

Миңҗиһан.

Айгөл. Ничек Исбах?.. Булмас...

Асыл Шәмгунович. Сәрмәдия Мөкаддәсне сөйгән, Исбах — Сәрмәдияне. Сәрмәдиядән Мөкаддәсне көнләп, бәлки, ул суга батыргандыр.

Миңҗиһан. Шул, шул үзе, тәре күз. Күзендә нур юк иблиснең. Эчә-эчә күзе бетләп беткән.

Айгөл. Тукта әле, әни! Буталып беттек без. Ә Кави карт...

Миңҗиһан. Йөзгә якынаеп килгән картның утыз биш яшьлек Мөкаддәскә ничек көче җитсен инде.

Асыл Шәмгунович. Ә шабашник чеченнар?

Миңҗиһан. Мин бит кызулыктан гына. Хәзер бит коровник төзергә чеченнар да, әрмәннәр дә килми. Хәзер коровник төземиләр, киресенчә, булганнарын сүтәләр.

Асыл Шәмгунович. Юк, белмәдегез. Аны Мөслих батырган.

Миңҗиһан.

Айгөл. Мөслих Мөслимович?.. Нигә?..

Асыл Шәмгунович. Гармунда уйнап, авыл халкын эштән аерган өчен. Төнлә белән буага ау салганда, шунда эләгеп Мөкаддәс батып үлгән.

Миңҗиһан. Үзе түгел, үзе түгел — Исбах.

Асыл Шәмгунович. Ничек, Исбах?

Миңҗиһан. Аның авын төнлә Исбах сала иде.

Айгөл. Менә ни өчен буаны җибәртми ул.

Миңҗиһан. Җинаятьче — Мөслих үзе!

Айгөл. Соучастник — Исбах!

Асыл Шәмгунович. Миңҗиһан апа, авыл халкы сине дә, Мөкаддәсне яратмый иде, дип сөйли, Мөкаддәс югалган көнне кулыңда китмән күргәннәр. Син үзең...

Миңҗиһан. Әй, чукынып кына утырма әле. Син нинди милиция соң, следователь, имеш. Бөтен авылны үтерүче итеп бетердең инде. Әйдә, кызым, кайтабыз. Милиция түгел, дивана бит бу.

Чыгып китәләр.

Музыка. Ут сүнә.

*БЕРЕНЧЕ КАРТИНА*

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн. Багана башындагы прожекторда гына ут яна. Буа ягыннан гармун тавышы агыла. Тәрәзәләрдә берәм-берәм утлар кабына, кеше баш-
лары күренә.

Мөслих Мөслимович. Бу нәрсә?! Нинди хикмәт бу?!
Миңҗиһан. Бу нинди моң?!
Исбах. Ярты төн уртасында кем безнең белән шаяра?
Айгөл. Бу бит Мөкаддәснең гармун тавышы!
Сәрмәдия. Сеңлем, әллә саташасыңмы? Атна буе су астында яткан Мөкаддәс гармун тарта аламыни?
Айгөл. Юк, ул үлмәгән! Ул исән. Әйдәгез, авылдашлар, безне ул үз янына чакыра.
Исбах. Үлгән Мөкаддәсме?
Айгөл. Әйе, Мөкаддәс!
Исбах. Ашыксаң, бара тор, сеңлем. Мин анда барырга ашыкмыйм. Миңа җылы ястыгымда бик рәхәт әле.
Мөслих Мөслимович. Авылдашлар, әйдәгез, кулыгызга нәрсә эләгә, балтамы, көрәкме, ломмы, коралланыгыз да тау астына, алга! Безне мыскыл итүче Мөкаддәсне фаш итеп авылга тотып алып кайтабыз.

Урамга эчке ыштан, эчке киемнән, кулына кем нәрсә туры килсә шуны
эләктергән авыл халкы чыга.

Мөслих Мөслимович. Бу нинди галәмәт?! Бу нинди оятсызлык?!
Кави карт. Молодец! Егет икән!
Айгөл. Мөкаддәс моңы! Мөкаддәсемнең гармун моңы!
Рушания. Исән икән, исән!
Миңҗиһан. Иблис икән. Тагын колакка басты. Кая, кая следователь?! Кая үзе Асыл Шәмгунович, үзе кая?
Рушания. Милиция кая?
Сәрмәдия. Кич караңгы төшеп килгәндә районга китте.
Айгөл. Мөкаддәс, монда кил, бире кил, без сине авылыбыз белән сагындык.
Миңҗиһан. Кил, кил, тәрәз төбемә килеп төннәр буе сайра, моңлан. Башка һичкайчан да сүз әйтәсем юк.
Исбах. Җитте! Булды! Хватит! Безне мыскыл итә. Әйдәгез, әйдә, авылдашлар. Үзебез үзен тотып алып кайтабыз!
Мөслих Мөслимович. Әйдәгез, җәмәгать!
Барысы бергә. Алга! Тау астына! Буага!

Шау-гөр килеп тау астына төшеп китәләр. Сәхнә уртасында Кави
карт кына басып кала.

Кави карт. Мескеннәр! Бичаралар!!! Күңелдән качкан моңны тотып булмый ул!

Музыка. Ут сүнә.

Пәрдә.

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*БЕРЕНЧЕ КАРТИНА*

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн. Арып-талып, барысы да сәхнәгә чыга.

Сәрмәдия. Вот черт! Буага килеп җитүебез генә булды, моң юкка чыкты.
Исбах. Моң да юк, Мөкаддәс тә юк.
Миңҗиһан. Сез берәр нәрсә күрдегезме-юкмы? Мин этле җан да күрмәдем.

Айгөл. Мөкаддәсемне мин дә күрә алмадым.
Рушания. Аермачык моң агыла, ә кеше-фәлән юк. Вәт әкәмәт!
Мөслих Мөслимович. Мин күрдем!
Сәрмәдия. Нәрсә күрдең?
Мөслих Мөслимович. Мөкаддәсне күрдем.
Миңҗиһан. Кайда күрдең?
Мөслих Мөслимович. Басмада!
Исбах. Кулында гармуны бар идеме?
Мөслих Мөслимович. Кулында гармуны бар иде.
Сәрмәдия. Гармунын тартып-тартып уйный идеме?
Мөслих Мөслимович. Гармунын тартып-тартып уйный иде.
Айгөл. Шуннан нишләде?
Мөслих Мөслимович. Суга, буага чумды.
Миңҗиһан. Гармуны беләнме?
Мөслих Мөслимович. Гармуны белән.
Исбах. Кереп ят син, туган, кереп ят.
Рушания. Кереп ят, Мөслих Мөслимович, кереп ят.
Барысы бергә. Әйдә, өеңә озатып куябыз.
Мөслих Мөслимович. Яшерен-батырын түгел, җәмәгать, булмый, куркам. Мин, булмаса, Сәрмәдия, сиңа гына кереп кунармын инде.
Исбах. Укыган кеше укыган кеше инде. Беркайчан да югалып калмый. Әйдәгез, авылдашлар, таралышыйк. Иртәгә Кадер киче түгел. Миңа карамагыз, иртәгә эшкә барасыгыз бар.
Миңҗиһан. Вакыты вакыт түгел аның. Төнге сәгать ике. Җеннәрнең котырган чагы.
Сәрмәдия. Бастырылып ятасың килмәсә, берәр ир-атны эләктереп кер, Миңҗиһан апа. Ир-ат янына җеннәр килми ди ул. Әнә Кави бабай свободный.
Миңҗиһан. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, юньсез!
Кави карт. Телеңә тилчә чыккыры!

Барысы да берәм-берәм керә башлыйлар. Мөслих Мөслимович белән Сәрмәдия генә култыклашкан килеш сәхнә уртасында кала.

Мөслих Мөслимович *(йодрыгын буа ягына болгап).* Күрсәтәм әле мин сиңа — молокососка — раки где зимуют! Ник туганыңа үкенәселәрең алда әле. Гомер бакый кулыңа гармун алмаслык итәм әле мин сине. «Әй, Мөкаддәс, моңлы сазым, уйнадың ник син бик аз» дигән көнеңә китерәм әле мин сине.
Сәрмәдия. Әйдә, әйдә керәбез, Мөслих Мөслимович. Калтырыйсың. Прямо бизгәк тоткан кеше сыман калтырыйсың. Дер-дер киләсең. Бик курыккансың бугай.
Мөслих Мөслимович. Курыкмадым, курыкмадым мин. Туңдым, туңдым, аңлыйсыңмы?!
Сәрмәдия. Әйдә, әйдә керик. Төне салкын. Таң салкыны төшә. Юеш чалбар белән озак басып торырга ярамый. Салкын тидерерсең.

Кереп китәләр. Тәрәзәләрдә утлар сүнә. Чикерткәләр сайравы астында зәңгәрләнеп таң атып килә. Янәдән тау астыннан — буа ягыннан моңлы көй агыла. Тәрәзәләрдә кабат утлар кабына. Барысы да сәхнәгә йөгереп чыга.

Айгөл. Янәдән моң! Мөкаддәс моңы! Уйна, уйна, җаным! Бар җиһан уянсын!
Мөслих Мөслимович *(буа ягына йодрыгын төйнәп).* Үтерәм, сволочь!
Сәрмәдия. Мөкаддәс, жәллә безне, зинһар, жәллә!
Исбах. Бу юньле эш түгел, моның хикмәте бар. Җен эше бу!
Рушания. Китче әле, сугып очырырмын. Мужик башыгыз белән, авылыгыз белән дер-дер калтырап, «җен бар» дип куркып басып торасыз.
Сәрмәдия. Сөйлисе юк. Син үзең җен! Җенгә син кирәк идең. Җен синең үзеңнән куркып кача. Рушанияңнең итәк астыннан башыңны чыгарып, юрган астында гына ят инде. Нигә чыгып азапланып йөрисеңдер?
Рушания. Кагылма минем Исбахетдинемә! Утыз яшенә кадәр әбисенең әкиятен тыңлап, әбисенең аяк очында гына йоклап тәрбияләнгән бала ул!
Сәрмәдия. Бала?.. Бала диме? Ха-ха-ха... Сакаллы сабый түгелме?
Исбах. Әйдә, әнисе, әйдә, Рушаниякәем, өйгә керәбез. Ходай үзе сакласын. Иртәгәдән намазлыкка басам, Алла боерса. Ялгышып та бүтән авызыма аракы алмыйм. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, Ходаем, үзең сакла. Җен булмыйча, җен, әлбәттә.
Сәрмәдия. Җәмәгать, икегә бүленәбез. Яртыбыз уңнан, яртыбыз сулдан. Буаны уратып алабыз да үзен кулга алабыз.
Мөслих Мөслимович. Сәрмәдия, мин синең командаңда, ярыймы?
Исбах. Ә мин Рушаниям белән бергә.

Кави карт. Мин уңга да, сулга да кушылмыйм.
Барысы бергә. Нигә?
Кави карт. Моңны сулдан да, уңнан да уратып тотып булмый.
Мөслих Мөслимович. Безгә моң кирәкми! Безгә Мөкаддәс үзе кирәк. Безгә тынычлык кирәк.
Кави карт. Ялгышасыз, балалар! Безнең халыкка тыныч кына яшәргә язмаган. Тыныч җирдә җеннәр аза, ди. Безгә үзебезнең барлыкны сиздереп яшәсәк тә таманга гына туры килә.
Сәрмәдия. Әй, нәрсә дип комы коелган картның сүзен тыңлап торасыз. Әйдәгез, авылдашлар!
Рушания. Әйдәгез, җәмәгать!

Барысы да дәррәү кубып, икегә бүленеп, тау астына, буага төшеп китәләр. Сәхнә уртасында Кави карт берьялгызы кала.

Кави карт. Комы коелган дисез инде. Үткәннәргә борылып карарга онытмагыз, үткәннәргә. Уян, авыл, уян! Сиңа күптәннән уяныргa вакыт. Үз моңыңны югалтма. Үз милли моңыңны югалтырга синең хакың юк!

Рушания белән Исбах өйләренә таба баралар.

Рушания. Каһәр суккан төн булды бу. Тәмам күздән йокы качты.
Исбах. Тәүлек буе йокы күргән юк. Бу авылдан күчеп китик, анасы.
Рушания. Юк инде. Моңны тотмыйча беркая да китү юк.

Өйләренә кереп китәләр. Тау астыннан Миңҗиһан белән Айгөл күренәләр.

Миңҗиһан. Кызым, бу галәмәт синең аркаңда. Мөкаддәснең җаны синең үзенә кияүгә чыкмаганын кичерә алмый. Иртәгә үк шәһәргә күчеп китәбез.
Айгөл. Юк, әни, мин китә алмыйм. Минем күземнән йокы качты. Күзем йомсам, колагымда Мөкаддәснең гармун моңы. Мин аны да, ул моңны да ташлап китә алмыйм.

Өйләренә кереп китәләр. Тау астыннан Сәрмәдия белән Мөслих Мөслимович күтәреләләр.

Сәрмәдия. Мөслих Мөслимович, буаны иртәгә үк җибәр. Мөкаддәснең гәүдәсе җир куенына кермичә, ул безгә, авыл халкына тынычлык бирмәячәк.
Мөслих Мөслимович. Нәрсә?! Мөкаддәснең башы ике балык башына тормый. Буа төбендә целое состояние! Йөз дә егерме тугыз миллион алты йөз мең чиста табыш.
Кави карт. Ялгышасың! Мөкаддәснең моңын миллионнар белән генә чагыштырып булмый. Мөкаддәснең моңы бизмәнгә сыймый. Мөкаддәснең моңы — миллионлы халыкның моңы, милләт моңы!

Музыка. Ут сүнә.

*ИКЕНЧЕ КАРТИНА*

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Мөслих Мөслимович, урындыкларны тезеп, үз бүлмәсендә гырлый-гырлый йоклап ята. Бүлмәгә Асыл Шәмгунович килеп керә.

Асыл Шәмгунович. Да, күмәк хуҗалык чәчәк ата. Авыл хуҗасы йокы бүсә.

Асыл Шәмгунович радионы ача. Аннан сыздырып уйнаган гармун тавышы яңгырый. Мөслих Мөслимович сискәнеп сикереп тора да тәрәзәгә таба сикерә.

Асыл Шәмгунович. Стой! Кая барасың?!
Мөслих Мөслимович. Уф, куркудан җаным чыгып очты дип торам. Бу Мөкаддәснең гармун моңы инфаркт ясый бугай инде. Ярый әле сез икәнсез.
Асыл Шәмгунович. Моңнан куркырга калгач, димәк, кыйблаңны бутагансың булып чыга.
Мөслих Мөслимович. Минем кыйблам дөрес. Менә Мөкаддәс үз кыйбласын югалткан. *(Асыл Шәмгуновичка.)* Кая югалдыгыз сез? Самый кирәк чакта сез юк. Кичә төнлә безнең авылда целый кошмар булды. Мөкаддәс кайтты.
Асыл Шәмгунович. Кунаккамыни?

Мөслих Мөслимович. Коләсез. Юк, сез миннән көлмисез, сез бөтен авыл халкыннан коләсез. Без бүген төне буе авылыбыз белән, авылдан — буага, буадан авылга йөгереп, моң куып йөрдек.

Асыл Шәмгунович. Моңны куып буламыни аны?! Моң бит ул күзгә күренми, кулга алып тотып булмый, исе юк.

Мөслих Мөслимович. Колакка, колакка ишетелә.

Асыл Шәмгунович. Тоттыгызмы соң?

Мөслих Мөслимович. Тотарсың, бар. Буага гына төшеп җитәбез, моң юкка чыга. Моң да юк, Мөкаддәс тә юк.

Асыл Шәмгунович. Моңны аны колак белән генә тыңлап булмый, моңны аны күңел ишетергә тиеш. Шул вакытта гына моңны тотып була. Чын татар башка милләт моңын колагы белән ишетсә дә, күңеле белән кабул итә алмый. Чит милләт кешесе чын татар моңын ишетә, әмма үзенеке итә алмый, күңеле белән ишетми.

Мөслих Мөслимович. Сез акыллы инде, иптәш Асыл Шәмгунович. Сез бит философ. Ә мин простой кеше, минем образование техническое. Кая инде безгә сезгә җитәргә?

Асыл Шәмгунович. Йә, юньләп аңлат, нәрсә булды?

Мөслих Мөслимович. Кичә төнге икедә буа ягыннан Мөкаддәснең гармун тавышы яңгырады. Авылыбыз белән буага йөгереп төшеп киттек. Буага барып җитүебез булды, гармун моңы тынды.

Асыл Шәмгунович. Мөкаддәснең үзен күрмәдегезме?

Мөслих Мөслимович. Юк, күрмәдек. Ну шулай да басма яныннан нәрсәдер шап итеп суга сикерде. Су өсте дулкынланып, кайнап торды. Мөгаен, Мөкаддәс булгандыр ул.

Асыл Шәмгунович. Чыннан да гармун тавышы идеме?

Мөслих Мөслимович. Чәчрәп китим. Мин бит инде дивана түгел. Дөрес, моңны сезнең кебек күңелем белән кабул итмәсәм дә, колагым бераз гына булса да гармун тавышын аера.

Асыл Шәмгунович. Мөкаддәснең гармуны кая?

Мөслих Мөслимович. Өендәдер...

Асыл Шәмгунович. Өендәдер... Тикшерергә кирәк иде.

Мөслих Мөслимович. Мин бит тикшерүче, ягъни сезнең кебек следователь түгел. Кирәк бит. Шул башка килмәде.

Асыл Шәмгунович. Мә Мөкаддәс өенең ачкычын. Бар, кара әле, гармун өйдә микән? Өйдә булса, бирегә алып кил.

Мөслих Мөслимович. Юк инде, иптәш следователь, иптәш Асыл Шәмгунович, миннән булмый. Мин ул өйгә керә алмыйм.

Асыл Шәмгунович. Нигә?

Мөслих Мөслимович. Санкциям, ордерым юк.

Асыл Шәмгунович. Алайса бар, бөтен авыл халкын бирегә җый.

Мөслих Мөслимович. Менә монысын булдыра алам. Монысы минем эш. Хотя, анысына да ышандыра алмыйм. Безнең авыл халкы хәзер мәчеттән чыкмый. Чүгендер дә уталмый, сыерлар да савылмый. Целый анархия бездә хәзер.

Асыл Шәмгунович. Бар. «Милиция, следователь Асыл Шәмгунович чакыра» диген.

Мөслих Мөслимович. Мине тыңламыйлар. Шул сезне тыңлап килсәләр генә инде. Ярый, мин барып чакырып карыйм.

Мөслих Мөслимович чыгып китә. Кави карт керә.

Кави карт. Нихәл, энем? Рөхсәтме?

Асыл Шәмгунович. Рөхсәт, бабай, рөхсәт.

Кави карт. Майор иптәшне кем дип белик?

Асыл Шәмгунович *(кулын сузып).* Асыл Шәмгунович булам мин, бабай.

Кави карт. Ә мин — Кави карт.

Асыл Шәмгунович. Утырыгыз, Кави бабай.

Кави карт. Нәрсә дисең?

Асыл Шәмгунович. Ничә ел утырдыгыз димен?

Кави карт. Гомер буе утырдым дисәм, ялганчы булырмын.

Асыл Шәмгунович *(үз-үзенә).* Нинди авыл бу? Кайсысыннан сорама, барысы да утырган.

Кави карт. Үзең дә утыргансың инде.

Асыл Шәмгунович. Кем?! Минме?! Кайда? Кайчан? Нәрсәгә? Сез нәрсә, бабай?

Кави карт. Кем? Син! Кайда? Биредә! Кайчан? Бүген! Нәрсәгә? Әнә бит урындыкка утыргансың.

Асыл Шәмгунович. Шутник син, бабай. Юк, мин синнән, ничә ел утырдың, дип сорыйм?

Кави карт. Егерме ике ел ярым.

Асыл Шәмгунович. Егерме ике ел ярым...

Кави карт. Кеше ярты гомерен йоклап уздыра, диләр. Миңа туксан бер яшь. Яртысы кырык биш ярым була. Шул кырык биш ел ярымның яртысын кеше утырып уздыра, диләр. Кырык биш ярымны урталай бүл инде.

Асыл Шәмгунович. Шустряк син, бабай.

Кави карт. А ты как думал?! Мин өч ел немец лагеренда утырдым. Өч ел немец палачы миннән сорау алды. Лагерьдан качканым өчен, сәвит власте биш ел төрмәдә утыртты. Биш ел сәвит төрмәсендә утырганда, йөз дә биш НКВД следователе канымны эчте. Аннары җиде ел Колыма. Колымадагы следовательләрнең санын хәтерләмим. Син дә мине сорау алырга чакырткансыңдыр инде.

Асыл Шәмгунович. Авылыгызда кеше батып үлгәне сезгә мәгълүм инде.

Кави карт. Шаярма, энем! Моң батып үлми ул! Кемнең дә булса күңелендә саклана.

Асыл Шәмгунович. Ягъни мәсәлән...

Кави карт. Ягъни мәсәлән, менә сезнең күңелегездә.

Асыл Шәмгунович. Һични аңламыйм.

Кави карт. Аңлыйсың. Бу комы коелган картны алдыйм дип уйлыйсың. Син милиция дә, следователь дә түгел. Син...

Асыл Шәмгунович. Каян беләсең?

Кави карт. Мөкаддәснең Алабуга культпросвет училищесында бергә укыган дусты син.

Асыл Шәмгунович. Каян белдең, Кави бабай?

Кави карт. Син анда укыганда, милиция киеменнән милиционер булып театр уйнагансың. Ә ул карточка Мөкаддәстә саклана. Ә мине тормыш кешене бер күрүдә кем икәнен танырга өйрәтте.

Асыл Шәмгунович. Кави бабай, син инде...

Кави карт. Борчылма. Синең күңелең яхшы. Уйнагыз. Бу халыкка уйнап акыл кертеп булса, бик әйбәт булыр иде әле ул. Тәмам кыйблаларын югалтып баралар.

Асыл Шәмгунович. Кави бабай, әнә килеп җиттеләр. Зинһар өчен...

Кави карт. Да, энем, сиңа назад пути нет. Авыл халкы сизеп алса, үзеңне терeләй бәйләп буага салачак. Син инде уеныңны азагына кадәр уйнап бетер. Ярты юлда уеннан китү синең файдага түгел.

Асыл Шәмгунович. Аңлыйм, Кави бабай, аңлыйм. Зинһар, сатма!

Кави карт. Борчылма, Кави бабаңны дөнья ничек яшәргә кирәклекне өйрәтте.

Бүлмәгә Миңҗиһан, Айгөл, аның артыннан Сәрмәдия, Мөслих Мөслимович, Рушания, иң азактан ишекне тагын да киереп ачып, чалма-чапан, култык астына калын Коръән кыстырган, уң кулына дисбе тоткан Исбах керә.

Кави карт *(Исбахны күреп, шаркылдап көлә).* Монысы тагын нинди клоун?! Артист!

Асыл Шәмгунович. Гражданин Кави әфәнде!..

Кави карт. Булды, булды, бетте.

Исбах *(дисбесен уң кулында уйнатып, Кави картка).* Көлмә! Затсыз! Сиңа да күптәннән иманга килергә вакыт. Җәмәгать, бүтән мине биш вакыт намазымнан бүлдереп, бимазалап йөртмәгез!

Сәрмәдия *(Исбахка).* Харап икән. Юеш ыштаның кайчан кипте?

Кави карт. Ну молодец, Мөкаддәс! Исбах булып Исбахетдинне дә иманга китергәч, милләт яшәячәк.

Асыл Шәмгунович. Тавышны бетердек, иптәшләр! Нишлибез?!

Исбах. Китап мәетне җир өстендә яткыруны гөнаһка саный. Буаны җибәрәбез!

Мөслих Мөслимович. Җибәрми генә тор. Безнең гөнаһыбыз юк. Безнең мәет җир өстендә ятмый, су астында ята.

Миңҗиһан. Җибәрүен җибәрербез дә, син салган Мөслих җәтмәсенә уралып Мөкаддәс килеп чыкса, гөнаһысын кая куярсың?!

Исбах *(тамашачыга).* Төне буе тышка чыкмыйча, чиләккә утырып та яшәп булмый инде. *(Җыелган халыкка.)* Буаны җибәрергә!

Рушания. Дөрес Җибәрергә! Төнлә куркудан күзгә йокы керми.

Айгөл. Адәм баласын күпме су төбендә яткырырга була.

Миңҗиһан. Ул безгә рәнҗеп ята.

Кави карт. Ә мин җибәрү ягында түгел.

Мөслих Мөслимович. Җәмәгать, авылдашлар, акылыгызга килегез! Озакламый көз җитә. Алда минем зур планнарым бар. Балыктан йөз дә егерме тугыз миллион алты йөз мең чиста табыш алгач, мин үзебезнең күмәк хуҗалыкка инкубатор сатып алырга уйлыйм.

Исбах. Йә, йә... Чебеш үрчетергәме, әллә каз бәбкәсеме?

Мөслих Мөслимович. Син үзең чебеш. Чебеш, бәбкә үрчетеп кем баеган? Африкадан крокодил йомыркалары кайтартам.

Кави карт. Нәрсә, крокодил үрчетәбезмени? Исбах, завферма булып керәсеңме?

Сәрмәдия. Керми. Аңа бит көненә өч коры ыштан кирәк булачак.

Мөслих Мөслимович. Үзебезнең тегү комбинатын ачып җибәрәбез. Үзебез үрчеткән крокодиллар тиресеннән затлы портфельләр, бумажник, курткалар тегеп, аларны сатып миллиордер хуҗалык булабыз.

Сәрмәдия. Мөслих Мөслимович, крокодиллар күп ашый түгелме соң ул? Бер ашаганда, бер сыерны кабып йоталар, диләр бит аларны.

Рушания. Берәм-берәм үзебезне ашый башласалар?

Мөслих Мөслимович. Крокодил җүләр түгел ул. Озакламый бәяләр тагын артса, авылда крокодил ашарлык кешеләр калмый. Крокодил сөяккә ташланмый.

Исбах. Юк инде. Әле монда Мөкаддәстән шүрләп абзарга чыгарга куркып яшибез, буага төшеп, крокодил ашатыр хәлем юк.

Мөслих Мөслимович. Ярар. Сезнеңчә булсын. Крокодиллар күп ашый дисез инде. Ә елан йомыркасы ничек? Еланның бер грамм агуы фәлән доллар.

Кави карт. Елан шәп. Елан йомыркасы шәп!

Миңҗиһан. Кирәкми. Безнең үзебезнең авылда да еланнар күп. Чагарга гына торалар.

Сәрмәдия. Миңҗиһан апа, кемне күз алдында тотасың?

Миңжиһан. Сине! Син берүзең егерме биш кобрага торасың.

Мөслих Мөслимович. Авылдашлар, сүзне уенга бормыйк әле. Сүз бит серьезный. Елан ашарына үзенә-үзе таба. Кобра йомыркалары кайтартсак...

Сәрмәдия. Кайтартып азапланмагыз. Үзем салырмын. Буар еланныкын кайтартыгыз. Миңҗиһан апаның комы коелып бара. Ул барыбер күкәй салалмый.

Рушания. Әллә син, Мөслих Мөслимович, дивана инде. Районда кемнеңдер авызыннан «Сезнең авылда Карпов Еланти Крокодилович эшлиме әле?» дип сорагач, аптырап калган идем, менә кем икән ул Карпов Еланти Крокодилович. Сез инде йә буаны җибәрәсез, йә булмаса, безнең авылдан үкчәләрегезне күтәрәсез!

Кави карт. Кызмагыз әле, кызмагыз, авылдашлар! Кеше бит безнең өчен тырышып йөри. Әйтегез әле, иптәш следователь, майор милиции, буаны җибәрәбезме, әллә юкмы?

Асыл Шәмгунович. Юк, җибәрмибез. Ышаныгыз миңа, иптәшләр, без озакламый финалга җитәбез. Мин сезгә Мөкаддәсне дә, моңыбызны да кайтарырга сүз бирәм.

Урамда гармун тавышы яңгырый.

Исбах. Таптың атаңның баш сөяген. Әнә үзе килә. Мөкаддәс үзе килә.

Исбах өстәл астына кереп кача. Бүлмәдәгеләр кайсы кая акырыша-бакырыша качалар.

Кави карт. Исбахетдин, Исбахетдин, өстәл астыннан чык инде. Алай-болай куркудан йөрәгебез шартлап, үлеп-нитеп китсәк, ясин чыгарсың.

Исбах *(өстәл астыннан башын гына чыгарып).* Булмый, тәһарәтем бозылды.

Асыл Шәмгунович. Иптәшләр, әйдәгез, күмәк көч белән моңны тотарга! Алга! Тау астына — буага!

Ут сүнә.

*БЕРЕНЧЕ КАРТИНА*

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, барысы да шау-гөр килеп сәхнәгә чыгалар. Асыл Шәмгуновичның кулында Мөкаддәс гармуны.

Кави карт. Гармун авылда. Йә, нишлибез инде, милиция майоры, следователь иптәш, Асыл Шәмгунович?

Асыл Шәмгунович. Аптыраган. Авылда тагын кемдә гармун бар?

Исбах. Авылда гына түгел, тирә-якта юк.

Мөслих Мөслимович. Менә сиңа әкәмәт. Гармун биредә, ә тау астыннан — буадан — һәр төн моң агыла.

Шул вакыт тау астыннан — буадан — моң агыла.

Исбах. Моң! Тау астыннан, буадан моң килә!

Рушания. Көпә-көндез!

Айгөл. Бу бит минем Мөкаддәсемнең гармун чыңы!

Рушания. Саташма! Әнә бит синең Мөкаддәсеңнең гармуны следователь кулында.

Мөслих Мөслимович. Җәмәгать, авылдашлар, карагыз әле, буага йөгерә-йөгерә авыл көтүе төшә. *(Гармун тавышына сыерлар мөгрәгән, сарыклар бәәлдәгән тавышлар кушыла.)* Әнә, әнә, Рушания, сезнең мүкләгегез арт аякларына баскан да бии.

Рушания *(көтү ягына карап)*. Кая, кая? Әллә саташасыңмы? Үгез сорый бит ул.

Исбах. Юк, карчык, ул бии.

Рушания *(Исбахның колагына пышылдап).* Тик кенә тор, дурак! Мөслихнең һәр сүзендә мәкер. Иртәгә үк, сыерыгыз котырган, дип, районга илтеп сата ул аны.

Исбах. Юк, юк, Мөслих туган. Ул инде бер атнадан бирле үгез сорый. Мин үзем дә, сыерым да бии белми.

Мөслих Мөслимович. Шулай дисеңме?! Күзгә әллә нәрсәләр күренә башлады инде.

Миңҗиһан. Алай димәгез әле сез. Сыер, сарыклар белән әллә нәрсәләр булды. Как моң ишетелә, минем абзардагы кәҗәм җырлый башлый.

Исбах. Минекеләр тыныч. Алланың биргәненә шөкер, тыныч. Шулай бит, әнисе Рушания?

Рушания. Шулай, шулай.

Мөслих Мөслимович. Авылыгызны җенле урынга салгансыз. Исән чакта уңышны гына җыеп алам да бу авылдан үкчәләремне күтәрәм.

Исбах. Күптән вакыт. Авылга син хуҗа булып килгәч, шушы галәмәт башланды.

Миңҗиһан. Барысына да син гаепле. Буаны җибәрткән булсаң, бу хәл килеп чыкмый иде.

Исбах. Сөйлисе юк. Мөкаддәсне табып, җирләп, поминкасын, өчесен, җидесен үткәреп, инде рәхәтләнеп кырыгына әзерләнә идек.

Кави карт. Соң, авылдашлар, төнлә караңгыда моңны да, Мөкаддәсне дә тота алмадык, йокымсырап тормыйк, аек акыл, аек баш белән көпә-көндез моңны тотар чак җитте, нәрсә карап торабыз, әйдәгез тау астына — буага, моңны тотарга!

Мөслих Мөслимович. Дөрес, Кави бабай, дөрес! Әйдәгез, авылдашлар!

Исбах. Көндез була, көндез мин курыкмыйм, бугазыннан алам.

Миңҗиһан. Әйдәгез, җәмәгать!

Исбах. Алга, Мөкаддәсне тотарга!

Сәрмәдия. Җитте! Бу моңга чик куярга вакыт җитте.

Асыл Шәмгунович. Әйдәгез, иптәшләр! *(Кабурасыннан пистолетын ала да күккә ата.)* Мин анымы, мин аны йә атам, йә тотам!

Барысы да йөгерә-йөгерә тау астына төшеп китәләр. Сәхнәдә Кави карт берьялгызы басып кала.

Кави карт. Әй бичаралар! Әллә бу милициясе дә, то есть артисты да, үз ялганына үзе ышана башлады инде. Мылтык атып, пистон шартлатып, моң тотмакчы булалар. Күңелдән качкан моңны тотарсың, бар. *(Гармунны кулына ала.)* Әй гармун, гармун... Синең көчне болар аңламый шул. Һәр халыкның үз моңы, үз көе, үз кыйбласы барын аңламыйлар. Ә син менә шушында гына, шушы бүкән өстендә утыр. Үз эшеңне эшлә. *(Гармунны бүкән өстенә куя.)* Ә мин алар янына төшим. Безгә әлегә бергә булырга ярамый. Алла сакласын. Моңын оныткан халык теләсә нәрсәгә бара. Аңа ата-баба да, нәсел дә, милләт тә, дин дә, ден дә, кыйбла да юк! Икебезне дә Мөкаддәс янына буага салмасыннар. Ә син үз эшеңне эшлә. Син генә минем халкымны саклап калаласың.

Тау астына төшеп китә. Бераздан авылда гармун тавышы ишетелә. Барысы да сәхнәгә чыгалар.

Мөслих Мөслимович *(елап).* Менә, иптәш следователь, Асыл Шәмгунович, хәзер үзегез свидетель. Озакламый бер ай була бит, бер ай! Бөтен авылыбыз белән буадан — авылга, авылдан буага йөгереп йөри торгач, өч пар аяк киеме туздырдык. Әле генә биредә — авыл турысыннан гармун тавышы ишетелә иде, менеп кенә җиттек, моң юкка чыкты. Авыл халкы буаның теге ягына чыгарга курка.

Сәрмәдия. Күрше авыллар безнең авылга килмәс булдылар.

Айгөл. Безнең авыл кешеләренә шикләнеп карыйлар. Җенлеләр авылы, диләр.

Миңҗиһан. Болай булса, кызларыбызга кияүләр, егетләребезгә киленнәр чыкмас.

Асыл Шәмгунович. Ә гармун биредә.

Кави карт. Гармун үз эшен эшли, иптәш следователь.

Рушания. Нишлибез, авылдашлар?

Исбах. Әйе, нишлибез?

Мөслих Мөслимович. Кадалып китсен буасы, суын җибәрәм.

Асыл Шәмгунович. Юк, кирәкми. Минем планым бар.

Кави карт. Сөйлә! Сөйлә! Синең планың миңа ошый.

Асыл Шәмгунович. Икегә бүленәбез! Авылның ярты халкы буаны, ә яртысы авылны саклый.

Исбах. Төнлә дәме?

Асыл Шәмгунович. Төнлә дә!
Исбах. Мин буага төшмим!
Асыл Шәмгунович. Нигә?
Исбах. Мине көзән җыера.
Асыл Шәмгунович. Мин бит сиңа буага төшеп утыр димим. Суга кермәссең.
Исбах. Су читендә, ярда басып торсам да җыера. Мин хатыным белән авылны саклыйм.
Сәрмәдия. Курка ул!
Исбах. Минме?
Мөслих Мөслимович. Әйе, син!
Исбах. Буаңны үзең сакла. Сиңа балык җене кагылган. Минем өчен авыл кадерле.
Асыл Шәмгунович. Кемнәр тау астына — буага төшә?
Сәрмәдия. Мин төшәм. Командировочный түләнәме?
Мөслих Мөслимович. Юк. Син бит авылдан чыгып китмисең!
Сәрмәдия. Сверхурочный түләнәме?
Мөслих Мөслимович. Юк!
Сәрмәдия. Нигә?
Мөслих Мөслимович. Син бит минем эшемне эшләмисең.
Сәрмәдия. Ә мин нишлим соң?
Кави карт. Моңны тотасың!
Сәрмәдия. Юк инде, Россия закунында, конституциядә язылган...
Мөслих Мөслимович. Син закунны беләсеңме соң?
Сәрмәдия. Мин белмәсәм, әнә закун кешесе, милиция майоры — следователь Асыл Шәмгунович белә. Әйтегез әле, закун кешесе, Россия закунында нинди юллар бар?
Асыл Шәмгунович. Конституциядә язылган, Россия гражданнары тәүлеккә сигез генә сәгать эшләргә тиешләр, диелгән.
Сәрмәдия. Ә сез мине ничә сәгатькә җибәрәсез? Суткага!
Исбах. Әйтмә әле шул сутка дигән сүзеңне. Район искә төшә. Егерме дүрт сәгать, диген.
Сәрмәдия. Әнә Исбах сутканың нәрсә икәнен белә. Мин төнге уникедән соң өемә кайтам икән, миңа командировочный һәм квартирный, гостиничный түләнергә тиеш.
Мөслих Мөслимович. Ярар инде, ярар, синеңчә булсын. Ике кешегә бер ярты исәбеннән куярмын.
Исбах. Мин дә буага төшәм!
Рушания. Төшәрмен мин сиңа. Биш вакыт намазың кая?! Кинәт буа янында гармун тавышы ишетелсә, нишлисең?! Белеп тор, юеш чалбарың белән йоклатам мин сине идәндә! Хатын-кызлар, без — буага, ә сез, ирләр, авылда каласыз.
Исбах. Ә командировочный?..
Мөслих Мөслимович. Сез авылда каласыз, сезгә не положено!
Асыл Шәмгунович. Сөйләштек. Буа янындагы хатын-кызлар армиясе белән син, Мөслих Мөслимович, авылдагы ирләр армиясе белән үзем идарә итәм. Ә хәзер барыгызга да әзерләнергә унбиш минут вакыт бирәм.
Барысы бергә. Авылдашлар, коралланырга!
Асыл Шәмгунович. Отставить! Моң тотарга корал белән бармыйлар.
Кави карт. Моң тотарга ачык күңел, саф йөрәк белән баралар.

Барысы да өйләренә таба китәләр. Сәхнәдә Мөслих Мөслимович белән Асыл Шәмгунович кына калалар. Мөслих Мөслимович пожарный так-
тасына ап-ак зур кәгазь беркетә.

Асыл Шәмгунович *(кәгазьгә сызып)*. Менә монда авыл. Минем оборона сызыгы. Ә биредә тау асты — буа — синең фронт линиясе, Мөслих Мөслимович. Әгәр синдә моң барлыкка килсә, без сиңа ярдәмгә киләбез, әгәр миндә — авылда моң туса, сез безгә ярдәмгә ашыгасыз! Килештекме?
Мөслих Мөслимович. Килештек. Әмма ләкин, Асыл Шәмгунович, безгә нинди дә булса условный знак уйлап табарга кирәк.
Асыл Шәмгунович. Атаңның баш баласы! Аңгыра! Әллә син армиядә хезмәт итмәдеңме?! Моң... Моң нәрсә соң ул?! Моң үзе шул условный знак бит инде ул, тити баш!

Сәхнәгә, төенчек, мендәр, юрган күтәреп, хатын-кызлар чыга.

Мөслих Мөслимович *(хатын-кызларга)*. Молодцы! А зори здесь тихие! Строится! Смирно! Направо! Шагом марш! Запевай!

Хатын-кызлар, җырлый-җырлый, тау астына төшеп китәләр.

Барысы бергә.

Дошманга каршы сугышка
Мөслих чакырган безне.
Без хатыннар яуга киттек
Сакларга буабызны.

Асыл Шәмгунович. Строится!

Сәхнәгә Кави карт белән Исбах керәләр. Алар үрә басалар.

Асыл Шәмгунович. Смирно! Равня-ясь! *(Башларын уң якка боралар.)* Вольно! Задание вакытында тартмаска, эчмәскә, сөйләшмәскә, йокламаска!

Исбах *(Кави картка пышылдап).* Авылдан хатын-кызлар фронтка чыгып киткәч, күңел тулды, ямансу булып калды.

Кави карт. Сөйлисе юк. Исән генә кайта күрсеннәр инде.

Асыл Шәмгунович. Отставить! Разговорчики!

Исбах. Бигрәк усал командир булып чыкты бу. Галәмәт кылана.

Кави карт. Сөйлисе юк. Культпросвет училищесын бетергән дип уйламассың!

Асыл Шәмгунович. Лежать!

Кави карт белән Исбах сузылып яталар.

Асыл Шәмгунович. Противник сезне күрергә тиеш түгел. *(Кесә телефоныннан номер җыя да колагына куя.)* Алло, алло, бу синме? Сиңа төшеп киттеләр. Әзер тор. Таң ата башлагач, эңгер-меңгердә, атыңа атланып, гармуныңны тартып, тегеләр өстенә һөҗүмгә!

Исбах. Нинди ат, нинди һөҗүм турында сөйли ул?

Кави карт. Шаулама инде! Тс-с! Әллә син армиядә хезмәт итмәдеңме?

Исбах. Бүсер белән кем мине армиягә алсын. Миндә бүсер бит. Тумыштан.

Кави карт. Командирларның сүзен тыңларга ярамый!

Асыл Шәмгунович *(телефонга).* Пока! *(Телефонын кесәсенә салып куя.)* Шушында гына ятыгыз! Кузгала күрмәгез! Башыгызны күтәрә күрмәгез! Противник Мөкаддәс үзегезне күрә күрмәсен. Ә мин, Исбах иптәш, сезгә кереп бераз гына черем итеп алам.

Исбах. Ә без нәрсә, шушында төне буе ятабызмыни?..

Асыл Шәмгунович. Прекратить разговорчики рядовой Исбахетдин... То есть мичман Исбахетдин...

Асыл Шәмгунович гармунны култык астына кыстыра да кереп китә.

Кави карт *(пышылдап).* Тик кенә ят инде, иптәш мичман! Командирга каршы әйтергә ярамый.

Исбах. Нәрсә?! Шулай таңга кадәр урам уртасында ятабызмыни?

Кави карт. Нишлисең. Важное задание! Моңны, Мөкаддәсне тотабыз. Кызык булып китте. Яшь чаклар, сугыш вакытлары искә төште. Вәт сиңа артист!

Исбах. Кемне әйтәсең, кем артист?!

Кави карт. Командирны әйтәм.

Исбах. Артист түгел, фашист ул! Бүсерле кешене урам уртасына, салкын җиргә сузып салып, үзе минем йомшак түшәккә йокы симертергә кереп китте.

Икесе дә яткан җирләреннән торып утыралар.

Кави карт. Нишлисең, укыган халык — чукынган халык. Кирәк булса — командир, кирәк икән — профессор, кирәк икән космонавт була ала. Профессия! Килештерсә дә килештерер икән. Коеп куйган милиция, следователь...

Исбах. Өстәвенә командир! Барысына да Мөкаддәс гаепле.

Кави карт. Нигә?

Исбах. Бер ай ята. Су өстенә чыгарга тиеш иде инде.

Кави карт. Мөкаддәс үте сытыла торганнардан түгел.

Исбах. Безне кызганырга тиештер бит инде ул. Бөтен авылыбызны үтләтеп бетерде бит.

Кави карт. Кадерен белергә кирәк иде. Тирә-якның бердәнбер сандугачының кадерен белергә. Ну егет икән!

Исбах. Торасың да, «Ну егет икән!» дисең, торасың да, «Ну егет икән!» дигән буласың, моның белән нәрсә аңлатмакчы буласыңдыр инде?

Кави карт. Моны аңлар өчен чит-ят җирләрдә кагылып-сугылып, туган җиреңне сагынып яшәргә кирәк. Моны аңлар өчен, халкыңның зурлыгын күрер өчен, читкә китеп ерактан карарга кирәк...

Исбах. Кави бабай, әнә таң да сызылып килә, җиргә чык та төшә башлады, әйдә шыпырт кына өйгә кереп ятабыз.

Кави карт. Чыннан да! Минем инде яшем дә шактый, мин керим әле.

Исбах. Ә мин?..

Кави карт. Син каласың инде. Синең фатирдан командир штаб ясады бит.
Исбах. Анысы бар бит әле, каһәр!

Шул вакыт, тыныч һаваны ярып, ат кешнәгән тавышлар килә.
Гармун тавышы, хатын-кызларның шау-шуы ишетелә.

Кави карт. Ложись! К оборону!

Икесе дә җиргә сузылып яталар.

Исбах *(пышылдап).* Кави бабай, командирга хәбәр итәргә кирәк, безнекеләр авылга чигенәләр бугай.
Кави карт. Бар, хәбәр ит!
Исбах. Булмый, минем тәһарәтем бозылды.
Кави карт. Сизәм. Алайса, читкәрәк китеп ят.

Исбах белән Кави карт торып басалар.

Исбах *(пышылдап)*. Иптәш командир, иптәш командир, торыгыз, тор, эшләр харап!
Асыл Шәмгунович *(эченнән генә).* Тик кенә ятыгыз! Мин оборонада, мин сезне прикрою!

Абына-сөртенә, сулышларына буыла-буыла, иң беренче Мөслих Мөслимович, аның артыннан берәм-берәм хатын-кызлар сәхнәгә керәләр.

Мөслих Мөслимович. Ике тинтәк, нишләп ятасыз?! Кая командирыгыз?!
Исбах. Йоклый, йокы бүсә, сволочь! Минем ястыкта!
Мөслих Мөслимович. Бетте, бетте баш! Мөкаддәс, Мөкаддәс менә!
Кави карт. Ничек Мөкаддәс менә?..
Сәрмәдия. Атка атланып...
Рушания. Гармун тартып...
Миңҗиһан. Үзе уйный...
Мөслих Мөслимович. Үзе җырлый... Буаны җибәрегез, җибәрегез, зинһар өчен, җибәрегез!
Исбах. Җен, җен ул, Мөкаддәс түгел! Качыгыз, кач, авылдашлар!

Барысы да өйләренә кереп качмакчы булалар. Исбахның капкасы ачылып китә. Капкадан, гармунын тартып, моңлы көй сызып, Асыл
Шәмгунович килеп чыга.

Исбах. Җен! Тагын бер җен!
Мөкаддәс *(сәхнә артыннан).* Тр-р, малкай!

Ат туктаган тавыш ишетелә. Сәхнәгә, гармун тартып, Мөкаддәс керә.
Авыл халкы сәхнә уртасында әрле-бирле йөренә.

Мөкаддәс. Исәнмесез, авылдашлар!
Барысы бергә. Син кем?
Мөкаддәс. Мин — моң!
Барысы бергә. Ә Мөкаддәс?..
Мөкаддәс. Мин үлдем.
Барысы бергә. Ә моң?
Асыл Шәмгунович. Моң мәңгелек!
Кави карт. Кеше китә, моңы, җыры кала.
Кабатланмас изге эше кала.
Асыл Шәмгунович. Кемдер туа галәм биләр өчен,
Океаннарны гизәр өчен!
Кави карт. Кемдер сабан сөреп, икмәк игәр өчен туа. Шул халыкны милләт итәр өчен, бик сирәкләр мәңге үлмәс «Саз»лы, моңлы итә.

Мөкаддәс белән Асыл Шәмгунович бергә гармунда уйный башлыйлар.

Пәрдә.
*2008*

# ТАШ САНДЫК

*Сатирик комедия ике пәрдәдә, сигез күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Мөстәкыйм — Йосыф белән Нуркасыймның
бертуган кече энеләре.
Нуркасыйм — Мөстәкыймнең олы абыйсы.
Миңлениса — Нуркасыймның хатыны.
Йосыф — Мөстәкыймнең кече абыйсы.
Суфия — Йосыфның хатыны.
Касыйм Сабирханович.
Вил Вилданович.
Сан Санович.
Гали Вәлиевич — галим.
Вәли Галиевич — галим.
Сәли Садриевич — галим.
Александр Александрович.
1 нче милиционер.
2 нче милиционер.
1 нче санэпидстанция кешесе.
2 нче санэпидстанция кешесе.
Ак халатлы кыз.
Егет.
1 нче илче.
2 нче илче.
3 нче илче.
Биюче кызлар.

Күмәк күренешләрдә шәһәр халкы һәм кунаклар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, Мөстәкыйм фатирының ярлы гына җиһазландырылган бер бүлмәсе. Аш-су әзерли торган урыны булганга күрә, Мөстәкыйм аны ике бүлмәле дип әйтергә дә күп сорап тормый. Гадәттәгечә, уртада — өстәл, берничә урындык, мәче тырнагыннан көч-хәл белән генә исән калган, кыршылган диван һәм башка җиһазлар. Мөстәкыйм махмырдан диванда гырлап йоклап ята. Бүлмәгә, ашыгып, Касыйм Сабирханович, аның артыннан Вил Вилдано-
вич, Ак халатлы кыз, ике милиционер керә.

Касыйм Сабирханович (*сәгатенә карап*). Сезгә унбиш минут вакыт. (*Мөстәкыймгә төртеп.*) Бу имгәкне тиз арада рәткә китерегез. Кырындырыгыз, юындырыгыз, киендерегез, бу дуңгыз абзарын рәткә кертегез!

1 нче милиционер
2 нче милиционер (*үрә катып*). Есть! Иптәш
Касыйм Сабирханович!

Мөстәкыймне ике яктан эләктереп алалар да ванна бүлмәсенә өстерәп алып кереп китәләр. Алар артыннан Ак халатлы кыз да кереп китә.

Вил Вилданович. Органнарда егерме биш ел эшләп, һич кенә дә башыма сыймый, гарәп илчеләре ни өчен бу фатирда очрашуны кулайрак күрделәр икән?!

Касыйм Сабирханович. Үзем дә аптырыйм. Ныклабрак кара әле, Вил Вилданович, адресны бутамадыгызмы?

Вил Вилданович (*папкасыннан кәгазь чыгарып*). Менә, минем күзләремә ышанмасагыз, үзегез укып карагыз. (*Кәгазьне Касыйм Сабирхановичка суза.)*

Касыйм Сабирханович (*укый*). Шулай шул. Казан каласы, Яңа бистә, Татарлар Шатлыгы урамы, җиденче фатир, Мөстәкыйм әфәнде Исхак улы фатиры. Гарәбстаннан диелгән.

Вил Вилданович. Шәехкә бу сасы көзән нигә кирәк булган?

Касыйм Сабирханович. Йоклыйсыз, иптәш Вил Вилданович, йоклыйсыз. Ярты сәгатьтән Гарәп самолеты Казан аэропортына килеп төшә. Ә сез Гарәп илчеләренең ни өчен килгәннәрен дә белмисез. Сагынам теге заманнарны, ай, сагынам. (*Кесә телефоныннан номер җыя.)* Әй сез, кая олактыгыз? Тизрәк булыгыз! Вакыт кыса. Нәрсә?! Ишек төбендә пычак калганмыни сезгә. Бирегә керегез! Нәрсә?.. Кертмиләр?.. Кемнәр?.. Мәскәүлеләр?! Бишенче отдел? (*Вил Вилдановичка.*) Нәрсә, мәскәүлеләр килеп тә җиттеләрмени?

Вил Вилданович. Һичнишләп булмый. Без Мәскәү контролендә.

Касыйм Сабирханович *(телефонын Вил Вилдановичка сузып*). Мә, имгәк, мәскәүлеләргә әйт, минем кешеләремне кертсеннәр.

Вил Вилданович *(телефоннан*). Алло, алло... Трубканы мәскәүлеләргә бир! Нәрсә, нәрсә... Миңгерәү дим! Трубканы мәскәүлеләргә бир, аңгыра! Алло... Алло, пятыймы? Пятый отделмы дим?..

Нәрсә?.. Что?! Кто?! Телевидениенең беренче каналы журналисты Василий Николаевич?.. (*Трубканы ала.*) Василий Николаевич, ди.

Касыйм Сабирханович. Төкерәм мин синең Василий Николаевичыңа. Тизрәк минекеләр керсеннәр!

Вил Вилданович (*трубкага*). Төкерәм мин аңа. (*Аңына килеп.*) Не тебе, не тебе... (*Трубкасын колагыннан алып.)* Үтерәләр болар мине. (*Трубканы уч төбе белән каплап, пышылдап.)* Мәскәү телевидениесенең беренче каналы, ди.

Касыйм Сабирханович. Миңа синең беренче каналың кирәкми! Миңа менә шушы эт оясын рәткә салыр өчен, санэпидстанция хезмәткәрләре кирәк. Күземә күренмә! Бер аягың — биредә, икенче аягың беренче катта булсын.

Вил Вилданович (*үрә катып*). Есть! ( *Ашыга-ашыга чыгып китә.)*

Касыйм Сабирханович (*бүлмә буйлап йөренә*). Ни өчен?! Кемгә кемгә, Гарәп иленә нигә кирәк булган бу фатир? Бу сәрхуш Мөстәкыйм белән Гарәп иле арасында нәрсә ята?

Бүлмәгә саклану костюмнарыннан, сиптерә торган аппаратлар күтәреп, авызларына респираторлар кигән ике кеше керәләр дә бүлмәдәге һәрнәрсәгә пар җибәрәләр. Берсе Касыйм Сабирханович янына килә
һәм аңа да пар җибәрә.

Касыйм Сабирханович. Нишлисең, имгәк?

1 нче санэпидстанция кешесе. Сезне стерилизовать итәм.

Касыйм Сабирханович. Итәрмен мин сиңа, имгәк! Ычкын янымнан. (*Үз-үзенә мыгырданып.*) Каян башларына килә?!

1 нче санэпидстанция кешесе. Сарымсак төнәтмәсе сибүме?! Безнең башка каян килсен инде. Хуҗа, хуҗа башлы безнең.

2 нче санэпидстанция кешесе. Беренче кварталда химикатларны сатып бетерә дә...

1 нче санэпидстанция кешесе. Калган өч кварталга сарымсак суы гына кала.

2 нче санэпидстанция кешесе. Сез әле бәхетле. Сезгә чистотел төнәтмәсе эләкмәде.

1 нче санэпидстанция кешесе. Анысын атна буе мунча кереп тә тәннән юып бетереп булмый.

Касыйм Сабирханович. Хуҗагызга кайтып әйтегез, Касыйм Сабирханович «Өчегезне дә мунчага алып кереп стерилизовать итәм» диде, диегез. Гарәпләр генә китсен әле...

1 нче санэпидстанция кешесе.

2 нче санэпидстанция кешесе. Яхшы.

Чыгып китәләр. Сәхнәгә эт талаган кыяфәттә Йосыф һәм чалма-
чапаннан Нуркасыйм керә.

Нуркасыйм. Бу татарга бер җирдә дә рәт юк. Үз туганыңа да керер хәл юк. Прямо өзгәлиләр. (*Үзенең тышкы кыяфәтенә карап.)* Кара инде! Кара, адәм мәсхәрәсе!

Касыйм Сабирханович. Нәрсә булды? Гарәп илчеләре янына бу кыяфәттә разве киләләр?!

Йосыф (*кулын сузып*). О-о... Исәнмесез, Касыйм Сабирханович! Исән калу шатлыгыннан сезне күрми дә торам. Өзгәлиләр прямо. Журналистлар ишек төбен камап алганнар, бер алга, бер артка төшәләр. Бер төймәмне дә калдырмадылар.

Касыйм Сабирханович. Кемгә кемгә, сезгә, Иосиф Исакович, мондый кыяфәттә йөрү килешми. (*Бүлмәгә күрсәтеп.*) Энегезнең яшәү рәвешен карагыз. Дуңгыз абзарында яшәтәсез түгелме?!

Йосыф. Әйтмәгез инде, Касыйм Сабирханович, әйтмәгез. Үзе дә дуңгыз, яшәеше дә дуңгызныкы кебек. Аттан ала да туа, кола да туа икән. Югыйсә бер ата, бер ана балалары инде. Бер авызына хуҗа була алмады. Юк, юньгә килми.

Касыйм Сабирханович. Димәк, тәрбия җитми. Димәк, тәрбияләү системагыз дөрес түгел.

Йосыф. Ничә тапкыр эшкә урнаштырып карадык. Өч көн эшкә чыга да дөреслек эзли башлый. Дүртенче көнне куалар.

Касыйм Сабирханович. Дөреслек эзли дисең инде...

Йосыф. Һәрнәрсәдән кер эзли.

Нуркасыйм. Өйләндермәкче булып та карадык. Бай, уңган, булган гаиләдән кыз да димләп карадык. Бай булса, ничек баеган, ди, хәерче булса, нишләп хәерче, ди.

Касыйм Сабирханович. Ярый, мин сезнең зарларыгызны тыңларга килмәдем. Үз кайгым да баштан ашкан. Менә моннан! *(Тамак астын күрсәтеп.)* Муеннан! Нигә соңга каласыз?! Нигә көттерәсез?!

Йосыф. Гафу итегез, Касыйм Сабирханович, безнең килгәнгә ике сәгатьтән артты инде. Кертмиләр бит, кертмиләр.

Нуркасыйм. Прямо өзгәлиләр.

Касыйм Сабирханович. Нигә чакыртканымны беләсезме?!

Нуркасыйм.

Йосыф. Юк, белмибез.

Касыйм Сабирханович. Белмисез шул. Менә мин дә белмим. Дөреслек эзләргә ярата дисез инде...
Йосыф. Не то слово...
Нуркасыйм. Киребеткән, үҗәт!
Касыйм Сабирханович. Аның янына хәзер биш минуттан Гарәп илчеләре килә.
Нуркасыйм. Гарәп илчеләре?..
Йосыф. Гарәп илчеләренә Мөстәкыймнең нигә керәге чыккан?
Касыйм Сабирханович. Менә анысын сездән сорарга кирәк инде.

Вил Вилданович керә.

Вил Вилданович. Касыйм Сабирханович, төрле каналлар буенча, аралашкан кешеләрен тикшереп чыктык, Гарәбстаннан бер кеше белән дә аралашмаган.
Касыйм Сабирханович. Менә шулай, Иосиф Исакович, сезнең эшләр бик харап.
Вил Вилданович. Сезнең нәселегез белән Мәскәүнең бишенче отделы кызыксына. Төрле илләрдән журналистлар, репортерлар килгән.
Касыйм Сабирханович. Шулай, Иосиф Исакович, җиденче бабагызны исегезгә төшерә башласагыз да була.
Вил Вилданович. Кем сез?.. Атагыз кем булган?.. Бабагыз?.. Уйлагыз, уйла! Вакыт бик кыска.
Касыйм Сабирханович. Өч катлы коттеджыгызны ничек салдыгыз?!
Вил Вилданович. «Мерседес»ыгызны, хатыныгызның «БМВ» сын ничек алдыгыз? Башка җирдәге байлыкларыгызны искә төшерегез.
Касыйм Сабирханович. Чит илләрдәге связьләрегезне...
Вил Вилданович. Бигрәк тә Гарәп илләрендәге элемтәләрегезне...
Касыйм Сабирханович. Сезнең чын исемегез ничек әле, Йосыфмы?
Йосыф. Туган илемне, хөкүмәтемне, тынычлыгымны, илемдәге тәртипне саклаучы милиция органнары аша кабат-кабат тикшерелеп бирелгән төп документымда — паспортымда — мин Йосыф түгел, ә киресенчә, Иосиф. Телисез икән, Осип дип дәшә аласыз, телегезгә җиңел дип санийсыз икән, Хосе дия аласыз. Әмма ләкин мин, Россия гражданины буларак, чын исемемне горурланып Иосиф дип кабатлап әйтәм. Отчествома килгәндә, Исхак түгел, Исак. Минем Исхак улы Мөстәкыйм атлы кеше белән берниндИ дә туганлык җебем юк.
Вил Вилданович. Бәлки, сез үз-үзегезгә уйлап тапкан исем-отчествогыз ширмадыр. Бәлки, Гарәп иле белән сезнең күперне Мөстәкыйм атлы энегез тоташтырып торадыр?!
Йосыф. Кабатлап әйтәм, минем Мөстәкыйм атлы энем юк. Минем Гарәп илләренә чыкканым юк. (*Нуркасыймга төртеп күрсәтеп.*) Менә бу чалма-чапаннан киенгән иптәштән сорагыз. Ул Хаҗны бик ярата. Исеме дә Нуркасыйм, атасы да Исхак бугай. Ул Гарәп илләрен бик ярата.
Нуркасыйм. Бу җөмләне миңа адреслап бик ялгышасың, кем, энем Йосыф. Аталар өчен балалар җавап бирми. Татарда Исхаклар күп. Аннары, күреп торасың, Мөстәкыйм белән минем арада охшашлык юк. Ул чандыр, мин... Ул хәмер ярата, ә мин терпеть не могу.

Урамда сирена тавышлары ишетелә.

Касыйм Сабирханович. Булды! Булды, җитте! Хватит! Разберемся! Килеп җиттеләр бугай. Үз-үзегезне тәртипкә китерегез! (*Юыну бүлмәсенә карап кычкыра.*) Әй сез, кая олактыгыз?! Җәһәтрәк булыгыз! Тизрәк чыгыгыз! Килеп җиттеләр.

Юыну бүлмәсеннән ике размерга зуррак костюм-чалбар кигән, муенына зур галстук таккан, зур туфлидән Мөстәкыйм, аның артыннан уң кулына сөлге аскан, сул кулына сиптерә торган грушалы одеколон
тоткан Ак халатлы кыз, ике милиционер чыгалар.

Ак халатлы кыз. Касыйм Сабирханович, объект әзер! Трусигына кадәр алыштырдык. Носки алып килергә генә оныткангбыз. (*Мөстәкыймнең бөтен җиренә одеколон сиптерә.)*
Мөстәкыйм. Носки булмаса да зыян юк. Чалбар озын, носки барыбер күренми.
Касыйм Сабирханович. Нәрсә бу?!
Мөстәкыйм. Нәрсә түгел, иптәш! Мин бу, мин — Мөстәкыйм!
Касыйм Сабирханович. Нәрсә соң бу?! Нинди чучело, бакча карачкысы?!
Мөстәкыйм. Гаепләмә инде. Бар булганым шушы. Әткәй белән әнкәй ат чырайлы итеп яраткач, нишлим. Матурлыкны сорап алып булмый. Бар булганыма шөкер кылып яшим.
Касыйм Сабирханович. Хикмәт синең ат чырайлы булуыңда түгел, хикмәт син кигән киемдә.
Ак халатлы кыз. Гафу итегез, Касыйм Сабирханович, сезнең ярдәмчеләрегез биргән размер буенча киендердек. Монда минем гаебем юк.
Касыйм Сабирханович (*Вил Вилдановичка*). Син нәрсә карадың?!
Вил Вилданович. Сез җибәргән карточка буенча, компьютер аша киендереп карап, размерын билгеләдек.

Касыйм Сабирханович. Размерын?.. Күзең чыкканмыни, дүрт размер зуррак костюм кидергәнсез!

Вил Вилданович. Гафу итегез, Касыйм Сабирханович, менә сезнең безгә җибәргән аның сурәте, ягъни карточкасы.

Касыйм Сабирханович. Сезнең — безгә, безнең — сезгә. (*Карточканы карап.*) Бу бит бу кеше түгел. (*Карточканы Йосыфка сузып.)*

Йосыф (*карточканы карап*). Юк, юк, ул түгел, Касыйм Сабирханович.

Нуркасыйм. Кая, карыйм әле?! (*Карточканы карый.*) Юк, ул түгел, Касыйм Сабирханович.

Мөстәкыйм (*карточканы алып*). Кая, үзем карыйм әле?! Мин бу, мин булмый кем булсын. Шешенкерәлгән, шешенгән килеш төшкәнмен. Но мин үзем тормышта болай ук түгел, вак сөякле мин.

Касыйм Сабирханович (*кесә телефоны шылтырый. Телефонны колагына куя).* Әйе. Тыңлыйм. Күтәреләләр?! Яхшы. (*Телефонын кесәсенә сала. Вил Вилдановичка.)* Бар, каршы ал. Күтәреләләр.

Вил Вилданович (ч*есть бирә дә чыгып китәргә җыена*). Тукта әле, ашыкма! (*Нуркасыйм белән Йосыфка.*) Сезнең хатыннарыгыз кая?

Нуркасыйм.

Йосыф. Урамда. Безне көтәләр.

Касыйм Сабирханович. Урамда? Алар биредә булырга тиеш! (*Вил Вилдановичка.*) Тизрәк хатыннарын тап та бирегә кертеп җибәр.

Вил Вилданович. Икесенекен дәме?

Касыйм Сабирханович. Юк, өчесенекен дә. Аңгыра!

Вил Вилданович. Яхшы!

Касыйм Сабирханович. Өч минуттан алып кермәсәң, погоннарыңны кертеп минем өстәлгә сал!

Вил Вилданович *(үрә катып*). Есть! (*Чыгып китә.*)

Касыйм Сабирханович (*Нуркасыйм белән Йосыфка*). Сез үзегезне тәртипкә китерегез дә тезелеп басыгыз! Ә бу карачкының җиңнәрен, чалбар балакларын бераз сызгандырыгыз!

Мөстәкыйм. Кирәкми, иптәш, кирәкми! Борчылмагыз! Ике сәгатькә генә түзәм. Ике сәгатьтән барыбер сез аны миннән салдырып аласыз.

Касыйм Сабирханович. Илчеләр китеп, исән генә калыйм, костюмыңны гына түгел, бер кат тиреңне салдырам әле мин синең. Барыгыз да әзерме?!

Йосыф. Әзер!

Нуркасыйм. Әзер, Касыйм Сабирханович!

Бүлмәгә зәвык белән киенгән Йосыфның хатыны Суфия һәм алтмышның теге ягындагы Нуркасыйм хатыны Миңлениса керәләр.

Касыйм Сабирханович. Сез кая йөрисез?!

Миңлениса. Урам чатында.

Касыйм Сабирханович. Алтмышка җиткәч, тапкансың урам чаты.

Суфия (*арт санын уйнатып, Касыйм Сабирханович янына килә дә үбәргә кулын суза).* Исәнмесез, Касыйм Сабирханович! Хәлләрегез ничек?

Касыйм Сабирханович ( *дорфа гына итеп*). Ару! Сафка бас!

Барысы да тезелеп, сул порталга басалар. Салих Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы» яңгырый. Ишек ачыла. Бүлмәгә гарәпләр киеменнән өч илче килеп керәләр. Аларның берсенең кулында — таш сандык, икенчесенең кулында — йомарлап төрелгән васыятьнамә. Алар уртасында озын гәүдәле, ап-ак сакаллы өченче илче. Керәләр дә сул порталга басалар. Гарәбстан гимны башкарыла. Илчеләрнең башлары югары күтәрелә. Гимн тәмамлануга, Татарстан гимны яңгырый башлый. Сул порталдагыларның башлары күтәрелә. Гимн тәмамлануга,
илчеләр, кулларын күкрәкләренә куеп, башларын түбән ияләр.

1 нче илче

2 нче илче

3 нче илче *(барысы бергә).* Әссәламегаләйкем!

Барысы бергә (*иелә төшеп*). Вәгаләйкемәссәлам!

3 нче илче. Исхакның углы Мөстәкыйм биредә яшиме?

Барысы бергә. Биредә яши, биредә. Менә ул.

3 нче илче, васыятьнамәне сораган рәвеш ясап, уң кулын суза.

2 нче илче (*васыятьнамәне аның кулына бирә*). Рәхим итегез! (*Уң кулын күкрәгенә куйган килеш иелә төшеп, артка чигенә.)*

3 нче илче. Хөрмәтле Исхак углы Мөстәкыйм галиҗәнап!

Мөстәкыйм. Галиҗәнап ук булмасак та, атам Исхак кушкан Мөстәкыйм исемем бар анысы.

1 нче илче (*васыятьнамәне укый башлый*). «Исәнме, минем нәсел җебемне, нәсел шәҗәрәмне дәвам итүче ерак, ерак туганым, төпчек углым! Гасыр, еллардан соң син минем телемне дә, шушы таш сандыкны ачып, минем әманәтемне укып, сандык эчендәге мирасымны кабул итәрлек хәлдә

булырсыңмы? Әгәр булсаң, кем син? Татармы, әллә... әллә үзеңә башка исем алдыңмы? Борынгы бабаңның юлын дәвам итәсеңме?.. Дәүләтлеме син?.. Әллә дәүләтсезме? Миннән калган шушы нәсел сандыгын кабул итеп алып, мине куандырырлык хәлдәме син? Мин бу таш сандыкны син яшәгән чордан мең ел элек, буш җиргә килеп сез яшәргә хаклы булган, борынгы бабаларның җиренә казан асар өчен казык каккан көннең шул ук айлы төнендә, ай яктысында да ташка уеп үз мирасымны, нәсел мирасын калдырам. Мин синең исемеңне дә, кем атлы икәнеңне дә белмим. Шуңа күрә дә бу сандыкны нәселемне дәвам итүче ир-ат затыннан булган төпчек тараныма, ягъни сиңа калдырам. Синнән гайре бу сандыкка һичкемнең дә орынырга хакы юк! Бу сандыкны ачарга син генә хаклы. Әгәр бу сандык ачылганчы синең белән ул бу хәл булса, сандык эчендәге мирас үз көчен югалтачак. Мин, ягъни Казан каласына беренче казык каккан хан бабаң, Казан каласына мең ел тулганнан соң, бу сандык сезнең кулга килеп эләккән җәйнең соңгы көннәрендә, халкым бәйрәм иткән айлы төндә, ай яктысында, ай мин каккан казыкның очына эленгәч кенә, син бу сандыкны ача аласың. Әгәр ки син сандыкны ачканда, ай казыкка чәнти бармакның бер буыны кадәр генә килеп җитешмәсә йә узып китсә, сандык эчендәге мирас үз көчен югалта».

2 нче илче. Көчен югалтачак.

1 нче илче. Чәнти бармакның бер буыны кадәр генә...

2 нче илче. Килеп җитмәсә...

1 нче илче. Йә узып китсә...

2 нче илче. Ай казыкка эленгәч кенә...

3 нче илче. Бары тик син генә...

1 нче илче. Ханның ир токымыннан булган иң соңгы буыны гына.

Йосыф (*күршеләреннән пышылдап сорый*). Ир токымыннан булган иң соңгы буын гына диме?

2 нче илче. Сандык синең кулга килеп эләккән елның утызынчы августындагы айлы төндә генә.

3 нче илче. Бары тик син генә, төпчек оныгы гына...

Йосыф. Төпчек оныгы дисез инде...

3 нче илче (*сандыкны тоткан илчедән аны ала да Мөстәкыймгә суза).* Рәхим итегез! Борынгы хан бабагызның мирас сандыгын кабул итеп алыгыз!

Мөстәкыйм (*кулларын сузып.*) Рәхмәт сезгә!

Йосыф. Чү, кагылма! Калтыраган кулларың белән хан бабабызның нәсел мирасын харап итәсең. Үзем алам.

Нуркасыйм. Сабыр, сабыр, Иосиф энем!

Мөстәкыйм (*сандыкны кулына ала. Аннан күзен ала алмыйча).* Таш сандык!.. Баш сандык!.. Хан сандыгы!.. Нәсел сандыгы!.. Бабам сандыгы!..

Көй яңгырый. Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Нуркасыйм, Йосыф, Суфия, Миңлениса, Касыйм Сабирханович пыр тузып сугышалар. Нуркасыйм өстенә Йосыф менеп атланган, Суфия өстендә Миңлениса. Касыйм Сабирханович диван арасына кысылган, ике аягы гына күренеп тора.

Касыйм Сабирханович (*аякларын болгый-болгый*). Коткарыгыз, коткарыгыз, үләм... Муеным кысылып калды.

Миңлениса (*Суфияга*). Беттеңме, себерке! Чәйнәп өзимме үзеңне!

Суфия. Төш, төш өстән, убырлы карчык, юкса күрмәгәнеңне күрсәтәм!

Нуркасыйм (*өстендә утырган Йосыфка*). Беттеңме, беттеңме? Шул кирәк сиңа, гәвнә!

Миңлениса. Нуркасыйм, Нуркасыйм, чалып ташлыйммы бу үләксәне?

Нуркасыйм. Кирәген бир! Күрмәгәнен күрсәт!

Касыйм Сабирханович. Коткарыгыз, коткарыгыз, тыным бетте!

Миңлениса (*Суфия өстеннән тора да Касыйм Сабирхановичның аягыннан өстерәп чыгара).* Тор, үләксә! Диван ярыгыннан чыгалмый. Корсак үстергән булган. (*Касыймның изүеннән сөйрәп торгыза да яңагына сугып җибәрә, тегесе диванга ава.)* Бар, корсаклы ата чыпчык!.. Иркенләп диванда җан бир.

Йосыф (*Нуркасыймга*). Хәзер борыныңны кысып җаныңны чыгарыйммы?!

Миңлениса (*кулларын бөеренә куйган хәлдә Йосыфка*). Әле син шулай... (*Күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстыра да, кулларына төкереп.*) Мин синеме, мин сине хәзер бастырыклыйм. (*Нуркасыйм өстеннән Йосыфны өстерәп төшерә һәм өстенә менеп атлана. Нуркасыймга Суфияны төртеп күрсәтеп.)* Бар, теге чебешнең өстенә менеп кунакла. Аңа синең көчең җитә. Җаны чыксын, тыны бетсен, ике күзе борынына килсен.

Суфия (*яткан урыныннан сикереп тора да*). Аһ, сез шулай... (*Нуркасыймга сугып җибәрә.*) Мә, получай, гад! (*Нуркасыйм ишек белән бергә коридорга чыгып оча.)* Буталып йөрмә.

Ишек катында ике милиционер пәйда була. 1 нче милиционер сыбызгы кычкырта.

2 нче милиционер. Прекратите!

Касыйм Сабирханович (*елый-елый милиционерлар янына үрмәләп килә дә).* Кая йөрисез сез?! Иртәгә үк икегезне дә уволю. Хуҗагыз, капкынга кысылган тычкан кебек, диван арасында җан бирә, сезгә хоть бы хны. Хәзер үк барысын да камерага озатыгыз!

1 нче милиционер.

2 нче милиционер. Есть, Касыйм Сабирхано-
вич!

Икесе ике яктан килеп Миңленисаны эләктереп алалар.

Миңлениса. Ах, сез шулай!

Ике милиционерны якаларыннан тотып чәкештерә. Тегеләр идәнгә егылалар.

Касыйм Сабирханович. Бетерде, бетерде милиционерларымны, үтерде.

1 нче милиционер (*яткан килеш*). Борчылмагыз, Касыйм Сабирханович, борчылмагыз, тиз генә безне бетерә алмый әле ул!

2 нче милиционер. Бераз гына хәл алабыз да, Касыйм Сабирханович, аннары тәртипкә салабыз!

Касыйм Сабирханович *(Миңлениса өстенә килә башлый*). Мин синеме, мин сине... Мин сине подсуд җибәрәм!

Миңлениса (*Касыйм Сабирхановичның борын астына йодрыгын куя*). Тик кенә тор. Маңгаеңа тартырмын, җилегең атылып чыгар. Кара моны! Өстәл сугып өйрәнгән.

Касыйм Сабирханович. Молчу! Теләсә нәрсә эшләгез, бүтән арагызга керсәмме?! Тик шуны белегез, хан сандыгы, хан мирасы сезнең генә гаиләнеке түгел. Дәүләт байлыгы, татар мирасы! (*Милиционерлар аңгыраеп урыннарыннан торалар да Касыйм Сабирханович каршысына киләләр.*)

1 нче милиционер. Касыйм Сабирханович, барысын да илтеп ябыйкмы?

Касыйм Сабирханович. Исән калуыгызга шатланып, тыныч кына торыгыз.

1 нче милиционер. Балаларыбыз бәхетеннән инде, балаларыбыз бәхетеннән, Касыйм Сабирханович!

Йосыф. Менә шул. Бабам сандыгындагы мирас — минеке. Буш сандыгы синеке, Нуркасыйм туганым, дәү абый!

Нуркасыйм. Тоттырган диярләр!

Суфия. Дөрес, безнеке! Әткәй белән әнкәйне без җирләдек. Әнкәй белән әткәйгә чардуганны, кабер ташын без куйдык. Нәсел турында гел без кайгырттык.

Йосыф. Шулай булгач, нәсел мирасы безгә.

Касыйм Сабирханович. Туктагыз әле, туктагыз! Мирас сезнеке дә түгел, Нуркасыйм Исхаковичныкы да түгел. Мирас — милләтнеке!

Нуркасыйм. Дөрес! Мин килешәм. Мирас — милләтнеке! Ә безнең Йосыф — маңкорт. Ул үзе теләп Иосифка әйләнде. Паспортын карагыз.

Йосыф. Паспорт?.. Паспорт нәрсә ул. Паспорт ул — кәгазь. Минем татарлык менә монда! Душада!

Касыйм Сабирханович. Туктагыз әле, җәмәгать, туктагыз, сез бит бер ата, бер ана балалары!

Нуркасыйм. Сез нәрсә сөйлисез? Нинди бер ана, бер ата. Аның атасы — Исак, минем атам — Исхак.

Касыйм Сабирханович. Тынычланыгыз, иптәшләр, тынычланыгыз! Бүгенге көндә безнең милләтне бөтен дөнья халкы күзәтә. Күрмисезмени?! Шәһәребезне бөтен дөнья журналистлары, репортерлар камап алган. Безгә бүген аеруча бердәм булырга кирәк. Ә сез үзара бер фикергә килә алмыйсыз. Безгә төп мәсьәләгә күчәргә кирәк. Төптәнрәк уйлыйк. Ярар, хан сандыгын ышанып Мөстәкыймгә калдырыйк ди. Кая гарантия?!

Суфия. Анысы хак, сатып эчә ул аны.

Касыйм Сабирханович. Эш аңа ук барып җитмәс җитүен. Сандык җиде кат сак астына куелды.

Йосыф. Сатып эчмәсә, вакытыннан алда ачып, сандык эчендәге мирасны юкка чыгарачак.

Касыйм Сабирханович. Тирәнрәк уйлап карыйк әле, иптәшләр, тирәнрәк. Милләт язмышы безнең кулда. Нәселегездә иң төпчек ир бала Мөстәкыйм микән? Бәлки, мирас сандыгының төп хуҗасы башка кешедер?!

Нуркасыйм. Ягъни мәсәлән?..

Касыйм Сабирханович. Ягъни мәсәлән... Тормыштагы кайбер ялгышларыбыз милләтебез өчен, киресенчә, яхшылык булып кайтмый микән? Соңгы халык санын алуны гына искә төшерик.

Йосыф. Постой, постой... Уйланырлык урын бар монда. Чыннан да, тирәнрәк уйласаң, бәлки, хан мирасы, бабайның мирасы минем читтә адашып йөргән берәр улымныкыдыр...

Суфия. Нәрсә?! Берәр улымныкы дисеңме?! Аһ син, бабник, сволочь! Читтә әле син уйнаш итеп йөрдеңмени?! (*Өстенә килә башлый.)*

Йосыф. Чү, чү, Софочка, нишләвең бу?! Мин бит уйнап кына. Аллам сакласын! Юк, Мөстәкыймнән гайре нәселебездә хан мирасына ия булырдай ир-ат затыннан башка туганыбыз юк.

Суфия. Шулай дип котыл.

Нуркасыйм. Ашыкмагыз әле, минем өчен дә җавап бирмәгез. Бәлки, минем яктан бардыр.

Миңлениса. Дөрес, этисе. Уйлап кара әле, синең яктан юк микән.

Нуркасыйм. Мин соңгы вакытларда кай якларда булдым әле, әнисе?

Миңлениса. Син, этисе, соңгы вакытларда кай якларда булгансыңдыр, анысын хәтерләмим, но шунысын яхшы хәтерлим, миңа өйләнеп бер ай торгач, Волков урамындагы урологический больницада операция ясатканыңны гомер буе сизеп яшәдем.

Нуркасыйм. Юк, юк, безнең нәселдә Мөстәкыйм энекәштән гайре хан сандыгына хуҗа булырдай бүтән туганыбыз юк.

Касыйм Сабирханович. Ныклап уйладыгызмы?

Суфия. Безнең яктан, хатын-кыз ягыннан булса ярамыймы?

Йосыф. Юк, ярамый. Хатын-кыз ягыннан ярамый. Сез хан нәселеннән түгел.

Касыйм Сабирханович. Димәк, сандыкның төп хуҗасы Мөстәкыйм.

Йосыф. Туктагыз! Башка бер уй килде. Бу бәладән сезне без генә коткара алабыз. Шулай бит, әнисе Софочка?

Суфия. Ничек?

Йосыф. Малай алып кайтабыз.

Миңлениса. Ике ай эчендәме?

Йосыф. Нигә ике ай эчендә...

Нуркасыйм. Сандыкны ачарга ике ай калып бара.

Йосыф. Булмады. Бер татар арттырмакчы идек, барып чыкмады.

Касыйм Сабирханович. Иптәшләр! Әгәр без милләтебез язмышы турында уйлыйбыз икән, Мөстәкыйм әфәндене күз карасы урынына сакларга тиешбез!

Йосыф. Нәрсә?! Мин хәзер, бөтен эшемне ташлап, исерекбаш Мөстәкыймне саклап утырырга тиеш буламмыни?

Нуркасыйм. Юк инде, җәмәгать, миннән булмый. Намазлык җәярлек тә чиста урыны булмаган шакшы, сәрхуш Мөстәкыйм фатирында биш вакыт намазымны өзеп, Ходай алдында үземә гөнаһ җыеп вакытымны әрәм итәсем юк. Минем көн дә мәчеткә барасым бар.

Вил Вилданович. Сез сакламасагыз, үзем саклармын!

Касыйм Сабирханович. Мөстәкыйм кебек асыл татар егетләре теләсә кайда аунап ятмый. Мөстәкыйм әфәндегә без чебен дә кундырмаска тиешбез. Мөстәкыйм әфәндегә сабый җиле дә тиярга тиеш түгел.

Суфия. Дөрес, Касыйм Сабирханович! Үзем, үзем саклармын. Төннәрендә яныннан бер секундка да китмәм. Шулай бит, этисе?

Миңлениса. Хыялларың тормышка ашмас. Йокы бүсәргә яратасың. Үзем саклармын. Мин инде төннәрен мәет сакларга күнеккән.

Йосыф. Тукта әле, нишләп әле син минем бертуган энем Мөстәкыймне мәет белән тиңлисең? Нәрсә, синеңчә, ханның нәселе өзелгән, соңгы буынын мәет димәкче буласыңмы?! Касыйм Сабирханович, ишеттегезме? Нәрсә ди?.. Мәет, ди. Бу бит зур хата.

Суфия. Политическая хата.

Нуркасыйм. Ярый, ярый, җитте. Күпертмәгез. Сүзне икенчегә бормагыз.

Йосыф. Ишетәсезме? Алар бердәм эшлиләр. Алар татар милләтенең тамырын балта белән чабалар. (*Күкрәгенә сугып.*) Бабам хакына, нәселебез хакына, милләтебез хакына барысын да эшлим. Кирәк икән үземне дә, кирәк булса, хәләл хатынымны да корбан итәм!

Касыйм Сабирханович.
Вил Вилданович. Дөрес, Иосиф Исакович! Дөрес!

Йосыф *(елаган кыяфәттә).* Белә идем бит, сизә идем бит, тоя идем затлы кан, хан каны акканын.

Ут сүнә. Музыка.

*ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ*

Ут янганда, иркен зур зал. Бүлмәләргә чыга торган берничә ишек. Зал уртасында — тумбочка өстендә — пыяла аквариум эчендә таш сандык. Ул дүрт яктан прожектор белән яктыртылган. Залның стенасы тирәли урындыклар тезелгән. Сандыкның бер ягында — Нуркасыйм, икенче ягында, йокымсырап, урындыкта мылтык тотып,
Йосыф утыра.

Йосыф (*авызын зур итеп ачып).* Төне озын булды.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк.

Йосыф. Бу мәет саклаган әбиләргә Ходай ярдәм бирсен.

Нуркасыйм. Аның бернәрсәсе дә юк. Алар бит гайбәт сатып утыра.

Йосыф. Анысын син беләсең инде. Ни әйтсәң дә, егерме ел дин юлында йөрисең.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк. Егерме ел намазлык өстендә утырып, исерекбаш Мөстәкыймне саклап утыр инде.

Йосыф. Тәһарәтсез намазлыкка менмиләр аны.

Нуркасыйм. Менә анысын синнән сорамыйлар, кем, энем, Осип.

Йосыф. Мин Осип түгел. Аңлыйсыңмы, Осип түгел. Минем атам кушкан исемем бар. Мин— Йосыф!

Нуркасыйм. Нигә? Син бит үз теләгең белән паспортыңны алыштырдың. Элек Йосыф идең, хәзер Иосиф. Элек Йосыф Исхакович идең. Хәзер Иосиф Исакович.

Йосыф. Кабатлап әйтәм, мин Осип та, Иосиф та түгел, мин — Йосыф!

Нуркасыйм. Әйттем исә кайттым. Әле бер ай элек кенә, Йосыф дисәң, якага ябыша идең.

Йосыф. Заманасы үзгә иде.

Нуркасыйм (*кашынып алганнан соң*). Их, бер мунча керәсе иде ул.

Йосыф. Сөйлисе юк.

Нуркасыйм. Айдан артык утырабызмы?

Йосыф. Бүген ай да унҗиде көн була. Бетләп бетмәсәк ярый.

Нуркасыйм. Августның утызына кадәр күп калдымы әле?

Йосыф. Кул бармаклары гына түгел, аяк бармаклары да җитми.

Нуркасыйм. Айдан артык намазлыкка басканым юк.

Йосыф. Басып та азапланма. Укыганнарың барыбер Ходайга барып ирешми.

Нуркасыйм. Нигә алай уйлыйсың?

Йосыф. Уйламыйм. Беләм.

Нуркасыйм. Каян беләсең?!

Йосыф. Әнә Мөстәкыйм укымады да, аңа Ходай йомшак түшәк бирде. Ә сиңа каты урындык.

Нуркасыйм. Шулай дисеңме?

Йосыф. Шулай димен.

Нуркасыйм. Сөйлисе юк. Хатыныңны аяк очына салып гомер кичерә. Ә бит нинди заманалар бар иде.

Йосыф. Ничего, бер айлык уразаның барыбер гаете була.

Нуркасыйм. Ярый да бит мирастан өлеш чыгарса.

Йосыф. Өч югары белемле дипломың була торып, шул исерекбашны саклап утыр инде. Адәм көлкесе.

Нуркасыйм. Шатыр-шотыр кашынып диген.

Йосыф. Ничего, утызы гына җитсен.

Нуркасыйм. Нишләмәкче буласың?

Йосыф. Үз өлешемне генә алыйм, икегезнең берегезгә дә әйләнеп карамыйм.

Нуркасыйм. Әле син өлеш өмет итәсеңмени?!

Йосыф. Нигә итмәскә?! Мин дә бит ул ханның оныгы.

Нуркасыйм. Осип Исаковичмы?

Йосыф. Осип түгел мин. Аңлыйсыңмы, аңгыра! Осип түгел, Йосыф мин! Алла тарафыннан өстәлгән дигән төшенчәне аңлата. Күркәмлек, гүзәллек иясе. Легендар Йосыф!

Нуркасыйм. Белмим шул. Әткәй белән әнкәй ризалыгыннан башка Иосифка әйләнгән кешегә хан бабабыз сандык эченә берәр генә карамель булса да салды микән?!

Йосыф. Анысы өчен борчылма. Син үзең турында уйла, үзең турында!

Нуркасыйм. Минем уйлыйсым юк. Мин Ходай юлында. Ходай барысын да күрә.

Йосыф. Шулайдыр шул. Әйтәм җирле, төннәр буе агач мылтыгыңны кочаклап, прожектор яктысында, исерек, сәрхуш Мөстәкыймне саклап утырасың.

Нуркасыйм. Шулай, энем. Джузеппеме әле син? Ә, әйе, Хосе, то есть Осип Исакович, мин Мөстәкыймне саклап утырмыйм. Мөстәкыймне син сакла. Мин таш сандык саклыйм. Мирас саклыйм. Ә инде ул таш сандык эчендәге хан бабабызның мирасыннан сиңа ноль. Мирасның яртысы — Мөстәкыймнеке, яртысы үзебезнеке дип торабыз.

Йосыф. Бик жирный булмасмы? Үтләрсең. Әткәй белән әнкәйнең кер бавына кадәр даулап алган бәндә бит син.

Нуркасыйм. Кем? Минме?!

Йосыф. Нигә?.. Кер каптырмасын сорап өйгә ничә тапкыр килдең?

Нуркасыйм. Әкиятеңне кайтып хатыныңа сөйлә. Син аларның башына җиттең. Син, син, Осип энем! Шәһәрдән зуррак фатир алыр өчен, әткәй белән әнкәйнең йортларын саттырып, Казанга алып киттең дә аннары үзләренә вокзалдан, урамнардан буш шешә җыйдырдың.

Йосыф. Син сүзеңне чамалап сөйлә. Дәү абый дип тормам, ипи шүрлегеңә менеп төшәргә дә күп сорамам.

Нуркасыйм (*утырган җиреннән сикереп тора*). Мендергән диярләр! Менәрсең син минем ипи шүрлегенә. Ничек төшкәнеңне дә сизми калырсың. Мин сиңа Мөстәкыйм түгел. Эчеңне тишеп агызырга да күп сорамам.

Йосыф *(әтәчләнеп, Нуркасыйм өстенә килә*). Попробуй! Өтәчке! Койрыксыз әтәч, тәһарәтсез мулла калдыгы! Сине белмиләр ди. Кеше алдап, байлык туплап, шул акчага ел саен диңгез буена барып, яшь кызлар сатып алып, яшь кызларны бозып йөргәнеңне...

Нуркасыйм. Докажи!

Йосыф. Кирәк булса, докажем!

Нуркасыйм. Нәрсә?! Ялган диплом сатып алып түрә булдыңмыни?.. Мин синең белемеңне беләм. Әлифне таяктан аера алмаган аңгыра сарык, дундук бит син!

Йосыф. Ах, син шулай... (*Нуркасыймны якасыннан эләктереп ала.)* Мә, получай, гад! Мә, паразит! Мә, фиргавен токымы! Ал үзеңә тиешлесен. *(Сугыша башлыйлар.)*

Нуркасыйм. Барыбер мирасның яртысы минеке, яртысы Мөстәкыймнеке.

Йосыф. Шулаймы? (*Башы белән Нуркасыймның йөзенә тарта.*) Мә мирасның яртысын! (*Тагы башы белән бирә.)* Мә мирасның тиешле өлешен! (*Тагы сугып җибәрә.*) Мә мирасны бөтен килеш. Күңелең булдымы?! (*Тагын суга.*) Мә, получай, гад!

Нуркасыйм. Үтерәләр!.. Коткарыгыз!.. Каравыл!..

Югарыдан тавыш ишетелә.

Микрофоннан. Әй сез, фиргавен токымнары! *(Йосыф белән Нуркасыйм тынып калалар.*) Молчать! (Икесе дә *үрә каталар.*) Хуҗага йокларга ирек бирмисез! Бытла!

Нуркасыйм (*пышылдап, Йосыфка.*) Нәрсә ди?

Йосыф. Бетле, ди!

Нуркасыйм. Бардыр инде, ике айга якын мунча кергән юк бит.

Микрофоннан. Разговорчики!

Йосыф
Нуркасыйм (*честь бирәләр*). Есть!

Микрофоннан. Иртәгә үк икегезне дә уволю!

Йосыф
Нуркасыйм *(икесе ике якка югарыга, почмакка карап тезләнәләр. Кулларын ияк астына куеп*). Не надо!.. Не надо!.. Мы больше так не будем...

Микрофоннан. Вольно!

Йосыф
Нуркасыйм *(тезләнгән килеш честь бирәләр).*
Есть!

Микрофоннан. По местам!

Йосыф
Нуркасыйм *(сикереп торалар да, үрә катып, честь бирәләр).* Есть!

Йосыф *(үз-үзенә мыгырданып*). Шушы почмактагы глазокны уйлап тапкан инженерның күзләрен чокып алыр идем!

Нуркасыйм. Ярый әле аннан күзәтеп торалар. Юкса үтерәсең син мине. Валлаһи, үтерәсең. Иртәгә үк аппарат җитәкчеләренә жалоба язам.

Йосыф (*үз-үзенә сөйләнеп*). Тырный тагын. Биткә сикерә. Чалып ташланган көзге әтәчмени! (*Нуркасыймга.*) Яз! Син гомер буе жалоба язган кеше, ананимчик!

Нуркасыйм. Үзеңне бел, аңгыра баш! Жалоба язарга да грамота кирәк. Кояш дигән сүздә биш хата ясап, жалоба язып булмый ул.

Йосыф. Кем?! Минме?.. Әллә саташа башладыңмы, тинтәк?

Нуркасыйм. К, ы, и краткий, я, а, ш, мягкий знак! Син язганча — кояш.

Микрофоннан. Җиттеме сезгә, юкмы? Иртәгә үк икегезне дә уволю. Почетлы каравылга куйганга рәхмәт юк, сугышалар тагын. Шатланыгыз! Халык, милләт мирасын саклыйсыз. Сөенегез!

Нуркасыйм *(ялагайланып*). Ай рәхмәт, ай рәхмәт! Сәламәт булыгыз!

Йосыф. Бетерәм мин бу почмактагы глазокларны. Шартлатам, кибини матери! (*Мылтыгын почмакка төзи*.)

Нуркасыйм (*аның аяк астына тезләнеп, кулларын аңа суза*). Чү, энекәш, кирәкми... Икебезне дә харап итәсең... Мирассыз калдырасың. Акылыңа кил.

Йосыф (*мылтыгын төшерә*). Өелеп торган байлыгым була торып, шушы каһәр суккан таш сандык янында айлар буе йокысыз төннәр уздыр инде.

Нуркасыйм. Уздырма. Кем сине мәҗбүр итә. Кайт та йокла!

Йосыф (*Нуркасыйм булып*). Кем сине мәҗбүр итә... (*Паузадан соң. Ишеккә бармагы белән төртеп.*) Син һәм ул. Юк инде. Еллар буе утырсам утырам, китмим. Икегез генә бүләр идегез бугай.

Эчке бүлмәдән Суфияның чыркылдаган тавышы ишетелә.

Нуркасыйм (*авызын зур итеп ачып, иснәнеп*). Уяндылар бугай.

Йосыф (*ул да авызын зур итеп ачып, иснәнеп*). Ниһаять, тагын таң атты. (*Тагын чыркылдашу ишетелә. Йосыф, сискәнеп.)* Бар әле, бар, кара. Нишлиләр анда?..

Нуркасыйм. Үзең кара. Сиңа кирәк, ни әйтсәң дә, синең хәләл хатының Софочкаң түгелме соң анда?!

Йосыф. Кызлар сорады бит.

Нуркасыйм. Сораса, артык юмартланмаска иде. Хатын тикле хатыныңны бирмиләр аны. Хотя энекәшкә, Мөстәкыймгә жәл түгел дигәнсеңдер инде.

Йосыф. Көлмә. Кая барасың?! Яшь кызлар сорады бит. Кертеп кара син аның янына чит кызлар. Беләм мин ул хәзерге яшь кызларны. Аларга Мөстәкыйм кирәкми, аларга хан сандыгы, таш сандык, мирас сандыгы кирәк. Төн чыкканчы ун тапкыр кияүгә чыгып, ун тапкыр загска алып баралар алар. Аннары көтеп утыр. Хан сандыгыннан миңа да өлеш чыгар дип. Болай, ичмаса, ышанычлы.

Нуркасыйм. Үз хатыным дисең инде.

Йосыф. Кая барасың. Түзәсең. (*Чыркылдашкан аваз янә кабатлана. Йосыф түзми, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлый. Нуркасыймга.)* Бау бир, асылынам! Бар инде, кара, нишлиләр?

Нуркасыйм (*ипләп кенә, тавыш килгән бүлмәнең бераз гына ишеген ачып, ярыктан карый*). Булдыра Мөстәкыйм энекәш!

Йосыф. Нишли?

Нуркасыйм. Нишли, нишли?! Бар да кара!

Йосыф. Йә, әйт инде, нишлиләр?

Нуркасыйм. Нишләсеннәр... Мөстәкыйм аркасына массаж ясата.

Йосыф. Ходай бар икән. Ныклап карадыңмы, массаж гынамы?

Нуркасыйм. Массаж гына булмый. Син, энекәш, бигрәк. Как будто син Мөстәкыймне белмисең.

Йосыф. Ышан. Абый хатыны, җиңги дип тормас.

Нуркасыйм. Мин Мөстәкыйм энекәшкә ышанам. Менә синең хатының Софочкаңа гына шигем зур.

Йосыф. Ул Софочка түгел, ул — Суфия. Аңлыйсыңмы, Суфия!

Нуркасыйм. Аңлыйм, аңлыйм, энекәш! Бүген ул Суфия, иртәгә — Софочка, берсекөнгә — Сонечка.

Сәхнәгә чәче-башы тузган кыяфәттә Суфия килеп чыга.

Суфия (*дорфа гына*). Җитте, хватит миннән. Башка булдыра алмыйм!

Йосыф *(Суфия янына килә дә шикләнеп пышылдап).* Нәрсә? Издеваться итте, да?

Суфия. Сорыйсың тагын. Төне буе йоклатмады.

Йосыф. Сволочь! Түз, үз өлешебезне генә алыйк. Күрмәгәнен күрсәтәм әле мин аның. Төне буе азаплады дисең инде.

Суфия. Төне буе. Атна буе диген.

Йосыф. Нишлисең бит. Түзәргә туры килә, җаным. Хан байлыгыннан баш тартып булмый.

Суфия. Юк, башка түзә алмыйм. Хет ас, хет суй, башка түзә алмыйм. Адәм баласы бер сутка, ике сутка, конца да концов өч сутка йокламый түзә ала. Ә мин...

Йосыф. Түз, җаным, түз. Озак калмады. Озакламый ханбикә буласың.

Суфия. Ханбикә булганчы, үтерә әле ул мине.

Йосыф. Вот маньяк!

Суфия. Маньяк кынамы, зверь! Юкса бит аяк очына гына ятам. Тибә дә төшерә, тибә дә төшерә. Йокыга гына төнәрәм, тибә дә төшерә.

Йосыф. Тибә дә төшерә?

Суфия. Әйе, син нәрсә, мине кемгә саныйсың! Абый хатыны белән йоклап ятарга син мине кем дип уйлыйсың. Хан нәселенең оныгы Йосыфның хатыны булуыңны онытма. Безгә, хан нәселенә тап төшерергә ничек җөрьәт итәсең, ди. Булды, җитте, хватит! Бүген үк өйгә кайтып китәм. Әнә сменага Нуркасыйм хатыны Миңлениса калсын. (*Пыр тузып чыгып китә.)*

Йосыф (*артыннан кычкырып кала*). Суфия, Суфия, Софочка, нишләвең бу?!
Нуркасыйм (*шаркылдап көлеп*). Нәрсә, капитуляцияме?
Йосыф. Авызыңны җәеп ыржайма, аңгыра! Авызыңны ябарга да өлгермәссең, хан бабаңның мирасыннан колак какканыңны сизми дә калырсың. Әнә сменага остабикәңне чакыр.

Сәхнәгә Мөстәкыйм чыга.

Нихәл, энем?
Мөстәкыйм. Әбиеңнеке кебек!
Нуркасыйм. Нәрсә булды, энекәш?
Мөстәкыйм. Нәрсә булды, нәрсә булды, белмисең инде как будто. Әгәр бүген төнлә тагын берәрегезнең хатыны минем бүлмәгә мине сакларга керсә, белеп торыгыз, йә асылынам, йә тәрәзәдән сикерәм. Йокыга гына төнәрәсең, мәче кебек куенга керергә генә торалар. Настоящий ханга әверелсәң, нишләмәсләр!
Йосыф. Соң бит, энекәш, өстән шулай куштылар. Төнлә синең белән берәр хәл булса, күз-колак булырга кирәк, диделәр.
Мөстәкыйм. Дисәләр. Без бит өч бертуган. Менә шушында, сабый чактагы кебек, идәнгә сузылышып ятып өчәүләп йокласаң ни булган?
Нуркасыйм. Без бит сандык саклыйбыз.
Мөстәкыйм. Ә хатыннарыгыз мине саклыймы?
Йосыф. Нишлисең, өстән килгән положение шундый.
Мөстәкыйм. Төкерәм мин аларның положениеләренә.
Нуркасыйм
Йосыф (*пышылдап*). Чү, энекәш... (*Түшәм почмагындагы глазокка ымлап.*) Тыңлап һәм күреп торалар.
Мөстәкыйм. Сез бәхетле, сезгә мешать итүче юк.
Нуркасыйм. Алай дип әйтмә әле, энекәш. Йокысыз төннәр уздыру бик рәхәт түгел ул.
Йосыф. Минем үземә ошый.
Нуркасыйм. Ошый, ошамыйча, йокымсырап, өч тапкыр урындыгыңнан егылып төштең. Микрофоннан кычкырып кына уяттылар.
Мөстәкыйм. Төне буе Осип абыйны кызганып чыктым.
Йосыф. Осип түгел мин, энекәш, Осип түгел...
Мөстәкыйм. Ә, әйе бит әле, Иосиф абыйны.
Йосыф. Мин Иосиф та түгел.
Нуркасыйм. Ярар инде, кем, энекәш, Мөстәкыйм... Джузеппе абыеңны үртәп утырма.
Йосыф. Каян ул исемнәрне табасың да, каян башыгызга килә.
Нуркасыйм. Нигә?.. Үзең бит, үзең мактанып йөрдең. Минем сигез исемем бар дип.
Йосыф. Кайчан?
Нуркасыйм. Әткәй кушкан исемеңнән ваз кичеп, паспорт алмаштырып йөргән чагында. Атам кушкан исемем — Йосыф, русларда — Иосиф, Осип, инглизләрдә — Джозеф, французларда — Жозеф, испаннарда — Хосе, итальяннарда — Джузеппе, полякларда — Юзев, дип. Мин алдасам, әнә Мөстәкыйм энекәш үлмәгән. Ул дөресләр.
Йосыф. Ну бу татар, ну бу татар... Шулкадәр тар күңелле булырга кирәк бит, ә?! Үз туганыннан көнләшә.
Нуркасыйм. Хатын кадәр хатыныңны сатып та ярап булмый.
Йосыф. Сатмадым. Нәселебез турында кайгырттым. Нәселебез турында мин дә кайгыртмасам, син дә кайгыртмасаң, ул да кайгыртмаса, кем кайгыртыр?! Әйт, энекәш, нишлибез?! Нәсел сандыгы белән нәрсә эшлибез?!
Мөстәкыйм. Нәрсә эшләргә кушасыз, шуны эшлим.
Йосыф.
Нуркасыйм. Сандыктан баш тарт!
Мөстәкыйм. Мирастан?!
Йосыф.
Нуркасыйм. Әйе, мирастан.
Мөстәкыйм. Ничек итеп?
Йосыф. Васыятьнамәдә борынгы бабабыз доверенность турында бер сүз дә әйтмәгән. Минем исемгә доверенность яз!
Нуркасыйм. Юк инде. Минем исемгә яз!
Мөстәкыйм. Була ул. Кая кәгазегез, кая каләмегез?

Музыка. Ут сүнә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, Мөстәкыйм белән Нуркасыйм идән уртасын-
да, ә Йосыф өстәл алдына кәгазь куйганнар да язарга җыеналар.

Мөстәкыйм. Башлыйбызмы?

Йосыф.

Нуркасыйм. Башлыйбыз!

Йосыф *(Мөстәкыймгә)*. Нәрсә, энекәш, әллә үз-үзеңә доверенность язасың?

Мөстәкыйм. Әйе. Нигә, әллә ярамыймы?

Йосыф. Ярый. Нигә ярамасын. (*Тамашачыга.*) Дуракларны чәчеп үстермиләр.

Нуркасыйм. Ну баш бар да инде үзеңдә, энекәш Мөстәкыйм.

Йосыф. Сөйлисе юк инде, сөйлисе юк. Шушы яшемә җитеп, үз-үзенә доверенность язган кешене беренче тапкыр күрәм.

Мөстәкыйм. Нигә алай дисең? Сезнең халыкны, начальство халкын әйтәм, берүзләренә ике оешма ачып, ике печать ясатып, үз-үзләренә доверенность язып утыралар түгелме соң?

Йосыф. Син, энем, тирәнгә кермә. Чыга алмый азапланырсың.

Мөстәкыйм. Ходайга тапшырып башлыйм.

Йосыф. Башла!

Мөстәкыйм. Әйтеп торыгыз. Минем грамот бәләкәй. Мин доверенность яза белмим.

Йосыф. Мин әйтеп торам.

Нуркасыйм. Ни өчен син?!

Йосыф. Мин югары белемле! Мин өч институт бетердем!

Нуркасыйм. Мин риза. Кояш кебек елмаеп әйтеп тор әле.

Йосыф. Көлмә, аңгыра! Сез әзерме?

Мөстәкыйм.

Нуркасыйм. Әзер!

Йосыф. Мин дип язып куй, энекәш Мөстәкыйм.

Мөстәкыйм. Яздым, абзыкай.

Йосыф. Молодец! Булдыргансың. Хәзер мин язам. (*Иҗекләп яза.)* Ми-н. Булды бу. Икенче сүзне язабыз. Мөстәкыйм, яз. Үз исемеңне яз. Мөс-тә-кыйм дип яз.

Мөстәкыйм. Аңлашылды, абый. Димәк, үз исемнәребезне язабыз. Мин, кыскартып кына, үз исемемне «мин» дип яздым.

Нуркасыйм (*Мөстәкыймгә*). Нәрсә минем кәгазьгә карыйсың, үзең яз! Күчермә миннән.

Мөстәкыйм. Исемеңне дөрес язасың микән дип карыйм.

Нуркасыйм. Син мине ул кадәр аңгырага санама инде. Үз исемемне дә яза белмәскә. Менә кара, Нур-ка-сыйм! Шәпме?

Йосыф. Изумительно! Өченче сүзне язабыз. Үземнең дип языгыз.

Мөстәкыйм. Яздым, абый.

Йосыф (*Нуркасыймга*). Син яздыңмы?

Нуркасыйм. Яздым инде, яздым. Колакка акырма. Чукрак түгел.

Йосыф. Хәзер үзем язам. (*Яза*.) Ү-зем-нең. Булды бу. Хәзер борынгы дип языгыз.

Нуркасыйм. Нигә борынгы?

Йосыф. Борынгы булганга борынгы! Беренче булмаганга борынгы. Как бу кадәр аңгыра син?!

Нуркасыйм. Ярар, телеңә салынма. Яздым. Синеңчә булсын. Борынгы дип яздым. Хан булгач, дураку ясно, борыңгы була инде ул. Язмыйча да аңлашыла.

Йосыф. Хан дип языгыз!

Нуркасыйм (*иҗекләп яза*). Ха-н.

Йосыф (*Нуркасыймга*). Өч хәрефле җөмләне иҗекләп язмасаң булмыйдыр. Син яздыңмы, Мөстәкыйм энекәш?

Нуркасыйм. Җөмлә түгел, сүз. Аңгыра кояш!

Мөстәкыйм. Яздым. Мин әллә кайчан яздым инде, абзыкай.

Йосыф. Молодец! Үзем дип язып куйыйм әле. *(Яза.)* Хан! Олы хәреф белән яздыгызмы?

Нуркасыйм. Нигә олы хәреф белән язарга?

Йосыф. Хан булганга олы хәреф белән язарга. Аңгыракаем, тити баш, өстәвенә надан!

Нуркасыйм. Нигә акырасың, акырма! Төзәтеп була бит аны. (*Төзәтә.*) Менә төзәттем. Сизелми дә.

Мөстәкыйм. Мин төзәтмим. Мин надан. Мин аңгырага ничек тә ярый.

Йосыф. Дальше киттек.
Нуркасыйм. Кая?
Йосыф. Бөгелмәгә!
Нуркасыйм. Нигә?
Йосыф. Әйттерәсең әллә ни.
Нуркасыйм. Әйт, эчеңдә калмасын.
Йосыф. Башка бер сүз дә әйтмим. Мыскыл итеп утыра. Үзе әйтсен.
Мөстәкыйм. Ярар инде, кечкенә абый, үпкәләмә. Арабызда иң грамотные син бит.
Нуркасыйм. Сөйлисе юк. Үпкәләмә инде. Мин бит карт. Зиһен тарала.
Йосыф. Зиһенең таралгач, ни пычагыма сиңа хан сандыгы. Кәфенлек алырлык кына акчаң бардыр бит. Булмаса, үзем биреп торам.
Нуркасыйм. Ашыксаң, үзең бара тор. Синнән әҗәткә акча алып торсаң, каберемә төшеп азапларсың.
Йосыф. Дүртенче җөмләгә киттек.
Нуркасыйм. Дүртенче җөмләне язабыз диген. Тапкан сүз, киттек!
Йосыф. Ба-бам-ның.
Мөстәкыйм. Ба-бам-ның.
Йосыф. Үземә дип язгыгыз.
Мөстәкыйм. Ү-зе-мә. Булды бу.
Нуркасыйм. Атап дип язгыгыз.
Нуркасыйм.
Мөстәкыйм. А-тап.
Йосыф. Җи-бә-рел-гән.
Нуркасыйм. Кем җибәрелгән?!
Йосыф. Син!
Мөстәкыйм. Сандык... Сандык җибәрелгән, дәү абый!
Йосыф. Үтерә бу мине.
Нуркасыйм. Үзең бит әллә нинди сүзләр эзләп табасың. Җибәрелгән дигәч, башка әллә нинди уйлар килә.
Нуркасыйм.
Мөстәкыйм. Җи-бә-рел-гән.
Йосыф. Ашыкмагыз. Хәзер үзем дә язып куям. Җи-бә-рел-гән. Точка.
Нуркасыйм. Беттемени?
Йосыф. Нигә?
Нуркасыйм. Точка дисең бит.
Йосыф. Ни эшләп бетсен инде, аңгыра! Яз!
Нуркасыйм *(яза)*. Яздым точка дип.
Йосыф. Нәрсә язасың син?! Нигә точка дип язасың?!
Нуркасыйм. Үзе точка дип яз, ди, үзе җенләнә.
Йосыф. Мирас дип яз! Мирасны дөрес язгыгыз. (*Нуркасыймга.*) Бигрәк тә сиңа әйтәм. Ми-и-и-рас дип өч и белән язма. Бу сиңа аять түгел.
Нуркасыйм. Өйрәтмә! Башың яшь! Ничек язарга кирәген белермен.
Йосыф. Кемгә тапшыра?..
Нуркасыйм. Миңа!
Йосыф (*Нуркасыйм булып*). Миңа... Сиңа гына түгел шул, безгә тапшыра.
Нуркасыйм. Аңладым инде, аңладым. Безгә тапшыра. (*Яза.*) Без-гә. Булды.
Йосыф. Ашыкмагыз. Хәзер мин язам. (*Яза.*) Менә шулай.
Мөстәкыйм. Хәзер исемнәребезне куябыз, әйе бит, дәү абый. (*Иҗекләп яза.*) Мөс-тә-кыйм-гә.
Нуркасыйм (*Мөстәкыймгә ияреп*). Мөс-тә-кыйм-гә. Булды бу.
Мөстәкыйм. Дәү абый, минем кәгазьгә кара әле, исемемне дөрес язганмынмы?
Нуркасыйм. Эчемне пошырып, секунд саен сорап утырма инде. Тот та миннән күчереп яз.
Йосыф. Тап-шы-рам дип язгыгыз.
Нуркасыйм.
Мөстәкыйм. Тап-шы-рам.
Йосыф. Бүгенге числоны, айны куярга онытмагыз.
Нуркасыйм. Өйрәтмә. Аңа гына башыбыз җитәр.
Мөстәкыйм (*Нуркасыймның кәгазенә күз ташлый*). Дөрес икән.
Нуркасыйм. Нәрсә дөрес икән?!
Мөстәкыйм. Исемеңне дөрес язгансың икән.

Нуркасыйм. Мин бит, энекәш, армиядә писарь булган кеше. Йосыф Исхакович шикелле өч диплом сатып алмасак та, Аллага шөкер, төшеп калганнардан түгел. Кояш дигән сүздә биш хата җибәрмибез. (*Йосыфка*.) Нәрсә сырлаган буласың инде? Кайсы исемеңне язарга белмисеңме әллә?.. Кыскарагын яз. Хатасы азрак булыр. Хосе, йә булмаса, Осип дип куй. Юзев дип яза күрмә. «Е» белән «и»не бутыйсың бит син. Менә мин атам кушкан исememне Нуркасыйм дип тутырып язып куйыйм әле. (*Яза*.) Нур-касыйм! Булды бу. Менә хәзер ностоящий точканы куйсаң да була. Точка!

Йосыф. Өйрәтмә аңгыра башың белән. (*Язган кәгазенә карап*.) Булды бу, Мөстәкыйм энекәшнең кулы гына кирәк. (*Кәгазьне Мөстәкыймгә суза*.) Ал, энем.

Нуркасыйм. Ашыкма, энем. Чиратсыз кермә. Атаң урынына калган дәү абыеңның барлыгын онытма. (*Мөстәкыймгә кәгазен суза*.) Мә, энем! Башта үзеңә-үзең кул куй да аннары миңа куярсың.

Мөстәкыйм. Китер. *(Нуркасыймның кәгазенә кул куя*.)

Нуркасыйм (*кәгазен алып*). Ниһаять, булды бу.

Мөстәкыйм. Кая, кечкенә абый, сиңа да куйыйм.

Йосыф. Мә, куй, энекәш.

Мөстәкыйм (*кәгазьне алып кул куя*). Булды бу.

Нуркасыйм. Димәк, Мөстәкыйм — беренче, мин — икенче, син, Хосе, өченче!

Йосыф. Хикмәт беренчедәмени?..

Мөстәкыйм. Зато өчебездә дә доверенность бар. Әйдә, дәү абый, укып җибәр үзеңнең доверенностеңны.

Нуркасыйм. Була ул, энекәш. (*Укый.)* Мин, Нуркасыйм, үземнең борынгы Хан бабамның үземә атап җибәргән мирасын безгә — Мөстәкыймгә тапшырам. Беренче число, ай, ел. Нуркасыйм.

Йосыф. Фамилияңне дә куй инде Нуркасыйм Февральский дип.

Нуркасыйм. Нәрсә?

Йосыф. Аңгыракаем! Син бит үз-үзеңә доверенность язгансың. Менә тыңла, доверенностьны ничек язалар аны. Мин, Мөстәкыйм, үземнең борынгы Хан бабамның үземә атап җибәрелгән мирасын үземә — Йосыф Исхаковичка тапшырам. Беренче число, ай, ел. *(Йосыф кәгазьгә карап торганнан соң*.) Тукта әле, нишләп болай килеп чыкты соң әле бу? Үземә... Йосыф Исхаковичка... Йосыф Исхаковичка дип язганмын. Мөстәкыйм кул куйган.

Музыка. Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, бүлмәдә Мөстәкыйм, Касыйм Сабирханович, Вил Вилданович, Нуркасыйм, Миңлениса, Йосыф, Суфия.

Вил Вилданович. Хөрмәтле иптәшләр, хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде!

Мөстәкыйм *(тамашачыларга*). Кызык бу дөнья. Кичә генә адәм калдыгы идем, ә хәзер... (*Вил Вилдановичка.*) Мөстәкыйм генә диегез. Әфәндесе миңа килешеп бетми.

Касыйм Сабирханович. Алай димәгез, Мөстәкыйм иптәш, сез милләтебезнең йөзе!

Вил Вилданович. Иптәшләр, мин сезгә важный яңалык ачам. Кичә безнең егетләр, кабаттан ханның васыятьнамәсен тикшергәннән соң, шундый мөһим җөмләгә тап булдылар.

Нуркасыйм. Ягъни мәсәлән?..

Вил Вилданович. Ягъни мәсәлән... Тыңлагыз. Васыятьнамәдә шундый юллар бар. Исәнме, минем нәсел җебемне, нәсел шәҗәремне дәвам итүче ерак, ерак туганым, төпчек углым.

Касыйм Сабирханович. Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз?

Вил Вилданович. Васыятьнамәнең ахырына игътибар итегез. Мин синең исемеңне, кем атлы икәнеңне белмим, шуңа күрә бу сандыгымны нәселемне дәвам итүче, ишетәсезме, дәвам итүче, игътибарлы булыгыз, ир-ат затыннан булган төпчек тораным, ягъни оныгым сиңа калдырам диелгән.

Касыйм Сабирханович. Нәселебезне дәвам итүче... Вил Вилданович, кабатлап шул җирен укыгыз әле.

Вил Вилданович. Нәселне дәвам итүче, ир-ат затыннан булган...

Касыйм Сабирханович. Мин сезгә тик торганда гына, васыятьнамәнең өтеренә кадәр өйрәнегез дип, бюджеттан миллионлаган акча бирдермәдем. Күрәсез, васыятьнамә төбендә нинди фикерләр ята.

Йосыф. Һични аңламыйм.

Нуркасыйм. Мин дә.

Суфия. Йөз сиксән тапкыр укыган җөмлә.

Миңлениса. Алай димәгез, моның төбендә бик мөһим мәсьәлә ята.

Йосыф. Ха-ха-ха... Мөһим мәсьәлә, ди...

Мөстәкыйм. Юк инде, туганнар, уйларыгыз барып чыкмас. Мин өйләнмим. Үз тамагымны туйдыра алмаган килеш, кеше баласын алып, бәхетсез итеп, хәерче тудырасым юк.

Вил Вилданович. Ялгышмагыз, Мөстәкыйм әфәнде, Мөстәкыйм Исхакович.

Касыйм Сабирханович. Хан бабагыз сезне хөрмәт итеп, мең еллар элек сезнең бу якты дөньяга киләсегезне сизеп, сезгә шундый дәүләт калдырган икән, сез инде борынгы бабагызның йөзенә кызыллык китермәгез.

Вил Вилданович. Бабабыз диегез, Касыйм Сабирханович.

Касыйм Сабирханович. Сез инде хан нәселен дәвам итәргә алынгансыз икән, давай өйләнегез. Күреп торасыз, нәселемне дәвам итүче, дигән. (*Мөстәкыймгә.*) Ә сез дәвам итәсезме? Юк. Бүгенгә кадәр өйләнмәгәнсез. Үзегезгә шактый яшь.

Йосыф (*Суфияга пышылдап*). Син авырлы. Син авырлы.

Суфия (*Йосыфка пышылдап*). Ничек авырлы?..

Йосыф. Син корсаклы!

Суфия. Ничек корсаклы?

Йосыф (*пышылдап).* Аңгыра! Син корсаклы! Мин нәрсә әйтсәм, шуны җөпләп бар. Иптәшләр, гафу итегез. Ул өйләнде!

Касыйм Сабирханович (*аптырап*). Ничек өйләнде?

Вил Вилданович. Өйләнде?..

Йосыф. Әйе, өйләнде.

Нуркасыйм.

Миңлениса. Кайчан өйләнде?..

Йосыф (*Нуркасыйм белән Миңлenisaга пышылдап*). Тик торыгыз, аңгыралар! Сизмисезмени, хан мирасын кулдан тартып алмакчы булалар. Мин нәрсә әйтсәм, әйе, дип торыгыз. Җәмәгать, Мөстәкыйм өй-лән-де!

Касыйм Сабирханович. Кемгә?

Йосыф. Суфияга!

Вил Вилданович. Ничек Суфияга?

Касыйм Сабирханович. Суфия бит синең хатының.

Йосыф. Элек минем хатын иде, хәзер энекәш хатыны.

Касыйм Сабирханович (*Мөстәкыймнән*). Җиңгәңә өйләндеңмени?

Мөстәкыйм. Белмим шул. Күптәннән эчкәнем дә юк инде...

Вил Вилданович. Үзенең җиңгәсенә өйләндеме?

Йосыф. Әйе, үз җиңгәсенә.

Касыйм Сабирханович. Ә син Суфия белән кайчан аерылыштың?

Вил Вилданович. Әйе, судыгыз кайчан булды?

Йосыф. Ә без суд белән аерылышмадык, шулай бит, дәү абый?!

Нуркасыйм. Нәрсә дип әйтергә дә белмим шул.

Йосыф. Без хәзер шәригать законнары белән яшибез. Без — хан нәселе. Борынгы бабабыз законы белән яшибез. Суфия белән Мөстәкыйм, төнлә икәүдән-икәү генә калгач, мин өч тапкыр Суфияга «Талак, талак, талак» дидем. Шулай бит, җиңги Миңлениса?

Миңлениса. Әйе, әйе, өч тапкыр «талак» дидең.

Йосыф. Әйттем бит, Нуркасыйм абый?

Нуркасыйм. Әйттең, энекәш, әйттең. Әле өстәвенә үзеңә әйттем, хатын кадәр хатыныңны да җәлләмисең инде, юмарт булсаң да булырсың икән, дидем.

Касыйм Сабирханович (*Суфияга*). Ә син аның «талак» дигәнен ишеттеңме?

Суфия. Ишеттем, ишетмичә.

Вил Вилданович. Ябык ишек аркылымы?

Суфия. Ул кычкырганда, мин ишекне тибеп ачтым.

Вил Вилданович. Нигә?

Нуркасыйм.

Миңлениса.

Йосыф. Шатлыктан!

Касыйм Сабирханович. Аерылышу шатлыгыннанмы?

Нуркасыйм.

Миңлениса.

Йосыф. Кавышу шатлыгыннан!

Касыйм Сабирханович. Һични аңламыйм. (*Вил Вилдановичка.*) Син берәр нәрсә аңлыйсыңмы, юкмы?

Вил Вилданович. Юк.

Нуркасыйм. Аның нәрсәсен аңлыйсың?! Энекәш Йосыф өч тапкыр талак әйтүгә, мин, указлы мулла буларак, Мөстәкыйм белән Суфия киленгә никах укыдым. Шулай бит?

Миңлениса. Шулай, шулай.

Вил Вилданович. Ә син, Мөстәкыйм, ризалыгыңны бирдеңме?
Мөстәкыйм. Сез бигрәк. Нишләп мин ризалыгымны бирим. Абый хатынына өйләнергә сез мине кемгә саныйсыз.
Йосыф. Син, энекәш, давай не паникуй. Сүзеңнән кире кайтма. Хан оныгы икәнеңне онытма.
Касыйм Сабирханович. Дөрес, Мөстәкыйм әфәнде! Хан оныгы буларак үз сүзегездә нык торыгыз! Иртәгә үзеңә хатынлыкка кандидатлар конкурсы оештырабыз. Шәһәребезнең иң гүзәл, иң затлы кызлары сезнең алдыгызда сезнең йөрәгегезне яулап алыр өчен көч сынашачаклар. Әзер булып торыгыз.
Мөстәкыйм. Карагыз аны, күбрәк чакырыгыз. Мин үзем төскә-биткә, буй-сынга алама булсам да, хатын-кыз мәсьәләсендә бик нәзберек.
Касыйм Сабирханович (*тамашачыларга*). Сасы көзән! Татар баеса, хатын ала, урыс баеса, чиркәү салдыра. Хак икән!

Музыка. Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, сәхнәдә шул ук бүлмә. Әмма ул бик матурлап бизәлгән. Бәйрәм төсе алган. Сул порталда кечкенә генә, үзбәкләр чәйханәсенә охшаган, ковер капланган сәке. Сәкедә — аш-су. Уртада, аякларын бөкләп, Мөстәкыйм, аның уң ягында — Нуркасыйм һәм Йосыф, ә сул ягында Касыйм Сабирханович, Вил Вилданович утыра. Каршыларында затлы, ялтыравыклы чалма-чапаннан яшь егет
курайда уйнап утыра. Аның алдында зур бизәкле кувшин.

Егет *(уйнавыннан туктап)*. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде, хөрмәтле шәһәребез кунаклары! Кувшиннан елан чыгарып булмады. Бүгенге бәйрәмнең шарты елан чыгару түгел. Бүгенге мәҗлесебезнең максаты, күңел ачу белән генә чикләнмичә, борын-борыннан килгән мирасыбызны, милләтебезнең асыл кызларын барлау, хан нәселен дәвам итүче хан оныгы Мөстәкыйм әфәнде Исхак улына яр эзләү. (*Уң кулын сузып.)* Хан оныгы, хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде галиҗәнаплары беренче номерлы чибәр, яшь сылу кызны бирегә чакыра.

Шәрык музыкасы уйный. Бүлмәгә ярым шәрә, шәрык кызларына хас кием кигән, уң кулына беренче номер таккан Кыз чыга да бии башлый.
Ара-тирә Мөстәкыймгә килеп сырыша.

Йосыф (*Нуркасыймга пышылдап*). Ничек тә сайлатмаска тырыш. Хан мирасын үзләренә калдырыр өчен уйлап табылган хәйләләре.
Нуркасыйм (*кул чабып).* Булды, булды, хватит!

Музыканың тавышы кими, кыз биюеннән туктый да, матур кыяфәт
ясап, бүлмәдән чыгып китә.

Мөстәкыйм. Нәрсә булды?! Нигә туктаттыгыз?! Дөньямны онытып карап утырган җирдән, шап-шоп кул чабып, матурлыкны, гүзәллекне туктаттыгыз.
Йосыф (*Мөстәкыймнең колагына пышылдап*). Исең китмәсен, күрмисеңмени, аяклары кәкре.
Мөстәкыйм. Булса соң. Сиңа кыз сайлыйбызмы, әллә миңамы?!
Йосыф (*Нуркасыймга*). Әйт әле шуңа берәр сүз.
Нуркасыйм. Күзең чыкмагандыр бит, энекәш, кендегенә кара!
Йосыф.
Мөстәкыйм. Кендегенә нәрсә булган?
Нуркасыйм. Нәрсә булган, нәрсә булган? Борчак кадәрле генә калган.
Касыйм Сабирханович (*Мөстәкыймнең колагына*). Абыең хаклы. Борчылма, алда әле аның затлылары.
Егет. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде! Хөрмәтле кунаклар! Сезнең алда чыгыш ясаган беренче номерлы асыл зат турында кыска гына мәгълүматлар. Исеме — Декабрина! Алдагы гасырда туган, нәселе затлы. Кичә үзен урыс милләте вәкиле дип санаса, хәзергесе минутта үзен татар милләтеннән дип белдерә. Буе бер метр да кырык тугыз сантиметр. Чәче сары, кашы кара, күзе яшел. Пони нәселеннән. (*Уң кулын сузып.)* Хәзер икенче номерны чакырабыз. Рәхим итегез, икенче номер! Маэстро, музыка!

Музыка көчәя.

Касыйм Сабирханович (*Мөстәкыймгә*). Минем үземә иң ошаганы менә шушы икенче номер.

Бии-бии икенче номер чыга. Мөстәкыйм шаркылдап көлеп
җибәрә.

Нигә көләсез?
Мөстәкыйм. Кызык бит.
Касыйм Сабирханович. Нәрсәсе кызык?
Мөстәкыйм. Көйгә баса белми.
Касыйм Сабирханович. Көйгә басу нәрсә ул?! Йөрәккә баса. Кара син аның фигурасына! Фигурасы шәп бит, ә?
Мөстәкыйм. Тяжеловес!
Касыйм Сабирханович. Чебеш түгел инде.
Мөстәкыйм. Ялгыш салып кайтып моның йодрыгына эләксәң, бер сугуда нокаут ясый бу.
Касыйм Сабирханович (*Вил Вилдановичка*). Сиңа ошыймы?
Вил Вилданович. Шәп бу, аркалыгын чамадан тыш күтәргән ат шикелле!
Касыйм Сабирханович. Синнән сораган мин дивана. Хатын-кыз аерган кеше сыман сөйләшеп торган буласың. Мөстәкыйм туган, тукта шушы кызга, алдатмассың. Минем бу мәсьәләдә опыт зур. Мин, җиде хатын алып аерган кеше буларак, хатын-кызны мичкә керсә дә арт санынннан таныйм.
Мөстәкыйм (*кул чабып туктата*). Җитте, булды. Азапламагыз баланы. Бар, сеңлем, бар, кер. Бии белмәгән кешегә биюдән дә авыр әйбер юк.
Касыйм Сабирханович. Нәрсә, сиңа бу кызның бер җире дә ошамадымыни?
Мөстәкыйм. Бер җире дә дип инде... Күкрәкләре ошады да соң, ну күкрәккә генә карап яшәп булмый бит әле. Тормыш булгач, бит бераз гына муены да, арт саны да, бил дигән нәрсәсе дә булырга тиештер.
Егет. Хөрмәтле туганнар! Хәзер сезнең рөхсәт белән икенче номер хакында кыскача гына мәгълүмат. Исеме — Нуркасыймә... Буе ике метр да...
Нуркасыйм. Булды, булды, мәгълүмат кирәкми. Өченче номерны чакыр!
Егет. Хөрмәтле әфәнделәр! Хөрмәтле галиҗәнап Мөстәкыйм әфәнде! Хәзер сезнең игътибарыгызга күпмилләтле илебезнең иң гүзәл затларыннан берсен — өченче номерлы илаһи затыбызны — татар һәм урыс тырышлыгы белән дөньяга туган, ике милләтне дә уртак күреп, үзенә Элеонора исеме алган чибәркәйне чакырабыз.

Бүлмәгә бии-бии өченче номер чыга.

Вил Вилданович *(кул чаба*). Браво, браво! Афәрин! (*Мөстәкыймгә.)* Менә бу ичмаса асыл! Кара син аның аякларына! Аяклары колактан төшкән. Ә ул муен, ул күкрәкләре... Сезнең урында, Мөстәкыйм әфәнде, үзем булсам, ике дә уйламыйча шушы асыл затка тукталыр идем.
Мөстәкыйм. Да... Дөрес әйтәсең. Миңа да ошый бу гүзәл.
Касыйм Сабирханович. Браво, браво! Афәрин! (*Кул чабып туктата.)* Рәхмәт, сеңлем. Сез Мөстәкыйм әфәндегә ошагансыздырмы-юктырмы, анысын белмим, но әтиегез Вил Вилдановичка искитмәле ошадыгыз. Рәхмәт сезгә!

Өченче номер бии-бии чыгып китә.

Егет. Хөрмәтле дуслар! Хөрмәтле әфәнделәр! Хәзер бирегә дүртенче номерны чакырабыз.
Касыйм Сабирханович. Постой, постой, энем. Өченче номер турында мәгълүматны ишетмәдек.
Егет. Гафу итегез, хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде! Извините, господа! Әле генә сезнең каршыгызда сезне таң калдырган өченче номерлы гүзәл зат — Элеонора Вилевна. Егерменче гасырның азагында туып, егерме беренче гасырның башында күпләрне таң калдыручы Элеонора — урыс һәм татар милләтенең гүзәл өлгеләренең берсе...
Касыйм Сабирханович. Рәхмәт! Безгә башкасы кирәкми.
Вил Вилданович. Нигә бүлдерәсез?! Сөйләсен, сөйләсен!
Нуркасыйм. Сөйләмәсен. Безгә саф татар кызы кирәк. Шулай бит, Мөстәкыйм энем?
Мөстәкыйм. Шулай, абый!
Йосыф. Дүртенче номерны чакырсыннар, дүртенче номерны!
Егет. Хөрмәтле кунаклар! Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде! Хәзер сезнең соравыгыз буенча шәрык музыкасына коенып, шәрык музыкасында йөзеп, бүгенге мәҗлесебезгә тагын да якты нур өстәп, дүртенче номерлы Мәгъруфкамалны, алкышларга күмеп, бирегә чакырабыз.

Музыка көчәя, бүлмәгә бии-бии ярым шәрә Суфия чыга.

Нуркасыйм (*шаркылдап көлә*). Охшаса да охшар икән. Ка-а-ра әле, ка-ра! Монысы гел безнең Суфия киленгә охшаган.
Йосыф. Кая охшасын инде. Суфия янында бу курчак. Аннары, Суфия белән чагыштырганда бу бит әле сабый гына.
Нуркасыйм. Ха-ха-ха... Кара инде, кара, сикереп-сикереп куямы?.. Әй бичара! Байлык адәм баласын ниләр генә эшләтми! Ха-ха-ха... Иелеп, аягыңны да күтәреп күрсәт инде.
Мөстәкыйм. Ха-ха-ха... Афәрин, афәрин! Молодец, булдырасың!

Йосыф (*Мөстәкыймгә).* Әллә ошыймы, энекәш?

Мөстәкыйм. Класс! Во, абый! Вот это номер! Браво! Браво! Бис!

Йосыф. Афәрин! Афәрин! (*Онытылып китеп.*) Әйдә, әйдә, Суфия!

Нуркасыйм. Кем дисең?! Суфия дисеңме?

Йосыф. Син үзең Суфия, колагыңны чистарт! Мәгъруфкамал димен!

Мөстәкыйм. Уф, үтерә бу мине. Әйдүк, әйдүк, әйттер генәсе, сыгылмасмы идәне! (*Барысы кәлә-көлә кул чаба башлыйлар. Суфия бии-бии кереп китә.*) Рәхмәт, абый! (*Йосыфка кулын суза.*) Молодец, абый! Синең башка гына мондый юмор килә ала. Менә ичмасам бу номер. Алайса, скучно була башлаган иде. Җәмәгать! Мин болай хатын сайлый алмыйм.

Касыйм Сабирханович. Нигә?

Мөстәкыйм. Нигә, нигә?! Беренче чыккан кызның йөзен онытып та өлгердем инде мин. Сез каршы килмәсәгез, барысын да бергә чакырыйк. Сез каршы түгелме?

Вил Вилданович. Мин каршы түгел.

Касыйм Сабирханович. Мин дә каршы түгел.

Йосыф. Мин каршы.

Касыйм Сабирханович. Нигә каршы?

Йосыф. Потому что, энекәш Мөстәкыйм арыды. Ялгышып үзенә ошамаган хәләл, ягъни кәләш-хатын сайлавы бар. Ни генә әйтсәгез дә, без ханбикә сайлыйбыз.

Нуркасыйм. Мин дә каршы.

Мөстәкыйм. Юк инде. Көн дә хатын сайлап утырып булмый. Бүген эшне бетерәбез.

Касыйм Сабирханович (*Егеткә).* Барысын да бирегә чакыр!

Егет. Хөрмәтле Мөстәкыйм әфәнде! Хәзер сезнең йөрәгегезгә матур чәчәк булып кадалырга ут йотып торган хур кызларын чыгарам. Музыка! Хөрмәтле мөхтәрәм туганнар! Хан оныгы сезне көтә.

Бүлмәгә җиде кыз чыгып бии башлыйлар. Алар янына Мөстәкыйм
дә чыгып кушыла.

Мөстәкыйм (*биеп бетергәч*). Хөрмәтле туганнар! Сезнең рөхсәт белән мин сезгә шуны җиткерәм. Шушы минуттан бу җиде асыл затларның барысын да минем кәләшләрем дип уйлый аласыз!

Нуркасыйм.
Касыйм Сабирханович.
Йосыф.
Вил Вилданович. Барысы дамы?

Мөстәкыйм. Әйе, барысы да!

Нуркасыйм.
Касыйм Сабирханович.
Йосыф.
Вил Вилданович. Берүзеңәме?

Мөстәкыйм. Әйе, берүземә. Борынгы бабайлар көтүе белән хатыннар тотканнар, ә мин алардан киммени? Җиде хәләл, җиде хатын, җитмеш бала, җитмеш татар!

Музыка. Ут сүнә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мөстәкыйм бүлмәсе. Барысы да урыннарында утырып торалар.
Ишектә звонок.

Мөстәкыйм. Очтым. Хәзер ачам. Сабыр итегез.

Ишеккә юнәлә. Ишекне ачып җибәрүгә, бүлмәгә Гали Вәлиевич, Вәли Галиевич, Сәли Садриевич, Александр Александрович һәм Нуркасыйм керәләр.

Гали Вәлиевич.
Сәли Садриевич.
Вәли Галиевич. Исәнмесез!

Александр Александрович. Здравствуйте!

Йосыф. Саумысыз!

Гали Вәлиевич.
Сәли Садриевич.
Вәли Галиевич. О, Иосиф Исакович! (*Күрешәләр.*)

Александр Александрович. Здравствуйте, Осип Исакович!

Йосыф. Сан Саныч, извините, пожалуйста, я не Осип, Иосиф та түгел Минем атам кушкан исемем бар. Мин Йосыф, отчеством да Исхакович. Исем-отчествомны бозмавыгызны үтенәм!

Александр Александрович. Извините, пожалуйста, вы всегда представлялись Осипом Исаковичом.

Йосыф. Ну и что, хәзер Йосыф.

Александр Александрович. Извините!

Вәли Галиевич. Нигә, сез паспортыгызда Иосиф Исакович түгелме соң?

Йосыф. Паспорт нәрсә ул. Паспорт кемдер язып биргән кәгазь бит ул. Сез минем туу турындагы таныклыгымны карагыз.

Нуркасыйм. Әйе, әйе, җәмәгать! Мин аның атасы урынына калган иң зур дядясы буларак шуны әйтә алам: аның метрикасына Йосыф дип язылган. Алла тарафыннан арттырылган, өстәлгән дигән төшенчәне аңлата.

Йосыф. Күркәмлек, гүзәллек иясе. Легендар Йосыф пәйгамбәр исеме.

Сәли Садриевич. Иптәшләр! Без бирегә исем тикшерергә килмәдек. Төлкегә күпме генә «бүре» дисәң дә, төлке төлке булып кала. Хикмәт исемдә түгел. Хикмәт Казан каласының беренче казыгын табуда. Мин «Казык» фәнни-тикшеренү үзәге булып формалашкан «Казык» фәнни-тикшеренү институтының комиссия рәисе Сәли Садриевич. Бу югары дәрәҗәле урынны мин үзем сорап алмадым. Үзегезгә мәгълүм ки, бу югары постны миңа хөкүмәтебез ышанып тапшырды. Комиссиянең сәркәтибе итеп археология фәннәре докторы, профессор, академик Гали Вәлиевичны билгеләргә дигән тәкъдим белән чыгам. Кем дә кем мин әйткән, мин күрсәткән кандидатура белән килешә, Гали Вәлиевичны «Казык» фәнни-тикшеренү институтының баш сәркәтибе итеп сайларга тавыш бирүләре сорала.

Гали Вәлиевич *(кулын күтәреп*). Мин риза!

Вәли Галиевич (*кулын күтәрә*). Риза булырга мәҗбүрмен.

Александр Александрович. Мин тоткарланам.

Сәли Садриевич. Мин рәис буларак ике тавышка ия. Мин риза. *(Ике кулын да күтәрә.*) Каршылар юкмы?

Нуркасыйм. Мин каршы.

Йосыф. Мин риза.

Сәли Садриевич. Ә сез коллегия әгъзалары түгел. Димәк, күпчелек тавыш белән иптәш Гали Вәлиевичны институтыбызның баш сәркәтибе итеп билгеләргә дигән карарга килдек. Протоколга язып куегыз.

Вәли Галиевич. Протоколны кем яза?

Сәли Садриевич. Билгеле инде, сәркәтиб Гали Вәлиевич. (*Өстәлгә зур ап-ак кәгазь җәеп сала.*) Барыбыз да белгәнебезчә, сандыкны ачарга санаулы көннәр калып килә. Хөкүмәтебез безнең өскә зур җаваплылык тапшырды. Тиз арада сандыкны ачканчы, Казанның беренче казыгын табу мәсьәләсен. Кемнәрдә нинди фикерләр бар? (*Гали Вәлиевич кулын күтәрә.)* Рәхим итегез, Гали Вәлиевич!

Гали Вәлиевич. Сүз башы итеп, барыгызга да рәхмәтемне белдерәм! (*Күңеле тулып.*) Миңа ышанып шушындый зур пост — «Казык» фәнни-тикшеренү институтының баш сәркәтибе итеп сайлавыгыз белән барыгызга да рәхмәтлемен. (*Дымланган күз төбен кулъяулыгы белән сөртеп ала.)* Кичә Министрлар кабинетында бу эшкә лаеклы галим дип минем исемемне фәнни-тикшеренү институтына керткәч, мин шул ук минутта эшкә керештем.

Вәли Галиевич. Йә, йә?..

Сәли Садриевич. Нинди фикерегез бар? Иптәшләр, бүлдермәгез.

Гали Вәлиевич. Казык юк!

Мөстәкыйм. Юк?..

Йосыф. Ничек юк?

Мөстәкыйм (*дисбе тартуыннан туктап*). Казык бар!

Гали Вәлиевич *(Мөстәкыймгә*). Гафу итегез, казык юк!

Мөстәкыйм. Казык бар!

Сәли Садриевич. Мөстәкыйм әфәнде, гафу итегез, авыр булса да әйтим, сез әле бу мәсьәләдә бик надан.

Александр Александрович. Сезгә безнең арага керү өчен бер пот тоз ашарга кирәк.

Мөстәкыйм. Казык бар!

Гали Вәлиевич. Казык юк!

Сәли Садриевич. Нинди источникка таянып казык юклыгын фаразлый аласыз?

Гали Вәлиевич. Ягъни мәсәлән, казык мең ел элек хан тарафыннан Казан каласын төзергә дип шушы җиргә, шушы төбәккә кагылган дип фаразлыйк.

Нуркасыйм. Әйе, мең елдан артык.

Гали Вәлиевич. Мең ел элек кагылган казык нинди материалдан булган дип уйлыйсыз?

Вәли Галиевич. Билгеле, казык тимердән булган.

Александр Александрович. Әлбәттә, тимердән.

Гали Вәлиевич. Билгеле, казык агачтан булган. Мең ел элек безнең халык тимер эшкәртмәгән. Хан Казансу елгасы янына килгән. Биленнән балтасын алган да яр буенда үсеп утырган талны кисеп алып очлаган һәм Казан төзеләсе урынга казык каккан.

Вәли Галиевич. Юк инде, безнең бабайлар Болгарда сарай салганда ук тимер эшкәртә башлаган. Казык тимердән булган.

Гали Вәлиевич. Юк, агачтан!

Александр Александрович. Дөрес, мең ел элек сезнең халыкның тимер төшенә дә кермәгән. Казан каласы сез уйлаганча мең ел элек түгел, примерно җиде йөз илле ел элек төзелә башлаган. Җиде йөз илле ел элек урыслар тарафыннан тимер табылган, чуен эшкәртү эше җайга салынган. Казан каласына хан казыкны тимердән каккан.

Мөстәкыйм. Нәрсә?! Миңа сандыкны ачар өчен тагы ике йөз дә илле ел көтәргәмени?

Александр Александрович. Нишлисең, тарихка каршы килеп булмый.

Нуркасыйм. Сезнең фикер йөртүегез буенча, нәрсә, сандыкны китергән илчеләр ялгышканмыни?

Александр Александрович. Күрәсең, ялгышканнардыр. Иптәшләр, сез сандыкка игътибар итегез. Сандыкта берәр тимер кисәге бармы? Петля, бикләвеч, йозак ише әйберләр юк. Акылыгызга килегез, мең ел элек сезнең халыкта тимер булмаган. Димәк, Казан сез уйлаганча мең ел элек түгел, ә бәлки, җиде йөз илле ел элек төзелгән.

Сәли Садриевич. Яхшы. Сез уйлаганча, Казан каласына хан тимер казык каккач, миңа шуны әйтегез: ни өчен хан сандыкны тимер йозак белән бикләмәгән?

Александр Александрович. Бөтен хикмәт тә шунда шул. Сорау туа: ни өчен хан таш сандыкны тимер йозак белән бикләмәгән?!

Мөстәкыйм. Хан үзенең киләчәгенә, үз халкына, халкының иманлы, намуслы булуына ышанган. Хан сандыкны бикләүне кирәк дип санамаган.

Йосыф. Хан сандыкка тимер кертүне кирәк дип санамаган икән, димәк, казыкның тимер булуы да аңа мөһим булмаган.

Сәли Садриевич. Яхшы, казыкны агачтан булган дип фаразлыйк. Казык урыны кая?!

Александр Александрович. Әйе, казык агач ди, Казанга мең ел ди. Казык кая соң? Казык юк. Агач мең ел эчендә череп туфрак була.

Йосыф. Мең ел эчендә тимер казык та череп җир була.

Нуркасыйм. Димәк, ай казыкка эленеп калмаячак. Димәк, без сандыкны ача алмаячакбыз. Димәк, безнең милләтнең мирасы, киләчәге юкка чыгачак.

Александр Александрович. Хөрмәтле галимнәр! Сезгә безнең галимнәргә таянырга кирәк. Казанга нибары, күп булса, җиде йөз илле ел. Ышаныгыз миңа. Сезгә Казан казыгын табу өчен, дәүләтле булыр өчен тагын ике йөз дә илле ел көтәргә кирәк. Шул чагында гына сез дәүләтле булаласыз!

Вәли Галиевич. Юк инде, Александр Александрович, гафу итегез. Җәмәгать, мин сезне тыңлап-тыңлап тордым да сынап карамак булдым. Казык бит агачтан яисә тимердән булмаган. Казык сандык кебек үк таштан булган. Казан каласы — баш кала, баш калаларга таш кала!

Йосыф.

Нуркасыйм.    Менә галим! Афәрин! (*Кул чабалар.)*

Нуркасыйм. Галимнәрнең галиме сез, Вәли Галиевич!

Йосыф. Сезгә бу хезмәтегез өчен Нобель премиясе бирергә кирәк.

Александр Александрович. Туктагыз, туктагыз әле. Кул чабарга ашыкмагыз. Нобель премиясен алай тиз генә алып булмый ул. (*Вәли Галиевичка.)* Тирәнрәк аңлатуыгызны көтәм, нинди версиягә таянып, нигезләнеп, бу фикергә килдегез?

Вәли Галиевич. Минем версиям шул: моннан мең ел элек хан Казан каласына казык каккан. Ул тимер булгандырмы-юктырмы, беребез дә анысын әйтә алмыйбыз. Беребез дә барып күрмәгән. Тик шунысын беләм: мең ел вакыт эчендә агач та, тимер дә юкка чыга. Ә таш?! Таш — мәңгелек!

Йосыф.

Нуркасыйм.    Афәрин, афәрин, Вәли Галиевич!

Нуркасыйм. Болай булгач, сандык ачыла!

Йосыф. Болай булгач, милләт яши!

Йосыф.

Нуркасыйм.    Браво, афәрин, Вәли Галиевич! (*Кул чабалар.)*

Гали Вәлиевич. Яхшы, сезнеңчә, казык таш булган ди. Сезнең әйтүегезгә караганда, тимер булмаган. Булмагач, таш казыкны ничек эшкәрткәннәр?!

Александр Александрович. Әйе, ничек очлаганнар?!

Вәли Галиевич. Кем кем, сез, Александр Александрович, мондый сорау бирерсез дип һич кенә дә башыма китермәгән идем. Гали Вәлиевичка ярый инде. Ни әйтсәң дә, мылтыксыз кырда куян аткан кеше ул. Казык кагарга тимере булмаган хан елга буеннан билендәге үткен балтасы белән тал кисеп ала

да казык итеп җиргә кага. Ә син... Син бит зур галим. Сиңа мондый сорау бирү килешми. Очларга, шомартырга өйрәнгән халык, шуңа күрә очлау мәсьәләсен күршесеннән кереп сорамый.

Мөстәкыйм намазлык алып утыра.

Сәли Садриевич. Яхшы, казык таш булсын ди. Алга таба китик.
Мөстәкыйм. Юк инде. Казык таш та, агач та, тимер дә түгел.

Барысы да шаркылдап көләләр.

Йосыф
Нуркасыйм *(Мөстәкыйм янына киләләр дә, пышылдап).* Тик кенә утыр инде.
Йосыф *(пышылдап*). Намазлык өстендә утыра-утыра саташа башлагансың.
Нуркасыйм (*Мөстәкыймгә пышылдап*). Кетүләре белән эшләрен калдырып, безнең өчен, синең өчен казык эзләп утыралар. Ә син?..
Мөстәкыйм. Ә мин нәрсә?! Үзләре өчен, милләт өчен! Казыкны бүген эзлисе түгел иде. Алданрак эзлисе иде. Казык таш та түгел, тимер дә түгел, агач та түгел.

Барысы да кычкырып көләләр.

Сәли Садриевич (*Йосыф белән Нуркасыймнан*). Бу энегезнең тамагына ашаганы бармы? Врачка күрсәткәнегез бармы?
Нуркасыйм
Йосыф (*Мөстәкыйм янына киләләр дә, пышылдап).* Төш, төш намазлыктан, саташа башладың.
Нуркасыйм. Йосыф, энекәштән хан оныгы ясыйбыз дип, үзеннән җүләр ясыйбыз лабаса. (*Мөстәкыймгә.*) Төш, төш, энем, намазлыктан төш. Харап буласың.
Мөстәкыйм. Төшмим! Тәмам җилегемә төштегез. Җиде тапкыр намазымны бүлдердегез. Колагымда агач та таш, тимер дә агач, агач та таш! Шул казык белән үземне бастырыклап куйдыгыз. Җиттеме сезгә, юкмы?!
Сәли Садриевич. Алайса әйтегез, сезнеңчә, казык нинди материалдан?
Мөстәкыйм. Агач та түгел, тимер дә түгел, таш та түгел, вакыты җиткәч күрсәтермен.
Гали Вәлиевич. Ә син безгә хәзер күрсәт.
Вәли Галиевич. Безнең тотып карыйсыбыз килә.
Мөстәкыйм. Кызыкмыни?
Александр Александрович. Әйе, кызык.
Мөстәкыйм. Вакыты җиткәч тотарсыз!
Гали Вәлиевич. Юк, безнең хәзер тотып карыйсыбыз килә.
Мөстәкыйм. Ашыкмагыз. Күп калмады. Озакламый тотарсыз. Татар тотып карамый ышанмас.
Йосыф. Иптәшләр, аңа игътибар итмәгез.
Сәли Садриевич. Күрәсез, егетнең, таш сандык күргәч, зиһене таралган. Алмашына ук башлаган.
Гали Вәлиевич. Байлык харап итә ул.
Мөстәкыйм. Миңа сезнең казыгыгыз кирәкми. Кадалып китегез.
Барысы бергә *(җайлап кына, әкрен генә*). Сиңа нәрсә кирәк соң?
Мөстәкыйм (*түшәмгә төртеп күрсәтеп*). Ай!
Барысы бергә (*түшәмгә карап*). Ай?
Мөстәкыйм. Әйе, ай!
Сәли Садриевич (*Гали Вәлиевичтан*). Нәрсә ди?..
Гали Вәлиевич. Ай, ди.
Вәли Галиевич *(Александр Александровичтан)*. Ай, диме?
Александр Александрович. Ай, ди.
Нуркасыйм (*Йосыфк*а). Харап иттек энекәшне.
Мөстәкыйм (*намазлыкта тезләнгән килеш түшәмгә карап, ике кулын югарыга күтәреп).* Миңа ай кирәк!

Барысы да җайлап кына Мөстәкыйм янына киләләр дә аны ике ягыннан тотып бастыралар.

Нуркасыйм. Булыр, булыр, энем, ае да, кояшы да булыр.
Йосыф. Мөстәкыйм энем, әйдә, диванга ятып тор.
Мөстәкыйм. Миңа ай кирәк!
Сәли Садриевич. Булыр! Булыр, ае да булыр.

Вәли Галиевич. Син ятып тор.
Мөстәкыйм. Әгәр ул көнне айны болыт капласа.
Александр Александрович. Капламас. Капламас, борчылма.
Мөстәкыйм. Ай бабам казыгына эленеп калмаса...
Йосыф. Эленер, эленер, энем!
Мөстәкыйм. Милләт ни эшләр?! Таш сандык эчендәге халкым мирасына нәрсә булыр?
Александр Александрович. Борчылма, энем, борчылма!
Гали Вәлиевич. Без барда барысы да тәртиптә булыр.
Мөстәкыйм (*Гали Вәлиевичка*). Рәхмәт, галим абзый, рәхмәт!

Диванга алып барып яткыралар. Өстенә юрган каплыйлар.

Сәли Садриевич. Җәмәгать, өстәл янына килегез! Безгә хәзер казыкның урынын табарга кирәк.
Гали Вәлиевич. Нигә?
Сәли Садриевич. Нигә, нигә?! Казыкның урынын эзләп табып, казыкның ташмы, агачмы, тимерме икәнен белү өчен!
Вәли Вәлиевич. Кемдә нинди фикерләр бар? Казыкны каян эзли башлыйбыз?
Александр Александрович. Миндә бер фикер бар барын.
Сәли Садриевич. Йә, әйтеп карагыз, Сан Саныч!
Александр Александрович. Минем фикер йөртүем буенча, казыкны Яңа бистәдән эзләргә кирәк. Татар халкы Яңа бистәдә генә яшәгән.
Мөстәкыйм *(юрган астыннан башын чыгарып*). Фикерегез ялгыш! (*Юрганын кире бөркәнә.*)
Вәли Галиевич. Юк инде, казыкны Кремльдән эзлибез. Казан каласы шуннан төзелә башлаган.
Сәли Садриевич.
Гали Вәлиевич.
Нуркасыйм.
Йосыф. Дөрес! Казан Кремльдән төзелә башлаган.
Сәли Садриевич. Ә ничек эзлибез?
Александр Александрович. Минем бер фикерем бар.
Сәли Садриевич.
Гали Вәлиевич.
Вәли Галиевич. Йә, йә, нинди фикер?
Александр Александрович. Кремльнең почмакларыннан капма-каршы бау, ягъни җеп сузабыз.
Вәли Галиевич. Шуннан?..
Александр Александрович. Бау кайда кисешә, казык шунда була.
Барысы бергә. Дөрес!
Мөстәкыйм *(юрган астыннан башын чыгарып*). Кремльнең коймасы мең ел эчендә туксан тугыз тапкыр үзгәртелгән. Койма бабам төзегән чактагы рәвешен югалткан. Бау киселеше дөрес түгел! (*Юрганын яңадан бөркәнә.*)
Сәли Садриевич. Башына зәгыйфьлек килсә дә, аның сүзендә дөреслек бар.
Александр Александрович. Ә без бау кисешкән урынын киңрәк итеп казырбыз.
Йосыф. Анысы дөрес. Ә җепне ничек тартабыз?
Нуркасыйм. Җепне тартырга бит Кремль эчендәге йортлар мешать итәчәк! Ягъни мәсәлән, Сөембикә манарасы...
Александр Александрович. Сүтү мәсьләсен күтәреп, түрәләргә хат язабыз.
Сәли Садриевич. Риза булмаслар...
Гали Вәлиевич. Ни әйтсәң дә, үткәнебезнең тарихы, борынгы мирасыбыз...
Александр Александрович. Бу мәсьәләне үз өстемә алам.
Мөстәкыйм (*янә башын чыгарып*). Ул булдыра. Олы абыйлардан зур акча сорап ала да, иске Казанны сүттергән кебек, башында торып, Кремльне сүттерә. Ә сез авызыгызны ачып, шатланып үзегезгә яңа йорт салырга урын көтеп торырсыз. Юк инде. (*Урыныннан сикереп тора да диван өстенә баса.)* Минем борынгы бабам зиһенле һәм зирәк булган. Казан казыгы нәкъ менә шушы җирдә. Тереклек, үсемлек, яшәеш кояшка тартылган кебек, минем борынгы хан бабам да бирегә, менә шушы урынга тартылган. Яшәешнең казаны нәкъ менә шушы урында. Кояшның иң уңдырышлы нуры нәкъ менә шушы җирдә. Кояшның җылысы, назы ком сахраларында, йә булмаса, Себер котыпларында түгел. Моны борынгы бабам бик яхшы белгән. Тереклеккә ял кирәк булган кебек, безне тудырган Җир-анабызга да ял кирәк. Ямьле җәйдән соң туендырырга көз кирәк, йоклап алырга кыш, сулыш алыр өчен яз кирәк. Кояшның төп ноктасы бирредә. Ямьле җәе дә, Җир-ананы ял иттерүче кар-бураннары белән

ап-ак юрганлы кышы да булган уңдырышлы Җир кирәк. Минем борынгы хан бабам үз-үзенә сорау биргән: тереклеккә, адәм баласына яшәр өчен ни кирәк?

Барысы бергә. Һава!

Мөстәкыйм. Адәм баласына тереклек итәр өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Су!

Мөстәкыйм. Тагын нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Ризык!

Мөстәкыйм. Ризык табар өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Уңдырышлы җир, кояш кирәк!

Мөстәкыйм. Ул ризыкны пешерер өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Казан!

Мөстәкыйм. Ул казанны асар өчен нәрсә кирәк?

Барысы бергә. Вакытында җил дә исеп, яңгыры да ява торган җәй дә, карлы-буранлы кышы да, кояшлы җылы көзе дә, ямьле язы да булган борынгы бабам казык каккан, казан аскан җир кирәк.

Нуркасыйм. Син боларны каян беләсең?

Мөстәкыйм. Намазлыкка басып, күзем кыйблага төшкәч, мәрхүм атам сүзе искә төште. Бер кешегә күршесе кергән, ди. Хуҗа өстәлгә ботка куйган, ди. Ботканың уртасына, кашык йөзе белән чокыр ясап, май салган, ди. Комсыз күрше телгә килгән, минем туган авылда елга менә шушылай үргә ага иде, дип, боткадагы майны кашыгы белән ерып үзенә таба агызган, ди. Хуҗа янәшәсендә күзләрен мөлдерәтеп боткага карап утырган ач балаларына күз сирпеп алган да, ә менә мин үскән авылда елга менә шушылай борылып-борылып, болганып ага иде, дип, ботканы болгатып куйган, ди. Минем хан бабам казык кагарга, Казан асарга урынны дөрес тапкан. Боткасы да, мае да булган җирне сайлаган. Ботканы болгатырга гына өлгермәгән. Киләчәк буынга калдырган. Киләчәк буын йоклаган. Ботка мае елга булып күршегә аккан. Борынгы бабамның оныклары ач калган. Алар май елгасы буйлап бәхет эзләп чәчелгәннәр, сибелгәннәр. Тилмереп, диннәрен, гореф-гадәтләрен, татар булуларын онытканнар. Майлы боткадан мәхрүм калганнар.

Музыка. Ут сүнә.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, сәхнәдә Колшәриф мәчете балкып күренеп тора. Шәһәр халкы, килгән кунаклар Казанның меңьеллыгын бәйрәм итәләр. Алар уен-көлке, җыр-бию белән мәшгульләр. Әкренләп уен-көлке, җыр-бию басыла. Сәхнә караңгылана. Сәхнәдәгеләр барысы да намазлыкка утыралар. Бар белгәннәрен укыйлар. Күктә кызарып тулы ай калка. Айның яктысы багана булып халык өстенә төшә. Халык аптырашта калып, шаулашып: «Казык, казык! Хан казыгы!» — диләр. Халык уртасында — Мөстәкыйм, кулында — таш сандык. Янәшәсендә Касыйм Сабирханович, Вил Вилданович басып торалар. Ай яктысы Вил Вилдановичның аяк астына төшә.

Вил Вилданович (*Мөстәкыймгә*). Ач, ач инде сандыкны! Казык үзенең урынын тапты. Күрәсеңме, минем аяк астында.

Ай яктысы, аның аяк астыннан күчеп, Касыйм Сабирхановичка килә башлый.

Касыйм Сабирханович. Күрәсезме, сизәсезме, казыкның төбе минем аяк астымда. Мөстәкыйм туган, әзерлән, әзерлән сандыкны ачарга!

Яктылык Касыйм Сабирхановичтан узып китә.

Вил Вилданович. Аңлашылды. Син җиңдең, Мөстәкыйм! Казык синең кулда. Казык синең аяк астында!

Яктылык, Мөстәкыймне дә узып, Колшәриф мәчетенең аена килеп куна.

Барысы бергә. Сандыкны ач! Ач инде таш сандыкны, ач! Ай казыкка эленде!

Сәхнәдә барысы да шаулашып ала.

Барысы бергә (*Колшәриф мәчетенең аена карап*). Хан казыгы! Казан казыгы! Ач инде, ач!

Мөстәкыйм. Миңа сандыкны ачуның кирәге бетте. Сандык эчендәге серне мин болай да беләм.

Барысы бергә. Нәрсә? Таш сандыкта нәрсә?

Мөстәкыйм. Өмет!!!

Барысы бергә. Өмет!!!

Музыка. Ут сүнә.

Пәрдә.

# ХӨРМӘТКӘ КИРӘК ХӨРМӘТ

*Бер кешелек драма, өч күренештә*

КАТНАША:

Хөрмәт.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, тимер юл вокзалының алгы ягы күренә. Берсеннән-берсе горур ак төстәге дүрт колонна. Таш баскычның өске өлешендә, югарыда, колонналар артында ике якка ачыла торган имән ишекләрне саклап таштан коелган ике арыслан тора. Алгы якта, ямь-яшел чирәм аллеяда, берничә куак үсеп утыра. Сәхнәгә кап-кара костюм, кап-кара туфли, ап-ак күлмәк кигән, галстуктан, иңсәсенә сумка аскан Хөрмәт чыга да сумкасын куакның бер ботагына элеп куя. Уң кулын алга сузып, иелә төшеп, тамашачыларны сәламли.

Хөрмәт. Исәнмесез! Мин Хөрмәт абзагыз булам. Хөрмәт абзагыз Нигъмәтулла улы Хисмәтуллин. Китәм! Бөтенләйгә. Туган җиремнән китәм. Пока! Чау, господа! Пардон! Мерси! Үземнән үзем качып түгел, сездән качып китәм. Пока, друзья! Бу җирдә Хөрмәткә юк хөрмәт. Мадемуазельләр, еламагыз! *(Күңеле тулып.)* Мин кайткалап китәрмен. Конечно, по-другому. Баеп. *(Тәмәке кабыза. Үз-үзенә мыгырданып.)* Китмә, диләр. Безгә анда мондагыдан эш кыен... *(Ачуы чыгып, тамашачыга.)* Сафсата! Юләр Тукай... Монда тудык, монда үстек... Үссә соң... Нинди рәхәт күрдем, нәрсә кырдым... Монда тудык, монда үстек... Үссә соң. Үсеп рәхәт күрдемме?! Ә? Күрдемме? Нәрсә калган миңа бу җирдә?! Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары... Сафсата! Бабам Хисмәтулланың түре кайда?.. Салкын, чардугансыз кабердәме?.. Шушы җирдә туып, шушы җирдә яшәп, шушы җиргә бил бөгеп нинди рәхәт күрде. Үлгәндә күмәргә кәфенлеге дә булмаган. Ә атам Нигъмәтулла?! Икмәккә дә туймыйча, өстендәге сәләмәсен дә сала алмыйча каткан итеге белән дөнья куйды. Бәлки, исеме Нигъмәтулла булганга нигъмәте булмагандыр... Бәлки, миңа атам шуның өчен дә Хөрмәт исеме кушкандыр. Кая миңа хөрмәт?! Мы по-другим путем пойдем. Нет, уң! Рәхмәт сиңа, Сембер егете. Мин — татар. Татар сибелергә, чәчелергә, үз бәхетен читтә үзе эзләргә ярата. Мин дә шул халыкның бер улы.

Әнә пүчтәк Шәмси малае Сәгъди... Читкә китте дә кеше булды. Укыганда кем иде?.. Сыбызгы, аңгыра бер сарык, пүчтәк иде. Хәзер Себердә акча көри. Җәй көне үз машинасына утырып, җилдерттереп авылга ике ай ялга кайта да авыл кызларын шаккатырып китеп бара.

Ә Ата Каз Мәгъфүрәсенең җилдән туган, бер күзе көньякка, икенче күзе төньякка караган малае Нурислам... Тапкырлау таблицасын белмичә, мәктәпне бетерде. Быел авылга кайткач танымадым. Ул кыяфәт, ул буй, кигән киеме... Хәтта егетнең дөнья картасындагы көньяк һәм төньяк полушариесен хәтерләткән күзләре дә борынына тартылганнар. Танымадым. Валлаһи, танымадым. Бер алга, бер артка китеп карадым.

— Синме соң бу, Нурислам?

— Мин, — ди, күзләремә туп-туры карап. — Нигә гаҗәпләндең? — ди.

— Ә күзләрең? — мин әйтәм.

— Донбасс шахтасында ике күз уртасына таш төшкән иде, урынына утырдылар, — ди.

Ха-ха-ха... Вәт аңгыра. Укыганда биш матрас черетте. Шуның аркасында армиягә алмадылар. Абыйсына ияреп Донбасска китте дә кеше булды. Әле ул гынамы, шау-гөр китереп меңнәр чыгарып туй ясап, авылның иң чибәр кызы Гөләндәмне үзенә хатынлыкка алып китте.

Мин кемнән ким. Балыкчы Нурисламнанмы, әллә пүчтәк Шәмси малае аңгыра Сәгъдидәнме? Менә шушы алтын куллары, зиһенле башы барында югалмас Хөрмәт абзагыз. Атам миңа Хөрмәт диеп исем кушкан. Кая миңа хөрмәт?.. *(Тәмәкесен сүндерә дә чиертеп очыртып җибәрә.)* Пока, господа! Пока, дорогие друзья! *(Кузгалып китмәкче була. Аяк астында иснәнгән эт күреп тибеп җибәрә.)* Пошел! *(Эт чинап качкан тавыш ишетелә. Туфлиенә карап.)* Иснәнә тагын. Әйтерсең егерме ел күрешмәгән туганын очраткан, щенок! Син генә кирәк идең миңа. Кирәкле кишер яфрагы! Юашрак булсаң, тузан бөртеге кунарга да өлгермәгән өр-яңа туфлиләреңә, ботын күтәреп, эшен эшли. Пошел, дим, сволочь! Нигә карап каттың? Туганнан бирле өстемә бер затлы кием кидем, шуны да күпсенәсең. Җитмәсә, әнкәйнең пенсия акчасына. Иснәнә тагын. Туганнан бирле синең исемең белән атап йөрттеләр. Эт ялкавы, имеш... *(Тамашачыга.)* Күрсәтәм әле мин сезгә эт ялкавын. *(Эт качкан якка карап.)* Нәрсә, нәрсә кирәк, өтәчке! Нигә койрыгыңны бот арасына кыстырдың, ә? Куркасың?.. Куркасың шул. Куркак син. *(Арысланнарга бармак белән төртеп күрсәтеп.)* Синең урының әнә тегеләр урынында. Анда алар утырырга тиеш түгел, анда син утырырга... Бу җир арысланнар җире түгел, синең җирең, синең борынгы бабаларың — бүреләр җире. Әллә борынгы бабаңны саттыңмы?! Әллә ыруыңа хыянәт иттеңме?! Шуңа дәүләтсез калдыңмы?! Шуңа күрә чәчелдең, сибелдеңме?! Нигә башыңны иясең? Нигә күзләреңне яшерәсең? Җәлләтмәкче буласың?! Кол шул син... Ә колны беркайда да җәлләмиләр...

*(Туфлиен, салып, эткә ыргыта.)* Пошел, дим. *(Эт чинаган тавыш ишетелә.)* Мескен, бичара... Үз теләгең белән бер калҗа ит өчен үз муеныңа богау салган, бабаң бүрене саткан җан шул син. Ә синең бүре бабаң дәүләтле иде, горур иде, бил бирмәс батыр иде. *(Арысланнарга төртеп.)* Ул алар түгел иде, ул арысланнардан горур, батыр иде. Аны Җир йөзендәге бер генә җан иясе дә үз кубызына биетеп, манежларында дрессировать итә алмады. Ә син, койрыгыңны бот арасына кыстырып, хәер сорашасыңмы, иснәнәсеңме, хәлеңне аңлап, үзеңне кол иткәннәр якты чырай күрсәтерләр дисеңме? Аңгыракаем... Колның хәлен колдан гайре һичкем аңламый. Кол кол инде ул. Шуңа күрә дәүләтсезләр бәхет эзләп читкә сибеләләр дә. Менә Хөрмәт абзаң да бәхетен эзләп читкә китеп бара. Көт. Берничә елдан, бәлкем, Хөрмәтулла абзаң да үз поезды, үз составы белән биредән узып китәр. Үзеңә берәр ящик ысланган колбаса ыргытып китәр. *(Иңсәсенә сумкасын аса да баскычтан менеп китә. Күзе арысланнарга төшә.)* Нәрсә мине кабып йотардай булып утырасыз? Теге мәхлук җан иясе бүре оныгы белән сөйләшкәнемне ишеттегезме? Утырасыз! Кемнедер көтәсез... Илдән сөрелгән хуҗагызны көтәсездер әле. Карамагыз миңа ямьсез итеп. Мин кушмадым сезнең хуҗагызны бу җирдән сөрергә. Каткан итекле революционерлар эше ул. Янәсе, безне бәхетле итәр өчен. Кызганыч, үзләре дә бәхетле була алмадылар, безне дә бәхетле итә алмадылар. Каткан итекләрен ялтыраткан арада, власть үзгәреп, табаннарны ялтыратырга туры килде. Ә сез көтегез, көт. Хуҗагызны кортлар кимереп, нәселе корымаган булса, бәлки, берәрсе кайтыр. Әгәр инде читкә качкан хуҗагызны үзем очратсам, сездән сәлам әйтермен.

Бөек халык, имеш. Арысланнар!.. Җирдәге хаким... Ә бәлки, илегездә сездән дә көчлерәк, сездән дә хәйләкәррәкләр бардыр. Бәлки, шулар Арыслан исеме белән сезнең дә, безнең дә өстән хакимлек итәләрдер.

Анда мондагыдан эш кыен. Монда бик рәхәт. Рәхәт булса, Хөрмәт абзагыз бәхет эзләп читкә китмәс иде диярмен. Сез утырган урында әнә теге бая гына мин сөйләшкәннәр үзләре утырса, бәлки, мин фәкыйрегез дә бәхет эзләп үз иленнән качмас иде. *(Бер арысланның муенына сумкасын элеп куя да икенче арысланга менеп атлана һәм җырлый.)*

Арысланкай белән Юлбарысның
Кайсы икән аның зирәге.
Әллүки, бавырсак,
Кайда күрешербез, сагынсак.

Сәфәрләргә чыксам, ниятем бар
Шәһре Болгарны үтәргә.
Әллүки, ал гөлләр,
Җитте аерылыр көннәр.

*(Арыслан өстеннән төшә дә, кулларын чәбәкләп, тезләренә суга. Тамашачыга.)* Җир җимертеп яшиселәрем алда әле минем. *(Кулларын чәбәкләп, туфли табаннарына сугып ала.)* Ышанмыйсыз?! Күрерсез! Менә бу кулларым, менә бу аякларым, акыллы башым исән-сау булганда, атам-анам яши белмәгәнне яшәп күрсәтәм әле мин сезгә. Их-ма, дөньясы, башны кая куясы! *(Бии башлый. Биеп бетергәч, сумкасын ала да иңсәсенә аса. Кашын сикертеп.)* Күрдегезме абзагыздагы дәрт-куәтне! Чау, господа! Дөнья кулиса, бер әйләнә, бер баса. *(Имән ишекләрне киереп ачып кереп китә. Бераздан ишекне ярым ачып башын чыгара да.)* Пока! Сагынырсыз! Кунакка да кайтмам. Кадеремне белмәдегез! Хөрмәткә кирәк хөрмәт! Чау, господа!

Ишек ябыла. Поезд кузгалып киткән тавышка көй ялгана.

Әкрен генә сәхнәдә ут сүнә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, шул ук күренеш. Әмма ун еллап вакыт узганын сиздереп үзгәргән. Ак колонналар алтынсу төскә кергән, баскыч мәрмәргә әверелгән. Куаклар куерып үсеп киткән. Якынлашып килүче поезд
тавышы ишетелә. Аңа дикторның тавышы кушыла.

Диктор. Хөрмәтле пассажирлар! Йөз кырык сигезенче номерлы Мәскәү—Магадан поезды беренче юлга туктала. Сак булыгыз.

Бераздан поезд туктаган тавыш ишетелә. Вокзал ишекләре ачылып китә. Ишектән, сөрлегә-сөрлегә, өсте-башы тузып, таушалып беткән, кулына буш шешәләр, ярты буханка икмәк салынган чүпрәк сумка тоткан сукбай кыяфәтендә Хөрмәт очып керә һәм, баскычтан мәтәлчек ата-ата, яшел аллеяга барып төшә. Акрынлап ябылган
ишектән милиция машинасы гына күренеп кала.

Хөрмәт *(көч-хәл белән торып баса да, ябык ишекләргә бармагы белән янап).* Паразитлар! Сволочьлар! Сез әле минем кемлегемне белмисез! Хөрмәтулла абзагыз булам мин! Хөрмәтулла

Хисмәтуллин! *(Баскычтан абына-сөртенә йөгереп менә дә ишекләргә тибә башлый.)* Менә сезгә, менә!.. Менә! Шул кирәк сезгә! Кадалып китегез. *(Баскычтан төшмәкче була, әмма кире борылып йөгереп бара да ишеккә тагын китереп тибә.)* Получайте! Шул кирәк сезгә! *(Йодрыклары белән ишекне кыйнап.)* Бугазыгызны чәйним! *(Авырткан кулына өреп, баскычтан төшә-төшә, үз-үзенә мыгырданып.)* Күрмәгәнегезне күрдегезме?! Шул кирәк сезгә! *(Арт ягын кагып.)* Арт якка тибәләр, понимаешь ли. Погон тагып алганнар да хуҗа булганнар... Бер бөртек татарча сүз белмиләр, килмешәкләр! Кендек каның тамган туган җиреңдә арт ягыңа тибеп йөртсеннәр инде, понимаешь ли. *(Ишеккә бармагы белән янап.)* Сволочьлар! Зверюхалар! *(Елап җибәрә.)* Монда тудым, монда үстем, мондадыр минем әҗәл, бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез гыйззе вә җәл. Рәхмәт, Тукай абый, рәхмәт! Мең-мең рәхмәт, тугры Тукай! *(Ишеккә янап.)* Аңгыралар! Бөек Тукайны өйрәнегез! Әнә үз илегезгә кайтып командовать итегез, әгәр үз илегез булса. Нечу монда! *(Сумкасы яткан җиргә барып тезләнә дә, тамашачыга кулларын сузып.)* Мондадыр безнең бабайлар түрләре, оҗмахлары. *(Учына туфрак ала. Озак кына җиргә карап торганнан соң, тетрәнеп.)* Саумы, туган туфрак?! Саумы, туган җир?! Саумы, атам-анам җире?! Кендек каным тамган газиз җирем? *(Елап җибәрә. Озак кына учындагы туфракка карап тора да.)* Мин кайттым. Чит җирләрдә, чит илләрдә каңгырап, адашып йөргән улың — Хөрмәтулла кайтты. *(Туфракны җиргә сибә.)* Үз балаңны кабул ит. *(Тамашачыга.)* Сагындым, ай, сагындым. Барыгызны да сагындым. Кайттым. Сезнең бәхиллекне алыр өчен кайттым. Кичерегез... *(Башын түбән иеп, зәгыйфь тавыш белән.)* Мөмкин булса, кичерегез... Сезне сагынып йөрәгемнән кан таммаган бер генә минутым да булмады. *(Уң кулын йөрәгенә куя да, тамашачыга карап, патриотик рухта.)* Рәхмәт сиңа, йөрәк, рәхмәт! Сорадым, ялвардым, туган җиргә алып кайтуыңны үтендем, түздең!

Әй йөрәгем, бетмә янып,
Илгә кайтасым килә...
Илгә кайтып, җиргә ятып,
Туфрак буласым килә...

Хәзер туктасаң да, мәңге бәхил... Туган җиргә кайтып мәңгелеккә сүнсәм дә, миннән бәхетлерәк җан иясе булмас. *(Күзе арысланнарга төшә.)* Утырасызмы?! Беркая да китмәдегезме?! Хуҗагызны көтәсезме?! Кайтмый ул! Акыллы кеше туган җирен чит җиргә алыштырмый ул. Тау-тау алтын-көмеше, таш пулатлары өелеп калса да, алыштырмый. Моны бары тик минем кебек чит-ят җирләрдә сәфәр кылганнар гына аңлый. Әллә мине көтәсезме?.. Менә мин кайттым. Рәхмәт, сау-сәламәт кайт-кансың дисезме?.. Ялгышасыз. Тыштан гына сәламәт мин, эчемне ярып карасагыз, эчем буш, кабыктан гына торам мин. *(Арысланнар янына менә.)* Сезне сагынып кайттым. *(Бер арысланны кочаклап үбеп ала да үкереп елый.)* Таш, җансыз булсагыз да, сез генә халкымның үткәнен дә, моң-зарын да, кайгы-хәсрәтен дә, шатлыклы минутларын да буыннардан буыннарга сөйли аласыз. Сезне — арысланнарны — усал, диләр. Юк, һичкайчан юк... Кешеләр усал, кешеләр явыз. Бер-берсен талыйлар, бер-берсен үтерәләр, бер-берсенә хыянәт итәләр. Ә сез утырасыз. Таш пулат салып калдырган хуҗагызны көтеп утырасыз. Нигә дәшмисез?.. Ул да синең кебек чит җирдә бәхет эзләп, үз иленә ыштансыз качкан бер мәхлук иде дисезме?! Ә шулай да мин сезнең хуҗагыздан бәхетлерәк. Чит-ят җирләрдә таш пулатлар салып калдырмавым белән бәхетлерәк. Тинтәк, дивана син дисезме?! Шахтада син кискән күмерләрдән күпләр үзләренә хоромалар, таш пулатлар салдылар дисезме?! Төзесеннәр!.. Ә шулай да мин алардан күпкә бәхетлерәк. Чит җирләрдә сагынып, кызганып сөйләрлек байлыгым калмавы белән бәхетлерәк. Синең хезмәтеңне вагоннарга төяп ташладылар дисез инде... Юк, ялгышасыз. Үзем, үзем менә шушы кулларым белән совковой көрәк тотып төяп озатыштым. Үзең нәрсә белән кайттың дисезме? Мыскыл итәсез?! *(Куен кесәсеннән бөгәрләнеп беткән саклык кенәгәсен чыгара да, тамашачыга селкеп.)* Бөтен байлыгым шушы саклык кассасында! *(Арысланнарга.)* Күпме дисезме? *(Тамашачыга.)* Өч сум да унике тиен! Яндырдылар! Дуслар, яндырдылар! Егерме ел бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр шахтада күмер кискән хезмәтемне дә, сәламәтлегемне дә өч сум да унике тиенгә бәяләделәр.

Шул өч сум да унике тиенгә әле синең ул җирдә динең, телең, гореф-гадәтләрең дә калды дисезме?!

Минем намусым исән, намусым! Ә алар ничек кайтырлар? Миллионнар белән санала торган байлыкларны нишләтерләр? Миллионнарга төреп салган коттеджның чардак тәрәзәләренә капланып, туган якларны сагынып мәдхия җырлармы?.. Йә булмаса, сатып кайтырлармы?.. Кем алыр... Илне хәерчеләр төркеме баса. Хәлле кеше картлык көнендә үз нигезенә кайтып җан бирүне кулайрак күрмәсме? Моны минем кебек чит җирләрдә яшәгәннәр генә аңлый.

Ә мин сезнең хуҗагызны аңлыйм һәм кызганам. Авыр булгандыр аңа шушы байлыгын калдырып китүләре, ай, авыр булгандыр. *(Арысланнарга.)* Үзеңне шулай юат инде дисезме?!

Үлгәч, һәммәбезгә дә ике метр җир. Кемгә читтә, кемгә үз илендә. Утырасызмы? Алайса, мин дә утырыйм. Өчәүләп утырыйк. *(Башны аска иеп, арысланнар кыяфәте ясап, алар уртасына утыра һәм, мескен хәлдә.)* Юкны бушка әйләндереп, бармакка бармак та сукмый утырыйк. Таласыннар җиребезне, байлыкларны вагоннарга төяп алып китсеннәр. Ә без күрмик, ишетмик. *(Сикереп тора һәм ябык ишеккә бармагы белән төртеп.)*

Монда тудык, монда үстек,
Мондадыр безнең әҗәл.
Тиз генә бирешмибез әле,
Извините, господа!

Ә сез беләсезме, адәм баласына иң авыры нәрсә?

Күзләреңне соңгы тапкыр йомарга җыенып та, җаныңны өшетеп торган, мәңгелеккә китәргә куркыткан көчне? Соңгы минутларыңда үз-үзеңә хисап тотып, үткәнеңне үлчәп караудадыр.

Җир өстеннән, бакый тормыштан узган чакта, синең үзең белән бергә атлаган тереклеккә үз кулларың аша корган мәкер җәтмәңне сүтәрлек тә хәл һәм көч булмаудадыр. Син дә Чыршылы авылы егете Нигъмәтулла улы Хөрмәтуллин шулар рәтендә димәкче буласызмы?..

Бәлкем, сез хаклыдыр. Минем Нигъмәтулла каберенә чардуганлык акча эшләү нияте белән читкә китүем дә, авыл капкасы төбендә кул болгап мине озатып калган мәхәббәтем Назлыгөл белән, өйләнешеп, кечкенә генә өй җиткерү дә, бәлки, хата булгандыр. Бәлки, минем чит-ят җирләрдә нәселемне дәвам итүче булып калган юлдан язган улларым да, сәрхуш хатыным да шуларның бер билгеседер... *(Баскычка утыра. Арысланнарга.)* Килегез әле яныма! Килмисез... Танымыйсыз... Танымыйсыздыр шул... Безне күпләр танымый. Хәтта мин үз-үземне танымыйм. Их, дөньясы! *(Сикереп тора да биемәкче була, бии алмый.)* Күрәсезме, хәтта мине аякларым да тыңламый. *(Күзе аллеяда аунап яткан сумкасын иснәп йөргән этккә төшә. Сызгыра-сызгыра эт чакыра башлый.)* Акбай, Акбай, ко мне! Акбай! Кая качасың? *(Сумкасы янына килә.)* Күчтәнәч кирәкме? Качма инде. Кил әле яныма. *(Сумкасыннан икмәк сындырып ала да этккә суза.)* Акбай, Акбай, мә! Әллә син дә минем кебек хуҗаң кушкан исемеңне җуйдыңмы?.. Әллә син дә минем кебек атаң кушкан исемеңнән мәхрүм калдыңмы?.. Бәлки, син хәзер Акбай түгел, Шариктыр... Минем үземне дә әнә тегеләр... *(Арысланнарга төртеп күрсәтеп.)* Хөрмәт диеп хөрмәтләмәделәр, Харитон дип йөрттеләр. Телләренә, тешләренә җайладылар. Бәлки, син дә хәзер Акбай түгел, Шарик, Шариктыр... Әллә Тузикмы? Беләм, Вальдемар түгел, кыяфәтең минем кебек өтәчке! Акбай, Акбай, кил әле яныма. Курыкма инде, Алла колы. Тимим мин сиңа. Бәлки, син дә минем кебек үз ана телеңне онына башлаган бер җан ияседер. Бер кәлимә үз телеңдә сүз ишетергә гаҗиз булган бер җан иясе дер. Кил әле, кил, Алла мескене. Рәнҗетергә исәбем юк. Ышан сиңа, бабамны да рәнҗетеп киттең дисеңме?.. Әллә син шуның оныгымы? Менә үзеңне икмәк белән сыйлыйм. *(Икмәкне җиргә куя.)* Ыслаган колбасаң кая дисеңме? Кичер... Бөтен байлыгым, бар мал-мөлкәтем, шушы каткан икмәк кисәге дә буш шешәләр... Үз поездың, үз составың кая дисеңме?! Менә. *(Кесәсен әйләндерә, кесәсеннән ташкүмер коела.)* Аша инде, аша, тартынма. Җирәнәсең... Җирәнмә. Мин дә синең кебек шушы җирнең адашкан бер баласы. *(Җырлый.)*

Суда балык йөзәдер шул,
Су салкынын сизәдер шул,
Сизәдер...

*(Озак кына уйланып торганнан соң.)* Юк, юк, мин аны урламадым. Үзем, үзем эшләп таптым. Күпме сукбай булып яшәсәм дә, Ходай үзе әйтер, кеше хакына кермәдем. Әллә тамагың тукмы? Әллә минем кебек үзебезчә сөйләшергә интизармы? Сөйләшик соң үзебезчә. Безнең телне аңларга теләүчеләр аз. Коллар теле кемгә кирәк? *(Җирдәге икмәк кисәген кулына ала.)* Ашамыйм дисең инде... Ярый алайса, үзем ашармын. Төшке ашым булыр. *(Икмәкне сумкасына сала.)* Менә шулай. *(Этнең башыннан сыйпый.)* Дус булыйк. Ә бабаң өчен миңа рәнҗемә. Кем белә... Бәлки, безнең дәүләтсез булуыбызга, бу хәлгә төшүебезгә бары тик алар гаепледер. Янымарак кил әле! Менә шулай. Синең белән уртак тел табып була. Ә менә кешеләр белән... Сез куркыныч түгел, ә менә кешеләр, кешеләр куркыныч. Мин сезнең язмышны аңлыйм. Ходай сезгә кул һәм аң бирмәгән. Үз кулыгыз белән үз дәүләтегезне төзи алмыйсыз. Азау теш белән генә ерак китеп булмый, башта акыл кирәк. Иң авыры: алтын кулың, башыңда зиһенең була торып кол булып яшәү. *(Эт кебек дүрт аяклана да улап җибәрә. Улап туктагач, күз төбен сөртеп.)* Улаган чакларым күп булды. Туган якка карап улаган һәм елаган чакларым күп булды, Акбай. Кушылучылар табылмады. Чәчелдек, сибелдек без, Акбай. Сез бәхетле... Син миңа караганда бәхетлерәк, күпкә бәхетлерәк, Акбай. Сезгә әти-әни фатихасы кирәкми. Туасыз да йөгереп китәсез... *(Җырлый.)*

Суда балык йөзәдер шул,
Су салкынын сизәдер шул,
Сизәдер...

Ай да үтми, үз көнегезне үзегез күрә башлыйсыз. Адәм баласына туган җир фатихасы кирәк. Туган нигез фатихасы... Фатихасыз ашыйсыз, тапмасагыз, берәр бәндәнең күзләренә тутырып карыйсыз да, теге сезне кызганып берәр калҗа ыргыта. *(Җырлый.)*

Су салкынын сизәдер шул,
Сизәдер...

Адәм баласына авыр, һай, авыр. Адәм баласына адәм баласы ярдәм кулын бик сирәк суза. Егылганны таптый, абынганны типкәли. Ни өчен? Нәфсесе өчен! Кул биреп сөйрәп торгызучылар бик сирәк.

Әнә синең дә муеныңда ниндидер затлы каеш. Күрәм, ниндидер бәндәнең җылы фатирында, затлы келәмендә йоклап гомер кичергәнсеңдер. Ә шулай да чыгып качкансың. Әллә хуҗаңа хыянәт иттеңме? Бәлки, хуҗаңнан адашып калгансыңдыр, бәлки, хуҗаң сине үзе адаштыргандыр... Юк, үзең чыгып качкансың. Ирек эзләп. Ә адәм баласына ирек бирелми. Тугач та кулына, авырлыгын, буен үлчәп, тамга тагалар. Гомер узган саен, шул тамганы алмаштырып кына торалар. Йөрәге тибүдән туктагач та, шул тамганы илтеп тапшырмыйча, бичараны җирләмиләр. Үлгәч, илтеп биргәч тә, сортларга аерып, кабер ташыңа элеп куялар.

Сез ирекле, сезгә тамга кирәкми. Теләгән җирегезгә барасыз, теләгән җирегездә йоклыйсыз, сездән кесәгезнең ниндилеген сорамыйлар. Тамга да сораучы юк. Ә безгә, адашкан бәндәләргә, вокзалның таш идәнендә дә йокларга ярамый. Салкын кыш дип тормыйлар, яңгырлы көз дип тормыйлар, нигә идәндә йоклыйсың, нигә бу көнгә төштең диеп сорамыйлар, бер ишектән керәсең, икенче ишектән арт якка тибеп чыгаралар. Әгәр шул вакыт кесәңдә тамгаң булмаса, ташкапчыкка салырга да күп сорамыйлар. Ә сезнең халык, киерелеп, сузылып, вокзалның җылы батареясына аркасын куеп, эскәмия астында рәхәтләнеп йокы симертә. Көнләшәм мин сездән. Валлаһи, көнләшәм. Эт булып тумаганыма үкенеп куям. Синең әле туган авылың капкасы төбендә сине озатып калган мәхәббәтең, ягъни синең кайтуыңа өметен өзеп, бүтәнне яр иткән сөйгәнең Назлыгөлең дә, ят җирләрдә йөрәгеңнән өзелеп төшеп калган, үз күз алдыңда баю нияте белән кемнәрдер наркоман ясаган ике улың да юктыр. Булса да, алар — сине, син аларны белмисең. Һәрхәлдә, синең балаларың минекеләрдән бәхетлерәктер. *(Машина килеп туктаган һәм ишекләр ачылган тавыш ишетелә.)* Әнә, күрәсеңме, Акбай, нинди затлы машина килеп туктады. Күрәсеңме, важный кыяфәт белән синең туганың төшеп килә. Кара син аның кыяфәтенә. Ул буй, ул озын муен, ул озынча аяклар, өстендәге туны гына ни тора. Күрәмсең, парикмахерскийдан кайтып килә.

Сезнең халык, эт малае диеп уйламассың. Үзеннән хушбуй исе килеп тора. Затлы шампунь белән юганнар. Ә муенындагы каешы? Алтын-көмеш, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән. Чылбыры исә — чиста көмеш. Ә шулай да ул синнән күпкә бәхетсез. Ирексез ул! Муенында коллык билгесе. Кол ул! Коллык билгесе никадәр алтын-көмеш белән бизәлсә, андый коллыктан котылу мөмкин түгел. Андый коллыктан качу мөмкин түгел. Җиде кат җир тишегенә качсаң да, барыбер эзләп табалар. *(Күзе җирдәге кырмыскага төшә. Бармагы белән аңа төртеп.)* Акбай, Акбай, кара әле бу мәхлук җан иясен. Үзеннән дә зуррак йөк күтәргән. *(Кырмысканы кулына мендерә. Бармагына карап.)* Әй бичара, бичара, бүсереӊ чыга бит. Менә минеке кебек гомереӊ чыга бит. Кем өчен?! Балаларың өченме?! Кирәкми, кирәкми, туган, көчәнмә. Җир өстендә физик көч белән үзе теләгәнчә рәхәт яшәгән бер генә җан иясен дә күргәнем, очратканым юк әле. Кем өчен тырышасың, сөйгәнең өченме? Сөйгәнең өчен булса, ялгышасың. Үземнән чыгып беләм. Сөйгәннәр безне бөтен булганыбыз белән яратырга тиеш. Чын мәхәббәт шул чагында гына була. Байлык өчен сөйгәннәрдән ерак йөрергә кирәк. Әллә син дә, минем кебек әниеңнең фатихасын алмыйча, Ходай тарафыннан каргалып, чит-ят җирләрдә хәер сорашып йөрүче мосафирмы? Алай дисәң, күтәргән йөгең бик мул. Әллә юл басучымы, йә булмаса, угры, каракмы син?! Кемнеңдер байлыгын бастыңмы? Әллә узган алдагы тормышыңда хаталарың күп булып Ходай үзеңә шундый зур йөк тагып җибәрдеме? Әллә ана кортка ярарга тырышып йөргән көнеңме? Ә ул синең барлыкны беләме? Юк, белми! Иманым камил, белми. Белсә, ул сине шундый итеп бүләкләр иде. Дивана адәм балаларын алдаган кебек, түшеңә тимер медаль-орденнар асып, кесәңне буш итәр иде. Әйт әле, Акбай, әгәр Ходай миңа икенче гомер бүләк итсә, нәрсә итеп яратыр иде микән?

Юк, мин адәм булмас идем. Чү... Монысы тагын нәрсә. *(Бал корты очкан тавыш ишетелә. Кулларын изәп, бал кортын куа башлый.)* Кит, кит, мәлгунь, йөзең кара! Харап итәм бит үзеңне. Минем сиңа нинди зыяным тиде? *(Шап итеп битенә суга.)* Менә үзеңне харап та иттем. *(Бал кортын учына сала.)* Нигә кирәк иде? Нинди зыяным тиде? Үз гомереңне куркыныч астына куеп, нигә мине эзәрлекләргә иде? Кем өчен?! Үзең өченме, әллә балаларың өченме?! Бәлки, ана корт өчендер? Әллә син дә мине соры кортка тиңләдеңме? Ялгыштың син, туган, ялгыштың. Сабый чактан синең балыңны авыз иткәнем булмады. Авызым минем хәтта кара икмәккә дә туймады. Бөкрем чыкканчы ләмкә тарттым, йә, кем булам мин? Әллә мине чит иттеңме? Мин дә бит синең кебек шушы җирнең чәчәкле аланнарында уйнап үскән, кура җиткергән, каз көткән газиз баласы. Адаштым, чыгалмадым, юл күрсәтүче тапмадым, әй бичара, бичаракаем... Көтәрләрме безне? Безнең өчен яшь түгүчеләр булырмы!.. Әллә мин дә, синең кебек үз нигеземә кайта алмыйча, шәһәр чүплегендә җан бирерменме?! Синең кебек хәбәрсез югалырмынмы яисә туфрак булырмынмы? Ә шулай да син миңа караганда бәхетлерәк. Чәчәктән чәчәккә кунып яшәдең дә үзеңә җирләүче таптың. Хуш, сау бул, җан иясе. *(Бал кортын җиргә куя да учы белән туфрак алып аның өстенә сала.)* Синең мәңгелек йортың шушы булыр. Авыр туфрагың җиңел булсын.

Ә мине кем җирләр, Акбай? Кем миңа ясин чыгар да кем миңа туфрак ташлар? Чит җирләрдә торып калган улларыммы, әллә башка диндәге хатыныммы? Юк шул, Акбай, мин әнием җеназасында булмаган кебек, алар да миңа туфрак салмаслар. Бәлки, беренче мәхәббәтем Назлыгөл салыр... Юк, юк, сүземдә тора алмаганымны кичермәс.

Әгәр миңа Ходай тагын бер гомер бүләк итсә, беләсеңме, Акбай, мин нәрсә булыр идем. Мин, мин... *(Шул вакыт сандугач сайраган тавыш ишетелә.)* Мин сандугач булыр идем, әнә, күрәсеңме, сандугач сайрый. Сары сандугач. Мин дә бит үз халкымның сайрар сандугачы, сайрар кошы, кунып сайрар тирәген тапмаган, адашкан бер былбылы идем. *(Сумкасыннан икмәк төрелгән целлофан пакет ертып ала да, ирennәренә китереп, сандугач кебек сайраган тавыш чыгара. Ул сайрый, сандугач тына, сандугач сайрый, ул тына. Озак кына сандугач сайравын тыңлап торганнан соң.)* Их, Акбай, мин дә бит үз авылымның сайрар кошы идем. Менә шушы тезләремдә тальян уйната идем. Урманына керсәм, кура өзеп аңа җан өрә идем. Халкымның кайгысын да, шатлыгын да шушы бармакларым белән кура буыныңдагы сулышымны бүлеп, тирә-юньгә, болын-урманнарга моң аша сөйли идем. Хәзер инде бу бармакларда моң түгел, кан тама. *(Җырлый.)*

Нинди ямьле безнең үзәннәр,
Түшәлгәннәр йомшак хәтфәләр.
Ак чәчәкләр, яшел үзәннәр
Яшьлегемне хәтерләтәләр.

Яшьлегем дип өзелеп җырлар идем,
Өзелеп җырлый торган җыр булса,
Яшьлегемә йөгереп кайтыр идем,
Кире кайта торган юл булса. *(Иҗекләп.)*
Йө-ге-реп кай-та тор-ган ла юл бул-са...

*(Озак кына паузадан соң.)* Минсез авылда мәҗлесләр узмый иде, минсез солдат озатмыйлар иде, минсез туй туй түгел иде, минсез кичке уеннар узмый иде, минсез яшьләр клубка чыкмый иде. Минем тальян моңыннан башка авыл йокыга талмый иде. *(Сандугач сайравына сискәнеп китеп.)* Сайрама, сандугач, сайрама. Өзмә үзәкне, актарма күңелне. Кайтарма яшьлекне, калсын ул тәмле төш булып. Тирәгеңә кайт. Синең урының шәһәрдә түгел, авылда, инеш буйларында, тирәктә. Туган җиреннән, туган төбәгеннән аерылган җан озак сайрый алмый, аңлыйсыңмы, сайрый алмый. *(Җырлый.)*

Сайрамачы, сандугач, ник сайрыйсың,
Өзелә үзәк синең тавышка.
Сайрыйсыңмы син дә минем кебек,
Түзә алмыйча кайгы-сагышка!

Сайрамачы, былбыл, әй, каршымда,
Сайра бишек талларда.
Син сайрамасаң да, мин беләмен,
Кайгы-хәсрәт минем башымда.

Сайрама, дускай, сайрама. Кире кайтарма мине узганнарыма. Калсын алар, калсын матур төш булып. *(Сикереп, кулларын чәбәкләп.)* Көш-көш, тинтәк кош! Көш-көш, адашкан сандугач! Читтә бәхет табып булмый, читтәгеләр безнең көйне аңламый. *(Өзгәләнеп.)* Аңламыйлар. *(Үз-үзенә.)* Аңламыйлар... Ишетәсеңме, аңламыйлар. Үз талыңа кунып сайрауга ни җитә. *(Хәлсезләнеп.)* Көш... көш... *(Күккә карап.)* Очты асыл кош, очты сайрар кош. Минем хыялларым кебек юкка чыкты асыл кош. Күрәсеңме, Акбай, зәңгәр күктә сары төс калды. Минем язмышыма кунган көз төсле. Ә мин оча алмадым. Кагындым, оча алмадым. Талпынып-талпынып карасам да, оча алмадым. Әнә, Акбай, күрәсең, кояш та югарыга үрмәли. Кыздыра. Кыздырма, кояш, кыздырма! Тәнемне җылытсаң да, чит җирләрдә йөреп бозланган йөрәгемне, күңелемне җылыта алмассың. Җылытса җылытыр аны бары туган җир. Әйдә, Акбай, кил яныма. Минем якларга кайтыйк. Чит илләрдә солтан була алмадым. Олтан булу кадерлерәк үз илеңдә. *(Йөк күтәргән кыяфәт ясап, салмак кына сәхнәдән кузгала.)*

Көй яңгырый.

Ут сүнә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әкрен генә сәхнә алдын прожектор яктырта. Прожектор яктысында
Хөрмәт, чүгәләгән хәлдә, тәбәнәк өстәл артында язып утыра.

*Искәрмә: ул автор ролендә.*

Автор.

Бу бәянны сөйләдем мин сезгә гыйбрәт өчен,
Бәхет эзләп читкә китеп туфрак булган
халкым — татар өчен.
Хөрмәт дигән бәндә, бәлки, булмагандыр.
Мин тудырган бер ялгандыр, уйдырмадыр.
Тик шунысын беләм — минем авыл бик борынгы,
Зират читендә үсә алагаем зур өянке.
Картлар аны, бер мосафир бәхет эзләп бездән киткән
Авылдашның кабере, диләр.
Ташы да бар иде, тик язусыз,
Эт сурәте төшкән иде, диләр.
Бу бәяным кемгә охшар, әйтә алмыйм,
Алдыгызга салдым, шуңа күрә аңа сез хөкемдардыр.
Тик сулышым белән шуны тоям,
Күп татарлар бәхет эзләп чит җирләрдә
туфрак булган.

Китапны өстәлгә куя да, әкрен генә торып, сәхнәдән чыгып китә.

Музыка.

Пәрдә.
*2004*

# ӘНИ БУЛАСЫМ КИЛӘ

*Мелодрама ике пәрдәдә, унике күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Таңсылу — төп героиня, Флора ханым.
Рәшидә апа — Таңсылуның әнисе.
Айдар — Таңсылуның ире.
Эльза — аларның кызлары, журналистка.
Ратмир — Таңсылу белән Расихның малае.
Ләйлә Гомәровна — балалар йорты мөдире.
Табибә.
1 нче суд утырышчысы.
2 нче суд утырышчысы.
Загс хезмәткәре.
Расих.
Врач.
Судья.
Артистлар.
Ике солдат.
Шаһитлар.

Вакыйга бүгенге көннәрдә шәһәр җирлегендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капкадан уртача гына киенгән, кыршылган чемодан күтәргән илле яшьләр тирәсендәге Таңсылу чыга. Ул як-ягына карана да, авыр сулап, һаваны ярып кычкырган каргалар төркеменә озак кына карап торганнан соң, төрмә ишек төбендә басып торган берничә кешегә күз сала. Бу кешеләр арасында Айдарның юклыгын күрә һәм баруын дәвам итә. Парк эчендәге эскәмиягә Ләйлә Гомәровна янына барып утыра. Куллары белән битен каплап торганнан соң, янә башын күтәрә.

Ләйлә Гомәровна. Исәнмесез!
Таңсылу (*сискәнеп китеп*). Бу шәһәрнең вокзалы еракмы?
Ләйлә Гомәровна. Белмим шул. Бу шәһәрдә мин үзем дә беренче тапкыр. Бирегә бу шәһәргә ирем белән шәхси машинабыз белән килдек. (*Таңсылу китмәкче була.*) Туктагыз, китәргә ашыкмагыз. Биредә сезне каршы алучы бары тик мин генә. Сез мине танымыйсыз?
Таңсылу. Юк, танымыйм.
Ләйлә Гомәровна. Картайганмынмыни, үзгәргәнменмени?
Таңсылу. Мин сезне беренче тапкыр күрәм.

Ләйлә Гомәровна. Без сезнең белән ундүрт ел элек фатирыгызда очрашкан идек. Хәтерлисезме?
Таңсылу. Юк, мин бернәрсәне дә хәтерләмим. Һәм хәтерләргә дә теләмим.
Ләйлә Гомәровна. Сез бит Таңсылу Хәмитова?!
Таңсылу. Ялгышасыз, мин Таңсылу гына. Мин кузгалыйм әле.
Ләйлә Гомәровна. Кая ашыгасыз?
Таңсылу. Үзем дә белмим.
Ләйлә Гомәровна. Без сезне каршы алырга килдек. Әйдә безгә кайтыйк.
Таңсылу. Рәхмәт. Мин үз ягыма, авылыма юл тотмакчы булам.
Ләйлә Гомәровна. Вакыт соң. Кем белә, әллә авылыгызга билет ала аласыз, әллә юк. Аннары авылда сезне көтеп торучы кеше дә юк. Әниең моннан дүрт ел элек вафат булды.
Таңсылу. Беләм.
Ләйлә Гомәровна. Улыгыз Ратмир турында берәр нәрсә беләсезме?
Таңсылу (*сискәнеп китә).* Аның белән нәрсә булды?
Ләйлә Гомәровна. Сезгә нәрсә булды? Сезгә, бәлки, дару кирәктер? Йөзегез агарып китте.
Таңсылу. Ратмир белән нәрсә булды?
Ләйлә Гомәровна. Юк... Берни дә булмады. Ул Парижда яши.
Таңсылу. Парижда?!
Ләйлә Гомәровна. Чын источникларга таянып әйтмим, кеше сүзе.
Таңсылу. Парижда яши дисез инде?! Кызык...
Ләйлә Гомәровна. Айдар Айдарович турында нигә берни дә сорамыйсыз?
Таңсылу. Аның хакында да бик яхшы беләм. Яңа тормыш корган, яшь хатын, олы гына оешманың генераль директоры. Эльза кызым белән Луиза кызым ни хәлләрдә?
Ләйлә Гомәровна. Эльза быел көзен үзе белән бергә университетта, юрфакта укыган егеткә кияүгә чыкты. Ә үзе, журналистика факультетын тәмамлап, телевидениедә «Ана һәм гаилә» дигән тапшыру алып бара. Ә Луизагыз Мәскәүнең Ломоносов исемендәге университетында психология факультетының өченче курсында укый.
Таңсылу. Алар минем барлыгымны беләләрме?
Ләйлә Гомәровна. Юк, ахрысы. Алар сезне Рига шәһәрендә күмелгән дип уйлыйлар.
Таңсылу. Менә монысы өчен рәхмәт.
Ләйлә Гомәровна. Ә шулай да сез мине таныдыгызмы?
Таңсылу. Яшермим, таныдым. Картайгансыз, ябыккансыз, картлык төсмерләре йөзегезгә чыккан. Таныдым, әлбәттә, таныдым. Минем улым яшәгән детдом җитәкчесе Ләйлә Гомәровна бит сез!
Ләйлә Гомәровна. Сез үзегез дә танымаслык булып үзгәргәнсез. Урамда очрашсак, валлаһи, танымас идем.
Таңсылу. Ундүрт ел төрмә паегы үзенекен эшләгәндер. Зыян юк. Башка кияүгә чыгасым юк. Ә хәзер сау булыгыз. (*Урыныннан тора да китмәкче була.*)
Ләйлә Гомәровна (*аның артыннан*). Сез юкка миңа рәнҗисез. Мин бит сезнең балагыз — улыгыз Ратмир өчен.
Таңсылу. Барыбер чемпион була алмады. Ә менә Эльза белән Луиза әниләренең кабере Ригада дип яшиләр. Әниләре исән була торып ятим үстеләр.
Ләйлә Гомәровна. Бәлки, миңа кайтырбыз? Мин бит сезнең арттан килдем.
Таңсылу. Детдомгамы? Минем яшем детдом яшеннән чыккан инде. Берсен сезгә калдырып, үзем төрмәгә кереп, өч баламны да бәхетсез иттем бит инде. Сау булыгыз. (*Китеп бара.*)
Ләйлә Гомәровна (*аны куып тота да*). Ә кем уйлаган болай килеп чыгар дип. Мин бит әнилек хисе белән Ратмир өчен, аны дөньяга тапкан сезнең өчен яхшы булыр дип уйладым.
Таңсылу. Сезнең бөтен ялгышыгыз да шунда: бер баланы бәхетле итәм дип, калган икесе турында уйламавыгызда.
Ләйлә Гомәровна. Минем сезне каршы алуның төп сәбәбе нәрсәдә икәнен беләсезме?
Таңсылу. Белмим. Белергә дә теләмим.
Ләйлә Гомәровна. Мин эшләгән балалар бакчасында, интернатта, шундый вундеркинд бала бар. Ул, һичшиксез, дөньякүләм танылган классик язучы булачак. Философ!
Таңсылу. Аңа ничә яшь?
Ләйлә Гомәровна. Быел уналты тула, соңгы елын укый. Ул сезнең турыда роман язмакчы була. Коеп куйган философ.
Таңсылу. Уналтыда философ булып булмый. Философлар төрмәдә. Юкка вакытыгызны сарыф итәсез.
Ләйлә Гомәровна. Нигә алай дисез?
Таңсылу. Һәр кешенең язмышы маңгаена язылган. Насыйп булса, сезнең ярдәмсез дә үз теләгәненә ирешер.

Ләйлә Гомәровна. Минем профессиям яшь буынны тәрбияләү. Әтисез-әнисез калган балаларны олы тормыш юлына чыгару.

Таңсылу. Әти-әнисе исәннәрме?

Ләйлә Гомәровна. Юк, юк. Роддомда шушы баланы тудырганда әнисе үлгән, әтисе — билгесез.

Таңсылу. Уналтыда философ та, олуг язучы да булалмас. Әлегә тамагын туйдырырлык хикәяләр яза алса да, аның өчен зур уңыш. Мин өч бала анасы. Берсенә дә бәхет бирә алмадым. Бәлки, чыннан да, минем гыйбрәтле язмышым аның талантын ачуга ярдәм итәр. Киләчәктә зур язучы булып китәр. Мин риза.

Ләйлә Гомәровна. Ә сезне ничек эзләп табарга?

Таңсылу. Мин сезне үзем эзләп табармын. Мин сезнең ишекне каккан кеше. Көннәрдән бер көнне килеп кагармын.

Ләйлә Гомәровна. Дөрес, бәлки, мин сезнең алдыгызда гаепледер.

Таңсылу. Мин үземнең язмышымда берәүне дә гаепләргә җыенмыйм. Ходай тарафыннан бәхетсез булып туган бәндә мин. Мин дөньяга килгәч тә, әтиемнең үлеме, авыру әниемнең утыз сум пенсиясенә гомер кичерүебез, яшьтәшләрем уйнаганда, «уфалла» тартып дөнья көткәннәрем, ач-ялангач, сыңар күлмәк белән шәһәргә чыгып китүем, санап китсәң, башка сыймаслык хәлләр. Язмыш нык кыерсытты мине. Арыдым, бу дөньядан туйдым мин. Соңгы тапкыр ерактан гына булса да балаларымны күрсәм, бөтенләйгә китсәм дә үкенмим. Сау булыгыз. (*Китеп бара.)*

Ләйлә Гомәровна. Нигә кирәк? Кем өчен йөрим? Балалар, интернат балалары өчен йөрим. Араларыннан берәр гений чыгар да, интернатыбыз баер дип йөрим. Ә киресенчә килеп чыга.

Ут сүнә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таңсылу. Алло, телевидениеме? Миңа Эльза Айдаровна кирәк иде?

Эльза. Эльза Айдаровна мин булам. Тыңлыйм сезне.

Таңсылу. Мин гаиләмне югалткан бер ханым булам. Сезнең «Ана һәм гаилә» дигән телевизион тапшыруыгызны яктыртырдай, тормыштан алынган бик гыйбрәтле сюжетым бар. Бәлки, ул сездә кызыксыну уятыр. Миңа гонорар кирәкми, миңа бары тик меңләгән тамашачының фикере һәм тамашачыларның сезнең шушы тапшыруыгызга булган мәхәббәте артуы кирәк. Әгәр минем сюжетым сезгә ошамаса, мин сезнең вакытыгызны алганым өчен мең тапкыр гафу үтенәчәкмен.

Эльза. Безнең программабыз өчен янып-көеп яшәвегезгә зур рәхмәт. Сез безне сөендердегез. Без сезнең белән очрашырга каршы түгел. Тик шунысы кирәк, исемегез ничек була?

Таңсылу. Флора.

Эльза. Фамилиягез?

Таңсылу. Фамилиям... Фамилиям Садыйкова.

Эльза. Әгәр дә сезнең сценариягез безгә ошаса, сез проектта катнашудан баш тартмыйсызмы?

Таңсылу. Анысы минем өчен мөһим түгел. Мин тележурналистка да, язучы да түгел. Мин бары тик әни генә булып караган гади бер хатын.

Эльза. Телефоныгызны калдырсагыз яхшы булыр иде.

Таңсылу. Кызганычка каршы, мин бу дөньяда иллегә якынлашып барсам да, минем телефоным да, фатирым да юк.

Эльза. Алайса, Флора ханым, сез безне гафу итегез. Без сезнең белән ничек элемтәгә керә алырбыз?

Таңсылу. Сез дүртенче номерлы балалар бакчасын беләсезме?

Эльза. Билгеле, беләм. Минем сеңлем белән бергә йөргән бакча ул.

Таңсылу. Сезгә авыр булмаса, мин сезне шул бакча каршысындагы эскәмиядә көтәр идем. Сәгать тугызда очрашсак ничек булыр?!

Эльза. Яхшы, димәк, тугызда.

Таңсылу. Эльза балакай, кемгә кемгә, мин сезгә беркайчан да авырлык эшләргә тырышмам. Сценарием ошамаса, мине кичерерсез дип уйлыйм.

Эльза. Нигә алай? Безгә төрле сценарийлар килә. Хәтта күренекле авторлардан да бик слабый әсәрләр килгәли. Без башта сезнең сценариегызны худсовет белән берлектә укып чыгарбыз, әгәр ошый икән, кабул итәрбез. Ошамаса, кире кайтарырбыз. Сез безнең тапшыруны даими карап барасызмы?

Таңсылу. Кызганычка каршы, бер генә тапкыр күрү бәхетенә ирештем. Мине иң куркыткан нәрсә сценарийда катнашу.

Эльза. Борчылмагыз, безнең тапшыруда автор үзе тамашачы буларак кына катнаша. Сценарийдагы образларны безнең профессиональ актерлар башкара.

Таңсылу. Рәхмәт, кызым Эльза. Иртәгә сценарием сезнең кулыгызда булыр.

Музыка. Ут сүнә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, балалар бакчасы каршындагы эскәмиядә юынмаган, кырынмаган, сукбай кыяфәтендә Ратмир белән Таңсылу утыралар.

Ратмир. Ничек син мине эзләп таптың?

Таңсылу. Төрмәдә чыбыксыз телефоннар яхшы эшли. Мин синең кайдалыгыңны, ничек көн иткәнеңне, һәр минутыңны, һәр сәгатеңне белеп яшәдем. Өч ел гомереңне төрмәдә үткәргәнеңне дә беләм.

Ратмир. Төрмәдә яшәү миңа авыр булмады. Мин бит детдом баласы. Әни, бир миңа нибары ун сум?! Ун гына сум бир?!

Таңсылу. Юк бит, юк, Ратмир!

Ратмир. Үтермә, бир. Әнә аптека?! Шуннан ун сумга бер флакон гына алып эчәм дә кеше булам бит мин.

Таңсылу. Юк бит, балам! Юк бит!!!

Ратмир. Балам?! Балам, дисеңме?! Үз гомереңдә бер генә тапкыр булса да балаңа, ягъни миңа ярдәм иткәнеңне хәтерлисеңме?

Таңсылу. Кичер! Итә алмадым шул. Итә алмадым, кичер!

Ратмир. Нигә таптың?! Ни өчен?! Нигә кирәк иде?.. Детдомга ыргытырлык булгач, үзең карый алмагач, нигә таптың?! Үзеңнең постельдәге биш минутлык рәхәтең өченме?! Синең биш минутың — минем гомерлек газабым. Син аның белән ул минутларда рәхәтлек кичергәндә, минем хакта уйладыңмы?

Таңсылу. Мин ул минутларда да, хәзер дә, гомерем буе газап утында янып яшәдем.

Ратмир. Детдомда миңа яшәүләре җиңел булмады. Олы яшьтәге малайлар кыйнап, кышкы салкында яланаяк ягылмаган салкын коридорга куып чыгаралар иде дә аяклар бозлы идәнгә ябышып катканчы тоталар иде.

Таңсылу. Тәрбиячеләр нәрсә карый иде?

Ратмир. Үз анасына кирәкмәгән бала чит кешегә кирәкми. Кошлар булып кошлар да, хайван булып хайваннар да чит баланы кабул итмиләр.

Таңсылу. Юк, юк, син миңа кирәк идең. Кирәк идең, улым... Тик...

Ратмир. Кирәк булгангамыни, бер генә тапкыр да яныма килеп карамадың?!

Таңсылу. Килә алмадым шул, килә ал-ма-дым!..

Ратмир. Ә мин сине көттем. Үз-үземне белә башлаганнан бирле көттем. Детдом тәрәзәсеннән күземне алмый көттем. Син килерсең дә йомшак кулларың белән минем башымнан сыйпарсың, «Бу минем улым» дип дәшәрсең дип көттем. Ә син килмәдең. Рәхмәт әбигә. Баштагы мәлне ул минем янга килгәләде. Көннәрдән бер көнне ул да килмәс булды.

Таңсылу. Каберенә барганың бармы?

Ратмир. Юк! Минем өчен кабер дә, нәсел дә юк. Мине әбигә бирмәделәр. Мине әбигә бирмәделәр, әни! Ул бит мине күпме үзенә алырга тырышып йөрде. Мине әбигә бирмәделәр. Әбидә йогышлы чир иде. Әбидә туберкулез иде. Әгәр шул вакытта мине әбигә биргән булсалар, мин бит инде бу шыксыз, караңгы дөньялыктан әллә кайчан котыла идем. Дөньялыкта күргәннәрем үзенекен итте, ул чирне мин барыбер төрмәдә эләктердем. Аңлыйсыңмы, әни, эләктердем! Мин тәрәзәсез, ишексез ташландык өйләрнең подвалында йоклаганда, гел әбиемне исемә төшереп, төшләремә керсен иде дә үзе белән ияртеп мәңгелеккә алып китсен иде дип теләк теләп йокыга тала идем. Мин мәңгелектә — теге дөньяда сине табармын кебек идем. Әби сине «үлде» диде. Син ник үлмәдең?! Син ник үлмәдең, әни?.. Үлгән булсаң, без бит синең белән мәңгелектә кешечә очрашкан булыр идек.

Таңсылу. Озак калмады, балам! Кичер! Озакламый җитәкләшеп мәңгелеккә китәрбез. Син, дөньялыкта күргән газапларың өчен, һичшиксез, оҗмахка эләгерсең, ә мине нәрсә көтә анда?.. Нәрсә көтә?.. Анысы бер Ходай кулында.

Ратмир. Мин калтырыйм. Мин калтырыйм, әни! Бир, бир, зинһар өчен, ун сум?! Соңгы тапкыр, соңгы тапкыр мин синнән үтенеп сорыйм. Коткар мине. Гомерем эчендә мин синнән беренче һәм соңгы тапкыр бары тик ун сум сорыйм.

Таңсылу. Юк бит, юк. Җанымны сора, бирәм. Әмма башка сиңа ярдәм итәр чарам юк. Моңарчы тамагыңны ничек туйдырдың соң син, бала?..

Ратмир.  Акчага шахмат уйнадым. Башта ота идем. Шул акчага эчә идем. Соңрак оттыра башладым. Бурычка баттым. Бурычымны түләр өчен вокзалдан чемодан урладым. Өч елга утырттылар.

Таңсылу. Әбиеңнең өен нишләттең?

Ратмир. Синең ни эшең бар?! Йорт минеке! Йорт минеке иде. Әби үлгәндә, минем исемгә завещание язып калдырган. Йорт минеке! Йортта синең өлешең юк! Аңлыйсыңмы, юк! Мин ул йортны, әбием йортын, шахмат уйнап оттырдым. Аңлыйсыңмы, үз малымны үзем оттырдым!

Таңсылу. Аңлыйм. Барысын да аңлыйм. Минем сиңа гаеп тагарга бер генә дә хакым юклыгын мин бик яхшы аңлыйм...

Ратмир. Миңа эти булырга тиешле кеше исәнме?

Таңсылу. Юк! Ул исән түгел! Ул үлгән! Аңлыйсыңмы, ул үлгән! Синең өчен дә, минем өчен дә ул күптәннән үлгән!

Ратмир (*Таңсылуның алдына тезләнеп*). Зато син исән. Әни, бир, үтермә, җаным чыга?! Бир ун сум акчаңны, бир, әни?!

Таңсылу. Сайлаган юлың уң иде бит, ник тайпылдың, балам?!

Ратмир. Атларым абынды, офицерларым сатылды, солдатларым алынды, королем әсирлектә калды. Сындырдылар мине, әни... Юлымда, шахмат тактасында, миннән дә көчлерәк атларына атланып ут уйнатучылар очрады миңа, әни. Минем өчен барысы да бетте. Пешка хәлендә калдым мин, әни.

Таңсылу. Пешка да король була ала.

Ратмир. Шахмат уйнаудан гайре бу дөньяда мин бернәрсә эшли белмим. Ул да минем күз алдымда мираж булып эреп юкка чыкты. Күзем сукырайды, аңым томаланды. (*Җырлый.)*

Әй атларым, атларым,
Атларым — малкайларым.
Туры юлга чыккан чакта,
Тугарылды атларым.
Әй атларым, атларым,
Атсыз калган башларым,
Җир өстеннән атлаганда,
Калды ялгыз башларым.
Әй башларым, башларым,
Атка менгән башларым,
Кире юлга борылырга
Калмады хәлкәйләрем.
Әй атларым, атларым,
Инде ничек атларым?!
Ат та бетте, баш та бетте,
Мәңгелеккә ничек атларым?

Таңсылу. Их бала, бала... «Балам» дисәм, хакым юк. Ратмир, аңла! Нишлим?.. Мин сиңа ярдәм итә алмыйм. Теге дөньяга мин төрмәдән түгел, юньле адәмнәр яшәгән җирдән, урамнан булса да китәсем килә.

Алар янына Эльза килә.

Эльза. Исәнмесез! Сез Флора ханым Садыйкова буласызмы?

Таңсылу (*сискәнеп китеп).* Әйе, мин Флора булам.

Ратмир. Флора? Ничек Флора?!

Эльза. Ә бу кеше кем була?

Ратмир. Сиңа барыбер түгелмени, сеңлем, кирәк-кирәкмәгән җиргә башыңны тыкма, башсыз калырсың.

Таңсылу. Юк, юк, ул минем улым.

Ратмир. Әйе, әйе, сеңлем, мин бу ханымның улы булам. Сеңлем, бәгырькәем, коткар! Зинһар, ун сум гына акча биреп тор?!

Эльза. Эшләргә кирәк, абый, эшләргә!

Ратмир. Беләм, сеңлем, беләм.

Эльза. Сезгә шушы яшегездә хәер сорап йөрергә оят!

Ратмир. Беләм, сеңлем, беләм! Документларымны югалттым. Эшкә урнашып булмый. Коткар абыеңны, сеңлем! Бер атна тамагыма бер сынык икмәк капканым юк.

Таңсылу. Эльза, зинһар, кичер! Хәтта әйтүе дә читен, мин акчамны, бумажнигымны өйдә калдырганмын, мөмкин булса, биреп тор аңа ун сум. Мин сиңа иртәгә үк ул ун сумны кире кайтарырмын.

Эльза (*бумажнигыннан ун сум алып Ратмирга бирә*). Мә, абый! Синнән котылып булмас.

Ратмир (*Эльза алдына тезләнеп*). Рәхмәт, рәхмәт, туганым! Век не забуду! Рәхмәт, сеңлем, рәхмәт, туганкаем! Әни, мин хәзер киләм. (*Китә.*)

Эльза. Ана өчен нинди хәсрәт?

Таңсылу. Кирәкми, кирәкми, Эльза! Кагылма аңа. Аңа авыр сүз әйтергә ярамый.

Эльза. Ни өчен?

Таңсылу. Ул бу җиргә үзе теләп килмәгән.

Эльза. Котлыйм сезне! Сезнең сценариегыз худсовет тарафыннан йөз процентка кабул ителде. Сценариены җомга көн кич белән унтугыз сәгатьтә күрсәтәбез. Сез үзегез дә катнашырсыз дип уйлыйбыз.

Таңсылу *(эскәмиягә барып утыра*). Эльза кызым, яныма утырыгыз әле. (*Эльза утыра.*) Катнашырга дисез инде... Катнашуым бик кирәкле булмаса, мин экраннан гына карар идем.

Эльза. Телевидениенең художественный советының сезнең белән якыннан танышасы килә. Сезнең сценариегыз соңгы вакытта безнең эфирга килеп эләккән сценарийларның иң уңышлысы дип табылды. Киләчәктә без сезнең белән тыгыз элемтә урнаштырырга телибез.

Таңсылу. Кызганычка каршы, бу минем беренче һәм соңгы язмам.

Эльза. Флора ханым, сез бу сюжетны кайдан алдыгыз?

Таңсылу. Тормыштан.

Эльза. Бу хәл сезнең үзегез белән булдымы?

Таңсылу. Юк, бер танышым сөйләде.

Эльза. Сценарийдагы образларны чын исемнәре белән алдыгызмы?

Таңсылу. Монысы сер булып калсын.

Эльза. Сценариегызның исемен ничек дип атар идегез?

Таңсылу. Ә сез ничек уйлыйсыз?

Эльза. «Кем гаепле?»

Таңсылу. Юк, минем уемча, «Әни буласым килә».

Эльза. «Әни буласым килә». Кызык... «Әни буласым килә». Әйбәт. Әйбәт исем. Уйландыра торган. Сценарийның эчтәлегенә бик тә туры килә.

Таңсылу. Кызым Эльза, син үзең әни кешеме?

Эльза. Әлегә юк. Күптән түгел генә тормышка чыктым. Озакламый әни булырга җыенам.

Таңсылу. Әни булу теләгең зурмы?

Эльза. Билгеле. Хатын-кыз өчен әни кеше булудан да зур бәхет юктыр.

Таңсылу. Белгәнемчә, сез журналистика факультетын бетергәнсез. Каян килеп сез телевидениедә шушы проектны ачарга булдыгыз?

Эльза. Кызык, бу сорауны миңа беренче булып сез бирәсез. Телевидениенең җитәкчелегенә шушы проектны җиткергәч тә мондый сорау бирүче булмаган иде. Мин ятим үстем. Мин әнисез үстем. Сеңлем Луизага алты, миңа тугыз яшь чагында әниебез Ригада үлеп калды.

Таңсылу. Алай икән, сез элек Ригада яшәдегезмени?

Эльза. Юк. Әниебез Ригага командировкага киткәч, кире әйләнеп кайтмады. Автокатастрофага очрап дөнья куйды.

Таңсылу. Әниегезнең каберендә булдыгызмы?

Эльза. Кызганыч, сеңлем Мәскәү университетына укырга кергәч, әниебезнең каберен эзләп, Ригага бардык. Булмаган зиратыбыз калмады. Архивларны актарттык. Әниебезнең каберен таба алмадык. Әле дә булса эзлибез. Өмет белән яшибез. Әнисез үсү мине шушы проектны ачарга этәрде дә.

Таңсылу. Әтиегез аның каберен белми идеме?

Эльза. Юк, әни әтинең рөхсәтеннән башка командировкага киткән. Әти аны гомере буе кичерә алмады. Ул аны хәтта күмәргә дә бармады.

Таңсылу. Ә син, Эльза, үзең әниеңне хәтерлисеңме?

Эльза. Хәтерлим. Ул киткәндә, миңа бит инде тугыз яшь иде. Ә сеңлем Луизага — алты. Әниемнең ишектән чыгып киткәненә кадәр хәтерлим. Ул безне сеңлем белән күкрәгенә кысты да үксеп-үксеп елады. Соңгы сүзләренә кадәр хәтерлим. Кызым, диде ул миңа. Син зур кыз инде. Сеңлең Луизаны ташлама. Син аңа апа да, әни дә, диде. Әни китте. Икенче көнне әти безгә кайгылы, әниебезнең үлеме турында хәбәр алып кайтты. Сеңлем белән мине машинага утыртты да, бөтен мал-мөлкәтне төяп, башка шәһәргә күчеп китте. Без ялвардык, әтидән елый-елый үтендек. Китмик, әни кайтыр да безне көтеп ишек төбендә йөрер, дидек. Безне таба алмас, дидек. Юк, кайтмый ул, диде. Ә без көттек. Гомер буе көттек. Юк, кайтмады. Хәтта каберен дә таба алмадык. Флора ханым, сезгә ни булды? Сез нигә елыйсыз?

Таңсылу. Юк, зыян юк. Мин болай гына. Нигәдер күңелем тулды. Сез миңа игътибар итмәгез.

Эльза. Көннәрдән бер көнне әти яшь хатын алып кайтты. Ул бик әйбәт апа. Ул безнең әнине шул дәрәҗәдә алыштырырга теләде. Ул безгә игътибарлы булды. Әмма ләкин үз әниебезне алыштыра алмады. Бераздан өйдән әниебезнең карточкалары, аның кигән киемнәре юкка чыга башлады. *(Сумкасыннан кечкенә генә карточка чыгара да Таңсылуга бирә.)* Менә әниемнең истәлеге булып бердәнбер сакланып калган өчкә дүрт зурлыгындагы фотосурәте. Без аны Луиза белән зурайттык. Ул аның да, минем дә өстәлемдә саклана. Иртә белән озатып, кич белән каршы ала.

Таңсылу (*карточкага карап*). Син әниеңә охшагансың.

Эльза. Юк, мин әтигә охшаганмын. Ә менә Луиза суйган да каплаган әни. Йөреше, хәтта көлүләренә кадәр әни. Әти дә шулай ди. Шуңа күрә дә сеңлемне ныграк яратадыр.

Таңсылу. Әти-әни өчен баланың аермасы юктыр инде ул. Кайсы бармакны тешләсәң дә бертигез авырта.

Эльза. Флора ханым, мин сезгә карап-карап торам да, сеңлемә охшатам. Сез минем сеңлем Луиза белән шундый охшашлар, әйтерсең лә бертуганнар.

Таңсылу. Бәлкем... Дөньяда һәр кешенең двойнигы була, диләр бит.

Эльза. Фотога ныграк игътибар итегез әле. Андагы сурәт сезгә бик тә, бик тә охшаган.

Таңсылу (*сурәткә игътибар белән караган булып*). Ә мин охшашлык тапмыйм. (*Фотоны кире Эльзага бирә.*) Луиза исән-саумы?

Эльза. Аллага шөкер.

Таңсылу. Укуы ничек?

Эльза. Әйбәт. Ул безнең вундеркинд.

Таңсылу. Әтиегез?..

Эльза. Ул да әни белән матур гына яшәп ята.

Таңсылу. Әниегезне искә ала идеме?

Эльза. Юк. Әни турында сөйли башласак, сүзне икенчегә бора иде. Ул безне ничек тә үги әнигә якынайтырга тели иде. Әни үлгәч, сеңлем Луизага бик авыр булды. Аңа нибары алты гына яшь иде бит. Төннәрен «әнием» дип елап уяна иде дә үкси-үкси елый иде. Аны бары тик әниемнең исән калган бердәнбер эчке күлмәге белән яулыгы гына тынычландыра иде. Төннәрен мин, тугыз яшьлек бала, әниемнең эчке күлмәген киеп аның янына бара идем дә янына ята идем. Ул минем куенымда мышный-мышный йоклап китә иде. Әнием дип белгәндер, күрәсең. Көннәрдән бер көнне ул күлмәк тә юкка чыкты. Без ул күлмәкне күпме эзләдек, әмма таба алмадык. Сеңлем ул күлмәкне шундый юксынды.

Таңсылу. Эльза, гафу ит! Миңа китәргә кирәк.

Эльза. Флора ханым, әнә теге садикны күрәсезме? Әни безне иртә белән шунда илтә һәм кич белән алып кайта иде. Хәзер дә булса шуның койма ярыгыннан әниемнең елмаюлы карашын тоеп яшим мин. Ул койма артына чүгәләп утыра иде дә, елмайган рәвештә кулларын җәеп, безне үз кочагына ала иде. Ә без аның кочагына атлап түгел, абына-сөртенә йөгерәбез. Мин, бу койма яныннан узганда, тыныч күңел белән генә үтеп китә алмыйм. Колачын җәеп, әнием көтеп торадыр шикелле.

Таңсылу. Эльза кызым, әниеңнең әнисе, ягъни дәү әниегез бар идеме?

Эльза. Дәү әти үлгән, дәү әни бар иде. Әни үлгәч, авылдан көч-хәл белән өстерәлеп килде ул. Әти аңа: «Йортымның бусагасын атлыйсы булма, нәселегезне күрәсем килми. Синең сулышыңны минем сабыйларым тоярга тиеш түгел. Кызың тормышымны гына чәлпәрәмә китереп калмады, менә шушы сабыйларны да бәхетсез итте. Җитте миннән. Хватит!» — дип куып чыгарды. Дәү әнине без башка күрмәдек. Менә шул. Мин сезгә тагын бер гыйбрәтле вакыйга сөйләдем. Языгыз. Мин ышанам, сез моны җиренә җиткереп яза алачаксыз. Сез моны бөтен нечкәлекләре белән яза аласыз.

Таңсылу. Бөтен нечкәлекләре белән дисез инде... Исән бул, кызым! Мин бүтән яза алмам инде.

Эльза. Исән бул, Флора апа! Мин сезне эфирда көтеп калам.

Ратмир керә.

Ратмир. Әни, кем иде ул?

Таңсылу. Улым, ул... бер танышым.

Ратмир. Аңа синнән нәрсә кирәк?

Таңсылу. Ул миңа, миңа кирәк, улым Ратмир!

Ратмир. Сиңа аннан нәрсә кирәк?

Таңсылу. Аның сабый чагы.

Ратмир. Сабый чакка кире кайтып булмый, әни!

Таңсылу. Ә минем кайтарасым килә.

Ратмир. Ә минем сабый чагыма да, киләчәгемә дә, бүгенгемә дә кайтасым килми. Минем югаласым килә.

Таңсылу. Кая ашыгасың, бала?

Ратмир. Мин атымны саклый алмадым, әни! Мин соңгы партиядә оттырдым, әни! Җир өстеннән менә-менә атлап китәм дигәндә, мин абындым. Атымны-исемемне аклый алмадым. Сындым мин, әни! Кадалып китсен дөньясы. Әни, тап миңа өч сум?! Җитмәде! Зинһар, тап?!

Таңсылу. Сукыр бер тиен дә акчам юклыгын беләсең ләбаса. Нигә ул барында күбрәк сорамадың?

Ратмир. Әнә ломбард, колагыңдагы алкаңны сал! Сөйләшеп чыктым, алалар.

Таңсылу (*сискәнеп китеп*). Ә?! Алка?.. *(Ике кулы белән колакларын тота.)* Ал, ал, әбиең истәлеге! (*Колакларындагы алкасын салып бирә. Ратмир алканы уч төбенә кыса.)*

Ратмир. Рәхмәт, апа, то есть, әни! Мин аны сиңа кайтарырмын. Эшкә генә урнашыйм, кайтарырмын. Мин хәзер... (*Урыныннан кузгала. Китә-китә.*) Ә син мине көт, көт, әни! Мин әле сиңа бик кирәк.

Музыка. Ут сүнә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә телевидениенең тапшырулар алып бара торган зур залы. Сул порталга урындыклар тезелгән. Анда проектта катнашучы артистлар утыра. Иңсәләргә костюмнар эленгән. Проектка кирәкле җиһазлар булуы мөһим. Уртада — ике кресло. Алар арасында — журнал өстәле. Уң як креслода Таңсылу белән Ратмир утыра. Залга микрофон тоткан Эльза чыга.

Эльза. Хөрмәтле тамашачылар! «Ана һәм гаилә» тапшыруын башлыйбыз. Биредә, безнең арабызда бүгенге теманың авторы Флора ханым Илтизаровна Садыйкова катнаша. Флора ханым, халыкка күренегез! (*Артистлар арасында утырган Таңсылу йөзен яшерә.*) Флора ханым, тамашачы сезнең күренүегезне сорый!

Таңсылу. Юк, юк, миңа игътибар итмәгез. (*Йөзен яшерә.*)

Эльза. Хөрмәтле тамашачылар! Бүгенге тапшыруыбызның исеме «Әни буласым килә». (*Таңсылу ролен уйнаган артисткага күрсәтеп.*) Сезнең алдыгызда бүгенге теманың сәбәпчесе Таңсылу утыра. Әйтегез әле, Таңсылу, сез бала тапкач та балагызны бала тудыру йортында калдырдыгызмы?

Таңсылу. Юк, мин баламны балалар йортында калдырмадым. (*Ярсып.*) Мин баламны балалар йортында калдырмадым!!! Юк, юк, калдырмадым.

Аның янына, иңсәсенә ак халат салып, балалар тудыру йортының Баш табибәсе килә.

Табибә. Димәк, сез балагызны биредә калдырасыз?!

Таңсылу. Юк, юк, мин баламны сездә калдырырга теләмим.

Табибә. Теләмәгәч, алыгыз.

Таңсылу. Әлегә мөмкинчелегем юк.

Табибә. Охо! Аның мөмкинчелеге юк.

Таңсылу. Әлегә минем аны алып чыгарга урыным юк.

Табибә. Моңарчы кая яшәдегез?

Таңсылу. Общежитиеда.

Табибә. Общежитиега алып чыгыгыз.

Таңсылу. Мине балам белән общежитиега кертмәячәкләр.

Табибә. Анда минем эшем юк.

Таңсылу. Ышаныгыз, зинһар, миңа ышаныгыз. Мин баламны якын көннәрдә биредән килеп алачакмын.

Табибә. Сеңлем, син нәрсә?! Син кешеләр арасында үстеңме, әллә урманда, йә булмаса, таш-тау арасында, дикарьлар арасында яшәдеңме?! Хайваннар да, кош-кортлар да, хәтта бөҗәкләр дә балаларын ташламыйлар. Эт булып этләр дә балаларын ташламый.

Таңсылу. Мин эт түгел, мине эткә тиңләмәгез. Миннән көлмәгез.

Табибә. Сездән көлмәскә?! Сезне, бәлки, мактарга кирәктер.

Таңсылу. Сез үзегез дә хатын-кыз бит. Хатын-кызга хас йомшаклыгыгыз кая?

Табибә ( *ачуы тагы да көчәя төшеп*). Йомшаклык?! Сиңа тагы йомшаклык турында сөйләргә. Мине үзең белән чагыштырма. Мин ике бала анасы. Сезнең кебекләр өчен йомшаклык постельдә генә. Нәрсә, роддомда баласын калдырган сезнең кебекләр белән мин хәзер церемонится итеп утырырга тиешме?! Минем башка эшем юк иде. Көтеп тор. Менә сезгә кәгазь, менә сезгә ручка, «Баламнан баш тартам» дип гариза языгыз.

Таңсылу. Юк, мин баламнан баш тартмыйм.

Табибә (*кычкырып җибәрә*). Алайса, балагызны алыгыз!

Таңсылу *(елап)*. Апа җаным, зинһар, хәлемә керегез! Минем кунар урыным юк.

Табибә. Апа җаным, апа җаным!.. Синең тасма телеңә ышанып, әле дә мин сине, больница ризыгы ашатып, ике атна артыграк тоттым. Бу сиңа кунакханә түгел. Бу — авырулар йорты. Ә син савыктың. Әнә монда керергә күпме авыру чират тора. Тизрәк кулыңны куй да чыгып кит. Буш урыным юк. Аңлыйсыңмы, буш койкам юк. Тиз, тиз бул, кулыңны куй.

Таңсылу. Язмыйм да, куймыйм да. Мин баламнан баш тартырга җыенмыйм. Минем аны алып чыгарга урыным юк.

Табибә. Бала алып чыгар урының да булмагач, узмыйлар аны. Әти-әниең кая?

Таңсылу. Юк!

Табибә. Алдашма. Без барысын да тикшердек. Авылда әниең яши.

Таңсылу. Әни мине бу хәлемдә кабул итмәячәк.

Табибә. Шулайдыр шул. Әнисенә сыймый, бирегә сыя. Урам баласы үстерәләр дә, аннары тегеләр исә үз балаларыннан ваз кичәләр. Оясында ни булса, очканында шул булыр. Алма агачыннан ерак төшми. Әниең эзеннән атлыйсыңмы?

Таңсылу. Минем әнигә тел тидерәсе булмагыз. Минем әни — әүлия!

Табибә. Әүлия?! Эч пошырма! Әүлия, имеш... Әүлиядан туган тутый кош... Юньле әнидән синдәй бала тумый.

Таңсылу. Минем бу хәлгә калуыма әнием гаепле түгел. Ул мине кешеләргә мәрхәмәтле, миһербанлы бул дип үстерде.

Табибә. Күрәм. Кемгәдер шундый миһербанлылык күрсәткәнсез... Шушы миһербанлылыгыз аркасында тагын бер сабый ятим кала. Барысына да син гаепле.

Таңсылу. Юк, мин гаепле түгел. Ул гаепле. Барысына да ул гаепле. Ул мине алдады. Мин аңа чын күңелемнән ышанган идем.

Табибә артистлар янына барып утыра. Таңсылу янына Расих килә.

Расих. Мин сине алдамадым. Бала минеке түгел. Ишетәсеңме, бала минеке түгел.

Таңсылу. Кояшлы матур июль ае иде. Мин финанс институтына имтихан тотып йөрим. Икенче имтиханымнан икеле алып, башымны кая куярга белмичә елый-елый парктагы бер эскәмиягә барып утырдым. Шулчак яныма син килеп утырдың.

Расих. Әй, кызыкай, ник елыйсың?

Таңсылу (*елый-елый).* Икенче имтиханымны бирә алмадым.

Расих. Сер булмаса, нинди имтихан иде инде ул?

Таңсылу. Математика.

Расих. Юкка борчыласың.

Таңсылу. Авылга ничек кайтырмын да авылдашлар, классташлар йөзенә ничек карармын?! Әнигә нәрсә диярмен?

Расих. Шушы институтка имтихан тоттыңмы?

Таңсылу. Әйе, финансовыйга.

Расих. Нинди факультетка?

Таңсылу. Экономическийга.

Расих. Тапкансың елар нәрсә.

Таңсылу. Нинди йөз белән авылга кайтырга.

Расих. Авылга кайтырга кирәкми. Авылдан бер чыгып киткәч, авылга кире кайтырга кирәкми. Төзәтмәслек әйбер була алмый. Бүген — икеле, иртәгә — бишле!

Таңсылу. Ничек?

Расих. Син имтихан тоткан факультетның деканы минем әтием.

Таңсылу. Чынлапмы?

Расих. Мин ялганчы кешегә охшаганмынмы? Ә сез елап утырасыз. Кая әле... *(Кесәсеннән кулъяулык чыгарып, Таңсылуның яшен сөртә.)* Шундый асыл, чибәр затка елап утыру килешми. Хәзер үк миңа киттек. Иртәгә бары да җайланыр.

Таңсылу. Рәхмәт, мин сезгә бара алмыйм. Әгәр дә сез миңа ярдәм итә алсагыз, мин сезгә гомергә рәхмәтле булыр идем. Мөмкин булса, иртәгә тугызда биредә очраша алмабызмы?

Расих. Юкны сөйләмәгез, мин сезне шушы халәтегездә биредә ташлап калдыра алмыйм. Мин фатирда үзем генә. Декан абыең, профессор абыеңны әйтәм, ягъни минем әти, әни белән дачада яшиләр. Әйдә тор, киттек.

Таңсылу. Гафу итегез, мин сезгә бара алмыйм.

Расих. Ә сез кайда торасыз?

Таңсылу. Общежитиеда.

Расих. Сез... шундый гүзәлләрнең гүзәле общагада ятасыз?! Мин сезне анда җибәрмим.

Таңсылу. Сезгә бару минем өчен читен.

Расих. Нәрсәсе читен?! Әллә миннән куркасызмы?

Таңсылу. Юк ла, сез нәрсә?!

Расих. Бәлки, сезгә минем аурам ошамыйдыр...

Таңсылу. Юк, сез бик күркәм кеше.

Расих. Ә сез илаһи зат. Сез любовь с первого взгляда дигән сүзгә ышанасызмы?

Таңсылу. Ышанам.

Расих. Менә шул, матурым, яшермим, мин сезгә бер күрүдә гашыйк булдым. Юкса мин сезгә үзем туктап ярдәм итәргә ашыгыр идемме? Әлегесе минутта шәһәрнең күп эскәмияләрендә сезнең кебек имтихан бирә алмыйча елап-сыктап утыручылар меңләгән. Син имтихан тоткан әлеге институтка эләгү, охо-хо-хо! Сезгә ничә яшь?

Таңсылу. Унҗиде.

Расих. Ә миңа ничә яшь бирәсез?

Таңсылу. Егерме ике, егерме өч яшьләр тирәсе.

Расих. Юк шул, асылым, Расих абыеңа егерме җиде тула. Унҗиде яшьлек асыл затның исеме ничек инде?

Таңсылу. Таңсылу.

Расих. Таңсылу, матурым, бүген сиңа күңелсез. Син математикадан экзамен бирә алмагансың, институтка керә алмагансың. Ә менә бүген минем өчен иң шатлыклы көн. Мин егерме җиде ел эзләгән табышымны таптым. Бу минутларда миннән дә бәхетле кеше юк. Бөтен дөньяга, Расих, син бүген иң бәхетле кеше, син үз асылыңны, үз мәхәббәтеңне таптың дип кычкырасы килә. Кычкырыйммы?

Таңсылу. Юк, юк, кирәкми, җүләрләнмә!

Расих (*креслога менеп баса*). Кычкырам!

Таңсылу (*Расихны креслодан төшерә*). Юк, Расих абый, кычкырма. Кешеләр ишетә.

Расих. Кычкырам! Ишетсеннәр. Бөтен галәм ишетсен.

Таңсылу. Кирәкми, кирәкми, Расих абый.

Расих. Абый... Абый дисеңме?! Нинди абый, нинди абый, җаный диген. Биш минуттан син экономический институтның экономия факультеты деканының иң яраткан бердәнбер улының килене булачаксың. Дүрт бүлмәле фатирыңның ачкычын кулыңа ал. (*Кесәсеннән ачкыч чыгарып, кулында болгап тора һәм Таңсылуның уч төбенә сала.)* Менә фатирлы да булдың. Күзеңне йом. Сылуым, сиңа әйтәм, күзеңне йом. (*Таңсылу күзен йома. Икенче кесәсеннән, зур ачкыч чыгарып, Таңсылуның күз алдына китерә.*) Матурым, күзләреңне ач. (*Таңсылу күзләрен ача.*) Ә менә бу сиңа туй бүләге. «Жигули» ачкычы.

Таңсылу. Сез нәрсә инде, Расих абый.

Расих. Үпкәләтәсең, «абый» дип үпкәләтәсең.

Таңсылу. Гафу итегез. Сезнеңчә булсын, Расих.

Расих. Менә шулай. (*Тамашачыга карап, кулын изи-изи кычкыра.*) Әй такси, такси дим... (*Сәхнә читенә чыгып йөгерә. Бераздан өч чәчәк күтәреп керә.*) Туктамады гадюка. Ничего. Менә ал. *(Чәчәкләрне Таңсылуга суза.)* Сиңа чәчәкләр.

Таңсылу (*кулындагы чәчәкләрне иснәп*). Кай арада алырга өлгердегез?

Расих. Әй аппагым, урамда июль ае. Газон тулы чәчәкләр. Туктамады гадюка. Ничего. Мин ерак яшәмим. Трамвайлар йөреп тора. Халык арасында булырга кирәк, матурым. Әнә безнең трамвай да күренә.

Трамвай килгән тавыш ишетелә. Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, тәбәнәк өстәлдә җиләк-җимеш, эчемлекләр. Расих музыка куя. Таңсылу урындыкка утырган.

Расих. Мадам, сезне танцага алырга мөмкинме?

Таңсылу. Мөмкин.

Вальс әйләнәләр. Бераздан көй тына.

Расих. Мөмкинме? (*Таңсылуны күтәреп ала да креслога илтеп сала һәм өстәлдәге бокалның берсен Таңсылуга тоттыра.)* Әйдә, брудершафт!

Таңсылу. Юк, мин эчмим. Минем эчкәнем юк.

Расих. Дөрес, теләсә кем белән эчәргә ярамый. Бүгеннән минем рөхсәт белән бераз авыз итәргә ярый.

Таңсылу. Юк, юк, рәхмәт. Минем эчкәнем юк.

Расих. Айн момент, онытып торам. (*Үз муеныннан чәнти бармак юанлыгындагы алтын чылбырын сала да Таңсылуның муенына тага.)* Туй бүләге!

Таңсылу. Кирәкми, кирәкми, мин моны алалмыйм.

Расих. Алырсың! Бу минем бүләк. Ә хәзер безнең киләчәк уртак тормышыбыз өчен күтәрик бокалларны! Безнең якты киләчәгебез өчен! Бездән туасы балаларның сәламәтлеге өчен. (*Таңсылу кулындагы бокалны бармагы белән күтәреп.)* До дна, до дна... (*Таңсылу бокалдагы эчемлекне эчеп бетерә.*) Маэстро, музыка! (*Барып музыканы көчәйтә дә, күлмәген сала-сала, Таңсылу янына килә башлый.)*

Таңсылу. Сез нишлисез, Расих абый?! Сез нишлисез?!

Расих. Сине яратырга җыенам. Сине гомерлеккә үземнеке итәргә җыенам.

Таңсылу. Кирәкми, кирәкми, Расих абый!

Расих. Ояласыз?! Дөрес, интим яктылыкны яратмый! (*Утны сүндерә.)*

Пауза.

Ут янганда, Таңсылу креслода утыра.

Таңсылу. Таң атканда, мин инде унҗиде яшьлек хатын идем. Әни генә була алмадым. Алдандым.
Расих. Барысы да ялган. Минем хатыным, ике балам бар.
Таңсылу. Хәзер синнән миңа берни дә кирәкми. Син вәгъдә иткән Кара диңгез дә, син вәгъдә иткән затлы фатир да, фатирыңа атлап кергәч тә муеныма салган, ә инде таң алдыннан салдырып алып калган алтын муенсаң да.
Расих. Яшь кенә булсаң да, күпне өмет иткәнсең икән шул. Ялгышасың, сеңлем, ялган юл белән бәхетле булып булмый! Ялган юл белән баеп булмый. Минем муенга бала тагарга башың яшь.
Таңсылу. Күземнән югал. Мин синнән шактый яшь булсам да, бик күпкә көчлемен. Күземнән югал, диләр сиңа.
Расих. Яхшы, яхшы. Үз гаебеңне тану бигрәк тә яхшы. Димәк, әле, сеңлем, синдә намус дигән әйбер гел үлеп бетмәгән. Пока, сеңлем. (*Чыгып китә.*)
Таңсылу (*елап урыныннан тора да, Расих чыгып киткән якка карап).* Расих!.. Расих, ташлама мине! (*Үксеп кире урынына каплана.*)

Янәдән Таңсылу янына Табибә килә.

Табибә. Сеңлем, без күз яшьләренә ышанмыйбыз. Кулыгызны куясызмы, юкмы?
Таңсылу *(урыныннан сикереп тора да*) . Юк! Юк, куймыйм! Атсагыз да, суйсагыз да куймыйм. Минем яшисем килми. (*Ишектән атылып чыгып китә.*)

Урамда машинаның сызгырып нәрсәдер бәреп туктаган тавышы ише-
телә. Сәхнәдә ут сүнә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Таңсылу үз урынында утыра. Эльза басып тора.

Эльза. Шушы хәлләрдән соң сез машина астына эләктегез. Бу очраклы хәлме, әллә авырлыкларга түзә алмый машина астына кердегезме?
Таңсылу. Бу сорауга мин җавап бирә алмыйм. Ул минутларда мин үз-үземне белештерми идем.

Таңсылу янына, чәчәк бәйләме күтәреп, Айдар килә.

Айдар. Ниһаять, сез күзләрегезне ачтыгыз. (*Чәчәкләрне тәбәнәк өстәлдәге вазага утырта.)*
Таңсылу. Сез кем?
Айдар. Гафу итегез, мин сезнең алдыгызда иң гаепле кеше. Минем аркада сез биредә ятасыз. Мин сезне таптатучы Айдар дигән кеше булам.
Таңсылу. Юк, сезнең минем алдымда бер гаебегез дә юк. Мин үзем, үзем барысына да гаепле.
Айдар. Ни өчен?
Таңсылу. Ул көн минем өчен онытылмаслык мәхшәр булды. Озак йокладыммы?
Айдар. Җиде көн аңыгызга килә алмадыгыз. Иншалла, беренче кат күзегезне ачтыгыз.
Таңсылу. Җиде көн. (*Креслосыннан сикереп тормакчы була.*) Улым, балам! (*Авыртуга чыдый алмыйча креслосына ава*.)
Айдар. Ярамый, ярамый сезгә, кузгалырга ярамый.

Алар янына Таңсылуның әнисе Рәшидә апа килә.

Рәшидә апа. Әллә аңына килгән идеме?
Айдар. Килгән иде шул, Рәшидә апа. Улым, балам, диде дә яңадан күзен йомды.
Рәшидә апа. Тугач та дәү әнисе, иремнең әнисе, бәхетсез бала туды, диде. Рәнҗедем, чын йөрәгемнән рәнҗедем. Тумас борын балама ярлык тагасың, дидем. Рәнҗемә, килен, төшемә керде. Төшемә ышанмаган идем, баланың йөзен күргәч, төшемнең хаклыгына ышандым, диде. Каенанам белән сөйләшмәс булдым. Атна да үтмәде, Таңсылуның әтисе суга батып үлде. Каенанама бардым. Каян белдең, дидем. Бу әле башы гына, диде. Шул көннән башлап сабыемны, каз бәбкәсен канат астында ничек сакласа, күз карасыдай мин дә аны шулай сакларга тырыштым. Саклый гына алмадым. Унҗидесе тулар-тулмас югалттым.
Айдар. Рәшидә апа, юкны сөйләмәгез. Без Таңсылуны югалтмыйбыз. Ниндидер каһәр суккан төн булды шул.

Рәшидә апа. Беркем дә кеше таптатам дип юлга чыкмый. Адәм баласы тәкъдирдән ерак китә алмый. Күрәчәк, Айдар улым, күрәчәк.

Айдар. Без аны аякка бастырачакбыз. Мин аны аякка бастырачакмын, Рәшидә апа. Ышаныгыз миңа.

Рәшидә апа. Исән калса да, ул инде үз аяклары белән җир өстеннән атлап йөри алмас. Врач белән сөйләштем. Йөри алмас, диде.

Айдар. Йөриячәк, Рәшидә апа, йөриячәк.

Рәшидә апа. Дәү әнисе бик тә туры сүзле, усал карчык иде. Бу бала җир өстендәге кешеләрнең күзләренә туры карый алмаячак, диде. Аны авыл халкы сихерче, җен корткасы, дип йөртә иде. Нигә күпсенә микән?.. Үз баласының баласы бит. Үз-үземә, әллә соң сабыем бу якты дөньяга әтисенең, ягъни карчыкның бердәнбер улының гомерен алып килде диеп уйлый микән, дия торган идем. Йөри алмас. Кешеләр күзенә тутырып карап, башын югары тотып йөри алмас инде. Ул карчык әйтсә, хак әйтә.

Айдар. Адәм баласы дөньяга кеше гомере белән килми. Шул ук вакытта кешегә ике тапкыр гомер дә бирелми. Кыскамы, озынмы — һәрберебезнең үз гомере бар. Әтисе бер тапкыр гомер бүләк иткән икән, икенче тапкыр аңа гомер биралмый.

Рәшидә апа. Мин дә шулай уйлыйм. Адәм баласы дөньяга үз язмышы, үз ризыгы белән килә.

Айдар. Йөрер. Башын югары тотып йөрер.

Рәшидә апа. Юк, йөри алмас. Күңелем сизә. Ана күңеле барысын да сизә.

Айдар. Күзен генә ачсын. Сөйләшә генә башласын. Нинди генә хәлдә булса да, мин аны ташламам.

Таңсылу. Балам!.. Балам!..

Айдар. Саташа, Рәшидә апа, саташа.

Таңсылу. Су, су?..

Айдар ( *иреннәренә су тидерә*). Менә, менә шулай.

Таңсылу (*күзләрен ача*). Су, су бирегез?

Айдар. Сиңа ярамый. Түз, түз, Таңсылу.

Таңсылу. Син кем?

Айдар. Айдар мин, Айдар. Тынычлан. Сиңа дулкынланырга ярамый.

Рәшидә апа (*йөзенә иелә төшеп*). Кызым, мине таныйсыңмы?

Таңсылу. Әни!

Айдар. Таныды. Сине таныды, Рәшидә апа.

Рәшидә апа. Кызым, хәлең ничек?

Таңсылу. Балам, балам кая?

Рәшидә апа (*читкә китеп елый*). Әй бала, бала... Син бит әле үзең дә бала гына. Балам кая диме? Саташа. Әйтәм бит, баш миенә зәгыйфьлек килгән.

Таңсылу. Әнкәй, минем улым, балам кая? Әнкәй!..

Рәшидә апа. Монда, монда, кызым. Борчылма.

Таңсылу. Баламны бирегез!

Рәшидә апа. Бирәбез, балам, бирәбез. Әлегә йокла. Йом күзеңне.

Таңсылу. Минем әни буласым килә.

Рәшидә апа. Булырсың, кызым, булырсың. Әни дә булырсың.

Айдар. Рәшидә апа, врач, күзен ачса, мине чакырыгыз, дигән иде. Мин врачны чакырып килим.

Рәшидә апа. Бар, бар, улым.

Айдар башка артистлар янына барып утыра.

Кызым, кая югалдың соң син? Суга төшеп югалгандай югалдың бит.

Таңсылу. Әни, ачуланма. Минем улым бар.

Рәшидә апа. Ни сөйлисең син, балам. Син бит әле үзең бала.

Таңсылу. Әни, минем балам бар, минем улым бар.

Рәшидә апа. Кая? Кая соң ул?

Таңсылу. Өченче роддомда.

Рәшидә апа. Юкны сөйләмә әле, кызым, саташасыңмы әллә?!

Таңсылу. Мин үз акылымда, әни. Мин бала таптым. Тизрәк барып ал. Минем улымны тизрәк барып ал.

Рәшидә апа. Бу сүзләрне чын булса да бүтән кешегә сөйләмә.

Таңсылу. Әни, ашык!

Таңсылу янына Айдар белән ак халатлы врач килә.

Врач. Хәлегез ничек? (*Таңсылуның, кулыннан тотып, йөрәк тибешен саный.)* Йөрәк тибешегез әйбәт. (*Бармагын Таңсылуның күз алдына китерә дә.*) Минем бармакка карагыз әле! *(Бармагын йөртә.*) Нормально.

Айдар. Акылындамы?!

Врач. Барысы да тәртиптә.

Таңсылу. Су, су бирегез?!

Врач. Кашык белән генә ярты стакан чамасы су бирегез.

Үз урынына барып утыра.

Айдар (*әз генә Таңсылуның башын күтәрә төшеп, кашык белән иреннәренә су тидерә*). Эч, эч, җаным, сиңа терелергә кирәк! Сиңа аягыңа басарга кирәк. Озакламый атлап та китәрсең. Эч, Таңсылу, эч!

Музыка. Ут сүнә.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Таңсылу креслода утыра. Ул бераз терелә төшкән. Эльза баскан.

Эльза. Таңсылу, нигә дип сез үзегезнең балагыз барлыгы турында Айдарга әйтмәдегез?

Таңсылу янына Рәшидә апа килә.

Таңсылу. Әни, балам кая?

Рәшидә апа. Әй кызым, кызым. Мирдә, нәселебездә булмаганны кыйлангансың. Авылыма кайтмаслык иттең. Ни эшләдең син, бала?.. Нишләдең?!

Таңсылу. Алдандым мин, әни, кичер! Улым кая?

Рәшидә апа. Улыңны балалар приютына алып киткәннәр.

Таңсылу. Нинди приютка, әни?

Рәшидә апа. Каян белим.

Таңсылу. Мин хәзер аны эзләп табам. (*Тормакчы була, тора алмый.)*

Рәшидә апа. Әй бала, бала!

Таңсылу (*үксеп елый башлый*). Балам!.. Улкаем!

Рәшидә апа. Җитте! Хватит! Унҗиде яшеңдә уйнаштан бала табып акырып утырма. Оятсыз! Бала, имеш. Ишетсен колагың, авылга үксез бала ияртеп кайтасы булма. Авыл капкасыннан күренүегезгә, бауга менәчәкмен. Ишетсен колагың. Әгәр үзеңне тапкан әниеңне бауга асасың килсә, эшлә! Бала, имеш... Син үзең хәзер бала хокукында. Берүк балаң бары хакында Айдарга әйтә күрмә. Балаңны да, үзеңне дә, мине дә мәңгелек утка саласың. Айдарга кияүгә чыгу ягын кара.

Музыка. Ут сүнә.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә Мендельсон маршы яңгырый. Шул ук урында, креслода туй күлмәге, фатадан Таңсылу утыра. Артистлар утырган җирдән кап-кара туй костюмыннан, ап-ак күлмәктән, бабочка таккан, кулына чәчәк букеты тоткан Айдар тора да Таңсылу янына килә. Уң кулын култыкларга җайлап куеп, Таңсылу янына килеп баса. Таңсылу аны култыклап ала.

Загс хезмәткәре. Хөрмәтле кәләш һәм кияү! Сезне бүгенге истәлекле көнегез белән котлыйбыз. Бүген Таңсылу Мәүлет кызы белән Айдар Айнур улының никахы законлы рәвештә теркәлә.

Репродуктордан көй яңгырый.

Сез бүген бик җаваплы юлга басасыз. Гаилә төзү буенча җаваплылыкны үз иңсәгезгә аласыз. Гаилә кору ул бер-береңә ышану, авыр чакларда бер-береңә терәк булу. Шатлыкта да, кайгыда да бер-береңә теләктәш булуда, бер-береңнең серләрен чит-ятларга чыгармыйча уртак хәл итүдә.

Музыка.

Актлар кәгазенә кул куюыгызны сорыйм.

Таңсылу, Айдар, шаһитлар кул куя. Фанфара.

Таңсылу, Айдар, Россия Федерациясенең гаилә төзү турындагы законы нигезендә сезне ир һәм хатын дип игълан итәм!

Фанфара яңгырый.

Сезнең гаиләгезнең беренче документы булган язылышу турындагы таныклыкны тапшырам. (*Кулларын кысып тапшыра*.) Мәхәббәт символы булган балдаклар алмашуыгызны сорыйм. (*Кулларына балдаклар кидерәләр.*) Ә хәзер бер-берегезне котлагыз. (*Үбешәләр.*)

Сәхнәнең бер читендәге артистлар, бокаллар тотып, котларга дип киләләр. Аларны котлыйлар. Вальс. Барысы да вальс әйләнәләр.

Айдар белән Таңсылу икесе генә калалар.

Айдар. Менә, акыллым, авыр көннәр артта калды. Хәзер безгә матур итеп яшисе дә яшисе. Син миңа малай белән кыз бүләк итәрсең. Мин сине дөньядагы иң кыйбатлы асылташтай саклармын.

Таңсылу. Рәхмәт, Айдар!

Айдар. Әлеге минутларда син бәхетлеме?

Таңсылу. Бәхетле, Айдар!

Айдар. Мин сине гомерем буе бәхетле итәрмен.

Таңсылу. Айдар, син минем белән бәхетле була алмассың.

Айдар. Нигә?

Таңсылу. Мин сиңа тиң түгел.

Айдар. Ни өчен?

Таңсылу. Шулай.

Айдар. Нәрсә, травмаң хакында әйтмәкче буласыңмы?! Борчылма, вакыт үзенекен итәр. Шәм кебек атлап йөри башларсың. Барысы да яхшы булыр.

Таңсылу. Юк, кайчан да булса минем сиңа тиң түгеллегемне аңларсың да үкенерсең. Соң булыр дип куркам.

Айдар. Юк, һичкайчан! Мин үзем сине шушы хәлгә төшердем. Мин, мин үзем барысы өчен дә гаепле.

Таңсылу. Юк, барысы өчен дә мин үзем гаепле. Бары тик үзем генә гаепле.

Айдар (*Таңсылуны күтәреп ала*). Ташласана. Бүген зур бәйрәм. Кеше гомерендә бер генә тапкыр була торган зур вакыйга. Бүген зур вакыйга. Бүген безнең бәйрәм. Бүген безнең туебыз.

Музыка яңгырый. Айдар Таңсылуны күтәргән килеш бии-бии бөтерелә.

Ут сүнә.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Таңсылу утырган урындыкта балалар йорты мөдире Ләйлә Гомәровна утыра. Аның янына Таңсылу килә.

Таңсылу. Исәнмесез!

Ләйлә Гомәровна. Исәнмесез!

Таңсылу. Миңа шушы балалар йортының заведующие Ләйлә ханым Гомәровна кирәк иде.

Ләйлә Гомәровна. Мин Ләйлә Гомәровна булам. Ә сезне кем дип белик?

Таңсылу. Мин Таңсылу.

Ләйлә Гомәровна. Таңсылулар күп. Фамилиягез?

Таңсылу. Хәмитова Таңсылу Мәүлетовна.

Ләйлә Гомәровна. Тыңлыйм сезне, Таңсылу Мәүлетовна!

Таңсылу. Моннан җиде ай элек мин өченче балалар тудыру йортында бала — малай тапкан идем һәм җитди сәбәпләр аркасында вакытлыча баламны шунда калдырып чыгарга мәҗбүр булдым. Авариягә эләктем. Өч ай больницада ятарга туры килде. Аягыма баскач баламны алырга дип барсам, миңа, сезнең балагыз біздә түгел, диделәр. Һәм мин аны, эзли торгач, ниһаять, таптым. Ул сездә тәрбияләнә.

Ләйлә Гомәровна. Өченче балалар тудыру йортында дисезме?

Таңсылу. Әйе, өченче балалар тудыру шифаханәсе.

Ләйлә Гомәровна (*журнал чыгарып*). Фамилиягезне тагын бер кат әйтегез әле?

Таңсылу. Хәмитова. Хәмитова Таңсылу Мәүлет кызы.

Ләйлә Гомәровна. Әйе, моннан бер ай элек сезнең балагыз... Так, так... Ребенок мужского рода, вес шесть килограмм тристо грамм, рост шестьдесят семь сантиметров. Әйе, безгә җибәрелгән. Улыгызның исемен белергә телисезме? Улыгызның исеме Ратмир.

Таңсылу. Мин аны алырга килдем.

Ләйлә Гомәровна. Бик яхшы. Һәр бала әнисе янында, үз гаиләсендә үсәргә тиеш. Соң булса да сездә аналык хисе уянган икән, бу бала өчен дә, безнең өчен дә зур шатлык. Кая, документларыгызны бирегез?

Таңсылу. Нинди документлар?

Ләйлә Гомәровна. Ул — бала сезнең балагыз икәнен дәлилли торган справка.

Таңсылу. Соң бит үзегез әйтеп торасыз, моннан бер ай элек минем баламны сезгә китергәннәре хакында.

Ләйлә Гомәровна. Кем? Минме? Ялгышасыз. Мин бала китерделәр дип әйттем. Әмма ләкин сезнең балагызны китерделәр дип әйтмәдем.

Таңсылу. Сез бит журналдан минем исем-фамилиямне укыдыгыз.

Ләйлә Гомәровна. Әйе, Хәмитова Таңсылу Мәүлетовна. Ну и что?

Таңсылу (*паспортын сузып*). Менә мин бит инде ул, мин — Хәмитова Таңсылу Мәүлетовна.

Ләйлә Гомәровна. Сеңлем, сезнең бу паспортыгызга карап кына әле сез баланың әнисе дигән сүз түгел. Бала хәзер сезнеке түгел, бала — хөкүмәтнеке! Бала — хөкүмәт милке! Сеңлем, ул бит сезгә сарык бәрәне түгел, адәм баласы. Сарык бәрәне алганда да, түләгән өчен счет, накладной күрсәтәләр.

Таңсылу (*сумкасын ачмакчы була).* Сезгә күпме түләргә?

Ләйлә Гомәровна. Сез нәрсә?! Хәзер үк сумкагызны ябыгыз. Мин взятка алып утырмыйм. Мин закон яклы кеше, мин закон тәртибендә эш йөртәм.

Таңсылу. Минем ул баламны тапканлыгыма роддомнан справкам бар. (*Сумкасын актара башлый.*)

Ләйлә Гомәровна. Кирәкми. Хәзер ул справка сезгә бернинди дә хокук бирә алмый. Дөрес, баланы табучы сез. Әмма ләкин ул хәзер дәүләт милке. Ратмир дәүләтнеке! Аңлыйсызмы? Сез тапкан бала сезнеке түгел, хөкүмәтнеке! Сез балагызны җиде ай буена хөкүмәт иждивениесендә яткыргансыз икән, килеп алмагансыз икән, бала алты айдан хөкүмәт җилкәсендә кала.

Таңсылу. Миңа хәзер нишләргә?

Ләйлә Гомәровна. Документлар җыярга.

Таңсылу. Нинди документлар?

Ләйлә Гомәровна. Беренчедән, баланы сез тапканлыкка роддомнан справка, икенчедән, үзегезнең сәламәтлегегез хакында, баланы карарлык хәлдә дигән медицинский справка, өченчедән, балагызны алып кайтырлык условиеләрдә яшәгәнлегегезне аклый торган справка, дүртенчедән, айлык хезмәт хакыгыз, чыннан да, сез эшлисезме, эш белән тәэмин ителгәнсезме, бишенчедән, сез тормыштамы?

Таңсылу. Әйе, мин кияүгә чыктым.

Ләйлә Гомәровна. Бик яхшы. Ирегезнең баланы алырга, ягъни киләчәктә карарга ризалыгын белдергән гаризасы. Соңгысы. Ул сезнең ирегез, баланың үз атасымы? Әгәр булмаса, баланың үз атасыннан отказ алырга. Әлегә шуларны җыя торыгыз.

Таңсылу. Мин баламны әниемә кайтармакчы булам.

Ләйлә Гомәровна. Әниегезнең балагызны алам дигән заявлениесе, баланы тәрбияләү өчен яшәү шартлары нормага туры киләме, әниегез сау-сәламәтме, сездән һәм баланың атасыннан балабыздан баш тартабыз дигән гариза һәм башкалар, һәм башкалар.

Таңсылу. Ничек инде?

Ләйлә Гомәровна. Шулай, Таңсылу сеңлем, шулай. Бала алу бала тудыруга караганда читенрәк ул. Монда кеше язмышы турында сүз бара. Документлар җыегыз. Килегез, алырсыз. Мин шатланып ярдәм итәрмен. Бала ата-анасы тәрбиясендә үсәргә тиеш. Әй сеңлем, сезне биредә яткан балалар белән бер генә көн тотар идем мин. Алар бит, бер генә тапкыр аналарын күрмәгән булсалар да, «әни» диеп саташалар, йокыларыннан «әни» диеп елап уяналар. Менә сиңа бер мисал. Безнең йортта Наташа дигән кыз тәрбияләнә. Аны безгә, тимер юл вокзалында хозяйственный сумкага салынган килеш, өч айлык чагында милиционерлар табып китергәннәр инде. Аңа хәзер унөч яшь. Ә ул бездән ничә ел буена әти-әнисен таптыра. Мондагы һәр баланың хыялы: әти-әнисе белән бергә үз фатирларында гомер итү. Һәр сабыйның үз гаиләсендә тәрбияләнеп, әти-әнисе кочагында назланырга хакы бар. Һәм шул ук вакытта Ратмирның да. Тиз арада документларыгызны әзерләп бетерегез дә балагызга ярдәмгә ашыгыгыз. Ратмир белән без сезне көтәбез.

Музыка. Ут сүнә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, шул ук креслода Таңсылу утыра. Ул олыгайган.

Эльза (*микрофонга*). Шулай итеп сез тыныч кына яшәп ятканда...

Таңсылу. Юк, мин беркайчан да, бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, хәтта бер генә минут та тыныч яшәмәдем. Мин гомерем буе икегә бүленеп яшәдем. Ярты җаным белән улым Ратмир янында булсам, ярты ягым белән гаиләм, кызларым янында идем.

Эльза *(микрофонга)*. Яхшы. Шушы хәлләрдән соң унбиш ел гомер узып киткән. Сезнең Эльвира һәм Розалия атлы кызларыгыз туган.

Таңсылу. Әйе, мин аларны югалтканда, Эльвирага — тугыз, ә кечкенәм Розалиягә алты яшь иде.

Эльза *(микрофонга).* Көннәрдән бер көнне сезнең ишегегезне улыгыз тәрбияләнә торган интернатның мөдире Ләйлә Гомәровна килеп какты.

Ләйлә Гомәровна керә.

Ләйлә Гомәровна. Исәнмесез!
Таңсылу. Исәнмесез! Рәхим итегез! Түргә узыгыз!
Ләйлә Гомәровна. Сез мине таныйсызмы?
Таңсылу. Әлбәттә, таныйм. Сез бит... Сез...
Ләйлә Гомәровна. Әйе, мин сезнең улыгыз тәрбияләнә торган интернатның заведующие Ләйлә Гомәровна булам.
Таңсылу. Бик яхшы хәтерлим.
Ләйлә Гомәровна. Сезнең безгә улыгыз Ратмирны алырга дип килгәнегезгә дә күпме гомер узды.
Таңсылу. Кызганычка каршы, шулай килеп чыкты шул.
Ләйлә Гомәровна. Ә без сезне килерсез дип көттек. Документларыгызны тиз арада җыярсыз да улыгыз Ратмирны килеп алырсыз дип уйладык.
Таңсылу. Язмыш!
Ләйлә Гомәровна. Язмыш дисез инде. Язмышны без үзебез язабыз түгелме?!
Таңсылу. Кызганычка каршы, мин алай дип әйтмәс идем. Безнең язмышлар үз кулыбызда гына түгел икән шул. Тирә-як мохит, безне әйләндереп алган кешеләр, без яшәгән җәмгыять, безнең белән идарә итүче җитәкчеләр белән бәйле.
Ләйлә Гомәровна. Ник алай уйлыйсыз?
Таңсылу. Сәбәпләре бар.
Ләйлә Гомәровна. Сер булмаса, бәлки, аңлатырсыз. Нинди сәбәпләр инде ул?
Таңсылу. Сәбәпләр күп. Беренчедән, унҗиде яшең тулар-тулмас килеш синең намусыңа төкереп, яшьлегеңне таптап, кешелеклегеңне мыскыл итсәләр, икенчедән, үз ялгышыңны төзәтергә теләп чәбәләнсәң дә, яңа гына дөньяга килгән нарасыеңны сыендырырлык та урының булмау, өченчедән, кимсетелеп, башыңны кая орырга белми үз-үзеңне куяр урын тапмаганда юлыңа кара шәүлә булып баскан бәндәләр торса... Санап китсәң, очсыз-кырыйсыз караңгылык.
Ләйлә Гомәровна. Ә сабыйларның боларга нинди катнашы бар?
Таңсылу. Шушы җирдә туып та, туган җиреңдә бишеген асарлык та урыны булмауда.
Ләйлә Гомәровна. Ә ул көтте. Хәзер дә көтә.
Таңсылу. Аның өчен мин үлгән. Минем өчен ул яши.
Ләйлә Гомәровна. Соңгы елда әниегез дә килми башлады. Ул аның бердәнбер юанычы иде. Ул аны көтеп ала иде.
Таңсылу. Әнине мин үзем ай саен аның янына җибәрә идем. Хәзер бара алмый. Йөри алмый. Урын өстендә ята. Мин әнигә улым Ратмирга «әниең үлде» дип әйтергә куштым.
Ләйлә Гомәровна. Адәм баласын өмет соңгы минутына кадәр озата бара. Адәм баласы соңгы сулышларын алганда да, иренәнә соңгы тапкыр су тидергәндә дә, теге дөньяның, мәңгелекнең булуына өметләнеп китә. Эчендә җаны булган, алда тормышы көтеп торган сабый киләчәккә өмет белән карый. Алдагы тормышында җан өргән, үзен тудырган ата-анасын очратырмын дип яши. Сабый күңеле сизгер.
Таңсылу. Аңлыйм. Бик тә аңлыйм. Әмма нишлим?! Кая барыйм? Ничек ярдәм итим. Шул сабыемны уйлап алты ел бала тапмадым. Иремне мин бала таба алмыйм дип алдадым. Балабыз булмагач, бәлки, балалар йортыннан бала алыйк дигән сүзе чыгар дип көтеп яшәдем. Алты ел буена больница юлын таптатты. Күрсәтмәгән профессоры калмады. Барысы да, синең хатының бала табарга тиеш, синең хатының таза-сау, диделәр. Аерылмакчы булдым. Ризалык бирмәде. Мин сине аякка бастырдым. Син минем алда бурычлы. Минем белән аерылып минем карьерама зыян китермәкче буласыңмы, диде. Авыру әниемне үз яныма алмакчы булдым. Юк, диде. Бер гарипне, кысырны асрап ятуыма да үкенәм. Алты елдан соң беренче баламны — Эльвирамны, өч елдан соң кечкенәсен — Розалиямне таптым. Мине бу тормышта бер сорау борчый: нигә ул мин больницада ятканда шундый игътибарлы булды да кинәт үзгәрде.
Ләйлә Гомәровна. Төрмәгә утырмас өчен. Үз шкурасын, карьерасын саклар өчен. Бәлки, балагыз тугач, ирегездә аталык хисе уянгандыр. Улыгыз барлыгын әйтеп карамадыгызмы?
Таңсылу. Юк, ул мине кичермәсен белеп яшәдем. Әгәр мин аңа улым барлыгы хакында әйтсәм, минем ике кызым ятим, этисез калырлар дип уйладым. Бер баламның бәхетсезлеге дә миңа бик җиткән. Ә бит мин улым янына көн дә бара идем. Ул яшәгән балалар йортының каршысына урнашкан унҗиденче йортның унөченче фатирына, Фәһимә атлы әбигә кереп тәрәзәдән сәгатьләр буе улымны күзәтә идем.
Ләйлә Гомәровна. Мин сезнең янга зур үтенеч белән килдем.

Таңсылу. Әйтегез, нинди үтенеч? Кулымнан килгәннең барысын да эшләрмен. Тик серне иремә генә ачмагыз. Балаларым хакына үтенеп сорыйм.

Ләйлә Гомәровна. Борчылмагыз, иregез бу хакта берни дә белмәс. Мин заслуженный педагог — тәрбияче. Күрәм, матур яшисез. Иregез зур урында эшли. Фатирыгыздан әйләнеп чыкмаслык. Белгәнебезчә, сезнең гаилә шәһәребезнең иң бай дип саналган ун гаиләнең берсе.

Таңсылу. Рухи байлык булмагач, материаль байлык байлыкмыни ул?

Ләйлә Гомәровна. Минем килүемнең төп сәбәбе: сезнең улыгыз Ратмирга унбиш яшь тулып килә. Егет талантлы. Аның киләчәге өметле. Ул узган ел шәһәрдә уздырылган шахмат ярышында яшүсмерләр арасында беренче урынны алды.

Таңсылу. Беләм, барысын да беләм.

Ләйлә Гомәровна. Быел яшүсмерләр арасында Мәскәүдә үткән гроссмейстерлар бәйгесендә икенче урынны алды. Озакламый Япониянең Нагасаки шәһәрендә үтәчәк бөтендөнья яшүсмерләр арасындагы шахматчылар турнирында көч сынаячак. Но... Безнең анда җибәрергә акчабыз юк. Дөрес, шахматчылар федерациясе, шәһәр җитәкчелеге аңа ярдәм итәчәк. Әмма ләкин балигъ булмаган унбиш яшьлек баланы ничек итеп үзен генә җибәрәсең. Аның үзен генә җибәрмәс өчен, физкультура укытучысы Мөнир Фәизовичны җибәрмәкче булам. Юлда ни булмас. Анда баргач, аның әле кунакханәгә урнашасы бар, санап китсәң, юл расходлары... Безгә билгеле, сез бай. Өстәвенә сез аны тапкан ана кеше. Ярдәм итегез безгә.

Таңсылу. Сез ялгышасыз, сез мине олы түрәнең хатыны булгач та бик бай дип уйлыйсыз инде. Ялгышасыз. Андагы байлык минеке түгел, аныкы. Мин ул йортта хезмәтче ролен генә башкарам.

Ләйлә Гомәровна. Кеше ышанмаслыкны чын булса да сөйләмәгез, ханым. Сез үз тормышыгыздан канәгать булмагач, безгә нишләргә кала?!

Таңсылу. Сез, бәлки, уйлыйсыздыр, бай йортта яшәгәч, ирләре бай булгач, аларның хатыннары байлыкта йөзәләрдер дип. Ялгышасыз. Адәм баласы күпме баерак булса, шулкадәр саранрак була. Бай тапкан акчасын бармак арасыннан гына сыгып чыгара. Минем ирем икмәккә дә акчаны санап кына бирә. Саран булмаса, ул байый алмас иде.

Ләйлә Гомәровна. Димәк, сез безгә ярдәм итәргә теләмисез. Димәк, сез үзегез тудырган баланы кабаттан язмыш кочагына ташлыйсыз?!

Таңсылу. Нишлим. Каян алыйм?! *(Кулындагы балдагын, колагындагы алкасын сала башлый.)* Менә алыгыз! Бар булган байлыгым шушы.

Ләйлә Гомәровна. Сез нәрсә, ханым! Мин сезне чишендерергә дип килмәдем. Сез мине дөрес аңлагыз. Мин үзем өчен түгел, сезнең улыгыз, интернатта тәрбияләнгән сабыйлар өчен, бәлки, сезнең улыгыз Ратмир дөнья чемпионы булыр да безнең интернатыбызның даны бөтен дөньяга таралыр, йортыбызга игътибар артыр һәм ярдәм итүчеләр табылыр. Бу хәлләр була калса, андагы балалар рәхәт яшәр дип йөрим мин.

Таңсылу. Рәхмәт, рәхмәт сезгә, Ләйлә Гомәровна. Мин сезне аңлыйм. Бик яхшы аңлыйм. Тик нишлим. Каян алыйм.

Ләйлә Гомәровна. Иregездән сорагыз.

Таңсылу. Нәрсә өчен дип?

Ләйлә Гомәровна. Интернатта тәрбияләнгән бер бала өчен дип.

Таңсылу. Ул аны бирмиячәк.

Ләйлә Гомәровна. Алайса, болай эшлисез. Дөреслекне ачарга туры килә. Минем улым балалар йортында тәрбияләнә, ул булачак чемпион, аңа ярдәм итәргә кирәк, дисез.

Таңсылу. Ул дөрес аңламаячак. Ул безне аңламаячак. Каш ясыйм дип, күз чыгарачакбыз. Тагын ике баланы бәхетсез итәчәкбез.

Ләйлә Гомәровна. Кызык кеше сез. Минем аңлавымча, ике балагыз балда-майда йөзә, ә бер балагыз табигать тарафыннан бирелгән шансын да югалтырга тиеш. Сез дә ярдәм итмәгәч, аңа кем ярдәм итәргә тиеш.

Таңсылу. Күпме кирәк? Кайчанга кадәр?

Ләйлә Гомәровна. Егерме биш мең доллар. Бер атна вакытыбыз бар.

Таңсылу. Озакламый ирем эбәткә кайта. Булдыра алганча табарга тырышырмын. Әмма егерме биш мең доллар дип өзеп әйтә алмыйм.

Ләйлә Гомәровна. Мин сезгә ышанып килдем. Минем сиземләвем беркайчан да үземә хыянәт иткәне юк. Сез бу минутларда иң бәхетле ана. Көтмәгәндә сезнең балагыз киләчәктә дөнья чемпионы булачак дигән хәбәр китерсеннәр әле, шатлыгыңнан күккә сикерерсең. Әйтеп аңлата алмаслык зур шатлык. Шатлык кына түгел, ана өчен зур бәхет. Кайчан килим?

Таңсылу. Үзем хәбәр итәрмен.

Ләйлә Гомәровна. Зинһар, оныта күрмәгез. Безнең бары тик бер атна вакытыбыз бар.

Таңсылу. Зинһар, бу хакта минем ирем белмәсен иде.

Ләйлә Гомәровна. Борчылмагыз, вакыты җитәр. Ратмир чемпион гына булсын, ул әле үзе теләп аңа ата да булыр.

Таңсылу. Мин сезне тоткарламыйм. Менә-менә озакламый ирем кайтып керәчәк.

Ләйлә Гомәровна. Киттем. Рәхмәт сезгә. Сез шундый бәхетле ана. Сез бу җиргә булачак чемпионны тудыручы, тарихка кереп каласы ана. *(Артистлар янына барып утыра.)*

Ут сүнә.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Таңсылу уң як порталда аерым урындыкта утыра. Аның ике ягында ике солдат басып тора. Артистлар утырган җирдән судья, беренче һәм икенче суд утырышчысы торалар, һәм алар уртасына судья
килеп баса.

Беренче суд утырышчысы. Встаньте! Суд идет!

Сәхнәдәге барлык катнашучылар да басалар.

Судья. Шәһәребезнең Елга порты районы суды гаепләнүче Хәмитова Таңсылу Мәүлет кызын шушы елның уникенче июлендә коралланган хәлдә шәһәребезнең беренче номерлы автозаправкасын һәм шул ук автозаправканың кассиры Куравлева Антонина Васильевнаны куркытып сиксән мең җиде йөз илле алты сум акчасын талауда гаепле дип тапты. Шәһәребезнең Елга порты районы суды, гаепләнүче Хәмитова Таңсылу Мәүлет кызы тарафыннан кылынган җинаять эшләрен өйрәнгәннән соң, үзенең хөкем карарын чыгара. Хөкем карары: гаепләнүче Хәмитова Таңсылу Мәүлет кызының җинаятен дөрес дип табарга. Россия Федерациясенең хөкем карары белән сигез елга ирегеннән мәхрүм итәргә.

Музыка. Ут сүнә.

## *УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ*

Ут янганда, Таңсылу креслода утыра.

Эльза (*микрофонга)*. Шулай итеп, сез сигез елга ирегегездән мәхрүм ителдегез. Ә ни өчен ундүрт ел утырдыгыз?

Таңсылу. Мин төрмәгә киткәндә, ике сабыем бусагада елап калдылар. Мин башка аларны күрмәсемне белеп киттем.

Эльза (*микрофонга).* Ни өчен?

Артистлар утырган җирдән Айдар тора да Таңсылу янына килә.

Айдар. Ни өченме?! Ни өчен дип уйлыйсыз инде. Җинаятьче, уйнашчы булганы өчен. Ул минем бөтен тормышымны чәлпәрәмә китерде. Син минем ике сабыемны бәхетсез иттең.

Таңсылу. Кичер мине, Айдар. Минем башка юлым юк иде. Мин балам өчен шушы юлга бастым.

Айдар. Уйнаштан туган балаң өченме?!

Таңсылу. Уйнаштан туса да, ул бит бала. Ата-ана ялгышы өчен бала җавап бирми.

Айдар. Ә син миннән тапкан балаларың турында уйладыңмы соң, Алла колы?!

Таңсылу. Шул сабыйлар турында уйлаганга күрә дә мин җинаять юлына бастым.

Айдар. Мин сине үлемнән йолкып алып калдым. Мин сине урамнан йортыма керттем. Тамагыңны туйдырдым. Ә син?! Ә син мине бөтен шәһәргә мәсхәрә иттең.

Таңсылу. Кичер, Айдар. Барысына да мин гаепле. Нишлим соң, язмыш... Язмыштан узмыш юк, диләр.

Айдар. Син мине тереләй гүргә кертмәкче идеңме?! Миңа булган рәхмәтең шушымы?

Таңсылу. Син миңа өйләнгәндә, мин сиңа әйттем бит, Айдар. Минем белән бәхетле булалмыйсың, мин сиңа тиң түгел, дидем.

Айдар. Нигә син шул вакытта миңа детдомдагы балаң турында әйтмәдең?

Таңсылу. Әгәр әйткән булсам, син мине кичерер идеңме?

Айдар. Юк! Мең тапкыр юк!

Таңсылу. Минем дә бу тормышта бәхетле булырга хакым бардыр бит. Унҗиде яшемдә кемдер минем өстән көлеп җинаять кылган икән, мин дә бит гомерем буена бәхетсез булырга тиеш түгелдер. Кайчан да булса син мине аңларсың дип яшәдем мин.

Айдар. Кеше эшләгән җинаятькә мин җавап тотарга тиеш түгел! Кеше эшләгән җинаятькә минем сабыйларым җавап тотарга тиеш түгел! Син үлдең! Безнең өчен син юк! Минем өчен дә, тудырган балаларың өчен дә син үлдең! Син юк! Син шушы минуттан ана булу хокукыннан мәхрүм! Ишетсен колагың, шушы минуттан синең балаларың юк! Безнең өчен хәтта синең каберең дә юк! (*Артистлар янына барып утыра.*)

Эльза (*микрофонга*). Сез төрмәдән качтыгыз. Сезгә тагын алты ел өстәделәр. Сез бу эшне нигә дип эшләдегез?

Таңсылу. Соңгы тапкыр балаларымны күрергә дип.

Эльза. Хөрмәтле тамашачылар! Безнең «Ана һәм гаилә» тапшыруыбыз азагына якынлашты. Әгәр дә безнең тапшыру сезнең күңелләрегездә нинди дә булса тәэсир калдырса, безнең «Ана һәм гаилә» программасына хатлар юллый аласыз. Бүгенге тапшыруны әзерләде Җәмилова Эльза Айдаровна, тавыш операторы Камил Сәгъдәтшин, тапшыруда Республикабызның күренекле артистлары катнашты. Бүгенге тапшыруның сценарий авторы Флора ханым Садыйкова. Флора ханым, рәхим итеп тамашачыларга күренегез.

Таңсылу урыныннан тормый.

Флора ханым... Флора ханым, сезгә бүгенге тапшыру ошадымы?

Таңсылу. Юк, юк, ошамады. Минем сценариемда ике кызым, ике сабыем — Эльза һәм Луизалар булырга тиеш иде. Мин бирегә шуларның сабый чагын күрергә дип килдем. Кая алар?! *(Үксеп елап.)* Эльза, Луиза, сез кая?! Сез кайда?! Кайда соң минем сабыйларым?! Минем дә бит әни буласым килә.

Музыка. Ут сүнә.

Пәрдә.

**Тәрҗемәләр**

***Рей Куни***

# ЯП ТӘРӘЗӘҢ, БЕТТЕ БАШ!

*Комедия ике пәрдәдә, ике күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Ричард — премьер-министр ярдәмчесе.
Джордж — премьер-министр ярдәмчесенең сәркатибе.
Памело — премьер-министр ярдәмчесенең хатыны.
Джейн — Ричард Уиллиның сәркатибе.
Ронни — Джейнның ире.
Глэдис Фостер — шәфкать туташы.
Мәет — шул ук Детектив — урта яшьләрдәге ир.
Управляющий.
Официант.
Горничная.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. «Вестмистер» кунакханәсе. Алтынчы каттагы унөченче бүлмә зәвыклы итеп җиһазландырылган. Уртада, арткы планда, коридорга чыга торган ишек. Ул ачылганда, коридор аша унөченче «А» номерының ишеге күренә. Уң як түшәмгә кадәр биеклектә зур тәрәзә. Тәрәзә аша еракта «Вестмистер» кунакханәсе күренә. Тәрәзә артында бөтен кунакханәне әйләндереп алган балкон. Тәрәзәдән уңдарак йокы бүлмәсенә керә торган ишек. Коридорга чыга торган ишектән сулдарак зур стена шкафы. Шкафның сул ягында — диван, ә уң ягында, тәрәзә каршында — кәнәфи. Коридорга чыга торган ишек янындагы стена буена радиоалгыч, телевизор, тумба куелган.
Диван янындагы өстәлдә телефон һәм факс. Пәрдә ачылганда, бүлмәдә ут яна. Тәрәзә пәрдәләре ябык. Диванда Ричардның портфеле ята. Ул телефон трубкасын колагына куйган да номер җыя. Түземсезлек белән җавап көтә. Ара-тирә сәгатькә карап ала.

Ричард *(трубкага)*. Кадерлем! Бу мин. Мин әле бу. Әйе, әйе. Әле генә бүлмәмә кердем. Шул ук унөченче бүлмә инде. Өйдә... Өйдә барысы да тәртиптә... Мин үзем дә синең биредә булуыңны теләр идем. Ну нишлисең, таңнан алып хәзергә тиклем ләчтит сату дәвам итә. Менә шул, без синең белән

барыбер бернәрсә дә эшли алмаган булыр идек. Миңа төнемне премьер-министр янында уздырырга туры киләчәк. Ул миңа өметләнә. Ярый, кадерлем, миңа китәргә вакыт...

Ишек шакыйлар.

Бер минутка сабыр итегез... *(Кычкырып.)* Кем бар анда?

Управляющий *(ишек артыннан).* Управляющий.

Ричард ишекне ача. Управляющий керә.

Ричард *(трубкага).* Управляющий керде. *(Управляющийга.)* Минем хатыннан сезгә сәлам.

Управляющий. Түбәнчелек белән башымны иям. Минем дә сәламемне тапшырыгыз.

Ричард *(трубкага).* Ул сиңа үзенең сәламен юллый. *(Управляющийга.)* Ул сиңа рәхмәт әйтә.

Управляющий. Рәхмәтенә рәхмәт белән җавап бирәм.

Ричард *(трубкага).* Сиңа да «рәхмәт» ди. Ярар, кадерлем. Тәмле төн сиңа. *(Трубканы куя, портфеленнән кәгазьләр чыгара да тиз-тиз кәгазьләрдә күзләрен йөгертә башлый.)*

Управляющий. Мистер Уилли, бу номерга нинди дә булса ризасызлыгыгыз юктыр бит.

Ричард. Сез нәрсә?..

Управляющий. Күптән түгел генә без бирегә дә яңа обстановка ясадык.

Ричард. Хәтта мондагы трубаларга кадәр алыштыргансыз.

Управляющий. Трубаларны?

Ричард. Әйе, җылылыкны кушулары була, әйтерсең лә ач бегемотның эчендә турыдан-туры репортаж, ягъни тапшыру, шоу бара.

Бүлмәгә, Ричардның чемоданын күтәреп, Официант керә.

Управляющий. Иртән сезне уятыргамы?

Ричард. Бик иртәләмәгез, төне буе утырыш. Сәгать тугызларда.

Управляющий. Яхшы, мин җылылыкны тугызда аерырга кушармын.

Ричард. Уйлавымча, мин тугызга әзер булырмын. *(Кәгазьләрен портфеленә сала.)*

Управляющий. Гадәттәгечә, чыгышыгыз чираттагы тар-мар итүгә корылганмы?

Ричард. Билгеле! Һәр оппозиция чамадан тыш булмаса. Кергәнегез өчен рәхмәт.

Управляющий. Сезгә лифт чакыртыргамы?

Ричард. Рәхмәт, мин үз аякларым белән төшәм. Буй-сынымны, гәүдәмне нормада тотарга кирәк.

Управляющий. Дөрес, әлбәттә, дөрес.

Корсагына суга-суга, Управляющий чыгып китә. Аның артыннан Ричард ишекне яба. Диваннан портфелен алып ата да диван астына тибеп кертә. Барып, йокы бүлмәсенең ишеген ача. Йокы бүлмәсеннән,
туфлиләрен күтәреп, Джейн күренә.

Джейн. Ул бирегә бүтән кермәс дип уйлыйсызмы?

Ричард *(аның кулларыннан тотып алмакчы була, әмма туфлиләрне тотып кала).* Әлбәттә, юк. Ә ни өчен сез пеньюарыгызны кимәдегез?!

Джейн. Өлгермәдем, мин тыңлап тордым.

Ричард. Алайса, хәзер нәкъ вакыты!

Джейн йокы бүлмәсенә кереп китә. Ричард туфлиләрне урындыкка
куя да йокы бүлмәсен күзәтә.

Ричард *(кычкырыбрак).* Молнияңне ычкындырырга булышыргамы?

Джейн *(ишек артыннан).* Рәхмәт, мин үзем.

Ричард *(йокы бүлмәсенә кермәкче булып).* Ә бәлки, булышыргадыр?

Джейн *(ишек артыннан).* Чыгыгыз!

Ишек артыннан атылган күлмәкне тотып калып, Ричард янәдән йокы бүлмәсен күзәтә. Ул кулындагы күлмәкне диванга ыргыта да телефон
янына килә. Номер җыя.

Ричард *(телефонга).* Общиналар палатасымы? Мин Ричард Уилли. Зинһар, минем секретарьны... Джордж! Бу мин. Фикер алышулар башланды, Алланың биргәненә шөкер. Хәзер тыңлагыз. Мине борчымасыннар. Аңладыгызмы? Әгәр дә андый-мондый бик җитди генә мәсьәлә тумаса, борчымасыннар. Әйе, әйе, премьер-министр гына таптырса. Өйгә, өйгә шылтырата күрмә. Яз. Ноль, җиде, бер, сигез, өч, тугыз, биш, ноль, тугыз, җиде. Мин унөченче номерда. Юк, юк инде, отель түгел, китапханә бу. Британ музееның китапханәсе! Җитте, булды! Ташла, ташла дим үзеңнең дурацкий сорауларыңны! Сиңа нәрсә әйтелде!

Йокы бүлмәсеннән, үтә күренмәле пеньюар киеп, Джейн чыга.

Ричард *(тез буыннары калтырап).* Сез могҗиза!

Джейн. Сез... Рәхмәт сезгә.
Ричард. Сез... Сез — хыял! Мечта! *(Кочакламакчы була.)*
Джейн *(кочагыннан шуып чыгып).* Беләсезме... Минем уйлавымча, мин чамадан тыш оятсыз кыланам, ахрысы.
Ричард. Билгеле, ямьсез һәм начар. Сез каршы килмәсәгез, мин дә киемемне алыштырыр идем. *(Портфелен алып, йокы бүлмәсенә кереп китә.)*
Джейн *(кычкырып).* Мин шул фикердән чыгыбрак. Сез премьер-министр ярдәмчесе, ә мин гади бер секретарша.
Ричард *(ярым чишенгән хәлдә карап).* Менә шушы була инде ул демократия. Өстәвенә мин идарә итүче партия вәкиле, ә сез — оппозиция. *(Йокы бүлмәсенә кереп китә.)*
Джейн *(көлеп).* Әгәр бу хәлне минем шеф белсә, ачуыннан шартлар иде.

Ричард халатын кия-кия чыга.

Ричард. Ә минеке көнчелектән.
Джейн. Ә беләсезме, элек мин үз-үземә беркайчан да мондый хәлне эшләргә юл куймый идем.
Ричард. Молодец. Мин дә. *(Үбә.)*
Джейн. Ой, мистер Уилли! Кем, кем сез...
Ричард *(хурланып).* Джейн!
Джейн. Ишетсәгез иде сез үзегез турынданиләр сөйләгәннәрен!
Ричард. Минем турыда?
Джейн. Сезнең турыда, сезнең турыда. Сезнең хакта ишеткәннәрне хәтта кабатлый алмыйм.
Ричард. Сезгә оят түгелме?!
Джейн *(көлемсерәп).* Ә мин юри генә, бераз гына сезне дәртләндереп җибәрер өчен.
Ричард. Ә, менә ничек?!
Джейн *(кыланып).* Дәртләндереп җибәрү сезгә үзегезгә ошамыймыни?
Ричард *(ул булып).* Дәртләндерүегезнең төбендә нәрсә ята бит? Ташласагыз иде миңа «мистер Уилли» диюегезне. *(Янына утыра.)*
Джейн. Мин бит сезне һәрвакыт шулай атыйм.
Ричард. Минем уйлавымча, хәзерге минутларда сез мине... Хөрмәм дип атый аласыз. Мине сабый чакта шулай дип атыйлар иде.
Джейн. Хөрмә! Лучше мин сезгә Ричард кына дип эндәшәм.
Ричард. Менә бу минем колагыма моңлы көй булып ишетелә. Кстати, мин бит шампанское заказать иткән идем.
Джейн. Искиткеч!
Ричард. Һәм кара икра!
Джейн. Бик күркәм!
Ричард. Өстәвенә өч диңгез моллюскысы.
Джейн. Диңгез моллюскысы. Әйтүләренә караганда, аны искитмәле диләр.
Ричард. Сәгать ничәләрдә сезгә өегездә булырга?
Джейн. Миңа гел кайтмасам да була. Мине апам Розада дип беләләр.
Ричард. Апаң Розада!
Джейн. Әйе, ул бик каты авырый, аның... Хәтта мин, анда кунып ук калам, дидем. Шылтыратырга уйласалар, аның телефоны юк. Шулай булгач...
Ричард. Димәк, ирең анда шылтырата алмый. Гениально! *(Джейнны үпмәкче була, әмма тегесе чытлыклана.)*
Джейн. Искитмәле төн. Мөмкин булса, тәрәзә пәрдәләрен ачыйк!
Ричард. Билгеле...

Тәрәзә пәрдәләренең җебен тарта, алар ачыла, ә анда ике тәрәзә арасына кысылган ир-ат гәүдәсе. Тәрәзәнең өске рамы аның муен тамырына төшеп, башы, җилкәсе, куллары — бүлмәдә, ә калган өлеше балкон ягында калган. Джейн куркуыннан чайкалып куя.

Джейн. Мистер Уилли...
Ричард. Без бит инде сөйләштек, Хөрмәм!
Джейн *(Ричардка ябышып).* Мистер Уилли!..
Ричард. Сез әллә биеклектән куркасызмы? Алтынчы этажны мин үзем алай ук биек димәс идем.
Джейн. Мистер Уилли...

Радиодан күңелгә ятышлы көй яңгырый.

Ричард. Сез аска карамагыз. *(Тәрәзә арасына кысылган гәүдәне күреп.)* Йа Ходай. *(Кысылган адәмнең йөзенә карап.)* Әйе, биредә музыка урынсыз.

Джейн радионы туктата. Ричард тәрәзәгә кысылган ирнең кулыннан йөрәк тибешен тикшермәкче була.

Ричард. Бу рам көтмәгәндә төшеп аның муенын сындырган булырга тиеш.
Джейн. Ходаем!
Ричард. Йөрәк тибеше юк.
Джейн. Димәк, ул үлгән, үлгән, шулаймы?
Ричард. Йөрәге типмәү шуны аңлата.
Джейн. Ә ул биредә күптәнме?
Ричард. Каян белим?! Мин монда кергәндә, пәрдәләр ябык иде.
Джейн. Аның кыяфәте коточкыч.
Ричард. Билгеле, ул бит үлгән.
Джейн. Бичара.
Ричард. Бичара?! Уйлавымча, карак ул.
Джейн. Шулай уйлыйсыз?
Ричард. Ә кем соң, алайса? Ул бит минем номерга кермәкче булган. Билгеле, карак. Балконга менгән дә *(тәрәзәгә карап),* ә балкон бөтен гостиница буйлап сузылган. Ничектер тәрәзәне ачкан. Ә шул вакыт өстәге рам аның муен тамырына. *(Куркыныч итеп муен тамырына төшкән рамны ишарәләп күрсәтеп.)* Бац!
Джейн. Аларның бу рамнары, күрәсең, ватык булган.
Ричард. Шуңа охшаган. Ну, минем уйлавымча, бу инде аларны судка биреп тормас.

Ричард, шнурын тартып, пәрдәне яба. Джейн телефон трубкасын ала.

Джейн. Полициягә шылтыратырга кирәк.
Ричард. Без полициягә шылтырата алмыйбыз. *(Трубканы урынына куя.)*
Джейн. Без бит шылтыратырга тиешбез.
Ричард. Ничек аңлатабыз?! Без синең белән биредә нишли идек дибез? Ягъни мәсәлән, мин үзем хәзерге минутларда җәмәгатьчелек палатасының төнге утырышында булырга тиеш идем.
Джейн. Ну, мистер Уилли, кеше үлгән ләбаса!
Ричард. Ә нәрсә, сезнеңчә, полиция аны терелтә? Алла сакласын, нинди скандал! Әгәр бу хәл урамга, халыкка ишетелсә, без сайлауда күп тавышыбызны югалтачакбыз.
Джейн. Болай да булмый бит. Мәет табып кул кушырып утырып булмый. Әгәр инде полициягә шылтыратмыйбыз дисез икән, әйдә Управляющийга шылтыратыйк.
Ричард. Ә нәрсә үзгәрә? Джейн, аңлагыз, мин бит иң элек сезнең турыда уйлыйм.
Джейн. Сез хатыныгыз, карьерагыз турында уйлыйсыз!
Ричард. Билгеле. Алар турында да. Һәм үземнең газета битендә чыккан групповой секс турында да. Премьерның ярдәмчесе, секретаре һәм Мәет!
Джейн. Без кемгә дә булса шылтыратырга тиештербез бит инде!
Ричард. Тиеш. Мин Джорджга шылтыратам. *(Телефонга бара.)*
Джейн. Мистер Пигденгамы?
Ричард *(телефон номерын җыя-җыя).* Әйе.
Джейн. Шуннан нәрсә? Нәрсә эшли ала инде ул сезнең секретарегыз?
Ричард *(трубкага).* Алло! Бу Уилли әле. Минем секретаремны... Джордж, кичекмәстән сез миңа кирәк. Төкерәм мин сезнең дебатларыгызга. Барысын да ташлагыз да тиз генә бирегә килегез. Нинди Британ музее! Отельгә — «Вестмистер»га, унөченче номерга. Килүегез хакында беркемгә ләм-мим. Нәрсә алып килергә? Җилкәгездәге башыгызны, башыгыздагы миегезне, Джордж! *(Трубканы куя.)*

Ишек шакыйлар. Ричард белән Джейн тынып калалар.

Ричард *(ягымлы рәвештә).* Кем бар анда?
Официант *(ишек артыннан).* Сезнең теләгегезне үтәү нияте белән мин биредә. Сезнең ишек төбегездә!
Ричард. Мин эш белән мәшгуль. Мин занят!
Официант. Бу шәхсән сезнең үзегезнең теләгегез! Шампанское, икра...
Ричард *(кычкырып).* Сабыр итегез, мин йокы бүлмәсендә идем.

Джейнны йокы бүлмәсенә төртеп кертә. Янәдән ишекне шакыйлар. Ричард өстәлдәге Джейнның туфлиен, күреп, йокы бүлмәсенә ыргыта.

Официант *(коридордан).* Унөченче! Мин сезнең заказыгызны алып килдем.
Ричард. Ачам! Ачам!

Тиз генә тәрәзә пәрдәләрен тикшерә дә ишекне ача. Шампанское, икра

һәм диңгез моллюскысы куелган арбаны этеп, Официант керә.

Официант. Кайнар ризык суынырга да өлгерде.
Ричард. Бирегә куегыз. *(Джейнның күлмәген эләктереп ала да йокы бүлмәсенә китмәкче була.)*
Официант. Сэр! Нарядка кулыгызны куйсагыз иде.
Ричард. Бирегез!

Телефон шылтырый. Официант аңа кул куяр өчен кулындагы кәгазен суза. Ричардның куллары буш булмау сәбәпле, кулындагы Джейн
күлмәген Официантка тоттыра да нарядны ала.

Ричард. Әйе, господин Управляющий. *(Нык дулкынланып, трубкага.)* Нәрсә күрдегез?.. Таныш булмаган кеше? Минем балкон...

Ричардның күзләре ябык тәрәзә пәрдәләренә төшә. Официант та ул
караган җиргә карый.

Ричард. Минем балконда... *(Трубкага.)* Юк инде, минем барысы да тәртиптә. Сез башка балконны күрәсездер. Юк, юк, минем тәрәзә пәрдәләрем ачылган. Мин аермачык күрәм, минем балконда беркем дә юк.

Официант ябык пәрдәләрне карый.

Ричард. Бу ниндидер хата. Әйе, һичшиксез, хата... *(Официантка.)* Ычкыныгыз! *(Трубкага.)* Юк, юк, мин сезгә түгел. Алло! *(Трубканы куйганда, Официантның тәрәзәгә барганын күрә һәм, кычкырып.)* Туктагыз!
Официант *(куркуыннан калтырап)*. Ә?!
Ричард. Нарядыгызны алыгыз. *(Нарядка кул куя да Официантка бирә.)* Менә булды.

Официант, йомшак кына тамак кырып, уч төбен ачып, кулын суза. Ричард кесәсеннән акча чыгара да Официантка бирә, һәм ишек төбенә озата. Ричард та, Официант та Джейнның күлмәге һаман да Официант
кулында калуына игътибар итмиләр.

Официант *(кулындагы зур акчаны күреп, шаккатып)*. Рәхмәт сезгә! Бик-бик зур рәхмәт!

Официант чыгып китә. Ричард тиз генә ишекне яба да, тәрәзә пәрдәсенең җебен тартып, пәрдәләрне ача. Күзләре белән бүлмә эчен тикшереп чыга да, шкаф кырыена килеп, ишеген ача. Буш шкафта берничә җилкәлек, элгечләр. Янәдән тәрәзә янына килеп, рамны күтәрә, урта яшьләр тирәсендәге ир кеше гәүдәсен бүлмә эченә сөйрәп ала. Гәүдәне үзенә каратып тота. Кулына сумка тотып, трусик һәм лифчиктан
Джейн килеп чыга.

Джейн. Мистер Уилли, сез нишлисез?!
Ричард. Сезнең уйлавыгызча, нишлим соң? Вальс әйләнәм.

Көтелмәгәндә, шапылдап, тәрәзә рамы килеп төшә.

Ричард *(калтыранып)*. Хәзер аңлашылды. Менә ничек булган ул. *(Мәетне шкафка өстери.)*
Джейн *(курыккан хәлдә)*. Полицияләрдән башка Мәетне кузгатырга ярамый!
Ричард. Аңа барыбер! Кем, кайчан һәм кайда аны тапкан. Хәзер Джордж килә дә, без барысын да җайлыйбыз.
Джейн. Бу бит дөрес түгел, мистер Уилли.
Ричард. Хикмәт хәзер дөреслектә түгел, киресенчә, безнең файдага эшләүдә.

Ричард Мәетне шкафтагы элгечкә аса да ишеген яба. Джейн аңа шак-
катып карап тора.

Ричард. Хәзер сезгә тоткарланмыйча тизрәк өегезгә кайтырга кирәк. Нигә күлмәгегезне кимәдегез?
Джейн. Ул бит биредә.
Ричард. Мин бит аны сезнең янга йокы бүлмәсенә ыргыттым.
Джейн. Сез миңа туфлиләремне ыргыттыгыз.
Ричард. Ә күлмәк... *(Исенә төшеп, шаккатып.)* Мин бит аны Официантка бирдем...
Джейн. Официантка?!

Ишек шакыйлар. Джейн белән Ричард бер-берсенә карыйлар.

Ричард *(бик итагатьле итеп)*. Да, да?
Управляющий *(коридордан.)* Бу мин, Управляющий.
Ричард *(Джейнга)*. Тиз бул, йокы бүлмәсенә!
Джейн *(пышылдап)*. Ә минем күлмәк?
Ричард. Тс-с! Соңыннан. *(Джейнны йокы бүлмәсенә төртеп кертә.)*
Управляющий *(ишек артыннан)*. Мистер Уилли!

Ричард. Хәзер! *(Өстендә халат кына булуын искә төшереп, пиджагын кияргә дип, йокы бүлмәсенә таба атлый.)* Пиджак!

Джейн йөгереп чыга да аңа пиджагын ыргыта. Яңадан йокы бүлмәсенә
кереп китә. Ричард халаты өстеннән пиджак кия.

Управляющий *(ишек артыннан).* Мистер Уилли!
Ричард *(кычкыра).* Бер минут!

Ишеккә таба атлавы була, Мәет асылган шкаф ишеге ачылып китә.

Ричард. Ах, каһәр! *(Шкафка таба йөгереп барып, ишеген яба.)*
Управляющий *(коридордан).* Мистер Уилли!
Ричард *(тыныч кына).* Ачам, ачам!

Ричард пиджак төймәләрен ычкындырып җибәрә дә ишекне ача.
Бүлмәгә, үртәлгән кыяфәттә, Управляющий керә.

Управляющий. Гафу итегез, ну эш кичектергесез мөһим. *(Уиллига карап тынып кала.)*
Ричард. Аңлыйм, аңлыйм, мин соңга калам. Мин инде күптән фикер алышуда булырга тиешмен. *(Үзенең тышкы кыяфәтен күреп алып.)* Кирәк бит, ә, кирәк бит. Эшкә шундый бирелеп киткәнмен.
Управляющий. Кабатлап әйтәм: бик җитди эш.

Управляющий тәрәзә янына бара да ачып карый. Ричард, җайлап кына,
Управляющийны бүлмә уртасына алып килә.

Ричард *(халатын салып, пиджагын киеп).* Мин әзер. Миндә барысы да тәртиптә.
Управляющий. Каршы йорттагы күршегез миңа балконнан ниндидер ир кешенең сезнең номерыгызны күзәткәне хакында әйтте.
Ричард. Ул ялгышкан.
Управляющий. Юк, ул именно сезнең балконыгызны күрсәтте. Аның әйтүенчә, ул кеше сезнең бүлмәгезне ун минут чамасы күзәткән. Ул кеше, тезләнгән килеш, сезнең тәрәзәгезгә башын тыгып карап торган. Өстәвенә әз генә дә селкенмәгән.
Ричард. Ходаем! Үзегез күреп торасыз лабаса, анда бер кеше дә юк.
Управляющий. Отельгә карак кермәгән дип өзеп әйтергә ашыкма. Миңа сезнең йокы бүлмәгезне тикшерергә кирәк.
Ричард. Йокы бүлмәсен?!
Управляющий. Мистер Уилли, бүлмәләрне тикшерү минем турыдан-туры вазифам.
Ричард. Яхшы, нишләмәк кирәк. *(Джейн ишетерлек итеп.)* Управляющийның вазифасы йокы бүлмәсенә кереп тәрәзәне тикшерү! *(Управляющийга карап елмая.)*
Управляющий *(аптырап).* Рәхмәт сезгә.

Управляющий, аны урап, йокы бүлмәсенә атламакчы була. Ричард аның юлын бүлә. Янәдән Управляющий бүлмәгә омтыла, ләкин тегесе
аның юлын кабат бүлә.

Ричард. Шулай ук беррәттән, господин Управляющий *(кулларын Управляющийның халат кесәсенә тыгып)*, сезгә рәхмәтлемен. *(Управляющийны йокы бүлмәсенә кертеп җибәрә.)*

Коридордан ишек какканнары ишетелә.

Ричард *(кычкырып, йокы бүлмәсенә кадәр ишетелерлек итеп).* Хәзер, кем шакыганын беләм! *(Кычкырып.)* Кем бар анда?
Джордж *(коридордан).* Мистер Уилли, бу мин, Джордж.

Ричард ишекне ача. Портфель тоткан Джордж күренә.

Джордж. Акылдан шашкан кеше кебек чаптым.
Ричард. Яхшы. *(Джорджны бүлмәгә тартып кертә.)* Игътибар белән тыңлагыз. Мин үзем, ягъни менә шушы номерда, кирәгеннән артык күңелсез гәүдә таптым.
Джордж. Ягъни мәсәлән, нинди мәгънәдә?
Ричард. Ул гәүдә, ягъни мәсәлән, Мәет, хәзергесе минутта шкафта.
Джордж. Гәүдә... Мәет... Бу сүз белән сез нәрсәне күз алдында тотасыз?
Ричард. Менә шул. Мин ул гәүдәне сезнең тарафтан башка җирдә һәм башка урында табылуын теләр идем.
Джордж. Нәрсәдер мин аңлап җиткермәдем.
Ричард. Именно сезнең тарафтан. Мондый эш эшләнергә тиеш. Мин җәмәгатьчелек палатасында чыгыш ясаганда, ә секретарша өенә кайтып, йокларга яткач.

Джордж *(озак кына алда сөйләгәннәрне аңларга тырышып азапланганнан соң).* Бәлки, миңа киредән чыгып яңадан кереп караргадыр?

Ричард *(Джорджны урындыкка утыртып).* Ә иң мөһиме, хәзер йокы бүлмәсеннән чыгачак Управляющий бу хакта берни дә белмәскә тиеш.

Джордж берни дә аңламаган хәлдә Ричардка карый.

Ричард. Минем балконга беркем дә менмәде. Мине һичкем борчымады. Шкафта бернинди Мәет тә юк.

Джордж. Ярый, монысы өчен рәхмәт...

Ричард. Дәшмәгез һәм исегездән чыгармагыз, бернәрсә дә булмады. Аңлашылдымы?

Паузадан соң Джордж, ризасызлык белдереп, башын селки.

Ричард. Кыскасы, мин нәрсә сөйлим, акыллы кыяфәт ясап, әйткәннәргә кушылып баш селкеп утырырсыз.

Джордж, ризалыгын белдереп, башын селки. Управляющий чыга.

Управляющий. Анда барысы да тәртиптә.

Джордж тормакчы була, Ричард аны артка этә.

Ричард. Мин бит сезгә әйттем. Ә бу минем шәхсән сәркатибем Мистер Пигден.

Джордж горур гына башын ия.

Ричард. Джорджның бүген чамадан тыш бик ашыгыч эшләре күп. Хәтта миңа бүген аның төнлә белән биредә калып эшләвен дә сорарга туры киләчәк.

Джордж башын селки.

Ричард *(Управляющийга).* Менә шул, ә минем сезгә кечкенә генә йомышым бар.

Управляющий. Кулдан килгәннең барысын да эшләрбез.

Ричард. Аңа минем янәшәмнән берәр номер алырга иде. Балконнарыбызның бер-берсенә тоташкан булуы бик мөһим. Безгә бер-беребез белән һәрвакыт элемтәдә торырга кирәк. Шулай бит, Джордж?

Джордж, ризалык белгертеп, башын селки.

Управляющий. Яхшы, хәзер үк барып карыйм. Безнең нинди номерлар буш икән?

Ричард. Отлично.

Управляющий. Беррәттән охрананы да кисәтеп куям, балкондагы чит кеше хакында әйтүем.

Ричард. Кирәкмәс дип уйлыйм. Ул сезнең отель өчен яхшы реклама булмаячак.

Управляющий. Шулай дисезме?

Ричард. Әлбәттә.

Управляющий чыгып китә.

Ричард. Молодец, булдырдың, Джордж. Шулкадәр гениально баш селкедең... Просто...

Джордж. Ходай хакы өчен аңлатыгыз, берни дә аңламыйм.

Ричард. Биш йолдызлы отельдән сезгә бушлай бүлмә, номер бирәләр.

Джордж. Мин, әнигә хәбәр итмичә, беркайчан да чит җирдә кунып калмыйм.

Ричард. Хәбәр ит, шатлансын карчык.

Джордж. Әни ятакта, аңлыйсызмы, постельдә. Аннары сестра Фостер...

Ричард. Апагыз Фостер?

Джордж. Медсестра. Мин эштә чагында авыру әнине карап тора. Аңа унынчы яртыда китәргә кирәк.

Ричард. Шылтырат та әйт, тоткарланам, диген.

Джордж. Яхшы түгел, уңайсызланам. Аннары мин вакытында кайтмасам, әни борчыла башлый.

Ричард. Сезнең өчен әниегез сиксән ел борчыла инде. Ә хәзерге минутта аңа хөкүмәт, правительство язмышы хакында борчылырга иде!

Джордж. Ә нәрсә булды соң?

Эчке күлмәктән, ишекне киң итеп ачып, Джейн чыга.

Джейн. Син, сез минем күлмәкне кире кайтардыгызмы? *(Джорджны күреп.)* О-о, Мистер Пигден!

Ричард *(Джорджга).* Хәзер инде сез эшнең нәрсәдә икәнен аңладыгызмы?

Джордж авызын ачып сүз әйтмәкче була, ләкин баш селкү белән чикләнеп кала.

Джейн. Хәерле кич!

Джордж *(аның лифчигына карап).* Хәерле, мисс... *(Ричардка.)* Мистер Уилли, сез ничек?!

Ричард. Әлегә мин берни дә эшли алмадым. Бу хәзер мөһим дә түгел. Иң мөһиме хәзер күлмәкне кире кайтару.

Джордж. Ә кая соң ул?

Ричард. Аны Официант алып чыгып китте.

Джордж. Официант алып чыгып китте... Ничек бу минем башыма килмәде.

Джейн *(Ричардка).* Сез мистер Пигденга Мәет турында әйттегезме?

Ричард. Әйттем, әйттем.

Джордж. Димәк, чыннан да Мәет бар?! Сез бит Мәет юк дидегез!

Ричард. Мин бит Управляющийга әйттем.

Джордж. Берни аңламыйм.

Ричард. Управляющий отельдә бары тик чит кеше пәйда булганын гына белә.

Джордж. Нинди чит кеше?

Ричард. Управляющий ул чит кешенең Мәет икәнен белми.

Джордж. Чит Мәет?

Джейн. Ул безнең тәрәзәгә кысылган.

Джордж. Кем? Управляющиймы?

Ричард. Чит кеше!

Джейн. Аның муен сөяге сынган.

Джордж. Хәзер барысы да аңлашыла. Сынык муен?!

Ричард йокы бүлмәсенең ишеген ача.

Ричард. Джейн, күлмәгегезне кире алганчы сезгә лучше йокы бүлмәсендә көтәргә туры килер.

Джейн. Ә мин каян белеп чыгам.

Ричард. Үзем чакырырмын!

Джейн *(Джорджга).* Безне бу эшкә тартканыбыз өчен сез миңа шундый кызганыч.

Джейн кереп китә. Ричард трубканы ала да номер җыя.

Джордж. Туктагыз әле, сез бит Мәетне шкафта дидегез.

Ричард. Чынлыкта да шулай. *(Трубкага.)* Номерларның заказларын тәэмин итүчеләр бүлегеме? Миңа унөченче бүлмәгә заказ керткән Официант кирәк иде. Ә-ә, бу сез! Карагыз әле, сез миннән нәрсәдер алып чыгып киткән идегез бугай! Әйе, әйе, мин үз кулларым белән сезгә тапшырып чыгардым... *(Джорджга.)* Балван. *(Трубкага.)* Менә шул, мин сезнең аны бирегә кертүегезне теләр идем. Әйе, әйе, унөченче бүлмәгә, тизрәк! *(Трубканы куя.)* Киләчәктә үлем җәзасының кертү-кертелмәвенә мин, һичшиксез, мин риза дип кул күтәрәчәкмен.

Джордж. Ничек инде Мәет тәрәзә арасыннан чыгып шкафка кадәр барган. Сез нәрсә, әллә үзегез аны шкафка яптыгызмы?

Ричард. Ашыгырга кирәк иде.

Джордж. Полициягә хәбәр иттегезме?

Ричард. Юк, шуның өчен дә сезнең ярдәмегез кирәк.

Джордж. Мистер Уилли, гафу итегез... *(Тора да номердан чыгып китмәкче була.)*

Ричард. Джордж! Минем хатын мине хәзергесе минутларда җәмәгатьчелек палатасында дип уйлый. Бу хәлне урамга чыгармаска иде. Аннары, үзең беләсең, мисс Джейн...

Джордж. Мистер Уилли, әгәр мин өйләнгән булсам, хатыныма беркайчан да хыянәт итмәс идем.

Ричард. Билгеле, шулай. Беләсезме, ни өчен? Чөнки сез миннән күпкә яхшырак. Тыңлагыз әле! Беләсезме, без сезнең белән хәзер нишләргә тиешбез.

Джордж. Без?! Юк инде, бернинди дә без юк!

Ричард. Яхшы, булды. Беләсезме, сез нишләргә тиеш?..

Джордж. Мин сезгә берни дә тиеш түгел!

Ричард. Управляющий сезгә номер бирүгә, без Мәетне...

Джордж. Нишләтәбез?!

Ричард. Мәетне сезнең номерга кертәбез дә тәрәзә арасына кыстырабыз. Мин җәмәгатьчелек палатасына, ә мисс Уорзингтон үз өенә кайтып киткәч, сез, тәрәзә пәрдәләрен ачып, Мәетне табасыз да Управляющийга хәбәр итәсез.

Джордж. Сезгә барысы да шундый җиңел! Минем номер. Минем тәрәзә. Ә сез мисс Уорзингтон белән җайлап кына үкчәләрегезне күтәрәсез, ә мин, мескен, Джордж Пигден...

Ричард. Ә иң мөһиме, сез бит боларны минем өчен түгел, премьер-министр файдасына эшлисез. Юкса ул миннән эштән китүемне таләп итәчәк. Ә бу безнең кабинетта өченче отставка, ягъни эштән китүче булачак. Безне бу бизәми. Сайлауларда без оттырачакбыз!

Джордж *(шикләнеп).* Сезнең әйтүегезчә, ул шкафта инде.

Ричард. Ишегенә элеп куелган.

Джордж *(шкаф янына бара да, ишеген ачарга кыюлыгы җитмичә).* Нервыларыгызны учыгызга җыегыз! Нервыларыгызны!

Джордж күзләрен йома да шкаф ишеген ачып җибәрә. Иплэп кенә күзләрен ачып, шкаф эчен күзәтә. Шкаф эчендәге элгечләрдән гайре бернәрсә дә булмавын күреп, шатлыгыннан көлә. Кинәт күзләре шкафка эленгән Мәеткә төшә. Куркуыннан кычкырып җибәрә. Управ-
ляющий ишекне шакып керә.

Управляющий *(керә-керешкә).* Мистер Уилли! Мин сезне шатландырырга телим.

Джордж, Управляющийны күреп, тиз генә шкаф эченә керә дә шкафның ишеген яба. Ричард аның игътибарын үзенә җәлеп итәр өчен
алдына тезләнә.

Ричард *(тора башлап).* Сезнең биредә шулкадәр затлы коверлар.

Управляющий. Мин Мистер Пигден өчен номер таптым. Ә үзе кая соң әле?

Ричард. Бәдрәфтә! *(Управляющийны шкафтан читкәрәк алып китә. Джейн ишетерлек итеп кычкырып.)* Мин Управляющийга сезне бәдрәфтә дидем. *(Управляющийга карап елмая.)*

Управляющий. Мин аның өчен унөченче «А» номерын әзерләдем.

Ричард *(тавышын күтәреп).* Управляющий әйтүенчә, сезнең номерыгыз унөченче «А».

Управляющий *(Ричардка аптыраулы караш белән).* Нәкъ сезнең бүлмәгә каршы.

Ричард *(кычкырып).* Аның әйтүенчә, нәкъ минем бүлмәгә каршы!

Йокы бүлмәсеннән лифчик һәм трусиктан Джейн чыга.

Джейн. Акырмагыз миңа алай. Мин саңгырау түгел, ишетәм. *(Управляющийны күреп алып.)* Ой!

Ричард *(паузадан соң).* Бу, бу миссис Пигден.

Управляющий *(шикләнеп).* Миссис Пигден?

Ричард. Мин сезгә әйтмәдеммени?

Управляющий. Юк!

Ричард. Алар хатыны белән икесе бергә биредә төн уздырмакчылар иде. Шулай бит, миссис Пигден?

Джейн. Әйе! Билгеле, шулай.

Ричард. Күрәсез, Управляющий сезгә барысын да оештырды. Рәхмәт аңа. Сезнең номерыгыз унөченче «А». *(Управляющийга.)* Сез кирәгеннән артык мәрхәмәтле.

Управляющий. Ә минем фикер йөртүемчә, мистер Пигденга номер эш өчен кирәк иде бугай.

Ричард. Билгеле, әлбәттә, шулай. Ну мин аны әз генә булган санаулы шатлыклы минутларыннан мәхрүм итә алмыйм. Аңларга кирәк, яшь хатын, сезнең отельнең күркәм, затлы номеры. Өстәвенә бушлай, хөкүмәт җилкәсеннән. Ул аңа шылтыратуы булды, ә миссис тавыш тизлегендә бирегә килеп җитте.

Управляющий. Аңлашылды.

Ричард. Күрәсез, миссис Пигден душтан гына чыкты. Ә мистер үзе бәдрәфтә. Барысы да тәртип, гаиләдәгечә. Шулай түгелме, миссис Пигден?

Джейн. Шулайрак килеп чыга.

Ричард *(Управляющийга).* Шулайрак.

Ишекне шакып, Горничная керә.

Горничная. Жумаргамы?

Ричард. Гафу итегез!

Горничная *(иҗекләп).* Урын җи-ре-без-не жу-а-алыш-ш-штыр-р-р...

Ричард. Ә-ә, урын-җирегезне алыштырырга? Юк, юк, кирәкми.

Горничная. Зур рәхмәт! *(Джейнны күреп.)* У-ур-р... ж-ж-жу...

Ричард. Әйттем бит, кирәкми, дидем. Без үзебез.

Горничная *(берни аңламыйча).* С-с-с-сез ү-ү-үзе-е-е-гез?

Ричард. Әйе, әйе, без үзебез.

Горничная. С-с-с-сез ү-ү-үзе-е-е-гез. Хороса, хороса.

Управляющий. Барыгыз, бар, Мария, чыгыгыз.

Горничная. Зур рәхмәт.

Горничная, башын түбән ия-ия, арты белән чыгып китә.

Ричард *(Управляющийга).* Сезгә дә бик зур рәхмәт.

Управляющий. Кирәкмәс. *(Джейнга.)* Хәзер мин сезгә унөченче «А» номерының ачкычын менгерәм. Хәзер үк урнаша аласыз.

Ричард. Зур рәхмәт.

Управляющий *(Джейнга).* Үзегезнең эшегезне төгәлләгәннән соң, үзегез йә, булмаса, миссис Пигденның аска төшеп регистрация үтүен сорар идем.

Ричард. Сез теләгәнчә булыр. *(Управляющийны ишек төбенә алып китә.)*

Управляющий. Минем белүемчә, сез утырышка ашыга идегез бугай?

Ричард. Әйе, әйе, йөгердем... Мин бәдрәфнең бушаганын гына көтәм.

Управляющий Ричардка карый. Шул вакыт әкрен генә шкаф ишеге ачыла башлый. Ричард яшен тизлегендә ишекне барып яба. Управляющий янәдән карый. Ул, каты кысталган кыяфәт ясап, чыраен сытып, эчен тота. Управляющий, аның хәленә кереп, башын селки һәм
чыгып китә.

Джейн. Сез нәрсә эшләдегез, мистер Уилли?

Ричард. Минем уйлавымча, барысы да яхшы. *(Шкаф ишеген ача.)* Джордж!

Джордж *(шкафтан чыгып).* Бу бит куркыныч.

Ишек шакыйлар. Джордж янәдән шкаф эченә кермәкче була, әмма
Ричард аны туктата.

Ричард. Кем бар анда?

Официант. Бу мин. Сезнең заказыгыз буенча.

Ричард. Яхшы. *(Джейнга.)* Бу сезнең күлмәк булырга тиеш. *(Ишекне ача.)*

Официант керә һәм Ричардка кәгазь суза.

Ричард *(кәгазьне әйләндерә-әйләндерә карап, Официантка).* Бу нәрсә?!

Официант. Наряд. Сез бит сорадыгыз.

Ричард. Мин сорадым...

Джордж. Сездән наряд турында сораган вакытта, күз алдында мистер Уилли күлмәкне тотты.

Официант *(Ричардка аптырап карап торганнан соң).* Күлмәк?..

Джейн. Куе зәңгәр күлмәк. Вак чәчәкләр төшерелгән.

Официант *(иҗекләп шигырь укыган кебек).* Куе зәңгәр, вак чәчәкләр белән... Матур, әйе шул. Бу күлмәк ничек әле безнең бүлмәгә килеп эләкте соң дип уйлаган идем мин?

Джейн. Зинһар өчен, шуны кертегез.

Ричард. Һәм тиз арада.

Официант. Ярар, Управляющийның әйтүенә караганда, кайсыгыздыр унөченче «А» номерына күчәсез бугай.

Ричард. Әйе, әйе, мистер һәм миссис Пигденнар күчә.

Джейн Джорджның кулыннан ала. Джордж, аңа карап алганнан соң,
ризалык белдереп, башын селки.

Официант *(Ричардка ачкычны биреп).* Ачкыч бирәү генә.
Ричард Джорджка ачкычын бирә.

Официант. Сезнең әйберләрегез бармы?

Ричард. Юк, аларга әйберләр кирәкми. Аларның зөфаф киче.

Джордж. О Ходаем! *(Урындыкка утыра.)*

Ричард. Бүген иртән язылыштылар. Джордж, отель миннән сезгә бүләк, ягъни мәсәлән, туй бүләге. Әлбәттә, бөтен отельне күз алдында тотмагыз, унөченче «А» номеры. Бүген төнгә! Зөфаф төнегезгә!

Официант *(Джорджка).* Сез кәләшегезгә бүген күлмәк кирәк булыр дип уйлыйсызмы?

Джордж. Билгеле.

Ричард. Һәм күпме тизрәк, шуның хәтле яхшырак.

Официант әкрен генә кулын суза, Ричард аңа биш фунт сала.

Официант *(ризыклы арбага карап).* Сез заказыгызга кагылмагансыз да.

Ричард. Нәрсәгәдер аппетит бозылып китте. Алып чыгып китә аласыз.

Официант *(арбаны тотып).* Яхшы, бер этаж түбәнгә сатармын.

Официант арбаны тартып чыгып китә.

Джордж. Мистер Уилли, мин сезгә шундый фикер җиткерәсем килә: болар барысы да мәгънәсез һәм ямьсез.

Ричард. Әйтәсе килгән фикерегезне кабул итәм, күлмәгегезне китергәнче йокы бүлмәсендә көтегез, Джейн. Күлмәгегезне киярсез дә өегезгә кайтып китәрсез. *(Йокы бүлмәсенең ишеген ача.)*

Джейн. Мистер Пигден, эшнең болай килеп чыгуы сезнең алда миңа шулкадәр уңайсыз.

Ричард. Сез нәрсә?! Ул бәхеттән җиде кат күк өстендә. *(Джейнны йокы бүлмәсенә төртеп кертә.)* Менә шул, Джордж, үз номерыгызга барыгыз.

Джордж. Сабыр итегез, сестра Фостерга булса да шылтыратыйм. *(Номер җыя.)*

Ричард. Зинһар өчен, Ходай хакы өчен тизрәк.

Ричард шкаф ишеген ача, ишектә Мәет пәйда була.

Джордж *(трубкага).* Алло, мисс Фостер?.. Хәерле кич... Әйе, барысы да тәртиптә... Хәлләр? Рәхмәт, әйбәт.

Ричард. Ташласана үзеңнең сәламәтлегең турындагы исәп-хисапларыңны!

Джордж *(трубкага).* Әни ничек анда?

Ричард. Әй Ходаем.

Джордж *(трубкага).* Да, кит аннан! *(Ричардка.)* Әни бүген бик борчулы ди.

Ричард. Бүген барыбыз да борчулы! *(Килеп тәрәзәне ача.)*

Джордж *(трубкага).* Сездән шуны сорыйсым килә: мин бүген бераз гына тоткарланам. Әйе, мөһим эш... Рәхмәт сезгә, мисс Фостер... Юк, юк! Әгәр әнинең шылтыратасы килсә, шылтыратсын, минем номер: ноль, җиде, бер, сигез, өч, тугыз, биш, ноль, тугыз, җиде.

Ричард. Джордж!

Джордж. На всякий случай, әни минем кайдалыгымны белеп торсын. *(Трубкага.)* Мин унөченче «М» яисә унөченче «А»да булам. Британский музейның уку залында. Бик зур рәхмәт сезгә. *(Трубканы куя.)*

Ричард. Ниһаять, Алланың биргәненә шөкер, хәзер үз номерыгызга керегез дә, тәрәзәгезне ачып, балкон аша бирегә килегез.

Джордж. Ә сез беләсезме, биеклектән минем башым әйләнә.

Ричард. Бигрәк яхшы, Мәетне үзегезгә өстерәгәндә, Мәет турында азрак уйларсыз.

Ричард Джорджны коридорга төртеп чыгара башлый. Джордж унөченче «А» номерының ишек яңагына ябыша. Көч-хәл белән Ричард үз ишеген яба да Мәет янына килә. Йокы бүлмәсеннән Джейн чыга.

Джейн *(тавышын күтәреп).* Мистер Уилли!

Ричард *(куркып).* Җен! Башка беркайчан да болай эшләмәгез!

Джейн. Яңа гына башыма китереп сукты, минем бит барыр җирем юк.

Ричард. Ничек инде барыр җирең юк? Ә өең?!

Джейн. Өйгә кайталмыйм мин. Ирем бит мине Роза апаларда дип уйлый.

Ричард. Соң, алайса, апаларыңа бар!

Джейн. Бу вакытта мин аңа барып керсәмме, ул куркуыннан һушыннан язып егылачак.

Ричард. Ул чагында Пигден белән бергә ятасыз. Уртак алган номерыгызда.

Тәрәзәдә Джордж пәйда була.

Джордж. Сез мине берни дә ишетмәде дип уйлыйсызмы?

Ричард. Әйдәгез тизрәк! *(Элгечтән Мәетне төшерә башлый.)*

Джордж. Беләсегез килсә, минем сезнең корган планыгызга шигем бик зур.

Бүлмәгә Управляющий кергәне күренә. Ричард Мәет белән шкаф эченә кереп югала. Джейн шкаф ишеген яба.

Управляющий *(керә-керешли).* Мин мистер һәм миссис Пигденнарны беркайдан да табалмадым.

Тәрәзә кырыендагы Джорджны күреп туктап кала. Джордж дустанә елмая һәм кулын болгый. Управляющий тәрәзә янына килә.

Управляющий. Мистер Пигден, сез нәрсә эшлисез?

Джордж. Хәерле көн!

Джордж тәрәзәгә таба бер адым ясый, тәрәзә рамы Джорджның борын төбендә шапылдап килеп төшә. Управляющий рамны күтәрә.

Управляющий. Мин сезгә кергән идем. Мин сезне инде кәләшегез белән үз номерыгызга урнашкансыздыр дип уйлаган идем.

Джордж. Ә безнең бу балконнан күренгән матурлык белән хозурланасыбыз килде. Искиткеч. *(Джейнга кулын бирә.)* Киттек, сөеклем, үз бүлмәбезгә кайтыйк.

Джейн *(Управляющийга).* Гафу итегез. *(Рам аркылы чыга, аның артыннан Джордж.)*

Джордж. Барысы өчен дә рәхмәт.

Управляющий. Аска, регистратурага төшеп, икегезнең дә теркәлүегезне үтенәм.

Ричард шкафтан чыга.

Джордж *(кычкырып).* Кичекмәстән!

Ричард *(Управляющийга).* Акылсыз яшь парлар!

Управляющий тавыш килгән якка борыла. Янәшәсендә басып торган
Ричардны күреп сискәнеп китә.

Управляющий *(коры гына).* Аңлавымча, сез, мистер Уилли, гомумән, бүген утырышта катнаша алмаячаксыз.

Ричард. Иң элек мин бәдрәфкә барырга тиешмен.

Ричард, эчен тоткан килеш, кысталган кыяфәт ясап, йокы бүлмәсенә юнәлә. Управляющий аны күзәтә. Ричард туктый да аңа текәлә. Управляющий чыга торган ишеккә берничә адым ясый. Шул вакыт кисәк кенә сөялгән урыннан рам килеп төшә. Управляющий борылып карый, Ричард кысталган булып кылана. Тегесе аның хәленә кереп баш селки дә чыгып китмәкче була. Көтмәгәндә шыгырдап Мәет белән
шкаф ишеге ачыла.

Ричард *(сизмәстән кычкырып).* Ах, каһәр!

Управляющий борыла. Ричард әйтерсең лә тышка чыгасы килгәненә түземлеге калмавын белгертеп сикергәли. Управляющий, аңа карап,
шкафка игътибар итмичә чыгып китә.

Ричард *(тәрәзә янына йөгереп килә дә рамны күтәрә, балконга таба башын борып кычкыра).* Джордж! *(Башын аска иеп.)* Джордж!

Ричард балконнан юкка чыга. Ишек шакыйлар. Бүлмәгә, күлмәк
күтәреп, Официант керә.

Официант. Мин сезнең заказ буенча. *(Берни дә аңламый басып тора.)*

Телефон шылтырый.

Официант *(трубканы ала).* Алло? Әйе, унөченче номер... Нинди читальный зал? Юк, номер дөрес. Ну бит бу Британ музее түгел, бу отель... Мадам, ышаныгыз миңа, әгәр мин Британ музеенда эшләсәм, мин, әлбәттә, белер идем. Кем ул Пигден? Ә бу отель. Менә монысы безнеңчә. Мистер Пигден бездә бар. Пигден безгә урнашты. Аңа ни дә булса әйтергәме? Нәрсә, энисе борчыла? Яхшы. Сез аның энисенә әйтегез, борчылмасын. Аның улы яшь, сылу, матур, булачак киленегез белән бергә зөфаф киче уздыра.

Официант трубканы куя, аннан күтәренке күңел белән чыгып китә.
Тәрәзәдән Ричард, Джейн, Джордж керәләр.

Ричард. Тизрәк булыгыз! Джейн, ишекне күзәт! Ә без үзебезнең проблеманы унөченче «А» номерына.

Ричард белән Джордж Мәетне чөйдән төшерәләр. Джейн шкаф
ишеген яба.

Джордж. Әй Ходаем, әни генә анда борчыла башламасын инде.

Ричард. Ике генә минутка булса да энигезне онытып торыгыз! Тизрәк!

Балконда кулындагы күлмәге белән Официант барлыкка килә.

Официант. Ну и ну!

Джордж белән Ричард Мәетне икесе ике яктан култыклап алалар да диванга ташлыйлар. Официант ачык тәрәзәдән килеп керүе була, Джордж һәм Ричард җырлый-җырлый Мәет белән бергә бии башлыйлар. Официант сокланып алар җырлап биегәнгә карап тора. Ричард
белән Джордж биюләреннән арып туктыйлар. Джейн кул чаба.

Ричард. Рәхмәт сезгә, миссис Пигден. *(Джорджка.)* Тагын бер-ике тапкыр репетиция ясасак, консерваториянең конференц-залында концертта чыгыш ясарлык булабыз.

Янәдән шапылдап тәрәзә ябыла. Барысы да куркып куялар. Джордж
куркудан, тигезлеген саклый алмыйча, Мәет белән бергә диванга ава.

Ричард *(теләр-теләмәс).* Дөрес, Джордж. Сезгә һәм сезнең абыегызга ял итәргә кирәк.

Джордж. Әй Ходаем.

Ричард *(Мәеткә карап).* Ә бу Фредны карагыз инде. Тәмам ычкынган.

Джордж. Әйе, ул тәмам ычкынды.

Ричард. Бирмәскә иде аңа шулкадәр эчәргә. *(Официантка.)* Иртә белән Джорджлар туенда Фред шофер иде. Менә сиңа мә! Күбрәк төягән. Фред, үзегезне кулга алыгыз инде.

Ричард Мәетнең иңсәсенә суккалый, Мәет алга таба ава башлый.

Джордж эләктереп ала да артка тарта.

Ричард. Ничего, Фред, бөтенесе дә җайланыр! *(Официантка.)* Мин сезне тыңлыйм.
Официант *(аптыраган хәлдә).* Ә?.. Мин ни... сезнең күлмәгегезне керттем.
Ричард. Котлыйм сезне. Сез бик мәрхәмәтле.

Официанттан күлмәкне алып чәйлек биш фунт бирә дә ишек төбенә озата бара.

Ричард. Әгәр тагын безгә берәр нәрсә кирәк булса, именно, без сезне чакыртачакбыз, кыскасы, сезнең исемегез ничек әле?
Официант *(Мәет белән кочаклашып утырган Джорджка карап).* Джек.
Ричард. Джек?! Ә минем уйлавымча, фамилиягез — Чишендерүче?
Официант. Юк, просто Пот Джек! Пот — мин.
Ричард *(аңа тагын биш фунт сузып).* Ычкыныгыз бирелән, Джек Пот. Үзегезгә берәр сувенир сатып алыгыз.
Официант *(һаман да Мәеткә карап).* Рәхмәт сезгә!!!
Джордж. Ул инде хәзер үзенә сувенир кибетен сатып ала ала.

Ричард Официантны ишектән чыгарып җибәрә. Джордж урыныннан тора. Мәет диванга ава.

Джордж. Oh, каһәр!
Ричард *(Джейнга күлмәген биреп).* Тиз бул, киен дә аска төшеп мистер һәм миссис Пигденнар булып регистратурада теркәл.

Джейн тиз генә күлмәген кия. Ричард куен кесәсеннән кара күзлеген чыгарып Джорджка бирә.

Ричард. Мә, тиз бул, кидер. Юкса аның кыяфәте, йөзе минем күңелгә бик ошап бетми.
Джордж. Әй Ходаем! *(Күзлекне Мәетнең борынына эләргә тырыша.)*
Ричард *(Джейнга).* Теркәлегез дә өегезгә. Ә без моны сезнең номерга.

Телефон шылтырый. Бөтенесе урыннарында кала. Ричард телефонны ала.

Ричард *(трубкага).* Әй?.. Кем-кем? Сестра Фостер?
Джордж. Сестра Фостер?!
Ричард. Тс-с! *(Трубкага.)* Юк, мистер Пигден хәзергә телефонга килә алмый.
Джордж. Әни ничек анда, әни?!
Ричард. Тс-с! *(Трубкага.)* Ул буш түгел... Кем әйтә?! Кем әйтә?! Британ музееның директоры! Юк, мин Британский музей директоры, просто... Отельдә яшим... Нәрсә-нәрсә?
Джордж. Нәрсә ди ул?
Ричард. Тс-с! *(Трубкага.)* Мин мистер Пигденга әйтермен, ул сезгә шылтыратыр. *(Трубканы куя.)*
Джордж. Нәрсә булган?!
Ричард. Сезнең соңга калганыгыз өчен әниегез җиңелчә генә борчылган.
Джордж. Җиңелчә генә?!
Ричард. Әйе, ә менә инде аңа әйтмичә генә өйләнгәнегез өчен бик каты үртәлгән.
Джордж. Өйләнгән?! Минме?! *(Сикереп тора, ә Мәет диванга ава.)*
Джейн. Кызык, ә ул каян белгән?
Джордж. Мескен әнием.
Ричард. Әниең ярый. Ә менә мисс Уорзингтон һәм менә бу... *(Мәеткә күрсәтеп.)*

Тәрәзә артында Управляющий пәйда була.

Управляющий. Әле сез һаман да бирелә!

Ричард Джейнны эләктереп ала да бии башлый. Джордж тиз генә диванга утыра да Мәетнең кулын үз җилкәсенә, үз кулын Мәет җилкәсенә сала. Управляющий тәрәзә аша бүлмәгә керә дә усал караш белән биегән парларга карап тора башлый. Аннары Ричардның җилкәсенә кага.

Ричард *(җырлап).* «Ла Довна е Мовил». *(Бии-бии ишек төбенә килә дә, ишекне ачып, Джейнны коридорга төртеп чыгара. Управляющийга.)* Үзебезнең партия конференциясенә үзебезнең членнар концерт куярга әзерләнәбез. Ә миссис Пигден регистратурага теркәлергә төшеп китте.
Управляющий. Бик яхшы! Мистер Пигден... *(Борыла һәм Джордж белән Мәетне күреп ала.)* Кем бу?
Ричард. Бумы?.. Бу... Фред, мистер Пигденның абыйсы.

Управляющий. Абыйсы?
Джордж. Әйе, борчылмагыз, Фред монда яшәмәячәк.
Управляющий. Мистер Пигден, сезнең абыегыз белән тәртипме?
Джордж. Әйе, тәртип. *(Мәеткә.)* Фред, син ничек? *(Управляющийга.)* Тәртип, ди.
Ричард. Егет бераз гына күбрәк төшергән.
Управляющий. Минем уйлавымча, без аңа да бүлмә табалырбыз кебек.
Джордж. Юк, юк. Фредка өенә кайтырга кирәк. Ул ерак яшәми. Шәһәр читендә генә.
Управляющий. Карап-карап торам да, аның хәле нәрсәдер бик яхшыдан түгел.
Джордж. Әйе, ул безнең тумыштан шулай, бераз гына бледный. Шулай бит, Фред? *(«Әйе» дигәнне аңлатырлык итеп, Мәетнең гәүдәсен селкетә. Мәетнең башы селкенә.)*
Управляющий *(Мәеткә)*. Мистер Пигден! Сез кирәк урыныгызга кайтып җитәрлек хәлдәме, үз күчегезгә ышанасызмы? *(Джорджж янына килеп утыра. Тегесе Мәетнең башын кире якка борып куя.)* Мистер Пигден!
Ричард. Кычкырыбрак, ул колакка каты.
Управляющий *(кычкырып).* Сез өегезгә кайтып җиталырмын дип үз көчегезгә ышанасызмы, мистер Пигден? Кайтырлык хәлдә булмасагыз, без сезгә номер табабыз!

Мәет, Джордж ярдәме белән «юк» дигән мәгънәне аңлатып, башын селки.

Управляющий *(кычкырып).* Өегезгә үз аягыгыз белән кайтып җитә аласызмы?

Мәет башын селки.

Управляющий. Минем уйлавымча, ул рульдә түгелдер бит?
Ричард. Сез нәрсә инде. Мондый хәлдә! Рульгә утыру, считай — покойник, мәет.
Управляющий *(Мәеткә).* Ну, ярый. Рәтләп, терел, мистер Пигден.

Мәет башын селки. Управляющий башын ия дә чыгып китә.

Ричард. Джордж, сез искиткеч.
Джордж. Күңел болгана.
Ричард. Тизрәк аны сезнең номерга күчерергә кирәк.
Джордж. Хәзер аны күчерүдә мәгънә юк!
Ричард. Нигә?
Джордж. Нигә?! Ә сез берни дә аңламыйсыз инде? Нигә дисез?!

Джордж сикереп тора, Мәет диванга ава.

Менә ни өчен, чөнки Управляющий хәзер аның минем абыем Фред икәнен белә! Менә ни өчен!
Ричард. Вәт каһәр. Чыннан да, сез хаклы!
Джордж *(авыр сулап).* Ни өчен мин сезне тыңладым?
Ричард. Так, паника куптарма. Гарасат чыгарма. Хәзер сез дә бу эштә минем кебек үк аяк-кулларыгыз белән кереп чумдыгыз. Кем хәзер генә Мәет белән сөйләшү алып барды?
Джордж. Әйе, шулай да булсын ди...
Ричард. Кем минем ялганымны җөпләп барды? Кем яшь гаиләнең зөфаф кичен уйлап чыгарды?
Джордж. Да, ну...
Ричард. Ә алкоголик абый?
Джордж. Шунысын әйтәм, үз гомеремдә башка беркайчан да үз партиябезне яклап тавыш бирмәячәкмен.
Ричард. Тынычлан! Чынлап уйлап караганда, нәрсә күрде инде ул Управляющий? Сезнең абыегызның йөзен күрмәде ул. Ул аның киемен генә күрде — плащын, шарфын, костюм һәм күзлеген.
Джордж. Шуннан нәрсә?
Ричард. Шуннан шул. Әгәр без аңа башка кием кидертсәк, сез аны тапканда, Управляющийның башына ул вакыттагы синең абыең дигән фикер кереп тә чыкмаячак.
Джордж *(курыккан хәлдә).* Мәет киендерергә? Һичкайчан!
Ричард. Джордж, хәзер көй көйләтә торган чак түгел. Әлегә үзен кире шкафка тыгыгыз. *(Телефонга бара да номер җыя.)*
Джордж. Нишлисез сез?
Ричард. Шылтыратам. *(Трубкага.)* Алло? Бу синме, минем иң якын дустым Джек Пот? Әйе, әйе, бу мин, Уилли. Әйе, әйе. Шул инде, унөченчедән, бай-богач булам.

Джордж Мәетне шкафка өстери, үзе Ричардның сөйләшкәнен тыңлый.

Әйтегез әле, Джек, сезнең берәр кирәкмәгән киемегез юкмы? Пиджак, бер чалбар, ботинка... Яхшы. Отлично! Нәкъ үзе. Хәзер үк минем бүлмәгә менгерегез. Әйе, әйе, хәзер үк... Без ятимнәр өчен кием җыябыз. *(Трубканы куя.)*

Кемдер каты итеп ишек кага. Джордж Мәет белән бер урында катып кала.

Ричард *(итагатьле рәвештә).* Кем бар анда?
Джейн *(ишек артыннан).* Бу мин, Джейн. Тизрәк, тизрәк!..

Ричард ишекне ачуы була, бүлмәгә, атылып, Джейн керә.

Ричард. Ни өчен сез китмәдегез?
Джейн. Чөнки анда аста Ронни!
Ричард. Ронни?! Кем соң ул Ронни?
Джейн. Минем ирем!
Ричард
Джордж *(икесе бергә).* Ирең?!
Ричард. Ул бит өегездә!
Джейн. Ул аста!

Джордж нишләргә белмичә тезләнә, Мәет аның белән бергә бу хәрәкәтне башкара.

Джейн. Мин чак кына куркудан үлмәдем. Бәхетемә каршы, ярый әле ул мине күрмәде.
Ричард. Каһәр төшкере, ул биредә нишли?
Джейн. Этем белсен.
Джордж. Мин белдем, мин сиздем...
Ричард *(аны бүлдереп).* Туктагыз! Тынычланыгыз! Торып басыгыз! Сезнең абыегыз белән бергә чукынганыгыз барыбер ышандырмый.
Джордж. Минемчә, безгә шул бергә чукынырга гына калды инде...

Телефон шылтырый, Ричард трубканы ала.

Ричард *(трубкага).* Алло! Сестра Фостер?! Мин бит инде сезгә әйттем!
Джордж. Мин үзем аның белән сөйләшәм!

Джордж урыныннан тора, Мәет тезләнгән хәлдә кала, ә башы өстәл өстендә.

Ричард *(Джорджка).* Абыең белән җайлабрак. *(Трубкага.)* Мисс Фостер, мистер Пигденны борчуыгызны туктатыгыз!.. Ну, шуннан нәрсә — истерика?.. Аның һәрвакыт энисенең истерика.
Джордж. Нәрсә тагын?
Ричард. Бернәрсә дә түгел. *(Трубкага.)* Мин сезгә әйтеп торам, аның кемгә өйләнүе сезнең эшегез түгел!
Джордж *(Ричардка).* Сез акылдан шаштыгызмы әллә?
Ричард *(трубкага).* Мистер Пигден зөфаф кичен уздыргач та өенә кайта! *(Трубканы ыргыта.)*
Джордж. Әй Ходаем! Әнигә хәзер анда тагы да авыр булачак.
Ричард. Мин дә шулай уйлыйм. Хоть сестра Фостерны телефоннан игътибарын бераз читкә юнәлтү өчен эш табылды. Җитте сезгә еларга. Әнә абыегызны асарга элгечкә алып килегез!
Джордж *(Мәетне күтәреп).* Әйдә, Фред! *(Мәетне шкафка озаталар.)*
Джейн. Ә Ронни белән нәрсә?
Ричард. Паника куптармагыз! Минем фикеремчә, ирегезнең көтелмәгән визиты очраклы түгел.

Джордж көч-хәл белән Мәетне элгечкә элүе була, каты итеп ишек шакыйлар. Барысы да катып калалар.

Ричард. Кем анда?
Ронни *(коридордан).* Ачыгыз!
Джейн *(курыккан хәлдә, пышылдап).* Ронни!
Джордж. Әй Ходаем!

Джордж шкаф эченә керә. Ричард аны тартып чыгара.

Ричард *(ягымлы итеп).* Сез заказлар бүлегеннәнме?
Ронни. Ачыгыз, юкса ишегегезне җимерәм!
Ричард *(Джорджка, пышылдап).* Аны номерыгызга алып китегез!
Джордж. Ниһаять, кич буена беренче тапкыр кеше рәтле фикер әйтте. *(Балконга чыга.)*

Джейн. Мистер Уилли, аң булыгыз, Ронни психланганда күзенә ак-кара күренми, ул бешеныйга әверелә.

Джордж. Киттек! Мистер Уилли үзе хәл итәр.

Джордж белән Джейн балконга чыгалар да качалар. Ишекне янәдән шакыйлар.

Ронни *(ишек артыннан).* Ачыгыз, дим!

Ричард *(ягымлы рәвештә).* Киләм, киләм.

Ричард тәрәзәнеябып өлгерми, бүлмәгә атылып Ронни керә.

Ричард *(ягымлы итеп).* Ә мин Официант дип торам.

Ронни. Мин Ронни Уорзингтон.

Ричард. Бик шатмын. Ричард Уилли.

Ричард кулын суза, Ронни аның кулын алмый.

Ронни. Да уж, кемне-кемне, мин сезне беләм!

Ричард *(елмаеп).* Менә бит ул парламентта эфирдан турыдан-туры чыгыш ясау. Сез, мөгаен, минем берәр сайлаучымдыр да әле?

Ронни. Пеләш җен! *(Йокы бүлмәсенең ишеген ача да кереп китә.)*

Ричард. Юк, минем уйлавымча, сез миңа, үзегезнең депутатыгызга, мөрәҗәгать белән килгәнсездер дип уйлаган идем.

Ронни чыга.

Ронни. Мин Джейнның ире.

Ричард. Джейн Уорзингтонның?! *(Көч белән йокы бүлмәсенең ишеген яба.)*

Ронни. Секретарша!

Ричард. Нигәдер хәтерләмим.

Ронни. Кая ул?

Ричард. Кем?

Ронни. Диванага салышмагыз! Ул монда, episодә!

Ричард. Миндә?! Премьер-министр ярдәмчесе бүлмәсендәме?

Ронни. Ташлагыз алдашуыгызны дим мин сезгә. Мин күптәннән сезне күзәтәм!

Шапылдап, тәрәзә рамы килеп төшә. Ронни тәрәзәгә карый.

Ричард. Күзәттегез?

Ронни. Сезнең аның белән барлык очрашуларыгызны! Барлык чаепитиеларыгызны, барлык кофе...

Ричард. Ә ул мисс Уорзингтонмыни? Әлбәттә! Джейн Уорзингтон! Секретарша. Бик күркәм, бик күркәм.

Ронни. Мин беләм сез ул күркәм кыз белән ниләр эшләгәнегезне!

Ричард. Стенографистка. Беләсезме, аның куллары алтын...

Ронни. Җитте! Стенографистка... Ул секретарша, но сезнеке түгел! Кайчан ул мине үзенең апасының бронхиты белән төп башына утырта башлагач та...

Ричард. Сез инде бу мәсьәләдә минем ничек фикер йөртүемне әйтмәкче буласыз.

Ронни. Минем әйтәсе килгәнем шул. Аның апасы отельдә, гостиницада яшәми.

Ишек шакып, Горничная керә.

Горничная. По-о-о-с-с-тиль-ләр-р-е-е-гез-не а-а-а-лыш-ш-ш-ты-ы-ыр-ыр-р-р-га-мы?

Ронни. Постель! Юк инде, постельләр бүтән монда булмас!

Горничная. З-з-з-у-у-ур р-р-ә-ә-х-м-м-мәт...

Ронни. Ычкыныгыз күз алдымнан!

Горничная *(мөлаем).* З-з-з-у-у-ур р-р-ә-ә-х-м-м-мәт...

Горничная чыгып китә.

Ричард. Менә шулай, яшь иптәш...

Ронни. Күрсәтәм мин сезгә хәзер яшь иптәшне! Мистер Бейкер сезнең үкчәгезгә басып барган һәм барысын да күргән. Башта сез үзегез генә бирегә теркәлгәнсез, как будто сез үзегез генә, ә соңыннан...

Ричард. Мистер Бейкер?! Кем ул?

Ронни. Шымчы! Мин аны сезне күзәтер өчен яллладым!

Ричард *(көләргә азапланып).* Шымчы дисез инде?

Ронни. Мин урамда калдым. Ә ул пожарный баскычыннан сезнең балконга төште...

Ричард моңсуланып тәрәзәгә карашын ташлый.

Ронни. ...тәрәзәдән кереп сезне вакытында фаш итәргә! Аңлашылдымы?
Ричард. Ул минем балконга менде дисез инде...
Ронни. Билгеле, шулай!
Ричард. Минем тәрәзәне ачты...
Ронни *(аны бүлеп)*. Ә-ә, барып җиттеме?!
Ричард. Әй Ходаем.

Ричардның күзе шкафка төшә, һәм Ронни елмая.

Ричард. Сез бит хәтта хатыныгызның отельдә икәнен дә белмисездер, сезнең хатыныгыз отельдә!
Ронни. Ничек кенә беләм әле, мин отельнең каршы ягында, парадный ишек каршысында басып тордым! Аның сезнең арттан шуып кына кереп киткәнен үз күзләрем белән күреп калдым!
Ричард. Яхшы! Шулай дип уйлыйк ди. Сез аны күрдегез ди.
Ронни. Уйлыйсы юк. Ул монда. Мин күрдем!
Ричард. Белеп торыгыз, ул минем арттан кермәде. Ул Пигден артыннан керде.
Ронни. Тагын нинди Пигден?
Ричард. Минем аны сатасым килмәгән иде. Ул минем шәхсән сәркатибем. Парламентыбызда беренче номерлы бабник. Бер итәкне дә читкә җибәрми.
Ронни. Сез мине диванага санамагыз! Ул элек тә сезгә свиданиегә йөгерде...
Ричард. Әйе, мин аның белән очраштым. Пигденның явыз ниятеннән саклар өчен. Ну, нишлим. Ул бик куркыныч донжуан. Әйтеп аңлата алмаслык маньяк.
Ронни. Минем башны бутама. Сез мине кемгә саныйсыз?

Ричард Роннины, кулыннан тотып, ишек төбенә алып килә.

Ричард. Сез аска администрациягә төшеп тикшертә аласыз. Отельгә мистер һәм миссис Пигденнар урнашмады микән?
Ронни. Әгәр сез алдашсагыз...
Ричард. Ышаныгыз миңа. Сезнең өчен бу бик авыр булган кебек, минем өчен дә бу хәл чамадан тыш күңелсез!

Ричард ишекне ачуы була, шул вакыт шкаф ишеге Мәет белән бергә ачылып китә. Ричард моны сизә, әмма ләкин Ронни күрми кала. Ричард
Роннины тынычландырып җилкәсеннән кагып ала.

Ричард. Ронни!
Ронни *(аптырап).* Нәрсә?
Ричард. Минем өчен бу хәл сезгә караганда да читен!
Ронни. Ничек дидегез әле сез, исеме ничек? Пигден?!
Ричард. Джордж Пигден. Миңа шулкадәр читен, сезнең артыгызда...
Ронни. Әгәр сез алдасагыз...
Ричард *(гарьләнеп).* Алдыйм?! Ронни, мин парламент депутаты!
Ронни. Һәм шуны онытмагыз, минем әле мистер Бейкерым бар.
Ричард. Ә менә мистер Бейкер турында, һичшиксез, онытмам.
Ронни. Ул миңа сезнең турыда барысын да сөйләячәк!
Ричард. Ышаныгыз, ул минем хакта сезгә бернәрсә дә сөйләмәячәк.

Роннины коридорга төртеп чыгара да, шкаф ишеген Мәет белән бергә
ябып, телефоннан номер җыя.

Ричард *(трубкага).* Джордж, Джейнны әләктер һәм тиз генә минем номерга керегез... Ронни администраторга төшеп китте. Күз ачып йомганчы ул сезнең бүлмәдә булачак. Әгәр ул сезне тапса, безнең икенче мәетебез дә булачак. *(Трубканы куя.)*

Ишек шакыйлар.

Ричард *(сөйкемле итеп).* Кем бар анда?
Официант *(ишек артыннан).* Сезнең заказ буенча.

Ричард ишекне ача. Алагаем зур киемнәр күтәреп, Официант керә.

Официант. Киемнәр сораган идегезме?
Ричард. Шәп. *(Киемнәрне алмакчы була.)*
Официант *(акча өмет иткәнен сиздереп).* Ә сез беләсезме минем менә шушы костюмны киеп өйләнгәнне.

Ричард аңа биш фунт бирә.

Ричард. Менә нәрсә, Джек. Монда хәлләр кискенләште әле.
Официант *(күтәренке күңел белән).* Бу инде яхшы.
Ричард. Инвалид коляскасы кирәк.
Официант. Коляска?
Ричард. Әйе, әйе, кресло-каталка кирәк...
Официант. Ә нәрсә, кемгә дә булса әллә начармы?
Ричард. Биредә безгә барыбызга да начар. Ә кресло әлегә беребезгә генә кирәк.

Джордж белән Джейн балкон тәрәзәсен шакыйлар. Ричард тәрәзәне ача.

Официант. Алар нәрсә, әллә номерга ишектән керергә икәнен белмиләрме?

Джордж белән Джейн бүлмәгә керәләр.

Джордж. Ну, нәрсә булды биредә?
Официант *(Джорджка).* Нәрсә, зөфаф кичегезне балконда уздырмакчы булдыгызмы әллә?
Ричард *(Официантка).* Ташлагыз әле, калдырыгыз аларны тынычлыкта. Коляска табыгыз!
Официант. Дөресен генә әйткәндә, бездә алар берничә бар иде бугай. Андый-мондый хәл килеп туса...
Ричард. Менә, менә нәкъ шундый хәл килеп чыкты.

Официант, ютәлләгән булып, кулын суза. Ричард кесәсенә кулы белән керә.

Официант. Ун фунт җитә.
Ричард. Карагыз әле, сез минем бөтен акчаларымны суырып бетердегез түгелме?!
Официант *(мәрхәмәтле кыланып).* Алайса, кирәкми.
Ричард *(аптырап, шаккатып).* Рәхмәт, Джек.
Официант. Чек кына яза аласыз. *(Чыгып китә.)*
Джордж. Тагын нәрсә булды? Нигә сезгә коляска?
Джейн. Йә, Ронни сездән нәрсә тели?

Шапылдап, тәрәзә ябыла.

Ричард. Ике яңалык бар: берсе — яхшы, берсе — начар. Кайсысыннан башлыйм.
Джейн. Начарыннан.
Ричард. Начары шул: сезнең ирегез безнең арттан күзәтер өчен шымчы яллаган.
Джейн. Уф Аллам!
Джордж. Кызык, моннан да начар тагын нинди яңалык булырга мөмкин?
Ричард. Яхшысы шул: ул шымчы әлегесе минутларда безнең шкафта эленеп тора.
Джордж. Әни! *(Курыккан хәлдә шкафка карый.)*
Джейн. Димәк, Ронни минем арттан күзәткән. Ничек аңа оят түгел!

Джордж белән Ричард аңа карыйлар.

Ричард. Чыннан да.
Джордж. Ә инвалид арбасы нигә?! Чыннан да әгәр минем өчен булмаса?
Ричард. Башыңны эшләт, Джордж! Бу бит сыщик, эзтабар! Сез аңлыйсызмы, әгәр минем номерда үлгән Детектив тапсалар, минем белән нәрсә буласын?! Юк, без аны инвалидлар арбасына утыртабыз да...
Джордж. Шуннан нишлибез?
Ричард. Шуннан шул: сез аны шәһәр паркына илтәсез.
Джордж *(һични аңламыйча).* Паркка?!
Ричард. Паркка, паркка! Мин кабатлап туйдым, егет үлгән. Аңа барыбер, кайдан тапсалар да. Паркка кадәр сез аны алып барасыз да куак төбендә калдырасыз.
Джордж. Мәетне куак төбендә калдырырга?
Джейн. Туктагыз әле! Ронни кая?
Ричард. Ә монысы икенче мәсьәлә. Джорджны тизрәк биредән җибәрергә кирәк. Хөрмәтле Роннины чамадан тыш чыгырдан чыгаруым өчен хәтта курка ук башладым.
Джордж. Ягъни мәсәлән.
Ричард. Мин аңа, сез аның хатынын үзегезгә каратырга, ягъни гашыйк итәргә телисез, дидем.
Джордж. Нәрсә?!
Ричард. Ул берничек тә минем сүзләремә ышанмый кала алмый. Чөнки ул регистрациягә бу отельгә мистер һәм миссис Пигденнарның урнашуларын тикшерергә дип төшеп китте.
Джейн. Ходаем, ә без бу отельгә теркәлгән.

Ричард *(шатлыктан).* Әлбәттә, унөченче «А» номерына.
Джордж. Мистер Уилли, беләсезме сез кем?

Ишек шакыйлар. Барысы да тынып калалар.

Ричард. Кем бар анда?
Ронни *(ишек артыннан).* Бу мин, Ронни.
Джордж. Беттек!
Ричард *(мәрхәмәтле итеп).* Барам! *(Джордж белән Джейнга.)* Тиз! Икегез дә!

Шкаф ишеген ача. Мәет һаман да ишектә эленеп тора.

Джордж. Бу мөһимме?
Джейн. Сайлагыз, йә үлгән эзтабар, йә сау-сәламәт Ронни!
Джордж
Джейн *(икесе бергә).* Үлгән шымчы, эзтабар.

Икесе дә шкафка керәләр. Ричард аларга Официант керткән киемнәрне ыргыта.

Ричард. Сез анда чагында мәрхүмгә туй костюмнары кидертә торыгыз.
Джордж. Анысы тагын ни өчен?
Ричард. Танымаслык хәлгә китерер өчен.
Джордж. Сезгә берәр мафиозный группада инструктор гына буласы.

Ричард шкаф ишеген ябуы була, кабаттан ишек шакыйлар, ишекне ача. Ронни керә. Ул бик каты ачулы.

Ронни. Сез хак, алар отельнең унөченче «А» номерында. Сезнең каршыдагы бүлмәдә.
Ричард *(гаҗәпләнгән булып).* Каршыдагы?! Бу инде чамадан тыш.
Ронни. Ишекләрен шакыдым, ачмадылар.
Ричард. Ачмадылар?!
Ронни. Шуннан соң мин ул ишекне җимердем.

Ричард коридорга карый.

Ричард. Менә сиңа мә!
Ронни. Ну алар анда юк!
Ричард. Юк?!
Ронни. Юк! Юк шул! *(Ричардның алдына тезләнә дә аякларын кочаклап үкси-үкси елый.)*
Ричард *(җиңелчә рәхәтлек кичереп).* Ну, ну, Ронни, үзегезне кулга алыгыз.
Ронни. Мин үзем гаепле! Үзем! Минем аркада ул сезнең Пигденыгызга китте. Ул мәсьәләдә миңа караганда яхшырактыр, күрәсең.
Ричард. Сез нәрсә хакында, Ронни!

Управляющий керә. Җимерек ишекне күреп туктап кала.

Ричард. Тынычланыгыз! *(Ронниның башыннан сыйпый.)*
Ронни. Юк! Юк! Бары тик шуның өчен!
Ричард. Нәрсә өчен, Ронни?
Ронни. Постельдә мин бернигә дә ярамыйм.

Ричард белән Управляющий Роннига гаҗәпләнеп карыйлар.

Ричард. Ташлагыз, Ронни. Сез шундый яшь, көчле!
Ронни. Юк, юк! Минем аркада безнең аның белән барысы да бик тиз...
Ричард. Ташлагыз! Үз-үзегезне бимазаламагыз...
Управляющий. Мистер Уилли!
Ричард. Мин... мин просто аңлаттым гына...
Управляющий. Мин сездән мондый аңлатма көтмәгән идем.
Ричард. Аңлагыз, кеше борчуда...
Управляющий. Мин аңладым.
Ронни. *(Үз-үзен кулга алырга теләп, урындыкка утыра.)* Гадәттә, мин кешеләр алдында сер бирмим.
Управляющий. Моны ишетү куандыра.
Ричард *(Управляющийга).* Аның белән мин үзем аңлашырмын.
Управляющий. Ул чагында беррәттән мистер Пигден белән дә аңлашсагыз иде.
Ронни *(урыныннан тора башлап).* Пигден белән дә?!
Ричард. Тынычлан, Ронни. Барысы да тәртиптә.

Управляющий. Тәртиптә! Ишек җимерелгән, мебельләрнең асты өскә килгән!
Ричард. Бөтен җимерелгән әйберләр өчен чыгымны мистер Пигден түләр...
Управляющий. Сүз дә юк, ну мин мондый тәртипсезлекләргә түзеп торалмыйм.
Ричард. Әлбәттә, сүз дә юк.
Управляющий. Дөрес, зөфаф кичендәге хәлләрне мин бик яхшы аңлыйм. Ну инде бу кадәресен үк башка сыйдыра алмыйм.
Ронни. Зөфаф киче?!

Ронни үкерә-үкерә елап идәнгә тезләнә. Ричард аны урындыкка утырта.

Ричард. Ронни, үзегезне кулга алыгыз.
Управляющий. Өстәвенә мистер Пигден үзе дә һәм хатыны да беркайда юк!
Ричард. Ресторанга төшеп карарга кирәк, ашап утырмыйлар микән?

Ричард Управляющийны ишек төбенә алып килә. Ишек төбендә, коридорда, инвалид арбасы белән Официант күренә.

Официант. Ә менә без дә!

Управляющийның күзе Официантның арбасына төшә.

Управляющий *(Официантка).* Биредә сезгә нәрсә кирәк?
Официант. Заказ керттем.
Управляющий. Кемгә?
Официант. Кем өчен бу, мистер Уилли?
Ричард. Бер яшь иптәш өчен.
Официант *(Роннины күреп).* О, сездә яңа кеше...
Управляющий *(Официантка).* Сез китә аласыз... *(Роннига торырга булыша.)*

Официант Ричардка ун бармагын күрсәтә дә чыгып китә.

Управляющий *(Роннига).* Яшь иптәш, мин сезнең кемлегегезне һәм биредә бу вакытта нишләп йөрүегезне аңламыйм. Сездән мин тиз арада отельне бушатуыгызны сорар идем. *(Ричардка.)* Ә киләчәктә, мистер Уилли, мондый төнге киңәшмәләргә килгәндә сезне җәмәгатегез озата килсә хәерлерәк булыр иде.

Управляющий горур атлап чыгып китә.

Ронни. Бәдбәхет, болар барысы да куркыныч!
Ричард. Өегезгә кайтыгыз да тынычланыгыз.
Ронни. Мин Пигденны тапмыйча беркая да китмим.
Ричард. Мин бит әйттем, ул, мөгаен, ресторандадыр.
Ронни. Табыйм гына. Ике аяк арасындагысын төбеннән кисәм.

Ронни чыгып китүе була, Ричард шкаф ишеген ача.

Ричард. Сез биредә нәрсә дә булса ишеттегезме?
Джордж. Мин барысын да ишетеп тордым, мине иң дулкынландырганы соңгы җөмләсе булды.

Джордж шкафтан чыга, аның артыннан Джейн.

Джейн. Ну, разве ул минем искиткеч түгел?!
Ричард. Сөйлисе юк.
Джейн. Ишеттегез, ул мине яратуы хакында ничек өзгәләнде. Элек беркайчан да бу хакта ачыктан-ачык әйткәне юк иде.
Джордж. Әй Ходаем.
Джейн. Хәтта икебез арасында гына була торган кечкенә генә проблеманы да сөйләргә батырчылык итте.
Ричард. Ярый, булды. Әйе, сез үзегезнең кечкенә генә проблемагыз хакында гаилә врачыгыз белән фикер алышырсыз. *(Джорджка.)* Сез Мәетне киендердегезме?

Джордж Мәетне тартып чыгара. Мәет өстендәге Официантның туй костюмы дөрес каптырылмаган. Башында колакларын каплап торган котелок*, күзләрен күзлек каплап тора.

Ричард. Сез акылдан шаштыгызмы әллә?
Джордж. Анда бит караңгы.
Ричард. Бирегә утыртабыз.

Ричард аңа колясканы этә. Джордж Мәетне коляскага утырта.

Ричард. Шунысы куанычлы, төнлә инде ул булмаячак. *(Джейнга.)* Пожарный баскычыннан төшегез дә өегезгә элдертегез! *(Тәрәзәне ача.)*

Джейн. Ронни кайткач нәрсә дип әйтәм.

Ричард. Пигден мине көчләп алып барды, диярсез.

Джордж. Ну, рәхмәт инде!

Джейн. Ходаем, белмим, Ронни белән очрашуны күтәрә алырмынмы мин.

Ричард. Яхшы, ул чагында парламентка кайтыгыз.

Джейн. Парламентта йоклый аламмы соң мин?

Ричард. Нигә? Депутатлар йоклый бит әле. *(Балконга төрткәли.)*

Джейн чыгып китә.

Ричард. Ә сез турыдан гына паркка. *(Ишекне ача.)* Хәзер лифтны чакырам да ябылмас өчен ишеген тотып торам. Ә сез хәзер йокы бүлмәсеннән җәймә алып чыгыгыз да абыегызны ябыгыз.

Джордж. Мистер Уилли, беләсезме сез кем? Сез сирәк хәзинә.

Ричард. Мин сезне ышандырып әйтә алам, кайчан да булса өйләнсәгез, һәрвакыт миңа таяна аласыз.

Джордж. Әгәр мине Ронни очратса, миңа өйләнү хакында онытырга туры киләчәк.

Джордж йокы бүлмәсенә кереп китә. Ричард бүлмәне караштыра, Мәетнең гәүдәсенә, яңагына суккалап ала. Пауза. Ричард китә. Көтмәгәндә Мәет селкенә башлый. Кулларын, башын селкеп ала. Аннары муенын кулы белән ышкый. Күзлеген сала һәм, күзлеккә озак карап торганнан соң, күзлекне түш кесәсенә тыгып куя. Муенын ышкый башлый. Кулы мискига тиеп китүгә, аны салып, озак карап тора. Янәдән башына кия. Сырхаулар арбасында утырганына аптырап торганнан соң, күзе өстендәге киемнәргә төшә. Чалбарының алдын артка кигәненә гаҗәпләнә. Тәрәзәне күреп, нәрсәдер исенә төшергәндәй, аның кырына килә дә балконга чыга. Иелеп башын
бүлмәгә тыгарга уйлагач, җиңел сулап елмая.

Мәет. Нәкъ үзе! Барысы да нәкъ шулай булды!

Тәрәзә рамы аның муенына килеп төшә. Гәүдәсе бизгәк тоткандай
калтырап ала һәм элеккеге хәленә кайтып кала.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Йокы бүлмәсеннән, кулына җәймә тотып, Джордж чыга да җәймәне арбага ыргыта, артка чыгып, арбаны этмәкче була, кинәт, арбада кеше
юклыгын күреп, аптырап кала. Шул вакыт Ричард керә.

Ричард. Нәрсә инде сез йоклыйсыз, мин бит анда лифтны тотып торам.

Джордж. Ул юк.

Ричард. Кем?

Джордж. Ул.

Джордж буш арбага төртеп күрсәтә, Ричард аңа карый.

Ричард. Ә кая соң ул?

Джордж. Белмим.

Ричард. Сез аны кая да булса күчергәнсездер!

Джордж. Юк.

Ричард. Ну, каһәр! Ничек сезнең Мәетне югалтырга башыгызга килде.

Джордж. Мин аны югалтмадым. Ул үзе...

Көтмәгәндә Ричард тәрәзәгә кысылган гәүдәне абайлап ала.

Джордж. Сез лифт чакырырга киттегез, ә мин йокы бүлмәсеннән җәймә алып чыгарга чыксам...

Ричард *(әкрен генә).* Джордж...

Джордж *(гәүдәгә карап, үзе дә сизмәстән, башын селкеп).* Мин аның янынннан бары тик секундка гына китеп алдым. Ул биредә иде. Менә шушында, күзлектән, теге ыштан салдыручының туй костюмыннан... *(Аптырап башта гәүдәгә, аннары арбага, аннары Ричардка куркып карап торганнан соң.)* Ходаем, әни-и!

Ричард. Ни өчен моны эшләдегез?

Джордж. Мин бернәрсә дә эшләмәдем.

Ричард. Соң бит ул янәдән бер сәгать элек булган урында.

Джордж. Ант итәм, соңгы тапкыр мин аны менә шушы сырхаулар арбасында күрдем.

Ричард. Барысы да аңлашылды. Димәк, кем дә булса сизенгән.

Джордж. Сизенгән? Кем?

Ричард. Каян белим. Әмма ләкин сизәм, кемдер безне шантажировать итмәкче була.
Джордж. Шулай дисезме?
Ричард. Ул чагында кем аны кире анда илтеп тыккан соң? Кыскасы, полиция йә, булмаса, биредәге каравылчыларны чакыру җиңелрәк булган булыр иде.
Джордж. Әй Ходаем, нәрсә өчен? Мин бит бу кичне өйдә әнием белән үткәрергә теләгән идем!
Ричард. Әниегезне тынычлыкта калдырыгыз әле. Булышыгыз. *(Рамны күтәрә.)*
Джордж. Нәрсә эшлисез сез?
Ричард. «А» планына кире кайтабыз. *(Джордж ярдәме белән гәүдәне арбага утырта.)*
Джордж. Нинди «А» дигән план инде ул?!
Ричард. Шәһәр паркы.
Джордж. Әгәр кемдер безнең арттан иснәнгән булса?!
Ричард. Безнең башка чарабыз юк.
Джордж. «Б» планы бар.
Ричард. Сөйләп кара, нинди «Б» планы инде ул?
Джордж. Дөресен әйтергә.
Ричард. Акылдан шаштыңмы әллә?
Джордж. Әйе, сезнең өчен бу, әлбәттә, сәер, ә кемнәрдер шулай эшлиләр. Барысы да ачык һәм якты. Сез һәм мисс Уорзингтон Мәетне тапкансыз, бетте-китте.
Ричард *(коридорга чыга торган ишекне ачып)*. Ә сез беләсезме безне нәрсә көтә... әгәр шушы хәлләрдән соң без көтмәгәндә, Мәетне табып, хакыйкатьне ачсак... Сез бераз гына булса да мескен Роннины җәлләгез инде. Ул бит тәрәзәдән сикерәчәк. *(Мәеткә карап.)* Нәрсәдер җитеп бетми. Аның күзлеге бар иде түгелме!
Джордж. Хәзер ул аның түш кесәсендә. *(Күзлекне ала.)*
Ричард. Шантажистның безгә булган тагын бер сәламе. Ул безнең белән шаяра, аһ, ничек шаяра. Озакламый без аңардан хат кисәге алачакбыз!
Джордж *(Мәеткә күзлек кидертә-кидертә)*. Хат?..
Ричард. Әйе, акча таләп итеп.
Джордж. Туктагыз әле, әгәр ул, чыннан да, турыдан-туры шантажист...

Шапылдап тәрәзә ябыла. Джордж Ричардка ябыша.

Джордж. ...аның минем арттан паркта да күзәтүе бар.
Ричард. Бу куркыныч, әмма без анда барырга мәҗбүрбез.
Джордж. Без! Сезгә әйтергә җиңел!

Официант керә.

Официант. Мистер Уилли!
Ричард. Нәрсә булган?
Официант. Сезгә биредә хат, язу! *(Кәгазь кисәген суза.)*
Ричард *(Джорджка карап)*. Кемнән инде?
Официант. Миннән.

Ричард белән Джордж бер-берсенә карап алалар. Ричард кәгазьне ала.

Ричард *(укый)*. «Сырхаулар арбасы бөтен отельгә берәү — бәясе ун фунт». *(Кәгазьне йомарлап, идәнгә ыргыта.)*
Официант *(Мәеткә карап, Джорджка)*. Карап-карап торам да, сезнең абыегызга тагы да начаррак бугай.
Джордж. Сөйлисе юк, азапланды-азапланды да кабат ауды.
Официант. Аңа күп биергә кирәкмәс иде.
Джордж. Әлбәттә, разве аны тотып калып була.
Официант *(Ричардка)*. Артык кызыксынуым өчен гафу үтенәм, ә ни өчен ул минем туй костюмымны киде?
Ричард. Ул... туйга җыена.
Официант *(Джорджка)*. Алай икән. Ул сезнең туегызда булды түгелме соң инде?

Джордж, эндәшмичә, башын селки.

Ричард. Ә хәзер ул бүтән абыйсының туена бара.
Официант *(Джорджка)*. Ә-ә, сезнең тагын бер абыегыз бармыни?

Джордж башын селки.

Ричард. Әйе-әйе, аның тагын бер абыйсы бар. Исеме — Альберт.

Официант *(Ричардка)*. Димәк, ул да бүген өйләнә.
Ричард. Әлбәттә! Альберт белән Джордж алар бит игезәкләр. Берсе нишли, икенчесе дә шуны эшли.
Джордж *(авыр сулап)*. Әй Ходаем...

Ул, үз-үзен белештермичә, арбага утыра һәм куркуыннан сикереп тора.

Официант *(сәгатенә карап)*. Хәзер туй мәҗлесенә бик соң түгелме?
Ричард. Күпме соңарып өйләнсәң, шуның кадәр яхшырак.

Ричард Официантны ишек төбенә төрткәли башлый, шул вакыт бүлмәгә атылып Ронни керә. Джордж тиз генә Мәетне почмакка этеп чыгып
китә.

Ронни. Тапмадым! Теге кабахәт тә, хатыным да беркайда юк!
Официант. Хәерле кич, сэр!
Ронни. Ә сез кем буласыз, черт возьми!
Ричард. Бу отельдәге иң бай кеше.

Ричард Официантны коридорга озата.

Ронни. Алар миннән качып кайдадыр яталар.
Ричард. Бәлкем, сезгә өегезгә кайтырга кирәктер. Йоклап алырга. Ә инде иртә белән барысы белән дә аңлашырга.

Ронни бүлмәнең түренә уза.

Ронни. Юк инде, мин бүген аңлашам! Һәм, әлбәттә, менә шушы йолкыш Пигденнан башларга җыенам!

Арты белән басып торган Джорджны күреп, Ронни тынып кала. Джордж, Ронниддан үз йөзен яшереп, арбаны ишек төбенә — коридорга таба этә.

Ричард *(Ронниның кәефен күтәрергә теләп елмаеп)*. Ә бу доктор Ньютон иде.
Ронни *(уйланып)*. Ә арбадагы егет?
Ричард. Ул... абый.
Ронни. Кемнең абыйсы?
Ричард. Минем, минем Гарри исемле абыем. Доктор Ньютон аннан бер генә минутка да аерылмый. Абый бөтенләе белән уйлау, фикерләү сәләтен югалткан. Шизофрения.
Ронни. Бичара. Беләсезме, үзең муеннан уйга батып... Нигәдер башкаларда булган шундый ук кичерешләр хакында уйларга да онытасың.
Ричард *(Ронниның иңсәсеннән кочып)*. Кайтыгыз өегезгә. Ышаныгыз миңа. Сезнең хатыныгыз сезгә тугры.

Управляющий керә. Аларга сәерсенеп карый.

Ричард. Өегезгә кайткач янына барыгыз да, мин Ричард Уилли сүзләренә ышанам, диегез.
Управляющий. Мистер Уилли!
Ричард. Мин буш түгел!
Управляющий. Мин исегезгә генә төшермәкче идем. Сез әле дә булса җәмәгатьчелек палатасына ашыгасыздыр.
Ричард. Безнең биредә көтелмәгән эш килеп чыкты.
Управляющий. Чын күңелдән ышанам! Уйлавымча, хәзер сез ул мәсьәләне чишкәнсездер, сезне башка эш тоткарламыйдыр. Уйлавымча, шул ук вакытта Ронни да...
Ронни *(аны бүлеп)*. Минем белән мондый тонда сөйләшергә җөрьәт итмәгез.
Ричард. Ронни, минем уйлавымча, Управляющий хаклы.
Ронни. Хаклы! Бу отель түгел, фәхешханә!
Управляющий. Фәхешханә?!
Ричард. Ронни!
Ронни. Ә нәрсә? Нәкъ аның борын астында! Мистер белән миссис Пигден!
Управляющий. Мистер Пигден? Әйе, аның барысы өчен дә җавап бирәсе бар.
Ронни. Әлбәттә!
Управляющий. Әле генә мин аңа, бүлмәңдә булган галәмәтләрне аңлашу өчен номерыңда көтәм, дидем.
Ронни *(Управляющийга)*. Ә сез аны кая күрдегез?
Управляющий. Әле генә лифт янында.
Ронни. Ах, кабахәт!

Ронни ишеккә атыла.

Ричард. Ронни! *(Управляющийга.)* Нишләдегез сез!

Управляющий. Өстәвенә шуны да әйттем: «Тиз арада хатыныгыз белән бергә отельне бушатыгыз», — дидем.

Ричард. Аның хатыны инде өенә кайтып бара, үзе дә... Сез беләсезме, сез кешеләрнең зөфаф кичләрен боздыгыз.

Управляющий. Кыскасы, ни өчен әле мистер Пигден үзенең абыйсын отель буйлап инвалидлар коляскасында этеп йөри иде?!

Ричард. Аңа саф һава кирәк... Кыскасы, мин аның абыйсы Фредны күз алдында тотып әйтүем. Егетнең күңеле болгана. Туйда артыграк төшергән. Джордж аны өенә илтергә уйлады.

Управляющий. Җәяүләп? Шәһәр буйлап? Коляска этеп?!

Курыккан хәлдә Джордж йөгереп керә.

Джордж. Мистер Уилли!

Ричард. Пигден! Сез инде күптән парк юлында булырга тиеш идегез!

Джордж. Ул торды!

Ричард. Кем? Кем торды?

Джордж. Ул!

Ричард. Кем ул?

Джордж. Коляскадагы!

Управляющий. Абыегыз Фредмы?

Ричард *(Управляющийга).* Сез безне үзебезне генә калдырмассызмы?

Джордж. Ул аякларына басты!

Ричард. Нәрсә?!

Управляющий. Димәк, сезнең абыегыз бик каты исерек булмаган. Айныган.

Ричард *(Управляющийга).* Рәхмәт инде!

Джордж. Мин аны лифтка төртеп кенә кермәкче идем, ә ул...

Ричард. Ул берничек тә аягына басарга тиеш түгел иде.

Управляющий. Йа Алла, ни өчен әле ул басмаска тиеш?

Ричард *(Управляющийга).* Алла хакы өчен чыгып торыгыз! *(Джорджка.)* Ә сез нәрсә эшләдегез?

Джордж. Качтым.

Ричард. Ә ул?

Джордж. Кнопкага басты да аска төшеп китте.

Управляющий. Әй Ходаем. Ул бит прямо вестибюльдә косарга мөмкин.

Управляющий үз артыннан каты итеп ишекне ябып чыгып китә.

Джордж. Әгәр дә ул җен булса? Гомеребез буена ул бит безнең күзгә күренәчәк.

Ричард. Әкиятеңне сөйләмә! Ул үлмәгән булган, менә шул.

Джордж *(җиңел сулап).* Шулай дисезме?

Ричард. Әйе, безнең өчен яхшы яңалык түгел бу!

Джордж. Сез нәрсә! Моннан да ары яхшы булалмый.

Ричард. Мәет өчен яхшы. Ә синең белән минем өчен начар.

Джордж. Ә минемчә, барысы да яхшы. Миңа аны хәзер паркка илтәсе юк. Әни янына өйгә кайтам да шәфкать туташы Фостерны алыштырам.

Ричард. Шатлыктан сез тәмам уйлау, фикерләү функцияләрегезне җуйдыгыз бугай! Әгәр дә ул исән икән, ул бит минем һәм мисс Уорзингтон хакында барысын да сөйләячәк! Ә-ә, тукта әле, сез алай-болай коридорда мистер Уорзингтонны очратмадыгызмы?

Джордж. Очраттым. Ул миңа бик куркыныч булып күренде.

Ричард. Күренмәгән. Чынлыкта шулай. Ул негодяй Пигденны эзли.

Джордж. Мине әйттеңме әллә?

Ричард. Юк, ул сезне Ньютон дип уйлый.

Джордж *(уйга батып).* Ньютон дип?

Ричард. Әйе, доктор Ньютон дип. Кыскасы, без синең белән кичекмәстән теге шымчы-сыщикны табарга тиешбез. Әгәр бездән алда Ронни аның белән очрашса, бөтенесе дә ачылачак... Ах, җен!

Джордж. Нәрсә булды?

Ричард. Мин бит Роннига ул сыщикны, минем абыем шизофреник Гарри, дидем...

Джордж. Яхшы әле бу, әз-мәз булса да буталчыграк килеп чыга. Калганнарга бит сез Фредны минем алкоголик абыем дидегез.

Ричард. Кыскасы, әгәр ул сыщик көтмәгәндә биредә пәйда булса, сез аны мин әйләнеп кергәнче моннан чыгармагыз.

Джордж. Әйтергә җиңел...

Ричард. Ә инде көтмәгәндә Ронни килеп керсә...
Джордж. Ул чагында нишләргә?
Ричард. Ул чагында инде сезне Ходай Тәгалә үзе сакласын!

Ричард чыкмакчы була, ишек төбендә инвалид коляскасын этеп кергән Официант белән очраша.

Официант. Беләсезме, минем сезгә кечкенә генә шелтәм бар.
Ричард. Кечкенә генә?! Ул минем сәркатибемә...

Ричард чыгып китә.

Официант *(Джорджка).* Мин бу колясканы сезгә шундый авырлык белән таптым...
Джордж. Мин сезгә шундый рәхмәтлемен.
Официант. Ә сезнең абыегыз аны лифт ишек төбенә ташлап киткән.
Джордж. Фредка ул бүтән кирәкми.
Официант. Ул чагында мин аны алып китәм.
Джордж. Әлбәттә.
Официант. Шулай да әзер тотам. Сезнең биредә һәрвакыт нәрсә дә булса туып тора.
Джордж. Бик зур рәхмәт.

Официант чыгып китә.

Джордж. Йа Аллам...

Ишек шакыйлар.

Тагын нәрсә инде?!

Джордж ишекне ача, Памело күренә. Аның кулында саквояж.

Памело *(гаҗәпләнеп).* Джордж?! Исәнмесез! *(Яңагыннан үбеп ала.)*

Памело бүлмәгә уза, Джордж ишекне яба.

Памело *(шаккаткан хәлдә Джорджка борылып).* Менә сиңа мә. Көтелмәгән дулкынландыргыч очрашу.
Джордж. Миссис Уилли!
Памело *(саквояжны идәнгә куеп, елмаеп).* Ничек сез биредә?
Джордж. Мистер Уилли!..
Памело. Әйе!
Джордж. Миссис Уилли...
Памело. Ә минем уйлавымча, сез Ричард белән киңәшмәдә булырга тиеш идегез бугай! *(Сәгатенә карап.)* Йә, булмаса, өегездә, әниегез янында.
Джордж. Ә мин... теге... ни... килдем.
Памело. Килдегез?! Кая?
Джордж. Бирегә.
Памело. Нигә?
Джордж. Ярдәм итәргә... Мистер Уилли... Әйе, әйе, ул биредә оныткан... Кәгазьләрен... Мине җибәрде. Мин — монда, ул — анда. Менә шул...
Памело. Аңлашыла. Бүген Ричардның эшләре муеннан ашкан.

Джордж башын селки.

Памело. Күрәм, бүген сезгә дә бик җиңелдән булмаган.

Джордж башын селки.

Памело. Уйлавымча, бернинди дә куркыныч эш юктыр бит.
Джордж. Сез нәрсә?!

Ишек шакыйлар.

*(Бизгәк тоткандай.)* Ә-ә?!

Памело тартылып куя.

Джордж *(ясалма йөз белән, көлеп).* Кем бар анда?
Официант *(ишек артыннан).* Мин кунакларның сорауларын канәгатьләндерү бүлегеннән.
Джордж *(ишек ача-ача, Памелога).* Официант!

Коляска белән Официант күренә.

Официант. Мин уйладым да шундый фикергә килдем: бәлки, моны сездә калдырыргадыр.

Джордж. Юк, юк, кирәкми. Минем аяк белән хәзер барысы да тәртиптә. Мин хәзер әз генә аксаклыйм. *(Памело өчен берничә адым аксаклап.)* Әйе, әйе. Хәзер бик күпкә җиңелрәк. *(Официантка.)* Рәхмәт сезгә.

Джордж, аксаклап барып, Официантка биш фунт бирә. Тегесе һаман урынында тора. Джордж аңа тагын биш фунтны өсти. Памело моны
күреп гаҗәпләнә.

Сез миңа шулкадәр ярдәм иттегез. *(Официантны коляскага утырта.)* Шулкадәр күп. Миңа хәзер әйбәт. Бик күпкә әйбәт. Миңа хәтта яхшы. Миңа үз гомеремдә дә бу кадәр яхшы булганы юк иде.

Официант утырган колясканы ишек артына чыгара. Коридорда бик каты суккан тавыш һәм Официантның бик каты ыңгырашканы
ишетелә.

Джордж *(берни булмагандай килеп керә дә).* Нәрсә турында сөйләшә идек әле, миссис Уилли?

Памело. Джордж, әллә сез егылдыгызмы?

Джордж. Егылдым. *(Аксаклавын дәвам итеп.)* Нәкъ парламентта. Шулкадәр оппозициягә ачуым чыкты!.. Ә мин сезне шәһәрдән читтә дип уйлаган идем.

Памело *(эшләпәсен салып урындыкка куя).* Әйе, мин анда булдым. Ну көтмәгәндә килеп Ричардка кечкенә генә сюрприз эшләмәкче идем.

Джордж. Сез нәрсә? Аның өчен бу зур сюрприз булачак.

Памело. Ярый алайса.

Памело идәннән саквояжны ала. Джордж аңа эшләпәсен суза.

Джордж. Димәк, сез хәзер мистер Уиллины күрәсез дә кичекмәстән тиз арада китеп барасыз.

Памело. Сез нәрсә?! Мин монда төн кунарга калам.

Джордж. Төн кунарга?!

Памело. Әлбәттә.

Джордж. Вообще-то, мистер Уиллиның бу төндә башка планнары бар иде. Минем шуны әйтәсем килә: төнге утырыш таңга кадәр сузылачак.

Памело. Беләм. Минем аның чыгышын тыңлыйсым килә. Мондагы хәлләр ничек?

Джордж. Лучше сорамагыз... Нинди хәлләр?

Памело. Киңәшмә? Правительствоның хәлләре ничек икән?

Джордж. Ә-ә, правительствоның... Гадәттәгечә. Правительство правительство инде ул!

Памело. Мин Ричардның җыелган халык өчен укыган чыгышын Палатага барып та тыңлый ала идем инде...

Памело йокы бүлмәсенә кереп китә.

Джордж *(курыккан хәлдә).* Юк, юк, моның булуы мөмкин түгел.

Памело, сумкасын калдырып, бүлмәдән чыга.

Памело. Ә мин бокал вино алып, телевизорны кушып, монда гына киңәшмәне тыңлый аламмы?

Джордж. Юк, юк, бары тик монда түгел.

Памело. Ә ни өчен?

Джордж. Чөнки... Лучше безнең номерга каршы бүлмәдә. Анда мондагыга караганда бик күпкә уңайлырак.

Памело *(гаҗәпләнеп).* Каршыдагы бүлмәдә?

Джордж. Әйе, ул минем бүлмә.

Памело. Сезнеке?

Джордж. Әйе, минеке. Нәкъ каршыда. *(Йокы бүлмәсенә йөгерә.)*

Памело. Димәк, сезнең дә монда үз номерыгыз?

Джордж Памелоның саквояжын алып чыга.

Джордж. Әйе, ул миңа мистер Уиллиның бүләге. Әйдәгез, әйдә. *(Башына эшләпәсен кидертә.)*

Памело. Сез нәрсә, әйдәгез дә әйдә?

Джордж. Тизрәк минем номерга керәбез!

Памело. Сез нәрсә сөйлисез?

Джордж. Сез һәм мин! Икәүдән-икәү! Мин һәм сез! Бәлки, безнең беркайчан да икәүдән-икәү генә мондый мөмкинчелегебез булмас.

Памело. Сез нәрсә хакында? Нинди мөмкинчелек?

Джордж. Хисләр дөньясына чумарга!

Памело. Кая чумарга?
Джордж. Хисләр, миссис Уилли, хисләр! *(Памелоны кочаклый.)*
Памело. Джордж!
Джордж. Сез мине күптәннән акылдан шаштырасыз! *(Үбә башлый.)*
Памело. Сез нәрсә, чынлапмы?
Джордж. Мин беләм, сез дә шундый ук тойгылар кичерәсез. *(Янәдән үбә.)*
Памело *(тын алырга азапланып).* Джордж!..
Джордж. О-о, сез нинди гүзәл! *(Үбеп.)* Үз теләгегездән курыкмыйсызмы?
Памело. Ходаем, кем әле курка?

Памело үбешүгә җавап бирә, соңыннан Джордж аннан ычкынмакчы була.

Памело. Димәк, сез шуның өчен үзегезне бик сәер тоттыгыз?!
Джордж. Әйе, мин хисләремне яшердем.
Памело. Киттек! *(Кулыннан электереп ала да ишеккә өстери.)*
Джордж. Юк, юк! Тәрәзә аша.
Памело. Тәрәзә аша?!
Джордж. Ә сез безне күргәннәрен телисезме? *(Тәрәзәне ача.)*
Памело. Әйе, сез дөрес! *(Тәрәзә аша балконга чыга башлый.)*
Джордж *(Памелоның саквояжын ала.)* Тиз, тиз!.. *(Аның артыннан балконнан чыга.)*
Памело. Ходаем, бу бит башка сыймый!
Джордж. Әйе, әйе, башка сыймаслык, искиткеч, башка сыймаслык!

Алар балконга чыгалар, Ричард керә.

Ричард. Әйтерсең лә бу сыщикны җир йотты... *(Бүлмәне күзәтеп.)* Джордж!

Тагын шалтырап тәрәзә рамы төшә. Ричард тәрәзә тирәсенә килә, рамны күтәрә дә башын тыгып карый.

Ричард *(кычкыра).* Джордж!

Балкон ягыннан сиздермичә генә Джейн пәйда була.

Джейн *(Ричардның иңсәсенә кагылып).* Мистер Уилли!

Көтелмәгән хәлдән куркып, кычкырып Ричард тураймакчы була, тик башы рамга бәрелә. Джейн бүлмәгә керә.

Джейн. Гафу итегез...
Ричард. Ни өчен һаман сез биредә?
Джейн. Мин адаштым.
Ричард. Адаштың?
Джейн. Сезнең әйтүегез буенча мин пожарный баскычыннан төштем.
Ричард. Шуннан?..
Джейн. Ул этаждан чыкмадым, анда Ронни бар иде.
Ричард. Ә ул сезне күрдеме?
Джейн. Юк, мин качтым. Ә Мәет кая?
Ричард. Соңгы тапкыр аны лифтта күргәннәр. Ул вестибюльгә төшкән.
Джейн. Нәрсә?
Ричард. Безнең Мәет мәет түгел ул.
Джейн. Мәет түгел?!
Ричард. Әйе, әгәр аңа синең Ронниең белән сөйләшергә җай чыкса, ул түгел, без мәетләр булачакбыз. Парламентка кайтыгыз. *(Тәрәзә янына озата.)* Зинһар, бүтән адашмагыз! Ә мин теге сыщикны эзләп карыйм. Ул бездән алда синең Ронниеңны эзләп тапканчы.
Джейн. Ә мистер Пигден кая?
Ричард. Этем белсен. Хет ул вакытын бушка уздырмасын иде инде.

Джейн балконга чыга, Ричард ишеккә таба китә, ишекне ача. Ә анда муенын уып Мәет тора. Аның башында һаман да котелок. Пауза.

Ричард. Мин сезгә ничек тә булса ярдәм итә аламмы?
Детектив. Дөресен генә әйткәндә, белмим. Шундыйрак хәл... Сезгә бу сәер тоелыр. Нәрсәдер мин хәтеремне югалттым...
Ричард. Керегез, кер, дустым, керегез! *(Аны бүлмәгә тартып кертә. Кайгырып.)* Хәтерегезне югалттыгыз? Нинди аяныч.

Детектив. Мин хәтта исемемне дә хәтерләмим.

Ричард *(шатланып).* Булмас.

Детектив. Мин бу отельдә ничек пәйда булганмын икән?

Ричард. Кошмар!

Детектив. Әйе, үлеп баш авырта...

Шалтырап тәрәзә рамы төшә. Икесе дә сискәнеп куялар. Детектив нәрсәдер исенә төшерә башлый.

Ричард. Дустым, сезгә бу хәлегездә отель буйлап саташып йөрмәскә кирәк. *(Детективны диванга утырта.)* Кем кулына барып капмассыз. Аягыгызны күтәрегез әле, тынычланыгыз. *(Диванга яткыра да үзе ишеккә таба китә.)*

Детектив *(торып утыра).* Сез шулхәтле мәрхәмәтле.

Ричард *(борылып килә дә янәдән яткыра).* Шатланып ярдәм итәргә ризамын.

Детектив. Ниндидер сәер тойгы. Әйтерсең лә мин биредә... *(Бик сак кына.)* Без сезнең белән элек очрашканыбыз юк идеме?

Ричард. Юк, юк, беркайчан да, беркайда да. Озакламый минем коллегам кайта, уйлавымча, ул сезгә ярдәм итә алыр. Ул — врач! *(Диванга сузып сала да ишеккә юнәлә.)*

Детектив *(торып утыра).* Врач — анысы яхшы, димәк, миңа повезло.

Ричард *(килеп тагын диванга яткыра).* Сүз дә юк.

Тәрәзә аша балконнан Джордж керә.

Ричард. Ә-ә, менә ул.

Джордж. Мистер Уилли, сез биредә. Йа Рабби Ходаем!

Ричард. Доктор! Ниһаять! Мин инде борчыла ук башлаган идем.

Джордж. Кирәк бит, ә! Башка кар ишелгәндәй нәкъ минем башка ул.

Ричард *(бүлдереп).* Доктор Ньютон, иң элек төп мәсьәләне...

Джордж. Ул хәзер минем номерда. Минем аңа бирелүемне көтә. *(Аптырап.)* Доктор Ньютон?!

Ричард. Доктор Ньютон, ышанам, сез бу мескенгә ярдәм италырсыз. *(Диванда яткан Детективка күрсәтеп.)*

Джордж. Әни!

Детектив күтәрелә дә, борчылып, Джорджка карый.

Джордж *(җиңел сулап).* Котым чыкты. Кабаттан ул шул хәлендә ята.

Шалтырап рам төшә, Джордж сискәнеп китә. Аннары рамны күтәреп куя.

Ричард *(Детективка).* Мин ышанам, доктор Ньютон сезгә ярдәм итәчәк. Ул крупный психиатр.

Джордж. Кем?

Ричард. Тынычланыгыз, доктор, тынычланыгыз! Бу бичараның хәтере югалган, аңлыйсызмы, хәтере.

Джордж *(әйтелгән фикерне аңлап, шатланып).* Ни өчен алай дип әйтәсез?

Детектив. Ниндидер аңлашылмаучылык... Хәтта исемемне дә хәтерләмим.

Джордж *(шатланып).* Шәп!.. То есть, кирәк бит, ә, нинди кызганыч.

Ричард. Әйе, хәтта ул отельгә ничек килеп эләккәнен дә хәтерләми.

Джордж *(шатланып).* Кошмар!

Ричард. Ә син нәрсә уйладың?

Детектив *(диваннан торып, шикләнеп).* Ә менә бу бүлмә миңа нәрсәнедер хәтерләтә. *(Тәрәзәгә күрсәтә.)* Шулай ук тәрәзә дә!

Ричард *(Джорджка).* Доктор, минем уйлавымча, сезгә авыруны берәр бүлмәгә урнаштырыргадыр.

Джордж. Бик дөрес фикер.

Ричард. Сезнең номерга...

Джордж. Ә менә бу бик үк яхшы фикер түгел.

Ричард *(гаҗәпләнеп).* Ну бит биредә һәрвакыт кеше.

Джордж. Анда да шул ук хәл.

Ричард *(үртәлеп).* Нәрсәдер мин сезне аңлап җиткермим, доктор Ньютон.

Джордж *(Детективны күтәрә төшеп).* Мин дә бит сезгә аңлатмакчы булам.

Ричард. Соңыннан аңлатырсыз, авыруны постельгә салгач. Аңа режим кирәк. Катгый ятак режимы.

Ричард йокы бүлмәсенә таба атлый. Шул вакыт бүлмәгә, атылып, Ронни керә. Джордж тиз арада Детективның башына котелок кидерә
һәм диванга утырта.

Ронни. Хатын өйгә качарга өлгергән, ә менә Пигденны мин таба алмадым...

Ричард *(Роннига).* Тагын бер кат унөченче «А» номерына күз төшерегез әле. Аның әйләнеп кайтуы ихтимал.

Ронни. Точно!

Джордж. Юк! Юк! *(Роннины туктата.)* Анда ул юк.

Ричард *(ачуланып).* Ә бәлки, бардыр! Карасын!

Джордж. Юк, юк, юк! Биш минут элек мин Пигденны күрдем.

Ричард *(берни аңламыйча).* Күрдегез! Кайда?

Джордж. Кайда?.. Бассейнда.

Ронни. Бассейнда?!

Джордж. Без аның белән бергә анда бераз йөздек.

Ронни. Хәзер мин аны йөздерәм. *(Ишеккә юнәлә.)*

Детектив, Роннины күреп, нәрсәдер исенә төшерә башлый.

Детектив *(Роннига).* Туктагыз әле. Сезнең тавышыгыз миңа таныш. Ә сез мине случайно белмисезме?

Ронни. Беләм. Сез — Гарри. Мистер Уиллиның абыйсы. Тиле.

Ронни чыгып китә. Джордж белән Ричард куркышып бер-берсенә карыйлар.

Детектив *(сәерсенеп).* Мин синең абыең Гарри?

Ричард. Ничек дип әйтим...

Детектив. Мин тиле?

Ричард. Нишлисең, Гарри. Син, чыннан да, сәламәт үк түгелсең.

Джордж. Кичер, әни! *(Урындыкка утыра.)*

Ричард. Тынычлан, доктор. Гарри әз генә буталган.

Джордж. Сезнеңчә Гарри буталган.

Ричард. Әлбәттә. Ни өчен без үзебезнең туганлык җепләрен башта ук аңа сөйләмәгәнгә, ул, билгеле, аңлап җиткерми, дөрес бит, Гарри.

Детектив. Дөрес!

Ричард. Менә нәрсә! Аңлыйсыңмы, Гарри, син бик озак авырдың. Билгеле, бу синең эзсез калмады, фикерләү сәләтеңне югалтты. Ул синең бер югала, бер кире кайта. *(Джорджка.)* Доктор, бу сезнеңчә ничек аңлатыла?

Джордж *(кайгыртучанлык күрсәтеп).* Әйтер идем инде мин сезгә ничек аталганын...

Ишек шакыйлар.

Ричард. Доктор, ачыгыз!

Джордж. Ашыкмагыз, минем сезгә әйтәсе сүзем бар.

Ричард. Соңыннан, соңыннан, доктор. Ишекне ачыгыз. Минем абыйны постельгә саласым бар.

Детектив *(Ричардка).* Син минем хакта шундый кайгыртасың.

Ричард. Шуның өчен дә, Гарри, тормышта үзеңнән олырак братлар кирәк тә шул.

Детектив. Шулай да синең чынлап торып минем Бен булмавыма шигең юкмы? Миңа калса, нигәдер минем исемем Бен кебек.

Ричард. Чир! Аңлыйсыңмы, чир! Рәхмәт әйт, ярый әле син үз-үзеңне Биг Бен дип уйламыйсың.

Ричард Детективны йокы бүлмәсенә алып кереп китә. Янәдән ишек шакыйлар. Джордж ишекне ача. Горничная керә.

Горничная. По-о-ос-с-стель-лә-ре-е-е-е-гез-з-зне юу-юу...

Джордж. Кирәкми! Каршы бүлмәнекен дә кирәкми!

Горничная. Б-б-б-бик р-р-р-ә-ә-ә... Пока, пока...

Джордж Горничнаяны типкәләп диярлек бүлмәдән куып чыгара. Балконда эчке күлмәктән Памело күренә, ул тәрәзә шакый. Джордж, кулын изәп, аның китүен сорый. Әмма ул кабаттан шакый. Джордж тәрәзәне ача.

Памело *(бүлмәгә үтеп).* Ни өчен сез озак? Сез бит Ричардның халатын гына алабыз дигән идегез.

Джордж *(пышылдап).* Тс-с! Мин аны табалмыйм.

Памело. Әйдәгез! Мин шампанское белән диңгез моллюскысы, ягъни устрицы заказать иттем. *(Бүлмәгә таба өстери.)*

Джордж. Ну...

Памело. Джордж!

Джордж белән Памело кочаклашып үбешәләр. Шул вакыт балконда поднос белән шампанское һәм диңгез моллюскысы күтәргән Официант пәйда була.

Официант. Шампанское һәм диңгез моллюскысы!

Джордж белән Памело куркышып як-якка тайпылалар.

Памело. Унөченче «А» номерына кертегез.

Официант. Мин шунда керткән идем дә, анда беркем дә юк. Уйладым-уйладым да, сезне биредәдер дип, бирегә кердем.

Джордж. Унөченче «А» номерына кертегез!

Официант. Теләгегез. *(Памелога.)* Ә сез, гафу итегез, кәләш ягыннанмы, әллә кияү ягыннанмы? *(Джорджка күрсәтеп.)*

Памело. Гафу итегез!..

Джордж. Кушылганны эшләгез!

Официант. Яхшы.

Официант чыгып китә.

Памело. Киттек инде.

Джордж. Нәрсәдер мин борчыла башладым, ә вдруг... Мистер Уилли...

Памело. Аның кичке утырышы. Ул таңга кадәр шунда булачак.

Джордж. Ә ул аннан китсә?! Бирегә килсә...

Памело. Да... Киттек инде!

Тәрәзә рамы Памелоның башына килеп төшә. Джордж секунд эчендә катып кала. Соңыннан әкрен генә Памелоны әйләндерә. Памело тәрәзә рамына кысылган.

Джордж. Ах, җен! *(Тиз генә рамны урынына куя, Памелоны бүлмәгә өстери.)* Миссис Уилли! Миссис Уилли!

Памело *(башын тоткан килеш).* О-о!

Джордж *(җиңел сулап).* Ходай бар икән!

Памело *(җиңелчә елмаеп).* Нинди үбү! *(Аның куенына керә.)*

Джордж. Миссис Уилли!

Ишек шакыйлар. Джордж нишләргә белми аптырап кала, тагын ишек шакыйлар. Джордж шкаф ишеген ача да Памелоны шунда кертеп яба. Янәдән ишек шакыйлар.

Джордж. Барам, барам!

Ишекне ача. Анда сестра Фостер Глэдис басып тора. Аның өстендә шәфкать туташлары киеме, кулында пальто һәм сумка. Ул бүлмәгә керә дә тирә-якны күзәтә. Каушаган Джордж ишекне яба да куркып аңа карап тора.

Глэдис. Йә, мистер Пигден? Үзегезне акларлык нәрсә әйтә аласыз?

Джордж. О-о, сестра Фостер.

Глэдис. Сезнең мескен анагыз шулкадәр борчылды ки, хәтта әздән үлми калды.

Джордж. Сестра Фостер...

Глэдис. Мин, гаҗәпләнеп кенә калмыйча, акылдан шашам дип торам. Мин бит сезгә бөтенләем белән ышана идем. Билгеле, әлбәттә, бүгенге көнгә кадәр.

Джордж. Сестра Фостер...

Глэдис. Ничек соң сез беркемгә берни әйтми, берни сиздермичә өйләнергә булдыгыз?

Джордж нәрсәдер әйтмәкче була, Глэдис аны бүлдерә.

Глэдис. Тем более әниегез шундый авыр чакта. Мин аңа, барысын да белмичә, төбенә кадәр төшенмичә кире әйләнеп кайтмыйм, дип сүз бирдем.

Джордж. Әйтегез аңа. Мин барысын да өйгә кайткач үзем аңлатам дип әйтегез.

Глэдис. Юк инде, мин кичекмәстән сезнең аңлатуыгызны көтәм.

Шкаф ишеге ачылып китә, аннан эчке күлмәктән йөзе агарынган Памело килеп чыга.

Памело. О-о, Джордж, нинди тәмле үбү! *(Глэдисны күреп.)* Гафу итегез, мин ишекләрне бутаганмын, ахрысы.

Шкафка керә дә ишеген яба. Глэдис Джорджка карый.

Глэдис. Димәк, шушы була инде сезнең яшь кәләшегез?
Джордж. Юк, бу мистер Уиллиның карт хатыны...
Глэдис. Мистерның... кыскасы, бу ханым премьер-министр ярдәмчесенең хатыны?
Джордж. Ну да.
Глэдис. Ну ул бит сезгә, о-о, нинди тәмле үбү, диде!
Джордж. Әйе шул, миңа да шулай ишетелде.
Глэдис. Сезнең монда күпме хатын-кыз соң?
Джордж. Мин инде санын югалттым.
Глэдис. Мистер Пигден?!
Джордж. Миссис Фостер, мин сездән өйгә кайтуыгызны ялынып, ялварып сорыйм. Юкса бирегә минутка минут дигәндә мистер Уилли һәм аның белән башкалар кайтып керәчәкләр.
Глэдис *(урындыкка утырып).* Йә, йә, кая соң синең кәләшең?
Джордж. Берничек тә ул кәләшем булалмый. Ул парламентта секретарша, ягъни сәркатип.
Глэдис. Ах, секретарша!
Джордж. Тс-сс!
Глэдис. Сез биредә нәрсә белән шөгыльләнәсез инде, мистер Пигден?
Джордж. Бөтенесенә дә яхшы булсын дип тырышам. Үтенеп сорыйм, әни янына кайтыгыз.
Глэдис. Сезсез мин беркая да кайтмыйм.
Джордж. Ярый, алайса, әйдәгез минем номерга. *(Үзенә каратып.)*
Глэдис. Ни өчен әле мин сезнең номерыгызга барырга тиеш?
Джордж. Әйдәгез, әйдә!
Глэдис. Нигә?
Джордж. Хисләр дөньясына чумарга!
Глэдис. Кая чумарга?
Джордж. Хисләр дөньясына, сестра Фостер.
Глэдис *(аның кочагына атылып).* Мистер Пигден!
Джордж. Нинди гүзәл сез! *(Көчле итеп үбә.)*
Глэдис. Сез акылыгыздан шашкансыз.
Джордж. Әйе, сезнең аркада! *(Янәдән үбә.)* Үтенеп сорыйм, табигать биргән рәхәтлегегезгә каршы килмәгез!
Глэдис. Сез нәрсә, кем каршы килә! *(Җилкәсе аша сумкасын ыргыта да Джорджны каты итеп кысып үбә башлый. Озак кына үпкәннән соң, көчкә исән калган Джорджны ычкындырып.)* Сездә миңа карата нәрсәдер барын мин һәрвакыт сизә идем.
Джордж. Әйе, хәзер моңа бик аз гына калды...
Глэдис. Ә миссис Уилли? Секретарша?
Джордж. Сез барда алар миңа хәзер нигә?
Глэдис. Киттек! *(Култыклап ала да ишеккә таба өстери башлый.)*
Джордж. Юк, юк! Бездә биредә тәрәзә аша йөриләр.
Глэдис. Тәрәзә аша?
Джордж *(Глэдисны тәрәзә янына алып бармакчы була).* Шулай куркынычсызрак. Сез алдан керегез. Ә мин биредә чишенәм дә балкон аша сезнең янга керәм.
Глэдис. Джордж!
Джордж *(арт саны белән тәрәзәгә таба этә).* Романтика өчен! Әз генә сезнең дәртегезне кузгату өчен.
Глэдис. Шуннан нәрсә, мин дә сезгә шулай ук җавап бирәм. *(Джордж ясаган хәрәкәтне ясый һәм тәрәзә аша кереп китә.)*
Джордж. Тизрәк, миссис Фостер, тизрәк!
Глэдис. Хәзер миңа Глэдис дип кенә дәшә аласыз.
Джордж. Глэдис! Хикмәт. *(Тетрәнеп.)* Глэдис, сак булыгыз!
Глэдис. Ә нәрсә бар?

Шалтырап тәрәзә рамы төшә. Глэдис көлеп Джорджка ике бармагын иреннәренә тидереп ярату мимикасын җибәрә дә рамны күтәреп куя
һәм балкон буйлап китә.

Джордж *(үз-үзенә).* Әйе, Джордж, узган гомереңне син юкка әрәм иткәнсең.

Шкафка ашыга, ишеген ача. Памело әкренләп кенә үз хәленә кайта.

Джордж. Миссис Уилли!
Памело. Йә, сез әзерме? Мин көтәм.
Джордж. Юк, юк, сезгә кичекмәстән өегезгә кайтырга кирәк.

Йокы бүлмәсенең ишеге ачыла. Джорджка аркасы белән Ричард чыга.

Ричард *(Детективка).* Менә шулай, Гарри, молодец, тыныч кына ят, йокла.

Джордж Ричардны күреп тиз генә шкафка керә дә ишеген яба.

Ричард *(кычкырып).* Джордж! Джордж?

Ишек шакыйлар.

Кем анда?
Официант *(ишек артыннан).* Кунакларның сорауларын канәгатьләндерү бүлегеннән.

Ричард ишекне ача. Официант керә.

Официант. Сез кул куярга тиеш. *(Кәгазь суза.)*
Ричард. Нәрсә бу?
Официант. Шампанское һәм өч диңгез моллюскысы өчен счет.
Ричард. Мин аларны заказать итмәдем.
Официант. Сез түгел, ә мистер Пигден.
Ричард. Пигден?
Официант. Ну да.

Ричард артындагы шкафның ишеге ачылып китә. Шкафтан сөйкемле елмаеп, аркасы белән бүлмәгә Памело чыга. Джорджның биленнән кочаклап ала. Джордж куркып Ричард һәм Официантка карый да
җайлап кына шкафка керә.

Ричард. Булмас.
Официант. Әйтеп торам бит, бу — аның заказы.
Ричард. Ә мин әйтәм, монда ниндидер хата.
Официант. Бернинди хата да юк. Менә бит күреп торасыз. Унөченче «А».
Ричард *(кәгазьгә карап)*. Унөченче «А».

Ричард, борылганда, Джорджның шкаф ишегенең ябылганын күреп
кала.

Ричард. Джордж!

Джордж шкафтан сикерә.

Ричард. Сез биредә нишлисез?
Джордж. Шкафтан чыгам.
Ричард. Ни пычагыма дип анда кердегез?
Джордж. Ул вакытта мин болай яхшырак булыр дип уйладым...
Ричард. Монысы тагын нинди галәмәт. Шампанское белән диңгез моллюскысын сез заказать иттегезме?
Джордж. Мин.
Ричард. Ни өчен?
Джордж. Ул вакытта мин...
Ричард *(бүлдереп).* Дәшмисез! *(Официантка.)* Менә нәрсә, Джек...
Официант *(Джорджка).* Күрәм, сезгә һаман да үзегезнең зөфаф кичегезгә керергә вакыт җитми, ә?
Джордж. Монысы хак!
Официант. Ә тегесе кем иде аның, әллә сезнең кәләшегезнең апасы идеме?
Джордж. Әйе, әйе, теща! *(Официантны ишеккә кысрыклый.)*
Ричард *(Официантка).* Сез чыгып киткәнче кечкенә генә йомышым бар иде...
Официант *(кулларын уып).* Без шатланып.
Ричард. Йокы даруы табаласызмы?
Джордж. Йокы даруы?
Ричард *(Джорджка).* Сезнең абыегыз Фредка кирәк. Ул бик күп әйберләрне исенә төшерә башлады. *(Официантка.)* Күпме көчлерәк булса, шулкадәр яхшырак.
Официант. Минем уйлавымча, Горничнаяда, мөгаен, бардыр.
Ричард. Тизрәк алып керегез.

Официант ютәлләгән булып кулын суза. Ричард бумажнигын чыгара,
ләкин ул буш.

*(Джорджка.)* Ярдәм кулы сузмассызмы?

Джордж бумажнигын чыгара.

Джордж *(Официантка биш фунт суза).* Сез бүген минем бөтен зарплатамны алып бетерәсез кебек тоелмыйммы?

Официант. Бөтен... юк ла...

Официант акчаны ала да чыгып китә.

Ричард. Мин Гарри белән эшне бетерәм... Ә сез уяу булыгыз, көтмәгәндә Ронни килеп кермәсен.

Джордж. Мистер Уилли! Минем сезгә әйтәсе сүзем бар!

Ричард *(түземсезләнеп).* Нәрсә?

Джордж. Сезнең хатыныгыз...

Ричард. Минем хатын?

Джордж. Тс-с!

Ричард. Нәрсә минем хатыным?

Джордж. Миссис Уилли шкафта!

Ричард. Бик яхшы. *(Йокы бүлмәсенә атлый, алда әйтелгәнне аңлап, кире борыла.)* Памело шкафта?..

Джордж. Әйе шул, эчке күлмәктән ул анда!

Ричард. Эчке күлмәктән?

Джордж. Шкафта.

Ричард. Памело эчке күлмәктән шкафта?

Джордж. Әйе шул.

Ричард. Ә ул анда нәрсә эшли? Эчке күлмәктән ул шкафта нишли?

Джордж. Минем үз янына чишенеп килгәнемне көтә.

Ричард озак кына паузадан соң тыела алмыйча көлә башлый. Джордж берни дә аңламыйча аптырап карап тора. Телефон шылтырый. Ричард
трубканы ала.

Ричард *(трубкага көлүеннән туктый алмыйча).* Әйе! *(Көлүеннән туктый.)* Сестра Фостер! Бу юлы сезнең анда тагын нәрсә булды инде?

Джордж. Йа Рабби! *(Ричардка.)* Бирегез әле, мин аның белән сөйләшәм.

Ричард *(трубкага).* Пигденның әнкәсенә әйтегез, аның бердәнбере бары тик ярты төн уртасында гына кайта алачак дип... Юк! Ә сез кайда соң?.. *(Тыңлый да Джорджка.)* Сестра Фостер сезнең номерыгызда нишли ул?

Джордж *(икеләнеп).* Минем чишенеп үз янына килгәнемне көтә.

Ричард *(паузадан соң).* Нәрсә, нәрсә?

Джордж. Хисләр дәрьясына чумарга...

Ричард *(трубкага).* Сестра Фостер! Бу төр хезмәтегез Сәламәтлек саклау министрлыгы аша яклангандыр дип уйлыйм. *(Трубканы ыргыта.)* Димәк, шампанское белән диңгез деликатисы сестра Фостер өчен?

Джордж. Юк, миссис Уилли өчен. *(Ричард башта шкафка, аннары Джорджка карый.)* Мин бит сезгә аңлатмакчы булам...

Ричард шкаф ишеген ача, аннан Памело чыга.

Памело *(башын югалткан хәлдә).* Йа Рабби, Ричард.

Ричард тыныч кына Памелоны бора да кире шкафка яба.

Джордж. Миссис Уилли сезгә сюрприз ясамакчы иде.

Ричард. Ул аның барып чыкты.

Джордж. Ул шымчы белән Роннины очратканчы, сез аны өегезгә озатыгыз.

Официант керә.

Официант. Ә менә без! Йокы даруыгызны алыгыз!

Ричард *(Джорджка).* Ярар, мин сезнең белән соңыннан аңлашырмын!

Ричард даруны алмакчы була. Официант Ричардның күзләренә тутырып карап акча кирәклеген сиздерә. Ричард Джорджның биш
фунтын алып официантка бирә дә даруны ала.

Ричард *(Официантка.)* Китәргә мөмкин. Башка сезнең безгә бернинди дә хезмәтегез кирәк булмаячак.

Официант. Ә мин сезнең урыныгызда алдан кычкырмас идем.

Ишеккә атлый. Джейн йөгереп керә.

Джейн. Мистер Уилли!

Ричард *(Официантка).* Ашыкмагыз.

Джордж. Миссис Уорзингтон, сезнең ирегез аңларлык хәлдә түгел.

Джейн. Менә сиңа премьер-министр, әйтмәсәң дә беләм!

Ричард. Йа Хода!

Официант. Әгәр биредә премьер-министр да пәйда булса, монда эшләр харап булачак.

Ричард белән Джордж аңа карыйлар.

Ричард. Нәрсә булды, миссис Уорзингтон?

Джейн. Анда хәзер киңәшмә түгел, мәхшәр!

Ричард. Аңлатып сөйләгез, нәрсә булды?

Джейн. Ну, башта әйбәт кенә иде. Соңыннан премьер-министр психлана башлады. Шул вакыт безнең арадан берсе басты да: «Кызганыч ки, нигәдер премьер-министр бүгенге киңәшмәгә үзенең куштанын алмаган. Алайса, аның бүген яклар кешесе юк», — диде.

Ричард. Куштанын?!

Джордж. Сүз сезнең хакта, мистер Уилли.

Ричард Джорджка карый.

Джейн. Шуннан, премьер карый, чыннан да сез юк. Шуннан соң китте котырып, китте котырып. Хәтта оборона министрының аягына китереп басты.

Джордж. Нинди куркыныч!

Официант. Күрәм, сезнең монда бик эсселәнә башлады!

Ричард. Тыныгыз чыкмасын!

Джейн. Миңа тизрәк кире йөгерергә кирәк. Әгәр минем сезне кисәткәнемне безнекеләр белеп алса, мине эшемнән куачаклар.

Ричард. Джейн, сез — фәрештә. Мин сезнең белән барам.

Джордж. Ә-ә, юк инде! Барыгыз, миссис Уорзингтон, мистер Уилли сезне куып тотар. Аның әле биредә кайбер әйберләрне җайлыйсы бар. *(Карашы белән шкафка ымлап.)*

Йокы бүлмәсеннән Детектив чыга.

Детектив. Тыңлагыз әле! Мин бу отельгә ничек килеп эләккәнемне исемә төшердем.

Ричард, Джордж һәм Джейн бер-берсенә карап алалар.

Джордж. Ах, җен! Тагын торган...

Ричард. Авыру туганым, сиңа бит торырга ярамый.

Джордж Детективны йокы бүлмәсенә төртеп кертә.

Джейн. Ә ул шымчы сезнең йокы бүлмәгездә ни эшли?!

Ричард. Борчылмагыз, Джордж аның артыннан карый.

Официант *(Джорджка).* Димәк, сезнең абыегыз шымчы?

Джордж *(Официанттан үтенеп).* Зинһар, югалыгыз!

Ричард *(Джорджка).* Абыегыз янына барыгыз да йокы даруы эчәргә мәҗбүр итегез, ә без Джейн белән кичекмәстән парламентка кайтабыз!

Детектив чыга.

Детектив *(Джейнга).* Ә без сезнең белән, яшь ханым, танышлар, ахрысы.

Ричард белән Джейн бер-берсенә карыйлар.

Джейн *(батыраеп).* Алай дип уйламыйм.

Детектив. Юк, иманым камил, мин сезне кайчан һәм кайдадыр күргәнем булды.

Ричард. Әлбәттә, хөрмәтле Гарри, күрдегез. Әлбәттә. Бу бит доктор Ньютонның хәләл җефете!

Официант *(ныклап игътибар белән карап).* Доктор Ньютон?

Джордж аның аягына китереп баса.

Детектив *(Ричардка).* Димәк, син чынлап ышанып минем Бен булмавымны әйтә аласың?

Ричард. Әлбәттә, ышанып. Син минем абыем Гарри. Гаррисон Уилли.

Официант. Менә сиңа мә!

Ричард *(Официантка ымлап).* Күземнән югалыгыз!

Детектив. Ричард, беләсезме нәрсә? Нигәдер миндә сез минем туганым булуыгыз хакында шик бар.

Официант. Нәрсә булып чыга инде бу?! Сез мистер Уиллиның абыйсы?!

Джордж янәдән аның аягына баса.

Ричард. Доктор, зинһар өчен, Гаррины караватына яткырып, аңа тынычланыр өчен дару бирсәгез иде.

Джордж Детективны йокы бүлмәсенә төртеп кертә.

Ричард. Ул йоклауга, минем шкафтан артык кирәкмәгән әйберләрне юкка чыгарыгыз. Шулай ук үз караватыгыздагыларын да. Җае чыгуга, мин кире әйләнеп кайтырмын. *(Чыга башлый.)*
Официант. Мистер Уилли, әлбәттә, мин гафу үтенәм! *(Джорджка күрсәтеп.)* Ничек ул аның абыйсы?.. Бәлки, ул сезнекедер?
Ричард. Кыскасы, әни бер, ә этиләр башка.

Официант Джорджка карый. Джордж күзен йома. Официант аның җилкәсенә суга.

Ричард *(Джорджка).* Барыгыз, Фредны карагыз!
Джордж. Киттем! Ләкин исегездә тотыгыз: аталарыбыз икенче кеше булуы белән мин бик бәхетле.

Джордж йокы бүлмәсенә кереп китә.

Джейн. Тизрәк булыгыз, мистер Уилли.

Ишекне ача да кинәт кире яба.
Ронни!
Ричард. Ронни?!
Джейн. Кыяфәте әйтеп аңлата алмаслык.
Ричард. Тәрәзәгә!

Ричард Официантны читкә этә дә тиз генә тәрәзә аша балконга чыга.

Официант. Ә бу Ронни кем яклы? Яхшылар или усаллар яклымы?
Джейн. Хәзер ул биредә иң усалы!

Джейн тәрәзәгә ашыга. Ишек шакыйлар.

Официант. Хәзер! *(Ишеккә бара.)*
Джейн. Ачма!

Аскы өлешенә сөлге ураган ярым шәрә Ронни килеп керә. Чәче юеш, ялан аягына туфли кигән. Тәрәзәдән чыгып китәргә өлгермәгән Джейн шкафны ача, ә анда елмаеп Памело утыра. Ул аның янына кереп бикләнә.

Официант. Хәерле кич, сэр. Сез, уйлавымча, бассейн эзлисез?
Ронни. Мин аны күптән таптым. *(Кабарынып.)* Мистер Уилли кая?
Официант. Әле генә чыкты.
Ронни. Мин аны очратмадым.
Официант. Ул, гадәттә, тәрәзәдән чыга.
Ронни. Мин аның секретаре Пигденны эзлим!
Официант. Мистер Пигденны?! Ул әле генә биредә булды.
Ронни. Биредә?!
Официант. Әйе.
Ронни. Аның белән хатын-кыз юк идеме?
Официант. Әлбәттә, яшь хатыны. Алар бүген иртән өйләнештеләр!

Ронни, тезләнеп, официантның аягын кочаклап үксеп елый. Официант, ничек тынычландырырга белмичә, аның башыннан сыйпый.

Официант. Ә беләсезме иң кызыгы нәрсәдә? Алар нindидер Ронни исемен ишетүгә, шул ук секундта алардан җилләр исте.
Ронни. Әлбәттә! *(Тәрәзәгә бара.)*
Официант. Әгәр дә мин аларның берәрсен очратсам, нәрсә дип, кем килде дип әйтергә?
Ронни. Ронни дип! *(Тәрәзәдән чыга башлый.)*
Официант. Ронни дип? Җиткерермен. *(Төшенергә теләп.)* Ронни?!
Ронни *(тукталып кала).* Нәрсә?
Официант. Туктагыз, менә шулай.

Кыска паузадан соң шалтырап тәрәзә рамы Ронниның муенына килеп төшә.

Официант. Кичер, Ходаем! *(Тәрәзә пәрдәсен яба, рамны күтәреп куя һәм шкаф ишеген шакый. Кычкырып.)* Золым иясе юкка чыгарылды!

Шкафтан Джейн чыга.

Джейн *(үз артыннан шкаф ишеген ябып).* Зур рәхмәт сезгә. *(Коридорга чыга торган ишеккә ташлана, туктап кала.)* Белмим, бәлки, сез хәбәрдардыр, анда шкаф эчендә ниндидер бер ханым.

Официант. Ханым?!

Джейн. Эчке күлмәктән.

Официант. Ә ул... Ә нигә, ул сезнең әниегез түгелмени?

Джейн нәрсәдер әйтмәкче була, кулын гына болгап чыгып кача. Официант кулына блокнот белән каләм ала. Яза.

Официант *(үз-үзенә).* Бер золым иясен юкка чыгару — ун фунт.

Официант чыгып китә. Ронни тәрәзә пәрдәсен ача.

Ронни *(авыр сулап).* Баш!.. *(Тәрәзәдән чыга.)* Ну, Пигден! *(Ишеккә юнәлә, телефон белешмәсен күреп.)* Биредә ул кабахәтнең адресы булырга тиеш.

Телефон белешмәсен актара. Йокы бүлмәсеннән, аяк башларына гына басып, Джордж чыга да, Роннины күрмичә, ипләп кенә барып шкаф ишеген ача.

Ронни *(телефон белешмәсен укып).* Бар! Менә ул! Пигден Джордж!

Джордж. Ә? Нәрсә? *(Шкаф ишеген яба.)*

Ронни *(укый).* Уимблдон Кенилворт урамы егерме биш. *(Белешмәне идәнгә атып бәрә дә ишеккә юнәлә.)*

Джордж. Сез кая, Ронни?

Ронни. Пигденның өенә!

Джордж. Мин анда юк, то есть ул анда юк. Мин бит сезгә аны бассейнда йөзә дип әйткән идем...

Ронни. Бассейнда бер генә кеше — мин генә йөздем. Ә ул, хайван, аннан тайган!

Номердан чыкмакчы була, әмма Джордж аны кире бүлмәгә өстери.

Джордж. Ашыкмагыз!

Ронни. Җибәрегез, доктор. Мин аларга барам!

Джордж. Кирәкми, үтенеп сорыйм, кирәкми! *(Тезләнә. Ронни уралган сөлгегә ябыша.)*

Ронни. Юк, мин барам!

Управляющий килеп керә һәм Ронни алдына тезләнгән Джорджны күреп катып кала.

Джордж. Юк! Юк, калыгыз!

Ронни. Җибәрегез!

Джордж. Үтенеп сорыйм, Ронни!

Ронни. Юк, мин барам. Мин аңамы?! Мин аңа күрмәгәнен күрсәтәм.

Управляющий шаккатып карап тора.

Джордж. Юк! Ронни, үтенәм! Минем белән кал!

Управляющий. Мистер Пигден! Әгәр сез шушы ук минутта үз аякларыгыз белән отельдән чыгып китмәсәгез, мин каравылны чакыртырга мәҗбүр булам. Алар сезнең кулларыгызга богау салып, бик тиз чыгарып ташларлар.

Джордж. Һәм дөрес эшлиләр дә.

Управляющий. Әгәр дә сезнең дустыгыздан да шушы ук секунтдта җилләр исмәсә...

Ронни. Тынычланыгыз, күреп торасыз, миннән озакламый җилләр исә.

Ронни Джордж янынннан үткәндә тегесе арттан аның сөлгесенә тотына.

Джордж. Үтенәм, Ронни! *(Сөлгегә ябыша, ә Ронни аны тартып алмакчы була.)* Ходай хакы өчен!

Управляющий. Туктатыгыз! *(Джорджның кулына суга.)* Бу җәмгыятьтәгечә түгел!

Джордж белән Роннины аермакчы булып уртага керә. Джордж аның чалбарына ябыша. Управляющийның чалбары әздән генә салынмый кала.

Управляющий. Җен! Туктатыгыз дим мин сезгә!

Йокы бүлмәсеннән пижама һәм котелок белән Детектив чыга.

Детектив. Мин барысын да искә төшердем.

Тарткалашу туктала. Джордж тезләнә. Управляющий чалбарын рәтли, ә Ронни сөлгесенә урала.

Управляющий *(Джорджка).* Сез бит аны китте дигән идегез!

Детектив. Бейкер! Мин исемә төшердем. Минем исемем Бен Бейкер!

Джордж. А ну-ка хәзер үк урыныгызга ятыгыз!

Управляющий. Яхшы! Мин охрана артыннан киттем! *(Чалбарын рәтли-рәтли чыгып китә.)*

Ронни. Кая әле! *(Детективның башыннан котелокны салдыра. Джорджка шаккатып карап.)* Бу бит минем эзтабар, частный Детектив. Аның белән нәрсә булган?

Джордж *(исе китмичә)*. Болай гына, аптырарлык берни дә юк.

Детектив *(Роннига төртеп)*. Сез — мистер Уорзингтон!

Ронни. Мин сез әйтмәсәгез дә үземнең кем икәнемне беләм.

Детектив. Әле миссис Уорзингтон да бар!

Ронни. Нәрсә?! Сез минем хатынымның кайда икәнен беләсез?

Детектив. Мин барысын да беләм... *(Дәвам итмәкче була, әмма каты итеп идәнгә утыра.)*

Джордж. Күрәсез, минем авыруыма постельгә ятарга кирәк.

Ронни. Ньютон, авызыңны яп!

Джордж. Яптым.

Ронни *(Детективны дер селкетеп)*. Кая минем хатын?

Детектив мыгырдана. Ронни аны ташлый да тәрәзә янына килә.

Детектив. Исемә төшердем, бөтенесен дә исемә төшердем.

Ронни борылып карый. Детектив нәрсәдер әйтмәкче була да, озын-озак иснәнеп, башын урындыкка куеп йоклап китә. Ронни тәрәзәне
ачып балконга чыга.

Ронни *(Джорджка)*. Пигден янына барам да шунда икесен тончыктырам! *(Янәдән башын тәрәзәдән чыгарып.)* Икесен дә үтерәм!

Джордж. Ронни, бер генә секундка шунда тыныгыз!

Ронни. Нәрсә?

Джордж өмет белән тәрәзә рамы төшмәсме дип карый. Таптана, сикерә,
кулларын изәп карый, рам төшми.

Ронни *(аңа гаҗәпләнеп карап торганнан соң)*. Тагын бер псих!

Ронни китә. Джордж тәрәзәгә төкерә. Шалтырап рам төшә. Балконда сөлгегә уралган Глэдис пәйда була. Аның кулында Памело киемнәре.
Тәрәзәне кага. Джордж тәрәзәне ача, Глэдисны кертми.

Джордж *(рамны күтәреп куеп)*. Сестра Фостер, мин бит сезгә мине номерда көтегез дип әйттем. Искиткеч гүзәл күренәсез.

Глэдис. Котлыйм сезне! *(Киемнәрен сузып.)* Менә. Мин боларны караватк кырыеннан таптым.

Джордж *(киемнәрне алып)*. О-о, рәхмәт, бу киемнәр миссис Уиллиныкылар. Ә сезнең киемнәрегез кая?

Глэдис. Шунда ук! Ышанам, миссис Уилли бүген анда йокламас!

Джордж. Сез нәрсә сөйлисез?

Глэдис. Ә сезнең секретаршагыз кая?

Джордж. Ул инде китте. Барыгыз минем номерга, көтегез мине.

Глэдис *(Детективны күреп)*. Ә бу кем?

Джордж. Бумы? Ул үз халәтенә кайта. Китегез, Глэдис. Мин миссис Уилли белән бөтенесен дә җайларга тиеш.

Глэдис борыла һәм шкафка таба атлый, шул вакыт аның муенына шалтырап тәрәзә рамасы төшә. Джордж катып кала. Озак кына
борылып карарга куркып торганнан соң, ниһаять, борыла.

Джордж. О-о, юк, зинһар өчен, бу кирәкми иде.

Ишек шакыйлар. Джордж куркуыннан Памелоның киемнәрен төшереп
җибәрә.

Детектив *(урыныннан торып)*. Менә шулай, мин барысын да исемә төшердем.

Джордж. Зинһар, бер сүз дәшмәгез!

Джордж Детективның артыннан башына суга, тегесе тына. Янәдән ишек шакыйлар. Джордж тиз генә тәрәзә рамын күтәрә һәм ярым
аңгырайган Глэдисны тартып ала.

Детектив. Йа Алла!

Джордж. Аллага шөкер!

Детектив. Сез мине нишләттегез?

Джордж. Шул инде, нәкъ башкалар кебек.
Детектив. Нинди иркәләү! *(Джордж кочагына керә.)*

Янәдән ишек шакыйлар.

Джордж. Кем анда?
Ричард *(ишек артыннан).* Мин, мин! Ачыгыз!

Джордж Глэдисны кочаклаган килеш ишекне ача.

Ричард. Фикер алышулар куркыныч бара... *(Глэдисны күреп тынып кала.)* Монысы тагын кем?
Джордж. Сестра Фостер.
Ричард. Күрәм, сез биредә вакытыгызны бушка уздырмыйсыз. *(Детективны күреп.)* Ни өчен ул ятакта түгел?!
Джордж. Үзеннән сорагыз!
Ричард. Ә сез аңа йокы даруы бирдегезме?
Джордж. Бер тапкыр бирдем.
Ричард. Нәрсә, бер таблеткамы?
Джордж. Бер кап.
Ричард. Минем тагын бер тапкыр киңәшмәгә барасым була. Бүген анда бөтенесе дә правительствоның катастрофасы белән тәмамланырга охшаган.
Джордж. Ә монда бөтенебезнең дә катастрофасы белән тәмамланачак.

Шалтырап тәрәзә рамы төшә. Куркудан Джордж Глэдисны кочагыннан ычкындыра, тегесе идәнгә шапылдап төшә.

Ричард. Сез минем хатынны өйгә озаттыгызмы?
Джордж. Юк, ул әле дә булса шкафта. *(Идәннән Памелоның киемнәрен күтәрә.)*
Ричард. Нәрсә?!
Джордж. Ә сез аны киенергә мәҗбүр итәргә тиешсез. Ронни бассейнга китте. Ә Управляющий — каравылчы чакырырга.

Ричард Джорджның кулыннан Памелоның киемен ала да шкаф ишеген ача.

Ричард. Памело, чык!
Джордж. Глэдис, керегез!

Джордж Глэдисны шкафка төртеп кертә. Памело хәтта аны искәрми.

Памело *(Ричардка).* Хәерле кич, Ричард!
Ричард *(кискен).* Памело, киен дә өйгә кайт.

Ул аңа киемнәрен бирә дә кулыннан йокы бүлмәсенә өстери. Памело Детективны күреп туктап кала.

Памело. Ә бу кем?
Ричард. Бу — Фред, Джорджның абыйсы.
Джордж *(тыныч кына).* Мин шулай буласын белгән идем.
Памело. Аның белән нәрсә булган?
Ричард. Джорджның туенда дуңгыз урынына тыгынган.

Джордж ачуыннан куллары белән битен каплый.

Памело. Туйда?!
Ричард. Әйе, ул бүген иртән языlышты. *(Джорджка.)* Шулай түгелме?

Джорджның ачуланганы сизелә.

Памело. Ну, Джордж, кем инде ул сезнең хатыныгыз?
Ричард. Әйтеп аңлатмаслык зат. Аның исеме Айви. *(Памелога.)* Киен!
Памело. Айви?! Ә кая соң ул? *(Джорджка.)* Кая сезнең хатыныгыз?
Джордж. Белмим!
Памело. Белмисез?!
Ричард. Хәзергесе минутта кайда икәнен белми. Алар аның белән... Биредә качышлы уйнадылар.
Памело. Димәк, ул качты?

Тәрәзә ачыла. Балконнан сөлгегә уралган Ронни керә. Ричард тиз генә Памело артына кача.

Ронни. Шайтан, теге үләксә тагын качты!

Памело. Ходаем, Ричард, кем бу?

Ронни *(Детективка).* Күптән моңа аңына килергә вакыт! *(Джорджка.)* Доктор Ньютон, бәлки, сез аңа берәр нәрсә бирерсез?

Памело, сәерсенеп, Джорджка карый. Ул әйтерсең лә аңа түгел, ә бүтән кешегә дәшкән сыман йөз ясый. Шапылдап тәрәзә рамы төшә.
Бөтенесе дә сискәнеп куя.

Ронни. Юк, нигәдер үземә дә кызык булып китте. Минем хатын кая качарга мөмкин?

Ронни йокы бүлмәсенә керә.

Ричард *(рамны күтәреп куя, Памелога).* Ронни да үзенең хатыны белән качышлы уйнарга ярата.

Памело. Ә кем соң ул Ронни?

Ричард. Кәләш ягыннан туганнары. Ул Айвиның ике туганнан туган кызына өйләнгән.

Джордж. Шулай.

Памело. Ә ни өчен соң ул Джорджка доктор Ньютон ди?

Ричард *(Джорджка).* Чыннан да, Джордж, аңлатыгыз, ни өчен ул сезне шулай атый?

Джордж *(Ричардка якын килеп, тыныч тавыш белән бик каты үртәлеп).* Ә менә ни өчен, чөнки мин, чыннан да, шул нәкъ үзе — Ньютон! Коперникның племянникгы! Өстәвенә Фредның энесе! Альбертның абыйсы.

Ишекне каты итеп ачып Ронни керә.

Ронни. Алама тәре! Әйтерсең лә җир тишегенә кереп югалды!

Памело. Ә ни өчен шулкадәр күңелсезләндегез? Соң бит сезнең аның белән бары тик уен гына?!

Ронни. Уен?! О-о, миссис Уилли! Аның өчен бу бары тик уен гына! *(Ричардның алдына тезләнеп аякларын кочаклый да үксеп елап җибәрә.)*

Памело. Мистер Пигден, Роннига су бирегез.

Джордж уйланмый әйтелгән бу сүзләрдән каушап куя. Ронни әкрен
генә тора да аңа таба атлый.

Ронни. Пигден?! Димәк, бу хайван Пигден... Бу сез?!

Джордж. Бу хайван, әйе, мин.

Ронни *(Памелога).* Бу тип минем хатынны үз койкасына салыр өчен нәрсәләр генә эшләмәде!

Джордж. Ходай күреп тора, мин беребезнең дә хатыны анда булмавын теләп барысын да эшләдем.

Памело. Әйе, Ронни, хәтта Джордж кебек тип та үзенең хәләл хатынының ике туганнан туган сеңлесе белән бу эшкә бармас иде.

Ронни. Ярар, ташлагыз аны яклавыгызны! Нинди тагын ике туганнан туган сеңлесе белән?!

Памело. Хатыныгызның ике туганнан туган сеңлесе. Айви һәм сезнең хатыныгыз туганнан туган сеңелләр түгелме соң?

Ронни. Айви?

Ричард. Әлбәттә, Айви, ә кем соң тагын? Джордж, аңлатыгыз үзенә.

Джордж Ричардка карый, аннары барысы да Джорджка карыйлар.

Джордж. Хәзер аңлатам. *(Роннига.)* Сезнең хатыныгызның анасы бармы?

Ронни. Шуннан. Булды ди.

Джордж. Менә шул. *(Пауза. Барысы да Джорджның аңлатуын көтәләр.)* Ә сезнең хатынның әнисенең сеңлесе бармы? Аның сеңлесенең кызы Айви бар. Менә шул Айви бүген иртән миңа кияүгә чыкты.

Пауза.

Ронни. Сез нәрсә дидегез?

Джордж. Сезнең җизнәсе булган хатыныгыз бармы? Ул җизнәсенең хатынының бүген иртән мистер Уиллиның сәркатибенә, ягъни миңа кияүгә чыккан Айви исемле кызы бармы? Аңлашылдымы?

Ронни *(бераз паузадан соң).* Әлегә барысы да түгел.

Ричард. Фикерегезне туплагыз, Ронни, сезнең хатыныгыз бар.

Барысы бергә. Ягъни җизнәсе бар. Җизнәгезнең хатынының бүген иртән мистер Уиллиның сәркатибенә, ягъни миңа кияүгә чыккан Айви исемле кызы бар.

Ронни авыр адымнар белән коридорга чыга торган ишеккә юнәлә. Уралган сөлгесе, ишек тоткасына эләгеп, идәнгә төшә. Арт ягы ачылганын сизмичә чыгып китә. Джордж сөлгене ишек тоткасыннан ала
да коридорны карый.

Джордж *(Ричардка).* Отельдән чыгып киткәнче үз кыяфәтен күрер дип ышанам.
Ричард. Памело! Бар, киен, зинһар өчен! Мине премьер-министр көтә!

Памелоны йокы бүлмәсенә төртеп кертмәкче була.

Памело. Юк, мин калырмын, ахрысы. Минем Айвины күрәсем килә.

Ричард белән Джордж бер-берсенә карыйлар.

Ричард. Сөеклем! Айви... буш түгел. Ул... качышлы уйный.
Памело. Аның белән танышасым килә.
Ричард. Ә мин синең аның белән танышуыңны теләмим!
Памело. Ни өчен?
Ричард. Чөнки ул миңа ошамый. *(Джорджка.)* Сез мине гафу итегез, әмма әйтми кала алмыйм. Миндә сезнең кәләшегез нindидер авыр, күңелсез тойгы уята. Дөресен генә әйткәндә, ул сезнең бик сирәк очрый торган аңлаешсыз зат.
Джордж *(авырлык белән әйтелгәннең серенә төшенеп).* Ә, минемчә, ул ярыйсы гына.
Памело. Джордж, табыгыз аны!
Ричард. Памело!

Джейн керә.

Джейн *(Ричардка, шатланып).* Мистер Уилли! Мин сезгә әйтергә тиеш дип уйладым, безнең Ронни белән барысы да тәртиптә!
Ричард. Мин шат.
Джейн. Без аның белән коридорда очраштык. Ул шунда ук барысын да аңлады, мине күреп чиксез шатланды.

Кире йөгерә.

Ричард *(Памелога).* Менә бу Джейн иде.
Памело. Юлыңда бул, сөеклем. Сине анда премьер көтә.

Памело йокы бүлмәсенә кереп китә.

Ричард. Эшләр харап, Айвины күрмичә ул китмәячәк!
Джордж. Алайса, ул биредә озакка!
Ричард. Туктале, ә безнең Айви бармы соң?
Джордж. Ничек инде?!
Ричард. Сестра Фостер?! Ул бит шкафта!
Джордж. Юк, зинһар, аны бу эшкә кыстырмыйк! Үтенеп сорыйм, мистер Уилли...
Детектив *(аңына килә башлап, торырга азапланып).* Уилли?! Ричард Уилли?!

Джордж аның муен тамырына суга. Детектив аңын югалта. Ричард Джорджны шкафка этә. Ишек шакыйлар.

Ричард. Сестра Фостерга нишләргә кирәклеген аңлатыгыз.
Джордж. Сезгә мин генә аз идем. Хәзер аның тормышын харап итәсегез киләме?

Ишекне ныграк шакый башлыйлар.

Ричард. Тиз, тиз бул! Шкафка!

Ярым аңгырайган Глэдис янына шкафка Джорджны төртеп кертә дә ишеген яба.

Ричард. Кем бар анда?
Официант. Сезнең шәхси официантыгыз!

Ишекне ача, Официант керә.

Официант. Мин, бушау белән, кичекмәстән бирегә кердем.
Ричард. Ә сезне беркем дә чакырмады.
Официант. Ә сезгә, случайно, миссис Айви Пигден кирәкмиме?
Ричард. Ә сез каян белдегез?
Официант. Тыңлап тордым. Күзегезне йомыгыз! *(Кычкырып.)* Мария, керегез!

Горничная керә, аның өстендә ак күлмәк, шляпа һәм фата.

Ричард. *(Официантка).* Кем бу?

Официант. Кыскасы, сезнең Горничнаягыз. Ә хәзер, Айви Пигден.

Горничная елмая. Ричард куркып шкафка карый. Йокы бүлмәсеннән киенеп Памело чыга.

Памело. Йә, Джордж, сез таптыгызмы үзегезнең... Ричард? Син һаман да бирелә?

Ричард. Мин сезне көтәргә булдым, сөеклем. *(Читкә алып китә. Официантка Горничнаяны алып китәргә ымлап.)*

Памело. Айви белән танышмыйча мин беркая да китмим дип сезгә әйттем бит.

Официант. Ә сез әйтәсез... *(Горничнаяны алга этә.)*

Ричард *(Официант һәм Памелога тетрәнеп карап).* Таныш бул алайса. Менә ул Айви!

Памело башта Горничнаяга, аннары Ричардка карый.

Ричард *(теш арасыннан сытып).* Чибәр түгел дип мин бит сезгә әйттем.

Памело. Ричард! *(Айвига.)* Бик күркәм.

Ричард. Менә барысы да булды. Сез аның белән танышып та өлгердегез.

Шкафтан Джордж белән Глэдис чыгалар.

Джордж. Миссис Уилли! Таныш булыгыз, бу Айви.

Озак паузадан соң Джордж Горничнаяга карый. Тегесе, елмаеп, Джорджның кулыннан ала.

Глэдис. Джордж, кем бу?

Джордж *(Ричардка карап).* Әлегә белмим!

Памело. Гафу итегез, ә сез үзегез кем буласыз?

Глэдис. Мин сестра Фостер!

Памело. Сестра Фостер?

Ричард. Аңламыйсыңмы, сөеклем, язылышканда кәләшнең шаһиты юк иде. Карыйбыз: биредә сестра. Моның әһәмияте юк. Иң мөһиме — син Айви белән таныштың!

Памело *(Горничнаяга).* Айви, әйтегез әле, сез чамадан тыш бәхетледер?

Горничная сораулы караш белән Официантка карый.

Официант. Ул инглиз телендә сөйләшми.

Джордж белән Ричард күзләрен йомалар.

Памело. Инглизчә сөйләшми.

Ричард. Сөеклем, хикмәт шунда ки, ул... итальянка.

Официант. Китаянка.

Ричард *(аңа карап).* Ә мин нәрсә дим. Яртылаш итальянка, ә яртылаш китаянка.

Памело *(Джорджка).* Менә ничек! Кызык. Ә каян сез аны эзләп таптыгыз?

Джордж *(кирәгеннән артык горурланып, ясалма).* Бассейннан!

Ричард. Ул Венециядән. Сусыз торалмый.

Джордж. Айви! Сине Официант бай-бай итәргә озата.

Горничная. С-с-с-сез-не-нең по-о-о-с-с-тель-лә-ә-ә-ре-е-гез а-а-а-алыш-ты-ы-ы-ыр-ыр-ыр-га-а-а-мы?

Управляющий керә.

Управляющий. Гафу итегез, комачауладым. Үзем дә белмим, ни өчен. Әгәр бер минут эчендә номерны бушатмасагыз, сез кулга алыначаксыз. *(Официантка.)* Джек! Ни өчен мин сезне һәрвакыт биредә күрәм?

Официант. Чөнки сезгә һәрвакыт җае чыгып тора, сэр.

Управляющий *(Горничнаяга).* Мария! Ә сез нигә биредә?

Горничная. По-си-ти-ра-ти пось-терь.

Памело. Мария?.. *(Ричардка.)* Сез бит аны Айви дидегез!..

Ричард. Әлбәттә, Айви. Айви Мария.

Барысы да Ричардка карыйлар. Управляющий Горничнаяның кулыннан эләктереп ала да ишектән өстерәп алып чыгып китә.

Памело. Ричард, Управляющий Джорджның кәләшен өстерәп кая алып китте?

Ричард *(авыр сулап).* Борынгы Рим гадәтләре буенча ул шулай эшләнергә тиеш.

Официант Джордж янына килә дә аңа карый. Джордж тыныч кына чалбарының кесәсен чыгара.

Официант. Әҗәтле булып каласыз.

Официант китә. Глэдис белән Джордж бер-берсенә карыйлар.

Глэдис *(Джорджка).* Бу хакта сезнең апагызга ни дип әйтергә дә белмим.
Джордж. Әйтегез, мин шундый кызны очраттым, дип, хәтта мин аңа өйләнергә дә җөрьәт итмәкче булам.
Глэдис *(салкын тон белән).* Чыннан дамы?
Джордж. Чыннан да.
Глэдис. Ә кем соң ул, сорарга мөмкинме?
Джордж. Сез!
Глэдис. Мин?!
Джордж. Сез бүген искиткеч идегез. *(Кулын үз кулына ала.)*
Глэдис *(дулкынланып).* Сез шулай уйлыйсызмы? Мистер Пигден!
Джордж. Сез искиткеч хатын!
Глэдис. Ах, Джордж! Ә сез... Сез дә искиткеч!
Джордж. Чынлапмы?
Ричард. Үбегез инде үзен, җен алгыры! *(Джорджны Глэдисның кочагына этә.)*

Джордж Глэдисны култыклап алып чыкмакчы була. Ишек төбендә Глэдисның сөлгесе төшеп китә. Арт ягы бер мәлгә ачылып китә. Джордж һәм Глэдис бер-берсенә карап аны сизми калалар һәм чыгып китәләр.

Ричард *(алар артыннан карап).* Каһәр, бу минем исемә төшерде...
Памело. Нәрсә?
Ричард. Мине көткән премьерның чыраен хәтерләтте.

Ричард Памелоны кулыннан эләктереп ала да, алар ашыгып-кабаланып чыгып китәләр.

Пәрдә.

# БУЛМАС ДИМӘ, ДӨНЬЯ БУ

*Ике пәрдәлек комедия*

КАТНАШАЛАР:

Сәйфиеч.
Наилә.
Җәмил.
Ана.
Ата.
Эльмира.

Җыйнак кына ике бүлмәле фатир. Ваннадан су аккан тавыш ишетелеп тора. Наилә кәгазьләр актара. Телефон шылтырый.

Наилә *(трубканы ала)*. Әйе, тыңлыйм. *(Шатланып.)* О-о, Дамир! Сәлам, энем. Йә, сөйлә. Ничек хезмәт итәсең? Нәрсә? Медаль алдың?! Кайчан? Шушы көннәрдә. Хәрби өйрәнүләрдә дустымны коткардым дисеңме?! Молодец! Молодец димен. Булдыргансың. Настоящий чын солдат! Нәрсә? Ничек шылтыратты? Әле мин кайтып кына кердем. Юк ла, әнидә булмадым, төрмәдә дә түгел. Командировкада буталып йөрдем. Ә мамуляга соңыннан, соңрак барам. Аның бит әле анда елга якын утырасы бар. *(Тирән сулап.)* Үзең ничек соң дип... *(Ванна ишегенә күз төшереп алгач, пышылдап.)* Ничек дип әйтергә. Дөресен генә әйткәндә, мин хәзер бер кеше белән яшим. Син инде хәзер җиткән егет, синнән боларны яшерү урынсыз. Исеме ничек дисеңме? Җәмил. Әйе. Без аның белән чынлап. Нәрсә? Аңа әни турында?.. Син нәрсә инде, Дамир! Авызыма су каптым. Әни турында ләм-мим. Ярый, пока. *(Ишектә звонок шылтырый.)* Пока, энем, пока. Ишеккә кемдер килде. Әни янына барып кайткач, мин, аның хәлен аңлатып, сиңа хат язып салырмын әле. Әлегә пока. Үбәм үзеңне. *(Трубканы куя.)*

Тагын звонок шылтырый. Наилә ишеккә китеп югала. Ваннадан Җәмил чыга да диванга җәелеп утыра. Наилә керә.

Җәмил. Нәрсә, Нинуль, кем анда? Кем килгән?
Наилә. Милиция, участковый.
Җәмил. Милиция?! Надеюсь, безнең арттан килмәгәндер бит.
Наилә. Безнең районда ниндидер ике аферист-мошенник барлыкка килгән, ди.
Җәмил. Ничек икәү?.. Димәк, безнең белән дүрт була.
Наилә *(көлеп).* Участковыйның әйтүенчә, карт-коры, әби-чәбиләрне, пенсионерларны төп башына утырталар, ди. Үзләрен райсобестан дип әйтәләр, ди. Янәсе, арзан гына бәягә дару тараталар һәм шул ук вакытта теге бичараларны сиздермичә генә таларга да өлгерәләр, ди.
Җәмил. Кабахәтләр.
Наилә. Менә шуның өчен участковый фатир саен кереп сорашып йөри. Кем булырга мөмкин. Янәсе, берәрегез күрмәдеме, ишетмәдеме?
Җәмил. Кирәк бит, ә? Тирә-якны аферистлар, жуликлар әйләндереп алды, хәтта куркыныч. *(Пауза.)* Кара әле, бәлки, кичен киногә йә булмаса театрга барырбыз. Ни генә әйтсәң дә, бүген бит ял көне. Йә, нишлибез? *(Наилә дәшми.)* Нигә эндәшмисең?
Наилә. Театрга?! Синең белән?.. Кайсы театрга? Һәм синең кемең булып? *(Пауза.)*
Җәмил *(йомшак кына).* Ну, Нинуля, син үзең дә бик яхшы аңлыйсың. Мин инде ике хатын аерган кеше, көтүе белән балаларым бар, алиментан башым чыкмый. Нигә инде миңа тагын камыт кияргә. *(Пауза.)* Дөрес, син миңа ошыйсың. Бик тә ошыйсың. Үзең беләсең, миңа озакламый илле тула. Ә инде бу яшьтә өченче тапкыр өйләнү бик җиңелдән түгел.
Наилә. Мин аңлыйм... Ә син? Син минем хәлне аңлыйсыңмы? Синең белән ярты ел яшәгәнебезне бөтенесе дә белә шикелле. Синең һәм минем яшьтәшләр, дус-ишләр, күршеләр турында әйтеп тә торасы юк. Алайса әйт. Мин аларның күзләренә ничек карарга тиеш?
Җәмил. Ә нәрсә булган? Күпләр шулай яши. Күпләр гражданский брак белән торалар.
Наилә. Җәмил... Әйдә күзгә-күз карап бер-беребезгә дөресен генә сөйлик әле. Син шәп кеше. Үзең юмарт, гадел, өстәвенә тәртипле. Дөрес, мин синең белән язылышмый гына күп еллар, бик күп еллар яшәр идем, әгәр миңа хәзер бары тик унсигез генә яшь булса.
Җәмил. Әлбәттә, син хаклы. Әйе, уйламаганда-көтмәгәндә башыма халкымның бер әйтеме исемә төште.
Наилә. Сөйләп кара.
Җәмил. Хатын-кызның кем икәнен беләсең килсә, анасына карап, кызын коч, дигәннәр.
Наилә. Сафсата.
Җәмил. Ә бу дөрес. Мин моңа ышанам. Ике аерган хатыным белән исбатлый алам. Менә шушыңа ук охшаш икенче әйтем. Алма агачыннан ерак төшми. Кыскасы, иң элек мин синең әниең белән танышасым килә.
Наилә. Минем әни белән?..
Җәмил. Әйе, бер генә тапкыр булса да әниеңне күрәсе иде. Синең бит миңа аның турында бер генә тапкыр да сөйләгәнең юк. Хәтта сурәтен дә күргәнем юк. Әгәр дә синең әниең миңа ошаса... *(Наиләнең битеннән үбеп ала.)* Нигә әле хыялны тормышка ашырмаска.
Наилә. Но... но... Анысы шулай... Минем бит әти-әнием еракта яшиләр.
Җәмил. Ничек?! Хәтерем ялгышмаса, әйтүеңә караганда син яшәгән шәһәргә поезд белән бер тәүлек юл. Шул да булдымы ерак. Кыскасы, җыеныйк та вакыт табып үзләренә кайтып төшик.
Наилә *(ашыгып).* Кирәкми.
Җәмил. Нигә?
Наилә. Беләсеңме... Соңгы вакытларда әни үзен начар хис итә. Ничектер мин аңа шылтыраткан идем, ә ул...
Җәмил. Авырый?
Наилә. Әйе.
Җәмил. Яхшы, терелгәнен көтәбез. Терелгәч кайтабыз. Ә хәзер магазинга чыгып керәбез. Ашарга нәрсә дә булса алырга кирәк. Әниеңнең сәламәтлеге өчен тамак төбен дә чылатып алу зыян итмәс. Йә, син минем фикергә кушыласыңмы?
Наилә. Үзең генә чыгып кер, ә мин кәгазьләремне рәткә салыйм.
Җәмил. Зарар юк.
Наилә. Җылырак киен. Ваннадан гына чыктың.
Җәмил. Бу сүзләрдән соң булачак тещамның ягымлы һәм кайгыртучан авазын күңелемдә тоям. Нәрсә турында уйлаганымны әйтимме?
Наилә. Ну?
Җәмил. Бала чакта яратып ашаган әйбереңне алыйммы?
Наилә. Ялагай.
Җәмил. Әйтсәгезче, туташ, нәрсә инде ул сез сабый чакта яратып ашаган әйбер?
Наилә.. Ялагайланма, хәйләкәр. Нәрсә теләсәң, шуны ал.

Җәмил. О’кей!

Җәмил чыгып китә. Наилә утырган җиреннән тирән уйга бата. Бераздан айнып, телефон номерлары язылган блокнотны ачып номер җыя.

Наилә. Исәнмесез... Роза Михайловнаны мөмкинме?! Нәрсә? Авырый. Больницада? Ә-ә... Ярый, борчыганым өчен гафу итегез. Үзенә сәлам әйтегез. Кемнән дисезме? Наиләдән. Кайчандыр без аның белән бер теплоходта ял иткән идек. Исән булыгыз. *(Тагын номер җыя.)* Так... Хәерле көн. Гафу итегез, мин Полина Алексеевна белән сөйләшә аламмы? Нәрсә? Ничек? Ничек үлде? Күптәнме? Бер ай элек? Йөрәк? Ярый, гафу итегез, хушыгыз... *(Трубканы куя.)* Да-а, гомерләр үтә. Кемгә шылтыратырга? Ә-ә, менә. Валентина Сергеевна? Исәнмесез. Танымыйсыз? Мин бу — Наилә. Ничек инде танымыйсыз?! Мин сезнең коляскадагы оныкларыгызны скверда карап торган идем. Соңыннан сезнең белән кафеда утырдык. Телефон номерларын алыштык. Кайчан дисезме? Яз көне. Исегезгә төшердегезме? Ниһаять. Рәхмәт. Йә, сөйләгез. Сәламәтлегегез ничек? Авырмыйсызмы? Оныкларыгыз ничек? Минемме? Барысы да тәртиптә. Әйе, ни өчен шылтыратаммы... Минем сезгә үтенечем бар иде, Валентина Сергеевна. Ничек дип әйтергә. Кыскасы, өч мең сум акча эшләргә теләгегез юкмы? Дөресен генә әйткәндә, бер генә көнгә сез минем әнием булалмассызмы?.. Бер ялгансыз. Әлбәттә, вакытлыча. Нигә үпкәләргә инде, Валентина Сергеевна, нигә үпкәләргә. Беләм, бик яхшы аңлыйм, сезнең артистка түгеллегегезне белеп шылтыраттым. *(Трубканы куя да, тирән сулап, блокнотын кабат актара башлый. Блокнотын актарып бетергәч, ертып-ертып ташлый... уртәлеп чөеп җибәрә.)* Берәү дә! Беркем дә! *(Звонок шылтырый.)* Җәмил, синме? Нәрсә дә булса оныттыңмы?

Ишекне ача. Бүлмәгә, зур сумка күтәреп, Сәйфиеч һәм Эльмира килеп керә. Сәйфиеч хатын-кыз киеменнән.

Наилә. Гафу итегез, сезгә кем кирәк?

Эльмира *(кыю итеп)*. Арзан бәядән электр приборлары сатабыз. Үтүкләр, фильтрлар, кофеваркылар.

Наилә *(ышанып бетмичә)*. Димәк, үтүкләр дисез? Чынлыкта, безгә үтүк кирәк. Алар күпме тора?

Сәйфиеч. Сезнең өчен, алтынным, почти бушлай!

Наилә. Ну шуны белегез. Мин башта тикшереп карыйм. Ә бәлки, ул сезнең эшләми торгандыр. Ышан сезгә. Янган үтүк төртерсез.

Сәйфиеч. Безме?! Безне нигә рәнҗетәсең, көмешем? *(Сумкасыннан берничә коробка чыгара.)* Менә. Менә йөрәгемнән өзеп алып бирәм. Сайла!

Наилә. Яхшы, менә монысын.

Сәйфиеч. Ай шома, ай булган. Кирәк бит, иң яхшысын сайлады. Үземә калдырмакчы идем. Димәк, а-ча-быз... Коробкасыннан чы-га-ра-быз.

Наилә. Искитмәле. Күпме сорыйсыз инде? *(Эльмираның юкка чыкканын сизеп, сискәнеп китә.)* Әй, ханым! Сез кая?

Сәйфиеч. Ай, нигә кычкырасыз? Хәзер су эчәргә дә ярамыймыни. Әллә суыгызны да җәллисезме?

Наилә *(кычкырып)*. Әйе! Сез кая?

Эльмира. Минме? Бередә мин, бередә...

Наилә. Кая кереп югалдыгыз?

Эльмира. Сусаган идем. Эчәсем килгән иде.

Наилә *(шикләнеп)*. Димәк, сез үтүкләр сату белән шөгыльләнәсез. Ә сезнең документларыгыз бармы соң?

Эльмира. Товаргамы?

Наилә. Әйе, әйе.

Сәйфиеч. Ә бу нәрсә, алтыным? *(Коробкага төртеп күрсәтә.)* Мондый товар өчен моннан да зур документ юк.

Наилә. Та-ак. Димәк, юк. Аңлашылды. Милициягә шылтыратам.

Сәйфиеч. Милициягә? Нигә?.. Ни өчен, алтыннан коелганкаем.

Наилә. Шулай. Ходай саклангнны саклармын дигән.

Сәйфиеч. Яхшы. Менә сиңа документ. Истәлек өчен. *(Үтүкне суза.)* Укы. Ә без...

Наилә. Стоять! Үрә кат! Алай-болай сез түгелдер бит картларны талаучылар.

Сәйфиеч. Без?! Картларны?!

Эльмира. Нинди картларны?

Наилә. Үрә кат! Стоять! (*Күлмәгеннән тота.)*

Сәйфиеч. Нигә ябыштың? Җибәр, дура. *(Көч белән этеп җибәрә.)*

Наилә *(гаҗәпләнеп)*. Сез нәрсә... Әллә ир кеше инде? *(Игътибар белән карап.)* Чынлап та ир кеше... Кирәк бит, ә... *(Эльмирага.)* Ну, ә сез, сез-то соң хет хатын-кызмы?

Сәйфиеч *(ашыгып)*. Бернәрсә хәтерләми. Фамилиясен дә, үзенең исемен дә, җенси ягын да һәм шул ук вакытта яшен дә.

Наилә *(Сәйфиечкә)*. Карагыз әле... Сезнең бер көндә өч мең акча эшлисегез килмиме?

Сәйфиеч. Бер көндә?! Ничек?

Наилә. Ну, әйтик... Әйтик, сез минем әни булып уйный алмассызмы?

Сәйфиеч *(аптырап)*. Кем, кем булып дисез?

Наилә. Минем әни булып.

Сәйфиеч. Тудырган әниең булып өч мең сум өчен.

Эльмира. Телисезме, ике меңгә уйныйм.

Сәйфиеч *(Эльмирага)*. Күземнән югал, бездарь! Өч тиенлек артистка аламасы. Күрмисеңмени, абзаңа контракт тәкъдим итәләр.

Эльмира *(Сәйфиечкә)*. Нинди ана буласың инде син, карт алаша. *(Наиләгә.)* Сеңлем, мине анаң ит.

Наилә *(шикләнеп)*. Сезнеме? Сез яшьрәк шул әле.

Эльмира. Минме?!

Наилә. Әйе, минем әни өчен. *(Сәйфиечка.)* Ә менә сез... Сез туры килер идегез.

Сәйфиеч. Дочь моя! *(Маңгаеннан үбеп. Кызым минем.)* Анаң белде, белде синең аны беркайчан да сатмаячагыңны. Кызыкаем минем, балакаем, әйт, зинһар, карт, авыру, синең тарафтан өзелеп яратылган анаңа, барлы-юклы дүрт меңең хәер генә түгелме?

Наилә. Өч, өч мең, әнекәччәем!

Сәйфиеч. Нишлим? *(Күз яше белән.)* Тала, тала үзеңне тудырган анаңны!

Наилә. Әйтегез әле, ни өчен бу уен-маскарад? Үтүк сатыр өчен нигә хатын-кыз булып киенергә?

Сәйфиеч. Аңла, балакаем, хатын-кызны фатирга җиңел кертәләр.

Наилә. Аңлашылды.

Сәйфиеч. Мәсьәләгә якынрак килик. Сөйләп, аңлатып кара. Йә, кемне чишендерергә тиеш була инде сиңа күкрәк сөтен имдереп үстергән, синең газиз, бердәнбер анаң?

Наилә. Минем белән бер түбә астында яшәргә, бер юрган астында ир белән хатын булып яшәргә теләмәгән бәндәне.

Сәйфиеч. Надо же!

Наилә. Сез инде аңа ошарга тырышыгыз.

Сәйфиеч. Кияүгә чыгарга телисез. Аңлашыла. Ә сезне дөньяга тудырган анагыз белән нәрсә булды? Аңлавымча *(тамак төбенә чиртеп)*, хотя моның бу операциягә бернинди дә әһәмияте юк. Нишлисең ведь. Кайчандыр мин налог инспекторы булган идем. Президентның ышанычлы кешесе дә булу бәхетенә ирештем. Гаишник булдым, чекист турында сөйләп тә тормыйм. Аксак-туксакларны һәр урам чатында уйнарга туры килде, хәтта Вьетнам сугышында һәлак булган, то есть ветеран булган, Голландия биеклеген яулаган солдат ролен дә яхшы башкардым. Ә менә ана роле, теща роле кызык, минем өчен яңалык.

Наилә. Озакламый Җәмил кайтачак. Әйдәгез, кайда да булса кичен очрашыйк. Мин сезгә шунда барысын да, барысын да төкми-чәчми, әнәсеннән алып җебенә кадәр аңлатырмын. Үзе кайтып кермәгәе. *(Тәрәзә янына китә.)*

Эльмира *(пышылдап)*. Чыгып киткәнче өстәл тартмасына күз төшерергә онытма, кесәсенә кереп чыксаң да әйбәт булыр.

Сәйфиеч. Юк, юк, ул әүлия. Ул әүлия. Шуның өстәвенә, хөрмәтле Эльмирочка, миндә искитмәле план туды.

Эльмира. План?! Нинди?

Наилә *(сагая төшеп)*. Ул подъездга керде. *(Сәйфиечкә.)* Кичке алтыда кафеда очрашырбыз. Ә хәзер баскыч буйлап өскә, икенче этажга. Ул сизенергә тиеш түгел. Өскә! Тиз булыгыз, өскә!

Сәйфиеч белән Эльмира тиз генә менәләр. Кинәт ашыга-ашыга Сәйфиеч керә.

Сәйфиеч. Сумкам, сумкам калган!

Ашыга-кабалана тиз-тиз сумкага үтүкләрне, коробкаларны тутыра да ишек катына атлый. Җәмил пәйда була.

Җәмил. Нинуля, ни өчен безнең ишек ачык? *(Пауза.)*

Наилә. Җәмил!.. Беләсеңме безгә кем килде?

Җәмил. Кызганычка каршы, белмим шул.

Наилә. М... м... ми-нем әни!

Җәмил. Бик яхшы булган. Әле генә без Наилә белән сезне искә алган идек.

Сәйфиеч. Кара инде моны, әйтерсең лә шатлыктан телен йоткан. Анаңның исемен онытмадыңмы әле?

Наилә. Га-а-лия.

Сәйфиеч. Молодец! Кара моны, анасының исемен онытмаган.

Наилә. Ничек инде... Әни ләбаса.

Сәйфиеч. Ничек инде, ничек инде... Ә дустыңны, ягъни мәсәлән яшь иптәшне, минем белән кем, Пушкин таныштырамы?

Җәмил. Гафу итегез, мин Җәмил булам.

Сәйфиеч. Шулай дисезме? Ә минем Наиләмнең особый вкус. Яхшы яклары үземә, начар яклары атасына охшаган. Әйт әле, аңгырам, хет атаңның исемен хәтерлисеңме?

Наилә. Әтиемнең? Ә-ә, ул... Вахит.

Сәйфиеч. Кара син моны, монысын да хәтерли.

Наилә. Нишләп инде әни?! Һәр көнне мин кайчандыр үзем яшәгән Әлмәтемне дә, сине дә, әтине дә, армия хезмәтендәге энем Дамирны да сагынмый калган көнем юк.

Сәйфиеч. Сагынмый гына кара. Анаң дип тормам, хайван, менә шушы анаңның йомшак куллары үзеңне буып үтерәчәк.

Наилә. Ярый инде, әни.

Җәмил. Сәламәтлегегез ничек?

Сәйфиеч. Сәламәтлекме? Сәламәтлек — ашауга карап.

Наилә. Әйе шул, мин Җәмилгә синең бераз гына сырхаулап торганыңны әйткән идем. Ә хәзер күрәм, син терелгәнсең.

Сәйфиеч. Сыер икәнсең, өстенә бастың.

Наилә *(Җәмилгә)*. Ә нигә син шулай бик тиз кайттың. Күрәм, үзең бер әйбер дә алмагансың.

Җәмил. Аңлыйсыңмы, универсамга барсам — анда санитарный көн икән. Икенче кибеткә киттем — анда ревизия. Өченче кибеткә җиттем. Әйберләрне алып кассага гына җиткән идем, акчамны өйдә калдырган булып чыктым. Бүген миңа гел кире килеп тора. Сукыр тычкан юлга чыкса, тез биеклеге кар ява дигәндәй... *(Көлә.)* Галия ханым, бу сезнең сумкагызмы?

Сәйфиеч *(бераз паузадан соң)*. Ну...

Җәмил. Күрәм, сумкаң зур. Кызыңа гөмбә, варенье, тозлы-мозлы күчтәнәчләр алып килгәнсеңдер инде.

Сәйфиеч. Ну...

Җәмил. Кайчандыр миңа да әнием профтехучилищега — СПТУга җиләкләр, гөмбәләр, алма, маринованный кыярлар-помидорлар алып килә иде. Әкияттәге кебек хәтердә генә уелып калдылар. Йә, кая илтим боларны? Туп-туры кухнягамы?

Наилә. Ну...

Җәмил *(сумканы күтәрә)*. Кара син моның авырлыгын. Озын кыш буе ашарлык гөмбәләр төягәнсез, ахры. *(Сумканың эченә күз төшерә.)* Нәрсәләр монда? Монда бит коробка да коробка. Коробка белән баскан, коробка белән изгән.

Сәйфиеч. Кая, кая, нинди коробкалар күрәсең син анда. Чукынды марҗа калачы. Кеше сумкасын алганмын.

Наилә. Кайда?

Сәйфиеч *(аптырап)*. Кайда... Кайда?

Җәмил. Поезддамы?

Сәйфиеч *(тамашачыга пышылдап)*. Үзе алдашырга мәҗбүр итә, үзе. Минем гаебем юк. *(Җәмилгә.)* Әйе, поездда. Янәшәмдә бер исерек баш барган иде, күрәсең, ялгышып минем сумкамны эләктергәндер. Ә шулай да мин кызыма әйбәт очып килеп җиттем. Ну... Ну-ка, нәрсәләр икән бу сумкада. Үтүк рәсемнәре төшерелгән. Ә менә монысы нәрсә?

Җәмил. Су фильтры. Ә менә монысы кофеварка. Бу — ниндидер вак сәүдәгәр сумкасы.

Наилә. Ә хәзер, Җәмил, бәлки, кибеткә чыгып керерсең. Әнине сыйларга кирәктер ведь.

Сәйфиеч. Чыгармыйм! Безгә Җәмилчик белән сөйләшеп алырга кирәк. Күрәсең, күпме күрешмәдек!

Җәмил. Кызык. Сөйләшергә?! Сезнең белән? Нәрсә турында?

Сәйфиеч. Нәрсә турында! Синең хакта, әлбәттә. Синең хакта, җуләрем. Башка нәрсә турында сүз булырга мөмкин, Алла колы. Мин бит иртәгә таң белән кирегә очам.

Җәмил. Нигә бик тиз?

Сәйфиеч. Шулай, Җәмилчик, ачык авызчик, шулай. Мине кызым янына бер генә көнгә җибәрделәр.

Җәмил. Кара әле, алтыным минем. Галия ханым белән безгә кофе гына кайнатырга куймассыңмы? Ә без ул арада сөйләшеп-аңлашып, бер-беребезне якынрак белербез.

Наилә. Телисең икән, рәхим ит. Әнкәй, әгәр дә сиңа минем ниндидер ярдәм кирәк булса, мин биредә, янында гына. Әйткәләп торырмын.

Сәйфиеч *(ялагайлы кыяфәт ясап)*. Сөйкемле сөягем син минем. Әйт әле, Җәмил, минем сүземдә хаклык бармы? Чынлап та, әүлия, хур кызы, оҗмах кошы ведь!

Җәмил. Сөйлисе юк.

Сәйфиеч. Ә менә мин шушы тутый кошка кайчандыр менә шушы күкрәкләремнән сөт имездем. *(Наилә чыгып китә.)* Сезнең фатирмы?

Җәмил. Юк, снимаем.

Сәйфиеч. Күркәм, пөхтә фатир.

Җәмил. Бөтенесенә дә Наилә өлгерә.

Сәйфиеч. Суйган да куйган үзем. Сабый чактан ук пөхтә-чиста иде. Үз почмагын һәр вакыт җыештырып, ялтыратып куяр иде. Курчакларына кадәр киендерелгән, юындырылган, ашатылган булыр иде.

Җәмил. Ашатылган? Курчаклар?

Сәйфиеч. Кыскасы, ачтан авыз күтәреп балавыз сыкмыйлар иде.

Җәмил. Кызык...

Сәйфиеч *(аңына килеп)*. Кызык түгел, яшь иптәш, кызганыч. Юмор аңламавыгыз кызганыч. Йә, үзегез кайда хәрәкәт итәсез? Кайда эшлисез? Ничек көн күрәсез?

Җәмил. Ничек дип аңлатыйм?! Кечкенә бер фирмада сигез мужик, өч хатын-кыз эшлибез. Лоджия-балконнарга тәрәзәләр куябыз. Ишекләрне ныгытабыз, яңаларны да куйгалыйбыз. Агачын да, кирәк булса тимерен дә. Йозак, күгән, тотка һәм башкалар.

Сәйфиеч. Хәтерем алдамаса, Наилә сезнең белән түгел иде бугай.

Җәмил. Юк. Ул бит бүтән эштә. Бухгалтер.

Сәйфиеч. Сез әле үз эшегезнең хуҗасы, начальнигыдыр?..

Җәмил. Урынбасар. Ә шулай да кулым белән дә бүтәннәрдән ким эшләмим. Дөресен генә әйткәндә, мин ул эшне яратам. Мин үзем дә бит әллә кем түгел, түбәннән күтәрелгән.

Сәйфиеч. Димәк, ипи-тозга җитә дисең инде.

Җәмил. Майлык та кала.

Сәйфиеч. Ә менә безгә, картларга?..

Җәмил. Аңлыйм. Элеккеге пенсия пенсия түгел, элек соң...

Сәйфиеч. Анысы чукынып китсен. Картайгач, сәламәтлек, сәламәтлек бетә, Җәмил.

Җәмил. Шулай шул.

Сәйфиеч. Белмим, бу хакта сиңа әйтеп тору урынлы булырмы, юкмы?..

Җәмил. Нәрсә хакында?

Сәйфиеч. Нәрсә хакында дип? *(Кухня ишегенә күз төшереп алгач, пышылдап.)* Мин синнән яшерә алмыйм инде, ачыктан-ачык әйтәм!

Җәмил. Әлбәттә, әлбәттә, шулай.

Сәйфиеч. Син, зинһар, Наиләгә бу хакта ләм-мим.

Җәмил. Аңладым.

Сәйфиеч *(пышылдап)*. Менә нәрсә. *(Тагын кухня ишегенә күз төшереп ала.)* Акча эзлим. Нелечканың атасы Вахитка операциягә.

Җәмил. Менә нәрсә...

Сәйфиеч *(елап)*. Наиләдән яшерәм. Нигә аның йөрәген бозарга.

Җәмил. Ә нәрсә булган аның белән?

Сәйфиеч. Ничек дип әйтим... Ну... Ну! *(Үз корсагына күрсәтеп.)* Аңа операция кирәк. Срочно, тиз арада. Юкса... *(Кулъяулыгын алып күзен сөртә.)*

Җәмил. Аңлашылды... Аңлашылды, күпме сорыйлар инде?

Сәйфиеч *(кухня ишегенә күз төшереп алгач, пышылдап)*. Биш мең!

Җәмил *(пышылдап)*. Биш мең?..

Сәйфиеч. Евро!

Җәмил *(сызгырып куя)*. Да...

Сәйфиеч. Тише! Су кап! Барысын да берьюлы түгел, бүлеп-бүлеп. Менә хәзер аңлашылдымы, мин ни өчен бирегә килдем.

Җәмил. Аңлашылды кебек.

Сәйфиеч. Көтмәгәндә Нелечканың берүзе генә булмавы хакында ишетеп белдем дә, тукта әле, мин әйтәм, Наилә акылсыз бала түгел, үзенә тиң акыллы, булган егет сайлагандыр дип уйлап... Аңлыйм. Җәмил, синдә андый ук акча булмавын да аңлыйм. Әмма ләкин, йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын, дигәннәр.

Җәмил *(икеләнеп)*. Дөресен генә әйткәндә, минем үземә дә авылдан чыгып китеп бирегә — шәһәрдә эшләвемә дүртенче ел гына. Белмим шул.

Сәйфиеч. Әй, хөрмәтлем! Җәмилкәем! Нәрсә дә булса уйлап тап. Кайчан да булса без сиңа ул акчаны акрынлап өлешләп кайтарырбыз. Телисеңме, мин сиңа расписка язам. Каным белән. Шаярам. Биш минуттан киявем буласы кешене алдарга җыену, үзең беләсең, минем тарафтан ахмаклык булыр иде. Нигәдер син телсез калдың, Җәмил?

Җәмил *(уйчан)*. Уйлыйм. Беләсезме, бар минем бер кешем, бар. Минем ике туганнан туган абыем. Беләсезме ул кайда эшли? Ул... ул солидный гына бер банкта эшли. Әгәр дә шуңа мөрәҗәгать итеп карасам...

Сәйфиеч. Җәмил! Син бит әүлия! Син бит акыл! Син бит үзең дә белмәгән, мин генә белә торган... Беләсеңме син кем?! Син... *(Тамашачыга карап.)* Дивана!

Җәмил. Рәхмәт! *(Башын ия.)* Рәхмәт! *(Телефоннан номер җыя.)* Алло, алло! Сәлам, Госман. Хәлләр ничек? Эшләрегез ничек бара? Банкаңда «яшел»ләрне күпме тозларга өлгердең? Ха-ха-ха... Әлбәттә, сүз пыяла банка турында бара. Госман, шаяруларны читкә куеп тор, минем сиңа бик җитди бер үтенечем бар иде. Миңа әҗәткә акча кирәк. Срочно, операциягә. Биш мең! Биш мең евро. Дөрес, бәләкәй акча түгел. Әмма ләкин операция ясатасы кеше дә минем өчен бәләкәй кеше түгел. Син аны беләсең. Мин сине аның белән урамда таныштырган идем. Хәтерлисеңме? Аның исеме — Наилә. Менә шуның этисенә операция ясатырга кирәк. Син нәрсә инде, Госман. Алар минем өчен иң изге, иң ышанычлы кешеләр. Әйе... әйе, срочно.

Сәйфиеч. Хәзер үк булса иде.

Җәмил. Мөмкин булса, хәзер үк. Нәрсә?! Кулыгызда андый сумма юк. Госман, үтенеп сорыйм, агай-эне... Аңлыйсыңмы, эш шунда ки, эш үлем белән яшәү арасында. Нәрсә?! Рәхмәт! Рәхмәт, туганым! Рәхмәт, Госман. Хәзер үкме? Йөгерәбез. Шунда сине Наиләнең анасы Галия ханым белән дә таныштырырмын. Пока. *(Трубканы куя. Сәйфиечкә.)* Очтык. Пока Госман кире уйлаганчы.

Наилә чыга.

Наилә. Кофе булды.

Җәмил. Наилә, соңыннан, без ашыгабыз.

Наилә. Ничек? Кая?

Сәйфиеч. Кызлар янына.

Наилә. Шаяруың шаяру төсле түгел, әнкәй.

Сәйфиеч. Эш көтә, кызым, эш!

Ашыгып чыгып китәләр. Наилә тәрәзәдән карый.

Наилә. Кая ашыктылар алар?! Әһә, машина тоталар. Монысы туктамады. Икенчесе дә туктамады. Өченчесенә утыралар. Кызык. Кая киттеләр икән? Җүләр мин. Нигә кирәк иде миңа бу жуликлар белән бәйләнергә?

Ишектә Ана белән Ата пәйда булалар.

Ана. Монда ачык! *(Ата кешегә.)* Ә син өскә дә өскә... Тиктомалга өскә алып менде. Ни хәлләрдә, кызым? Исән-сау торасыңмы?

Наилә *(дулкынланып)*. Сине... Сине чыгардылар?

Ата. Юк, качты! Ха-ха-ха!

Ана. Амнистия, президент кул куйган.

Ата. «А» да түгел, «Б» да түгел, анасының чыкканына рад та түгел!

Наилә. Син нәрсә инде! Ничек шатланмыйм. *(Икесен дә үбә. Анасына.)* Әйбәт саклангансың.

Ата. Ә син ничек уйладың. Диета, прогулка, свежий һава, өстәвенә режим!

Наилә. Әти!

Ана. Безнең өйгә кайтып барыш. Юл уңаенда сиңа кагылырга булдык.

Наилә. Күптән түгел генә Дамир шылтыратты.

Ата. Акча сорадымы?! Көчек! Анасының баласы!

Наилә. Юк, шушы көннәрдә үзенә медаль биргәннәр.

Ата. Меда-аль? Бөркет икән. Суйган да каплаган үзем!

Ана. Ничек ул анда? Авырмыймы?

Наилә. Бөтенесе дә тәртиптә, ди. Нишләп әле сез басып торасыз. Утырыгыз. Әти, әнинең чыгасын нигә шылтыратып булса да әйтмәдең?

Ата. Шылтыраттым мин сиңа, трубканы алмадың.

Наилә. Шулай шул. Мин командировкада булдым. Ә Җәмил, күрәсең, соңга кадәр эшләгәндер.

Ата. Син аның турындамы кайчандыр миңа телефоннан шылтыратып әйткән идең.

Наилә. Әйе.

Ана. Ә ул кая соң?

Наилә. Озакламый кайтыр.

Ата. Бирсен Ходай! Бераз гына җылынып та алырбыз. *(Кулларын уа.)* Дөресен генә әйткәндә, барысы өчен дә.

Ана. Һаман да җылынырга идең, ә, бөркет!

Ата. Тынычлан. Дөресен генә әйткәндә, әле моңарчы үз ояма шуышып булса да үзем кайттым.

Наилә. Хәзер җылынып чак түгел, әткәй!

Ата. Нәрсә?

Ана. Аңламадым?

Наилә *(дулкынлану кичереп)*. Әти, әни, минем сезгә әйтәсе килгән сүзем...

Ата. Ну...

Наилә. Ну... Озакламый Җәмил кайта. Ну... Ул үзе генә түгел, бер хатын белән. Юк ла инде, бер ир белән. Хатын кыз киеме кигән бер ир кеше белән...

Ана. Нәрсә, зәңгәрмени?

Наилә. Юк, мин аңардан... мин аңардан Җәмил алдында бер кеше булып кылануын сорадым.

Ата. Кылануын?! Кем булып?

Наилә. М-ми-нем әни булып.

Ана.

Ата. Ке-ем булып?..

Наилә. Ә нәрсә? Сезнең уйлавыгызча, миңа нишләргә кала иде? Иртә таңнан Җәмил миңа атка ияргән кигәвен кебек ябышты. Янәсе, минем әнине күрәсе килә. Ә мин төрмәдәге әнине каян алыйм?! Ә аның үз туксаны туксан. Анаңны күрәсем килә и вәссәлам. Менә шул. Күрде...

Ана. Та-ак... *(Пауза.)*

Наилә. Ә хәзергә сез берәр гостиницага урнашып торалмассызмы? Зинһар өчен! Мин үзем барысы өчен дә түлим. Ә кичен мин сезнең янга килермен. Утырырбыз, сыйланырбыз. Әнинең исән-сау чыгуын юарбыз.

Ана *(акрын гына)*. Рәхмәт! Рәхмәт сиңа, кызым!..

Ата. Дөресен генә әйт әле, чынлап та дөресен әйтеп булмый идеме?

Наилә *(кычкырып)*. Нинди дөреслек турында сүз булырга мөмкин?! Нәрсә, бер юбканы да калдырмый хатын-кыз артыннан сөйрәлчек урынына йөрүче атам или төрмәдә утырган анам турында сөйләргә идеме әллә?.. Мин аңарга шуларны сөйләргә тиеш идемме? *(Пауза.)*

Ана. Димәк, тудырган анаңнан баш тарттың?

Наилә. Сөйләмә әле юк-барны. Нишләп баш тартыйм?

Ана. Нindidер йортка кергән кеше алдында үз анаң оят тоелдымы?

Наилә. Әни!

Ана. Нинди әни, нинди әни?! Синең хәзер башка анаң.

Ата. Чалбардан. Дөресен генә әйткәндә, аңсыз син!

Наилә. Хватит!

Ана. Искитмәле! Ата-анадан баш тартты да, җитте, имеш!

Ата. Яхшы түгел, кызым! Яхшы түгел!

Ана. Башыма сыймый.

Наилә. Миңа ни эшләргә иде соң, әни, ни эшләргә иде?!

Ата. Ни эшләргә! Ул вакытта дөресен яшергән булсаң, хәзер дөресен әйтергә!

Наилә *(өзеп)*. Соң инде.

Ана. Ни өчен?

Наилә. Сез Җәмилне белмисез. Ул ялганны кичерә алмый.

Ата. Әллә прокурормы?

Наилә. Юк, гади эшче. Ул ялганлаганымны белүгә үк мине ташлап китәчәк.

Ата. Кит аннан.

Наилә. Әйе, ул ике хатыны белән дә шул ялган мәсьәләсендә аерылган.

Ана. Йөргәннәрме?

Наилә. Алай гына булса! Ә ведь нindidер вак-төяк тормыш ваклыкларына кызыгып, кемнедер җүләргә санап үзләре харап булганнар.

Ана. Белмим инде, белмим. Минем уйлавымча, әгәр дә кеше ярата икән, ул барысын да кичерергә, гафу итәргә тиештер. Менә ведь мин бу ата мәчене кичердем. Дөресен әйткәндә, беренче тапкыр гына да түгел, әмма кичердем.

Ата, гаебен таныган кыяфәт ясап, яңагыннан үбеп ала.

Наилә. Юк, юк, әни, Җәмил ул бөтән кеше.

Ана. Шуннан нәрсә... Бөтән, димәк, бөтән особый... Чыннан да безгә китәргә вакыттыр.

Наилә. Кунакханәгә урнашу белән шунда ук үземә шылтыратыгыз. Кич белән мин сезнең янга килермен.

Ана *(авыр гына)*. Юк инде, без сиңа шылтыратып тормабыз. Безгә килеп йөрүең дә кирәкмәс. Без туп-туры вокзалга. *(Ата кешегә.)* Киттек.

Наилә. Син нәрсә инде, әни...

Ана. Бетте, хуш. *(Ата кешегә.)* Киттек.

Наилә *(елап)*. Тукта әле, әни... Аңла, зинһар. Миңа ведь утыз җиде яшь, әни! Озакламый кырык тула! Неужели синең мине аңлыйсың килми. Минем үз гаиләмне булдырасым килә. Син бит үзең дә әти белән оныклар тели идең. Бәлки, бу минем иң соңгы мөмкинлегемдер. Ә ведь мин сезгә ышанган идем, ышанган идем. Минем иң якын кешеләрем — сез. Сез миңа ярдәм итәрсез дип ышанган идем. Ә сез, сез... *(Үксеп елый башлый. Пауза. Ана, килеп, Наиләнең башыннан сыйпый.)*

Ана. Булыр, булыр... Үзең белгәнчә эшлә, Наилә, үзең белгәнчә. Тормышың үзеңнеке. Үзең белгәнчә, үз йөрәгең кушканча эшлә. Сиңа үзеңә яшәргә! Ә оныклар безгә кирәк. Бик тә кирәк. Кыскасы, кунакханәгә урнашу белән, без сиңа шылтыратырбыз. Яхшымы?

Наилә. Әни... әнием. Әти... сез бит минем сезне ничек яратуымны яхшы беләсез.

Ана. Беләбез, беләбез, кызым, бәгырькәем!

Наилә *(күз яшен сөртеп)*. Ярый, бетте, бетте. *(Кемнеңдер тышкы ишеккә килгән аяк тавышы ишетелә.)* Алар! Кайттылар! Әй Ходаем! Әни, әни, син минем беренче укытучым! Аңлашылдымы? *(Кычкыра төшеп.)* Аңлашылдымы, әни?!

Ана. Аңлашылды, кызым.

Сәйфиеч белән Җәмил керәләр.

Наилә *(шатланып)*. Әни, әти килде!

Сәйфиеч. Что?..

Наилә. Менә! Әти, күз алдыңа китерәсеңме, ул сине көнли!

Сәйфиеч. Кит аннан!

Наилә. Әйе! Әйтерсең лә Отелло. Кирәк бит, синең эздән калмыйча бирегә килгән.

Сәйфиеч. Кара син аны, нинди...

Наилә. Йә, нәрсә, әти? Күрәсең, синсез әни беркем белән дә йөрми. Бары тик минем Җәмилем белән генә һава сулап, бераз гына шәһәр тормышына күз ташлап кайтты. Ә бу кем, таныйсыңмы, әни?

Сәйфиеч. Бик үк танып бетермим.

Наилә. Минем беренче укытучым Ания Хисмәтовна.

Сәйфиеч. Кирәк бит, ә!

Наилә. Ания Хисмәтовна.

Сәйфиеч. Ә-ә... Ничек инде, ничек инде танымыйм. Бүгенгедәй таныйм. Фотосурәттә сез, Ания Хисмәтовна, ә сезнең янызда ап-ак бантик белән минем кызым Наилә!

Наилә. Ходайга тапшырып, ул да менә дәреслекләр алырга шәһәргә килгән.

Сәйфиеч. Ания Хисмәтовна, күгәрченем! Ә мин, оятсыз, Наилә өчен сезгә бер тапкыр да рәхмәт әйткәнем булмады. Соң булса да хәзер үзеңне бер туйганчы үбим әле. Армый-талмый яшь буынны тәрбияләгәнең — укытучы һөнәрең өчен! *(Суырып үбә.)* Ә менә монысы Наилә өчен! *(Тагын суырып үбә.)*

Ата. Җитте! Җитте дим мин сиңа!

Сәйфиеч. Кыз өчен!

Ата. Җитте, достаточно!

Сәйфиеч. Аналарча керсез үбим!

Ата. Довольно! Шашма!

Наилә. Син нәрсә инде, әти! Монда да көнлисең! Кемгә ведь әле, Ания Хисмәтовнага!

Сәйфиеч. Кемгә көнли бит әле, намуслы ханымга.

Наилә. Ярый, әти. Хәзер әнинең яңагыннан пәп итеп ал да тынычлан. Сезнең арада тынычлык урнашсын.

Сәйфиеч. Әйе, хәзер көтеп торыгыз. Мин аның белән ялашырмын. Узган төнне дә үземне интектереп бетерде.

Наилә. Җәмил, Ания Хисмәтовнаның бездә кунарга каласы килә, син каршы түгелме?

Җәмил. Син нәрсә инде, сөеклем, әлбәттә, бездә кунасыз, Ания Хисмәтовна, бездә кунасыз. Наилә, син безнең раскладушканың кайда икәнен беләсеңме?

Наилә. Беләм, әлбәттә.

Җәмил. Раскладушканы кухняга куярбыз. Ә инде әтиең белән әниең менә бирегә диванга ятарлар.

Ата. Ә миңа идән дә ярый.

Җәмил. Идән?!

Ата. Әйе, менә бирегә, ишек төбенәрәк.

Наилә. Безнең әти спартанец. Күпчелек вакытта как идәндә, такта өстендә йокларга ярата.

Җәмил. Ә-ә.

Сәйфиеч. Баш очына утын түмәре кыстырып.

Җәмил. Утын түмәре?

Сәйфиеч. Әйе.

Ата. Арттыра.

Сәйфиеч. Вахитчик, оялма. Монда барысы да үзебезнекеләр.
Җәмил. Да... Утын түмәре табуыма ышандыра алмыйм.
Ата. Кирәге дә юк, рәхмәт.
Җәмил. Ә менә...
Сәйфиеч. Ә менә үтүк баш очына суйган да каплаган инде.
Җәмил. Баш очына үтүк?..
Сәйфиеч. Әйе, Вахитка йоклаганда моннан да зур ләззәт юк инде.
Ата. Арттыра.
Сәйфиеч. Ояла, бәгырь. Оялма, үз өеңдәге кебек бул.
Җәмил. Алай икән... Ә хәзер безне гафу итәрсез. Безнең сөйләшәсе сүзләр калган иде. Вахит әфәнде, сезнең рөхсәт белән без аны дәвам итәр идек. Сез каршы килмәссездер дип уйлыйм.
Ата. Юк, киңәшегезне шатланып кабул итәм. Рәхәтләнеп таңга кадәр сөйләшсәгез дә каршы түгелмен.
Җәмил. Рәхмәт! *(Сәйфиечне икенче бүлмәгә алып чыгып китә.)* Галия ханым, утырыгыз. Әйе, ә сез чыннан да Вахит әфәнденең чирле булуына үзегез ышанасызмы?
Сәйфиеч. Җәмилчик!
Җәмил. Аңлыйсызмы, миңа ул авыру ирне түгел, ә, киресенчә, чәчәк атып баручы гүзәл сәламәт иргетне хәтерләтте.
Сәйфиеч. Димәк, сез миңа ышанмыйсыз.
Җәмил. Ни эшләп ышанмыйм, ну...
Сәйфиеч. Их, Җәмил, Җәмил. Әгәр дә мин сезне алдасам, минем ялганым тиз арада ачыкланачак.
Җәмил. Зинһар өчен, Алла хакы өчен мине гафу итегез. Күрәсең, мин ялгышам.
Сәйфиеч. Сез ялгышсагыз, мин бәхетле булыр идем. Ул сау-сәламәт булыр иде. Минем өчен нинди зур бәхет. Йә, ярый.
Җәмил. Аның нәрсәсе авырта соң?
Сәйфиеч. Вахитныңмы? Почкасы, ягъни бөере!
Җәмил. Бөере?!
Сәйфиеч. Берсен тиз арада алып ташларга кирәк.
Җәмил. Ничек сез аны белә алдыгыз?
Сәйфиеч. Ә-ә, анымы? Безнең шәһәрдә ниндидер эпидемия килеп чыкты. Вьетнамислар алып килгән дип сөйләделәр.
Җәмил. Хм! Минем нәрсәдер бу турыда ишеткәнем булмады.
Сәйфиеч. Естественно, ишетмәдегез. Паника купмасын өчен чамадан тыш яшерен информация. Областьтан безгә врачлар җибәреп, бөтен шәһәрне тайна гына тикшереп чыктылар. Араларыннан берсе, минем Вахитны тикшергәне, настырные, хоп, Вахитның бер бөереннән вьетнамский заразаны чокып чыгармасынмы. Минем Вахит бу турыда авызына су капты. Чөнки ул үзе медицинага якын. Теге врач минем колакка, әгәр ирегезнең бер бөерен юкка чыгармасак, синең өчен начар булачак дип пышылдамасынмы. Эх, Җәмил, Җәмил. Синең ярдәм белән Вахитның бер почкасын алып ташлау мине шулкадәр бәхетле итәчәк. Син хәтта аңлап бетермисең. Шуның өчен тиз арада операция ясатмасак, миңа гына түгел, безнең гаиләнең Наиләсенә дә, Вәсименә дә зур кайгы булачак.
Җәмил. Кемнәргә кайгы булачак дидегез? Кемнәргә?
Сәйфиеч. Улыбыз Вәсимгә...
Җәмил. Но ведь аның исеме, ялгышмасам, Вәсим түгел, Дамир кебек иде.
Сәйфиеч. Кемнең?
Җәмил. Ну инде сезнең армиядәге улыгызның исеме!
Сәйфиеч. Да?
Җәмил. Әйе! Миңа бу турыда кайчандыр Наилә дә сөйләгән иде. Минем үземнең беренче хатындагы иң олы улым Дамир исемле. Шуңа күрә дә ул минем истә калды да. Боларның барысы өчен дә, димәк, Галия ханым...
Сәйфиеч. Нәрсә инде бу?
Җәмил. Чыннан да!
Сәйфиеч. Кирәк ведь, ә, кирәк ведь. Шулай инде, бер телемә хуҗа булалмагач. Язык мой — враг мой!
Җәмил. Димәк?
Сәйфиеч. Аңлыйсыңмы, Җәмил, Вәсим минем беренче балам.
Җәмил. Беренче?
Сәйфиеч. Әйе, но... Наилә дә, Дамир да, Ходаем сакласын, Вахит абыең да бу турыда белү түгел, ишеткәннәре дә юк.
Җәмил. Ничек инде?

Сәйфиеч. Ә менә шулай. Кыскасы, Вәсимем минем Вахит белән очрашканчы, танышканчы туган иде.

Җәмил *(шаккатып)*. О-о!

Сәйфиеч. Әйе, бер... Бер әкәмәт кешедән...

Җәмил. Уйнаштан туган.

Сәйфиеч. Нигә алай дорфа. Әйе, сабый шәһәр читендәге бай гына бер җүләрләр йортында, то есть балалар йортында үсте. Соңыннан орденлы Суворов училищесын алтын медальгә, ә соңыннан... Сиңа боларның нигә кирәге бар инде.

Җәмил. Аңлашылды.

Сәйфиеч. Әйе, Җәмил, сиңа нәрсә аңлашылсын. Сез бит чыннан да ир кеше. Самец. Тирәнрәк уйлаганда, сез ведь хайваннар семьялыгыннан. Сезгәме соң яшь кызның керсез сөюен аңларга.

Җәмил. Тәк-тәк, сам так! Бу нәрсә булып чыга инде... Димәк, Наиләнең дә үз Вәсиме булып чыга түгелме?

Сәйфиеч. Җәмил!

Җәмил. Ә нәрсә?! Үзегез әйтмешли, кызы чат әнисе, суйган да каплаган.

Сәйфиеч. Юк, Наиләм минем фәрештә!

Җәмил. Минем уйлавымча, әхлаксыз, түбән җан түгелдер.

Сәйфиеч. Юк!

Җәмил. Сез үзегез моңа ышанасызмы?

Сәйфиеч. Һичшиксез. Бу мәсьәләдә ул — кыя!

Җәмил. Нәкъ сез, үзегез?

Сәйфиеч. Юк, нәкъ Вахит. Әйе, әйе, ул. Өзгән дә куйган атасы.

Җәмил *(шикләнеп)*. Шулай дисезме?

Сәйфиеч. Шулай димен. Безнең гаиләдә Вахиттан да саф кеше юк. Миннән башка бернинди чит хатын белән дә элемтәгә, интимга кергәне юк, бичараның.

Җәмил. Сөйлисез тагын.

Сәйфиеч. Ант итәм. Бер-ике хатынкай үзен гашыйк итеп караганнар иде. Берни чыкмады, үтмәс номер. Буялган ирен дисезме, каш сикертүләр, кыска юбка, ярым шәрә күкрәк, ышкылып китүләр... Ә минем Вахит каккан казыкмыни, керфеге дә селкенми.

Җәмил. Бәлки, ул импотенттыр?

Сәйфиеч. Этем белсен. Кызы да нәкъ үзе. Әйтеп торам ведь, нәкъ үзе. Наилә безнең гаиләдә порядочная.

Җәмил. Да, яхшы, шулай булсын ди. Ә хәзер мин тартып керим әле. Бу кадәр информациядән ми кайный.

Ана. Күрәм, Наиләнең кавалеры болай ничевога охшаган.

Ата. Затлы адәмгә тарткан.

Ана. Тизрәк өйләнеп, безгә оныклар бүләк итсеннәр иде.

Ата. Сөйлисе юк.

Ана. Хәзер барысы да аңардан тора. Наилә кая югалды соң ул?

Ата. Әз генә командировка отчетлары калган булган, шуларны эшләп бетерәсе бар дигән иде.

Ана. Ә-ә... *(Пауза.)* Димәк, мине сагынды дисең инде?

Ата. Сорап торасың тагын.

Ана. Нәрсә, көннәрен берүзе генә үткәрдемени, иптәш кызлары белән аралашмадымыни?

Ата. Теге, теге Гамилә хатынкайны әйтәм, исән микән, күргәнең булмадымы?

Ана. Әллә зиратта саташып йөрдеңме? Судка кадәр барып җиткән үзеңнең сөекле секретаршаңнан сора, бәхетсез ата эт. Йә, әйт инде, аның белән ел буе кайда иснәштегез? Суд залының как скамейкасындамы?

Ата. Да, күрмәгәнеңне күрсәтте ул сиңа.

Ана. Сөйләп торасың. Аның тырышлыгы белән бер ел төрмәдә утырдым.

Ата. Кем сиңа чырае белән аны стенага сугарга кушкан?

Ана. Ә нәрсә?! Сине миннән тартып ала язганы өчен мин аны үбәргә тиеш идеммени?

Ата. Бер тапкыр урынына утырту җитәр иде. Тәртип өчен. Ә син бөтенләй инде кызып киттең.

Ана *(авыр сулап)*. Дөрес әйтәсең, нәрсә булды ул көнне минем белән, үзем дә аңламыйм.

Ата. Аны дөмбәсләр өчен урынын да тапкансың. Шәһәр суды бинасыннан гайре урын беткәндер.

Ана. Ә тагын кайда бәргәлим. ООНның Генеральный Ассамблеясында манчый алмыйм бит инде.

Ата. Анда яхшырак булган булыр иде. Алайса, бөтен судейский коллегия үзеңә әз генәдән ике ел чәпәми калдылар ведь. Әле дә бәхетең бар икән.

Ана. Йә, әйтеп кара инде. Синеңчә кем өчен бер ел утырдым инде мин? Дәшмисең, ә, ата мәче?

Ата. Ярый, туктатыйк. Кил әле, үзеңне иреннәреңнән бер пәп итеп алыйм.

Ана. Син нәрсә, бөтенләй?.. Әллә саташа башладыңмы? Көпә-көндез үбешеп ятарга.

Ата. Ә нәрсә булган?!

Ана. Атаң башы булган. Ә булачак киявең килеп керсә? Безнең турыда нәрсә уйлар? Кызлары да шулдыр дип уйламасмы?

Ата. Орып биргән аның уйлавын. Уйлап кара синсез бер елны.

Кочаклап ала да Ананы үбә. Бүлмәгә Җәмил керә.

Җәмил *(шаккатып)*. Ой! Гафу итегез! *(Ашыгып чыгып китә.)*

Ана. Әйттем бит мин сиңа, сарык! Рәхәтләнеп үптеңме?

Ата. Ишек шакымыйча гына керер дип кем уйлаган аны!

Ана. Кем уйлаган, кем уйлаган! Нигә аңа ишек шакып азапланырга. Әгәр дә ул монда бу фатирга хуҗа икән. Бүкән син, аңгыра сарык! Үзеңне дә, мине дә, кызыңны да, кызыңның беренче укытучысын да мыскыл иттең. Менә хәзер башыңны эшләт инде. Ничек котылу юлын эзлибез?

Җәмил Сәйфиеч янына керә.

Җәмил *(тирән дулкынлану кичереп)*. Галия ханым, Галия ханым...

Сәйфиеч. Әйе, тыңлыйм, Җәмил энем.

Җәмил. Белмим инде, белмим. Сезгә бу турыда сөйләү килешерме, белмим инде, белмим...

Сәйфиеч. Нәрсә турында?

Җәмил. Сезнең әйтүегезчә, сезнең ирегез кыя инде?

Сәйфиеч. Әйе, ә нәрсә булган?

Җәмил. Так, алайса тыңлагыз. Ул сезнең мактаулы кыягыз...

Сәйфиеч. Әйе, ну?

Җәмил. Ул... ул... Әле генә сезнең кыягыз шундый ярыгын күрсәтте!..

Сәйфиеч. Аңлатып сөйләгез инде, Җәмил.

Җәмил. Аңлатып дисез инде. Яхшы, бик яхшылап аңлатам. Менә шул сезнең буй җитмәс намуслы, горур кыягыз Ания Хисмәтовна белән...

Сәйфиеч. Нәрсә?

Җәмил. Шулай шул менә!

Сәйфиеч. Әй Ходаем!

Җәмил. Ә ул Наиләгез, кыя номер два иде бугай. Сезнең әйтүегезчә, нәкъ үзе, Вахит әфәнденең копиясе.

Сәйфиеч. О-о! Бөтенесе дә без уйлаганча гына түгел, Җәмил, без уйлаганча гына түгел. Вахитның бу эштә бернинди дә катнашы юк, аңлыйсыңмы, гөнаһысы юк.

Җәмил. Ничек инде катнашы юк?! Ул укытучыны мин түгел, сезнең ирегез ялап ята иде бугай.

Сәйфиеч. Яхшы, ярый, әйтми кала алмыйм. Гаиләбезнең серен ачмый булдыра алмыйм.

Җәмил. Шуннан?! Йә, мин көтәм.

Сәйфиеч. Телисез икән — ышанасыз, телисез икән — ышанмыйсыз. Монысы сезнең ихтыярыгызда. Ания Хисмәтовна утыз елдан артык Вахитка үлеп гашыйк. Ышанасызмы, утыз елдан артык.

Җәмил. Утыз елдан артык?..

Сәйфиеч. Әйе, утыз елдан артык! Моннан утыз ел элек Наиләне беренче сентябрьдә беренче класска алып барган көннән бирле. Утыз ел элек беренче сентябрьдә Вахитны мәктәп ишегалдында күргәннән бирле. Шул көннән алып бүгенге көнгә кадәр артыннан калмый үкчәсенә басып йөри. Сезнең уйлавыгызча ул нәрсә, китап алырга килгәндер дисезме? Юк, ул Вахит артыннан килде.

Җәмил. Нәрсә? Ул аны, Вахит әфәндене утыз ел буе почмакка кысрыклый димәкче буласызмы?

Сәйфиеч. Юк! Тагын бер кат әйтәм — юк! Кабатлап әйтәм — юк! Ул аны моннан берничә минут элек үз гомерендә беренче тапкыр почмакка кысты.

Җәмил. Сез моңа ышанасызмы?

Сәйфиеч. Сүзсез! Мин Вахитны үземнең биш бармагым кебек беләм.

Җәмил. Яхшы, шулай да булсын ди. Ул аны чын сөю белән сөйсен дә ди, әмма ләкин ул ведь үзе, үзе Вахит әфәнде аңа биреккән иде.

Сәйфиеч. Үзе?!

Җәмил. Үзе шул, үзе!

Сәйфиеч. Замечательно! Бигрәк тә яхшы! Ул үзе ябышкан да булсын ди. Ә сез? Ә сез, Җәмил?!

Җәмил. Ә нәрсә мин?

Сәйфиеч. Әйе, сез! Сез туксан алтынчы пробалы адәми зат аның урынында булсагыз, утыз ел буе артыгыздан калмый үкчәгезгә басып йөргән шушындый гүзәл хатыннан баш тартыр идегезме? Сез бер ел да түзә алмас идегез. Ә минем Вахитым түзде! Түзде. Ничә еллар түзде. Йа Раббым, йа Раббым. Әйтәм ведь, ул — кыя! Бөтенләе белән кызы Наилә!

Пауза.

Җәмил. Ә сез... Сез аны көнләмисезме?

Сәйфиеч. Вахитнымы?! Ания Хисмәтовнаданмы?!

Җәмил. Әйе.

Сәйфиеч *(борчылып)*. Юк.

Җәмил. Нишләп?

Сәйфиеч. Их, Җәмил, ничек көнлим? Яшәргә санаулы көннәре калган кешене ничек көнлим?

Вахит керә.

Сәйфиеч. Вахит, синме бу?

Ата. Мин, Галиякәем!

Сәйфиеч. Әллә мине сагындыңмы?

Ата. Әйе, карчыгым. Бәгърем минем!

Сәйфиеч. Бәхетем минем.

Ата. Шундый үкенгән чакларым була. Үземнең чит хатын кочагында калуымны сизеп алам да үз-үземне, үз гәүдәмне читкә ыргытам. Юк, юк, мин әйтәм. Мин бары тик Галиям өчен генә туган. Мин бары тик Галиянеке генә.

Сәйфиеч. Вахитым минем!

Ата. Музыка! Вальс! Хәтереңдәме, без аны кайчандыр үзебезнең туебызда биегән идек.

Сәйфиеч. Бүгенгедәй!

Ата *(приемникның тавышын ача)*. Рәхим ит! *(Алар бии башлыйлар.)* Бетте. Кызганычка каршы, бетте. *(Радионың тавышын яба.)*

Сәйфиеч. Гафу итегез, Җәмил энем. Без сезне үзебезнең хисләребез белән туйдырып бетергән булсак, кичерегез.

Җәмил. Сез нәрсә? Бу искитмәле зәвыклы булды. Ишетәсезме, зәвыклы.

Ата. Әйе, безгә хәзер тулы бәхет өчен бары бер генә нәрсә җитми...

Җәмил. Нәрсә җитми?

Ата. Оныклар!

Сәйфиеч. Сөйлисең юк.

Ата. Ә без үзебез кирәгеннән артык гади кешеләр. Без бу җәмгыятьтә ниндидер югары урын, чин, байлыкка ия түгелләр. Безнең мактаныр әйберебез бер генә. Без һәр кешегә дә хас булмаган көчкә ия. Без киң күңелле, игелекле, мәрхәмәтле, шәфкатьле, миһербанлы, өстәвенә сәламәт гаилә. *(Сәйфиеч ютәлли.)* Синең белән нәрсә булды, бәгърем?

Сәйфиеч. Ә-ә, болай гына... *(Кабат ютәлли.)*

Ата. Гаҗәп. Гомерендә дә ютәлләгәне юк иде. Кирәк бит, котыртып куйган кебек. Нәкъ моментында.

Җәмил *(тамак төбен төртеп)*. Ялгыш юлдан китте.

Ата. Шулайдыр. Шуннан соң... Шуннан... Җәмил, уйлап кара. Неужели син Наиләне һәм аннан туачак балаларны сәламәт тумаслар дип уйларга батырчылык итәсең? Ни әйтсәң дә, безнең ген, Аллага шөкер!

Җәмил.. Аңлыйм, нәсел.

Ата. А как же! Менә мине генә ал. Кыскасы, тутырылган тавык, нәсел үгезе!

Җәмил. Спортсмен!

Ата. Нәкъ үзе! Сыер икәнсез, өстенә бастыгыз. Менә, менә минем тешләремә игътибар итегез. Яңа туган сабыйныкы кебек тезелеп киткәннәр. *(Җәмилнең кулын сул күкрәгенә куеп.)* Ә йөрәк... Йөрәк Кремль сәгате кебек текелди. Ә бөерләр?.. Әйтик, ягъни мәсәлән...

Сәйфиеч. Мөгез...

Җәмил пырхылдап көлеп җибәрә.

Ата *(үпкәләп)*. Ярар инде, ярар, мыскыл итмәгез. Беләсегез килсә, мин хәзер дә бармагым белән кадак бөгәм әле.

Җәмил. Кит аннан?!

Ата. А ты как думал! *(Стена буйлап кадак эзләп китә. Тапмагач, стенадан браны идәнгә куя да, кадагын тартып чыгара һәм көч хәл белән бөгә.)*

Җәмил. Менә сиңа мә!

Ата. Тапкансың гаҗәпләнер нәрсә! Ә менә минем эти-батя! Йә булмаса, абый, но черт с ним, энекәш Шамил. Менә кемнәр настоящий алыплар!

Сәйфиеч. Ярый, булды. Ычкын моннан! Юкса шартлыйсың. Мин әле Җәмилгә Наилә хакында барысын да сөйләп бетермәдем.

Ата. Хәтереләң начар. Исеңдә тот. Сәламәтлеге хакында сөйләдең.

Сәйфиеч. Исемдә!

Ата *(Җәмилгә)*. Ышанасыңмы, юкмы, кыз, Наиләне әйтәм, сеңердән генә тора. Кыскасы, эш аты инде! Сабый чагыннан хәтерлим. Һәрвакыт аркасында капчык иде.

Сәйфиеч. Җитте, җитте, булды! *(Төрткәләп чыгара. Тамашачыга.)* Чаманы белми. Чирле! *(Ата чыгып китә.)* Мескенем! Үз сәламәтлеге белән мактанып гомере узды. Кирегә киткәнен аңламый, бәгырь. Коры сөяккә, шыр сөяккә калып барганын белми.

Җәмил. Белми шул, Галия ханым. Минем уйлавымча, киресенчә, сез үзегез.

Сәйфиеч. Тфү диген. Як-ягыңа төкер. Аллам сакласын.

Җәмил *(бераздан)*. Галия ханым...

Сәйфиеч. Әйе!

Җәмил. Сезнең справкагыз бармы?

Сәйфиеч. Нинди?

Җәмил. Ирегезнең чире хакында.

Сәйфиеч. Нигә? Нәрсә, Вахит кулына эләгеп, ул үзе белсен өченме?

Җәмил. Димәк, юк!

Сәйфиеч. Әлбәттә, юк. Әмма ләкин минем чын, намуслы, саф, чиста, пакь, эчкерсез, бернинди үлчәүгә дә сыймый торган ана йөрәгеннән саркып чыккан тугры сүзем бар!

Җәмил. Ә врач? Аны караган врач?

Сәйфиеч. Врач? Ә-ә-ә, доктор... Ә нәрсә врач, доктор?

Җәмил. Сез аны областной центрдан дигән идегез бугай?

Сәйфиеч. Ну, шуннан нәрсә?

Җәмил. Әгәр дә кирәк булса, ул бу диагнозны кабаттан исбат итәрме?

Сәйфиеч. Кыскасы... сез аны күрәсегез килә?

Җәмил. Сез бик акыллы ханым.

Сәйфиеч. Аның урынына сез, Җәмил, ышанмаучан.

Җәмил. Нишлисең? Гафу итегез, сумма кечкенә түгел.

Сәйфиеч. Яхшы, мин ул ханымга шылтыратырга тырышып карармын.

Җәмил. Ханымга?!

Сәйфиеч. Әйе, аңа илле яшьләр тирәсе. Бик тә, бик тә танылган медик. Зур стажлы профессор. Әйе, хәзер үк шылтыратыйм әле үзенә.

Җәмил. Сездә аның телефоны бармы?

Сәйфиеч. Хәтта кесә телефонына кадәр бар. Әгәр дә көтмәгәндә шылтыратырга туры килсә, Вахит белән андый-мондый хәл килеп туса дип алган идем, Аллам сакласын. Үтенеп сорыйм, әгәр дә ул бирегә килсә, зинһар, аны врач икәнлеге хакында биредәгеләргә ләм-мим. Әгәр дә ул килсә, сүзебез бер булсын иде. Имеш, ул — сезнең танышыгыз, бер генә минутка бирегә кереп чыкты. Шуннан соң, шул. Ничек тә Наиләне бирedән җибәреп торырга иде.

Җәмил. Наиләне? Нигә?

Сәйфиеч. Сизмәсен өчен. Синең белән ярты ел яшәү дәверендә ул синең танышларыңны белеп бетергәндер дип уйлыйм.

Җәмил. Шулай дисезме... *(Уйланып.)* Дөрес! Ә мин аны магазинга җибәрәм! Кунакларны нәрсә белән булса да сыйларга кирәктер ведь инде.

Сәйфиеч. Дөрес! Барыгыз. Ә мин... *(Җәмил чыгып китә, Сәйфиеч телефоннан шылтырата.)* Эльмира, синме? Коткар, зинһар өчен, коткар! Күз алдыңа китерәсеңме, теге кызыйның, Наиләнең, егете Җәмил тиз арада врач белән очраштыруны сорый. Менә шул врач син булалмассыңмы? Нәрсә?! Соңыннан, соңыннан. Бөтен эчтәлекләре белән төкми-чәчми барысын да аңлатырмын. Кыскасы, сиңа очып кына бирегә килергә дә, үзеңнән югары класслы врач ясап, минем ата дуңгызны, ягъни Вахитны, кыскасы, законлы иремне карарга кирәк булыр. Әйе, кияүгә чыгарга өлгердем, рәхмәт. Менә шул. Кыскасы, тиз арада син аны карарсың. Юк инде, юк. Нигә аны чишендерергә. Бигрәк тә кесәсенә якын киләсе булма. Нинди кесә, нинди кесә?! Как-будто белмисең инде нинди кесә турында сүз барганын. Эльмира, уяу бул. Син шушы минуттан медицина профессоры, академик! Дәвам итик. Кыскасы, сиңа врач булып түгел, ә Җәмилнең бик үк якын булмаган танышы булып килергә кирәк. Ишетсен колагың. Җәмилдән башка синең врач икәнеңне өйдәгеләр сизәргә тиеш түгел. Авыррак буласын беләм. Әмма син бит бу мәсьәләдә эт йоткан бәндә, ситуацияне минутында сизеп, тиз арада бу мәсьәләгә кереп китәрсең дип уйлыйм. Менә шул. Син авыру Вахитны карап тикшергән булырсың да тиз арада бер як бөеренең эштән чыгуын әйтерсең. Кайсы бөере булсын инде?.. Кайсысын кызганмыйсың, шунысын әйтерсең. Янәсе тиз арада операция ясарга кирәк. Молодец! Дөрес фикер йөртәсең. Әйе, әйе, солидный суммага. Ну үзеңдә акыл бар да инде. Бу эшне җиренә җиткереп башкарырсың, сине майлы калҗа, гонорар көтәчәк. Әлбәттә, биргән киңәшләрең өчен. Профессорлар акчасы алырсың. Нәрсә?! Монда утырып килгән такси хакын да кертеп дисеңме? Түлим инде, түлим! *(Тамашачыга.)* Кадалып кит! Бирәнең тыгылсын! *(Трубкага.)* Нәрсә-нәрсә?! Нинди бирән димен... Бирегә кил димен! Нәрсә? Наилә

таныячак?.. Ә без аны хәзер магазинга олактырабыз. Менә шул. Ул кибеттән кайтканчы эшеңне эшләп тай. Хәзер үк беренче очраган тачкага утырып бирегә килеп җит. Көтәм.

Трубканы куя, Җәмил керә.

Җәмил. Димәк, ул врач Вахит әфәндене үз шәһәрегездә карап, анализ куйды инде.
Сәйфиеч. Әйе.
Җәмил. Димәк, ул, Вахит әфәндене әйтәм, ул врач ханымны белә инде.
Сәйфиеч. Ничек дип әйтергә, алар анда, Вахит янында кара болыт кебек бөтерелделәр. Барысы да хур кызлары кебек ап-ак халаттан. Кайсы ткалый, кайсы сыпыргалый, кыскасы, минем фикерләвемчә, ул аны чамалап, танып калмавы да бик ихтимал.
Җәмил. Ә сез аны танып калдыгызмы соң?
Сәйфиеч. Әлбәттә, Вахит абыеңны караганнан соң ул мине үзе эзләп табып, барысын да түкми-чәчми аңлатып кайгымны уртаклашты, бөек ханым.
Җәмил. Операция мәсьәләсендә ул үзе әйткәндер бит инде? Күпме торачак инде ул операция?
Сәйфиеч. Әйтте. Телефон номерын да калдырды.
Җәмил. Исемен ничек дидегез әле?
Сәйфиеч. Мәмдүдә... Мәмдүдә Ханнановна! Әй, Җәмил, Җәмил. Мин Вахитым өчен бөтен барлыгымны бирер идем. Теләсә кайсы бөеремне! Бавырымны! Йөрәгемне! Башымны! Кыскасы, мин аларны күптән югалттым инде. Аның белән беренче тапкыр очрашкан кадерле минутларда ук. *(Звонок шылтырый.)* Әнә. Үзе дә килеп җитте, ахры.

Җәмил ишекне ачып җибәрүе була, кыска гына күлмәктән, җилбәзәг-рәк кыяфәттә Эльмира керә.

Эльмира. Хәерле көн!
Сәйфиеч. Менә, нәкъ үзе. Мәмдүдә ханым Ханнановна.
Җәмил. Исәнмесез!
Эльмира. Операция өстәленнән сезнең янга. Хәтта юньле-рәтле киенергә дә вакытым булмады. *(Кухнядан Ана карый.)*
Ана. Наилә, синме ул?
Сәйфиеч. Юк, бер генә минутка Җәмил янына килделәр.
Ана *(теләр-теләмәс кенә Эльмираның кыяфәтенә күз ташлап)*. Җәмилгә дисез инде? Ну-ну! *(Кереп китә.)*
Эльмира. Баш күтәрергә дә вакыт юк. Йә, кая ул безнең авыру?
Сәйфиеч. Иптәш профессор, кабат үтенәм, зинһар өчен, үзегезнең врач икәнегезне өйдәгеләргә сиздермәсәгез иде.
Эльмира. Хәтерлим. Әйе, врачларча серемне саклармын. Зинһар, үз исемегезне исемә төшерсәгез иде.
Сәйфиеч. Галия... Галия ханым дисәгез була.
Эльмира. Әйе бит әле. Ә бу сезнең улыгызмы?
Сәйфиеч. Юк. Бу яшь иптәшемнең исеме — Җәмил. Безнең кияү егете булырга җыена.
Эльмира. Димәк, аннан бернинди дә яшерен сүз була алмый?
Сәйфиеч. Әлбәттә.
Эльмира. Бик яхшы. Сезнең иптәшегезнең, ирегезнең исеме ничек әле?
Сәйфиеч. Вахит.
Эльмира. Ә, әйе, исемә төште. Сирәк очрый торган сул як бөер... Чамадан тыш таушалган.
Сәйфиеч. Әйе, әйе.
Эльмира. Так-так, сам так! *(Кулын сөртеп.)* Кая әле ул безнең ата? Хм... То есть авыру иптәш?
Сәйфиеч. Кухняда, Мәмдүдә Ханнановна. Әй, сез, бирегә чыгыгыз әле. *(Ата һәм Ана чыгалар.)* Таныш булыгыз, бу сылу ханым Җәмилнең танышы була. Бер генә чынаяк кофедан авыз итәргә кергән.
Җәмил. Әйе, әйе, бары бер йотым кофе. Ул минем янга бары тик бер генә минутка. Озакламый китә. Танышып калыгыз.
Эльмира. Мәмдүдә Ханнановна!
Ата *(буй-сынын җентекләп карап)*. Бик рәхмәтлебез. Мин үзем Вахит булам.
Ана. Ания! Ания ханым!
Сәйфиеч. Безнең таныш. Ә Вахит — минем иң якын, бердәнберем, хәләлем.
Эльмира. Так, бу сезнең тормыш иптәшегез. Турысын гына әйткәндә, бик-бик тә мәшһүр ир!
Ата. Шулай ук дисезме!
Эльмира. Алсу йөз... Күзләр уттай яна... Ә куллар, куллар... Ходаем, йа Раббым, йа Ходам! Ул күкрәк... Киң җилкә! Нинди асыл, күркәм, затлы ир! Кыскасы... Ахырзаман...

Сәйфиеч. Коткарыгыз! Көнчелектән шартлыйм. Валерианка бирегез! Менә, менә хәзер барысын да сөйләп җибәрермен кебек. Кулыма нәрсә күтәреп килгәнемне үзем түгел, Ходаем үзе генә белә.

Ата *(Анага)*. Әнисе... Бәгырькәем минем. Үтенеп сорыйм, минем сиңа киңәшем шул. Сиңа да нәкъ менә шушындый күлмәк алсак иде. Шушындый ук материядән, шушы ук фасонда. Уйлавымча, бик кыйммәт тормыйдыр. Ха-ха-ха!

Эльмира. Ә сез өстәвенә бик үткен дә.

Җәмил *(Эльмирага)*. Рәхим итегез, кофе!

Эльмира. О-о! Мең тапкыр гафу. Ләкин мин өлгермим. Бүтән чакта. Әмма ләкин мин сезгә, Җәмил, туганым, шундый рәхмәтлемен. Сез мине үзегезнең шундый да затлы, асыл дус-ишләрегез белән таныштырдыгыз. Искитмәле! Ә хәзер ашыгам. Эш, эш, эш!

Сәйфиеч. Без сезне Җәмил белән озатабыз.

Эльмира. Әгәр дә авыр булмаса.

Ата. Сау булыгыз!

Эльмира. Сәламәт булыгыз!

Эльмира, Җәмил һәм Сәйфиеч ишек катына киләләр.

Җәмил. Йә, ничек, доктор?

Эльмира бер сүз дәшмичә генә сумкасыннан сигарет чыгара да алтын йөгертелгән пистолет зажигалкасын кабыза.

Эльмира *(Җәмилгә)*. Тартасызмы?

Җәмил. Юк, рәхмәт. Сирәк кенә. Тәмен белмичә.

Эльмира. Ә мин... Көне-төне операцияләр, беләсезме, төрле стресслар, нервотрепкалар димме... *(Тартып җибәрә.)*

Җәмил. Күркәм, затлы зажигалка.

Эльмира. Австрия коллегаларым бүләге. *(Ашыкмый, тирән итеп сигарет суыра.)* Димәк, сез минем уйлавымча, аңа туган түгел. Яхшы. Бик яхшы. Мин сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшә алам. Өстәвенә Галия ханым барысын да белә.

Сәйфиеч. Әйе, әйе.

Эльмира. Менә шул, кызганычка каршы, мин үземнең куйган диагнозымны кабаттан кабатлыйм. Вахит әфәнде, Вахит әфәнде... Кызганыч ки... *(Сәйфиеч сулкылдап тетрәнеп куя.)* Нишлисең бит Галия ханым. Үз-үзегезне кулга алыгыз. Ирләрчә булыгыз!

Сәйфиеч. Тырышам...

Эльмира. Иң күбендә бер атна. Чын дөресен әйтим, дүрт-биш көн. Нишлим?! Мин сезнең алда бик катгый күренәмдер. Әмма ләкин минем профессиям — врач!

Җәмил. Хаталану урынсыз дисез инде?

Эльмира *(иренеп кенә көлеп)*. Мин? Хаталану?! Бик сәер, өстәвенә урынсыз, глупый вопрос!

Сәйфиеч. Бу ханым, Җәмил, докторларга доктор! Безнең бәхет. Даны бөтен Европага таралган. Бу бармаклары белән ул кеше күңелен генә аңлау түгел, хәтта җиде табышмаклы авыр йозакларның да телен аңлый.

Җәмил. Шулай да... Рентгенсыз, анализсыз, бернәрсәсез... Сез хәтта аның температурасын да үлчәмәдегез.

Эльмира *(иңсәсен җыерып)*. Температура?! Зачем? Җаным, миңа рентген та, сварка да, автоген да кирәкми. Менә шушы күзләрем, елгыр бармакларым барда, миңа бернинди дә киртә юк. Температура... Минем анализга нәрсә бирә ул. Күз алмасын карагыз... бетчәле тире... күз астында сары асылынып төшкән капчык... тырнагының төсе... Болар барысы да авыруның эчке халәтен, эчке органнарын сөйли торган факторлар. Менә йөрәгенә килсәк, һич шикләнми әйтәм, ат йөрәге. Превосходная селезенка... Ә бавырын хәзер үк табага сал да кыздыр. Прелесть... Ә менә бөерләре, бөерләре... Дөрес, берсе... сул яктагысын хәзер үк алып *(Сәйфиечка карап ала)* этләргә ташларлык. Ярар, мин ашыгам. Мине тагын унөч операция көтә. Баш капкачы ачу. Аяк тамырын алып йөрәккә ялгау, уң күзне сул күзгә алмаштыру. Дөресрәге, миңа, бәлки, бу фатирда акыл сату җиткәндер. Ә менә гонорар...

Сәйфиеч. Җәмил, энекәем... Мин бер тиенсез. Минем бөтен акчаларым Вахитта.

Җәмил. Күпме?

Эльмира. Ну, күрәм, сез банкир түгел... Мең.

Җәмил. Нәрсә?

Эльмира. Әлбәттә, үзебезнекен, урысныкын.

Җәмил. Ә-ә, үзебезнекен. *(Кесәсеннән акча ала да Эльмирага суза.)* Менә. Мә.

Эльмира. Әгәр кирәгем чыкса, шылтыратыгыз!

Җәмил. Сау булыгыз!

Сәйфиеч. Рәхмәт сезгә, Мәмдүдә Ханнановна!

Эльмира. Миңа? Нәрсәгә?

Сәйфиеч. Коткарганыгыз өчен! *(Кульяулыгы белән күз төбен сөртеп.)*

Эльмира. Пүчтәк! *(Катгый рәвештә.)* Житте балавыз сыгарга! Үзегезне кулга алыгыз! Ирләр булыгыз! *(Йомшак кына итеп.)* Билгеле, шушы йомшак хатын-кыз сыйфатларыгызны саклап *(дулкынлану белән)* калалсагыз, Ходай сезне үз ярдәменнән ташламас. *(Тиз генә чыгып китә.)*

Җәмил. Галия ханым, җыламагыз, борчылмагыз, зинһар. Ничек тә мин сезгә ул акчаларны табып бирергә тырышырмын.

Сәйфиеч. Рәхмәт, Җәмил!

Җәмил. Яшермим. Чыннан да, вакыты белән мин сезгә ышанып та бетмәдем.

Сәйфиеч. Мин әле бу хәлгә үзем дә ышанып бетмим.

Җәмил. Тагын шул...

Сәйфиеч. Әйе, Җәмил!

Җәмил. Сез миңа үзегезне әнием дип әйтергә рөхсәт итмәссезме?

Сәйфиеч. Миңа?

Җәмил. Әйе, әни дип. Сез... сез бит асыл зат! Сез — әүлия!

Сәйфиеч. Сез бигрәк инде!

Җәмил. Ышаныгыз! Кеше хатасыз булалмый. Дөрес, сезнең дә вак-төяк хаталарыгыз бардыр. Шулай да сез — әүлия! Мин сезгә әнием дип эндәшә аламмы?

Сәйфиеч. Әгәр дә... Әгәр дә сез, Җәмил, үзегезне миңа улым дип атарга рөхсәт итсәгез.

Җәмил. Әлбәттә! Әлбәттә! Чукынып китим, серне ачам!

Сәйфиеч. Нинди серне?

Җәмил. Наилә дә белми торган серне. Бераз акча җыйган идем мин. Кыскасы, менә шул. Ике мең евро. Сезнең кесәгездә дип уйлый аласыз.

Сәйфиеч. Минем асыл улым!

Җәмил. Өч кенә мең табасы кала.

Сәйфиеч. Дөрес.

Җәмил. Вахит әфәндене коткару минем дә изге бурычым.

Сәйфиеч. О-о, Җәмил! Димәк, сез чыннан да өйләнергә уйладыгыз?

Җәмил. Әйе! Әйе, әнием! Сезнең алдыгызда булган тирән хөрмәтем хакына. Әни-ем!..

Сәйфиеч. Улым! Улым!

Җәмил. Ярый, вакытны әрәм итмик. Телефонга утырыйм да акча эзлим.

Сәйфиеч. Уңышлар телим, улым!

Чыгып китәләр. Зур сумка күтәреп, Наилә керә дә кухняга үтә.

Җәмил *(үз бүлмәсеннән шылтырата).* Исәнмесез! Наил Ахатовичны мөмкинме? Командировкада? Ә кайчан кайта? Рәхмәт... *(Трубканы куя.)* Ә-ә, Чебыкинга шылтыратсам? *(Телефон трубкасыннан номер җыя.)* Занято... *(Блокнотын актара.)* Ә-ә, менә. Керәшен халкы юмарт ул. *(Шылтырата.)* Юрий Иванович?! Исәнмесез. Бу мин әле, Җәмил, борчыйм. Ну инде, сталь ишекләрне без сездә ясатабыз. Исегезгә төштеме? Юрий Иванович, сез миңа әҗәткә акча биреп торалмассыз микән? Өч мең евро... Сүз дә юк. Әлбәттә, расписка белән теләсә нинди процентка... Ике-өч көннән дисезме? Юк, миңа хәзер үк кирәк. Тиз арада кирәк. Яхшы, сезнең шылтыратуыгызны көтәм. Сау булыгыз... *(Яңадан блокнотын актара.)* А-а, вот... Олег Николаевич. Вышел? А Вы не подскажете, когда он… *(Наилә күренә, Җәмил, каушап, трубкасын куя.)*

Наилә. Ага! Йә, әйт инде, кемгә кача-кача шылтыратабыз?

Җәмил. Болай... По делам.

Наилә. По делам? Йә, йә...

Җәмил. Шул арада кайттың дамы?

Наилә. Әлбәттә.

Җәмил. Бик тиз.

Наилә. Тырыштым инде. *(Пауза.)* Җәмил, әле генә синең янга кем килде?

Җәмил. Минем янга?

Наилә. Әйе, синең янга? Миңа бу турыда Ания Хисмәтовна әйтте. Кемдер синең эштән.

Җәмил. Д-да...

Наилә. Сәер. Ул ханымга утызлар тирәсе булырга тиеш. Йә, әйт инде, шулай да кем иде ул? Бигрәк тә шунысы кызык. Бот төбеннән итәге, лифчиксыз, хәтта иң кирәкле киемен дә киярgә онытkан. Ул особа кем иде инде? Син миңа бу хикмәтне аңлатып бирә алмассыңмы? *(Җәмил дәшми.)* Әйе, хәзер аңлашылды. Менә нәрсә өчен син мине магазинга аткаргансың икән. Көтүен көткәнсең, әмма өй тулы кунаклар булачагын әйтергә онытkансың. Эх син... Мәхәббәт каһарманы! Мин үзем дә бик яхшы инде. Җүләр. Имеш, шундый тугры, честный кеше таптым. *(Пауза. Авырлык белән.)* Шуңа күрә безгә тиз арада аерылышырга кирәк...

Җәмил. Наилә! Син нәрсә! Синнән гайре беркемем дә юк минем.

Наилә. Хәзер генә трубканы нигә ыргыттың? Нинди сереңне миннән яшерәсең? Син бит һәрвакыт үзеңнең җитди сөйләшүләреңне минем алда сөйләшә идең. Ә бүген?! Әле генә. Юк, Җәмил, Ходай өчен, әйдә аерылышыйк.

Җәмил. Наилә, тыңла әле. Врач... Врач килде.

Наилә. Врач? Ышанмыйм.

Җәмил. Әйе, врач. Һәм ул синең атаңны карады.

Наилә. Әтине?

Җәмил. Әйе.

Наилә. Мин бит аннан, әтидән сорый алам.

Җәмил *(тезләнеп)*. Кирәкми, Наилә... Монда син уйлаганнан да катлаулы мәсьәлә. Менә шул. Вахит әфәнде авыру. Бик каты авыру.

Наилә. Син шаярасың?

Җәмил. Әгәр дә бу шаяру булса, бу шаяруны минеке дип уйлама. Бу шаяру әтиеңә диагноз куйган зур практикалы профессор, врач ханымныкы булыр.

Наилә. Димәк, синең танышың шул врач булып чыгамыни?

Җәмил. Йа Аллам, хәзер моның нинди әһәмияте бар.

Наилә. Әтинең йөрәгеме?

Җәмил. Юк.

Наилә. Нәрсәсе?

Җәмил. Нәрсәсе соң әле? Нәрсәсе? Ә-ә, билдән түбән нәрсә әле?

Наилә. Оятсыз! Бозык!

Җәмил. Син үзең бозык! Бөере!

Наилә. Бөере?

Җәмил. Кыскасы, сул як бөере.

Наилә. Ә нәрсә, врач шул арада белеп тә өлгердеме?

Җәмил. Әйе.

Наилә. Анализ да алмыйча?

Җәмил. Әйе! Кабатлап әйтәм. Ул докторларга доктор! Аны бөтен Европа белә. Менә шул атаңның сул як бөере озакламый, шушы якын көннәрдә эшләвеннән туктаячак.

Наилә *(куркып)*. Шушы көннәрдә? Ничек шушы якын көннәрдә? *(Җәмил авыр сулап куя. Наилә акрын гына аңын югалтып егыла башлый.)*

Җәмил *(аны эләктереп алып)*. Наилә! Аны әле коткарып була. Операция! Йа Раббый Ходаем! Аңын югалтты!

Сәйфиеч керә.

Сәйфиеч. Нәрсә булды сезнең белән? Кызым!

Җәмил. Аңын югалтты. «Ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк.

Сәйфиеч. Кирәкми! Әйдә әле без аны күрше бүлмәдәге караватка кертеп салыйк. Битенә юеш чүпрәк капларбыз.

Ата белән Ана кухняда.

Ата. Карчык, әнисе димен... Әйдә үбешәбез?

Ана. Үбешмәдек түгел инде, үбештек. Җитәр. Әнә Мәмдүдәң артыннан йөгер. Бәлки, куып тотарсың да рәхәтләнеп үбешерсез.

Ата. Тагын нәрсә!

Ана. Алайса, өйгә кадәр түз. Кайткач, теге мине утырткан секретаршаң белән рәхәтләнеп суд залындагы эскәмиядә ялашырсың.

Ата. Суд залында! Күптән мин андагы сукмакны оныттым.

Ана. Димәк, күршеләр сукмагын таптагансыңдыр. Теге чөгендер борын Асиянекен яки Валька Боброванықын.

Ата. Син нәрсә инде, аларга каберең якын булмасын.

Ана. Ышанды дисеңме?

Ата. Әйтәм ич, Аллам сакласын!

Ана. Димәк, Вәсимәне.

Ата. Тагын?! Син алар белән минем бөтен мозгамны ашадың.

Ана. Сиңа рәхәт булсын дип.

Ата. Соң, үзең уйлап кара. Вәсимә, имеш. Нинди Валька? Нигә миңа пеләш секретарша? Бары тик син. Син генә минем йөрәк түремдә.

Ана *(йомшара төшеп)*. Йөрәк түремдә, имеш...

Ата. Ант итәм. *(Күкрәгенә сугып.)* Монда, монда, биредә син, минем бәгырь кошым! Синең алтын ояң биредә. Менә монда — минем йөрәгем түрендә.

Ана. Күзгә төтен җибәрмә! Җибәрмә төтен! Ышанган диярләр. Сасыган кәҗә тәкәсе!

Ата. Ышанмыйсың?! Дөньяның якты чыраен күрмим. Валлаһи, димен.

Үбешә башлыйлар. Җәмил керә.

Җәмил *(шаккатып)*. Вахит әфәнде, Ания ханым!

Ана белән Ата бер-берсеннән читкә тайпылалар.

Җәмил. Вахит әфәнде, сез минем бүлмәгә бер генә стакан су алып керә алмассызмы?

Ата. Су? Нигә?

Җәмил. Кирәк иде. Мин сездән үтенеп сорыйм. Ә сез, Ания ханым, биредә калыгыз!

Ата иңсәсен уйнатып ала да суга дип чыгып китә.

Җәмил. Ания ханым! Дөрес, мин барысын да аңлыйм! Ялгызлыкның бик авыр хәл икәнен дә, мәктәбегездә өч тешле Лотфый карттан гайре ирләр булмавын да, әмма ләкин Вахит әфәнде бит өйләнгән, Ания Хисмәтовна! Әйе, күптән өйләнгән. Алар бәхетле парлар. Аның искитмәле гүзәл тормыш иптәше бар. Йа Раббый бер Ходаем! Утыз ел! Утыз ел ботинкага тагылган шнур кебек сез аның артыннан тагылып йөрисез. Утыз ел эчендә шнур булып шнур аңлар иде. Намуслы, чиста күңелле Вахит әфәнденең үз хатыныннан гайре башка һичкемгә күтәрелеп карамыйча бары тик үз хатынын гына өзелеп сөйгәнен сез аңларга тиеш. Мин сезне аңлыйм, Ания Хисмәтовна. Сезгә бу сүзләрне ишетү, әлбәттә, бик авыр. *(Пауза.)* Тагын менә нәрсә. Әгәр инде чын дөреслекне беләсегез килсә, тыңлагыз. Сез биредә чит кеше. Сезгә сөйләргә ярыйдыр дип уйлыйм. Хәтерлисезме, күптән түгел генә минем янга кергән ханымны?

Ана. Хәтерлим.

Җәмил. Менә шул. Ул доктор, ягъни врач!

Ана. Врач?! Сезнең ул танышыгыз врач?

Җәмил. Әйе, опытный, танылган профессор. Ул, Вахит әфәндене яхшылап тикшергәннән соң, миңа секрет итеп кенә Вахит әфәнденең каты авыру икәнен һәм озак яшәмәячәген әйтте.

Ана. Ничек? Ничек, яшәмәячәген?

Җәмил. Ә-ә... Агарып каттыгызмы! Менә шулай! Шулай ул. Гөнаһлы картлык йөзгә бәреп чыга. Ә хәзер мин сездән тезләнеп ялварам. Зинһар өчен, димен, китегез сез биредән! Китегез! Тиз арада китегез! Намуслы кешенең намусына тап төшермәгез! Хәзер генә булса да, санаулы көннәре калган бәндәне тынычлыкта калдырыгыз!

Ана *(калтыраган тавыш белән)*. С-с-соң-гы к-к-көн-н-н-нәре?

Җәмил *(кайгылы рәвештә)*. Әйе! Врач әйтүенә караганда, Вахит әфәнденең атналык та гомере калмаган. *(Ана аңын җуеп идәнгә ава.)* Йа Раббый Ходаем! Кара инде моны.

Стакан күтәреп, Сәйфиеч керә.

Сәйфиеч. Тагын су кирәкме? Ания Хисмәтовна, сезнең белән нәрсә булды?

Җәмил. Һуштан язды. Су кирәк.

Сәйфиеч. Юк, монда массаж кирәк.

Җәмил. Массаж?.. Ни өчен?

Сәйфиеч. Эчке сиземләү, Җәмил улым, эчке сиземләү. Күкрәгенә энергичный массаж кирәк. Кая әле. *(Күлмәк җиңен сызгана.)*

Җәмил. Ярдәм итәргәме?

Сәйфиеч. Юк, юк. Хәзер ясалма сулыш та алдырам. Иренне иренгә.

Җәмил. Арымадыгызмы? *(Сәйфиеч башын чайкый.)* Бәлки, мин?

Сәйфиеч *(аны этеп җибәрә)*. Үзем! Үзем! *(Дәвам итә. Вахит чыга.)*

Ата. Кая соң су, җен әвәләгән! *(Күзе Сәйфиечкә төшә, аның кыланмышына акаеп карап тора да Ана өстеннән Сәйфиечне тартып торгыза башлый.)*

Җәмил. Комачауламагыз әле!

Ата. Нәрсә?!

Җәмил. Бу — ясалма сулыш.

Ата. Ясалма сулыш?

Сәйфиеч. Ну! Авызга-авыз, иренгә-ирен! Ул бит аңсыз.

Җәмил. Әйе.

Ата. Үзем, үзем мин аңа ясыйм!

Сәйфиеч. Син?! Авызга-авыз? Почетлы укытучыны?!

Ата. Үзең соң, үзең?!

Сәйфиеч. Нәрсә үзең? Мин — хатын-кыз! А ну-ка мине ханымның гәүдәсе янына җибәр.

Ата. Брысь! *(Ясалма сулыш ясарга тырыша.)*

Сәйфиеч. Оятсыз! Минем алда, хәләл хатының янында чит-ят хатынны теге дөньядан йолкып алмакчысыңмы? Яле, миңа, хатын-кызга юл бир!!!

Ата. Хәзер. Көтеп тор!

Җәмил. Сабыр итегез! *(Авызына су алып, Анага бөрки. Ана авыр сулап күзен ача.)*

Ата. Исән!

Ана. Вахитым!

Наилә керә.

Наилә. Әти, әтием! Син биредәме, җанашым!

Ата. Кызым! Хәләлкәем, карчыккаем!

Сәйфиеч. Мин биредә, хөрмәм! *(Атаны кочаклый.)* Ярый, болай булгач булды. Киттек, Җәмил. Иркенләп үз аңына кайтсын.

Җәмил. Ничек?! Ташлап китәбез? Ярдәм кирәк булса?

Сәйфиеч. Җәмил, сез аларга ярдәм италырсыз дип уйлыйсызмы?

Җәмил. Белмим шул.

Җәмил белән Сәйфиеч чыгып китәләр.

Ана. Вахитым!

Наилә. Әтием! *(Әтисен кочаклап үбә, күзләре яшьле.)*

Ата. Нәрсә булды сезнең белән? Шундый итеп җылыйсыз, әйтерсең лә сез түгел, ә мин хуштан язганмын.

Наилә. Әтием... Минем сине рәнҗеткәнем булмадымы?

Ана. Ә минем?

Наилә. Әгәр рәнҗеткән булсам, гафу ит!

Ана. Мине дә!

Ата *(аптырап)*. Нәрсә өчен?

Наилә. Юк, болай гына.

Ана. Кыскасы...

Наилә. Ярый. Мин магазинга йөгердем. Тозлы кыяр, селедка, тагын кайбер әйберләр алып кайтыйм.

Ана. Бөркетебез син безнең!

Ата. Кая ашыгасыз? Барыбыз бергә җыелып утырабыз да...

Наилә. Әтием, зинһар өчен, син дулкынланма!

Ана. Әйе-әйе, сиңа дулкынланырга ярамый.

Ата *(куркып)*. Ярамый?! Миңа? Ни өчен? Йә, нигә күзләрегезне миннән яшерәсез? *(Йодрыгы белән өстәлгә суга.)* Җен әвәләгән нәрсәләр! Тагын нәрсә уйлап чыгардыгыз?!

Ана. Бәгырькәем минем! Ә бәлки... Бәлки, мәчеткә барырбыз?

Ата *(гаҗәпләнеп)*. Кайда-кайда?

Ана. Мәчеткә.

Ата. Әллә саташа башладыңмы? Син мәчетнең кайсы якта икәнен беләсеңме соң?

Ана. Ходай үзе күрсәтер. Керербез. Сиңа атап хәер бирербез...

Ата. Аңлашылды. Шизофрения башланган. Мәчеттә миңа бернәрсә дә калмаган.

Наилә. Бу очракта әни хаклы. Хәер бирерсез. Мәчет сафландыра, мәчет үткәнне дә, бүгенгене дә, мәңгелекне дә уйландыра.

Ата. Шулай... Вот кабахәт, подлец, балакаемны нинди хәлгә төшерде.

Наилә. Кем кабахәт?

Ата. Синең теге әнекәччәең, мамуляң! Артыгыннан тыш күбрәк уйнап ташлады. Җитте аңа! Бу эшкә нокта куярга вакыт. Кыскасы, мин аның янына киттем.

Ана. Кая?

Ата. Теге хатын-кыз күлмәге кигән өтәчкене тәрәзәдән ыргытам.

Наилә. Әти!

Ана. Вахит!

Ата *(аларны тыңламыйча, үз-үзенә)*. Кара син аны, кара еланны. Имеш, авызга-авыз, иренгә-ирен! Ә бәлки, күз төбенә менә бу йодрык кирәктер?! *(Кулын йомарлый.)* Арт ягына менә бу ботинкалар! Тәрәзәдән башың белән чыгарам!!! *(Тәвәккәл адымнар белән ишеккә юнәлә. Муенына Наилә белән Ана асылыналар.)*

Наилә. Әтекәччәем!

Ана. Вахиткаем!

Ата. Булды! Җитте! Балавыз сыкмагыз! Икенче генә итаж. Үлмәс!

Ана. Вахит, без җүләрләрне, зинһар, гафу ит. Ә беләсеңме Җәмилгә нинди танышы килде?

Наилә *(исе китеп)*. Син дә аның кем икәнен беләсең?
Ана. Син дә?! Врач, врач ханым иде ул!
Ата. Доктор, врач?
Наилә. Әйе, профессор. Ул синең сәламәтлегеңне тикшерде.
Ата. Сәламәтлегемне?
Ана. Әйе.
Ата *(иңсәсен уйнатып)*. Ни өчен? Кызганычка каршы, мин үземнең сәламәтлегемнән зарланмыйм. Ә нәрсә? Минем нинди дә булса берәр организмым белән...
Наилә. Әйе, ну... ну, синең, әти, бөерең...
Ата. Бөерем?
Наилә. Әйе, дөресрәге, бер бөерең...
Ата. Нәрсә уйлап таптыгыз?! Нинди бөер?! Минем барысы да тәртиптә!
Наилә. Юк шул, әти, юк! Кызганычка каршы, сул як бөерең...
Ата *(үз-үзен соткалап)*. Кая, кая була соң ул бөер?
Наилә. Менә биредә. *(Билен тотып күрсәтә.)*
Ата *(үз-үзен соткалап)*. Берни дә аңламыйм да, сизмим дә!
Ана *(өмет белән)*. Берни дә сизмим, ди...
Наилә. Димәк, үлгән. Бөере эштән чыккан.
Ата. Туктагыз әле. Күлмәгемне дә салдырмыйча ничек ул мине тикшерде соң?
Наилә. Бер күз сирпеп алу да җитә диагноз куяр өчен.
Ата. Димәк, профессор дисең инде?
Ана *(авыр сулап)*. Әйе.
Ата. Ә ул, бәлки, ялгышкандыр.
Наилә. Кызганыч ки, әмма ләкин... *(Пауза.)*
Ата *(үлеп бетеп)*. Шулай дисез инде. Кирәк бит, ә? Ә ул минем күпме гомерем калганны әйтмәдеме? Күпме шушы якты дөнья буйлап кырык бишле туфлиләремне өстерәячәгемне әйтмәдеме? Күпме?!
Наилә. Биш-алты көн...
Ана. Вахиткаем!
Ата *(калтыранган куллары белән)*. Мин аларга нигә инде? Гомерем буе тартмадым, кеше шикелле эчтем. Башкалар кебек эшләдем.
Ана. Башкалар кебек, имеш?.. Гомер буе өч кешелек эшләдең син!
Наилә. Кыскасы, эшләдең, эшләдең дә барып чыктың.
Ата. Ә ни эшлим? Сезнең өчен эшләдем! Үзем өчен бөкремне чыгармадым.
Ана. Менә үз-үзеңне кызганмасаң. Шулай ул. Барып терәлдеңме?

Пауза. Сәйфиеч ишектән башын тыгып ала.

Ата. Юк, юк, Ходай, күрәсең, бөтен гөнаһларым өчен...
Ана. Нинди гөнаh?.. Нинди гөнаһың булсын синең?..
Ата *(тирән кайгырып)*. Ә хәзер нигә яшереп торырга! Ходайдан яшереп булмый. Ходай барысын да белә, барысын да күреп тора. Галимәсе белән дә, Асиясе белән дә, Валька Бобровасы белән дә, кыскасы, теге кара күзле кызкай белән дә булды инде, булды! Белмим, син мине гафу итә алырсыңмы?..
Ана *(елый)*. Итәм, итәм, Вахиткаем!..
Ата. Рәхмәт! Белдем, сиздем мин синең мине гафу итәчәгеңне. Ә менә Ходай... Ходай гафу итәрме? Нәрсә кирәк? Дөньям түгәрәк иде бит. Янымда тутырган тавык кебек хатыным, сау-сәламәт балаларым, өем, яраткан эшем. Юк, кирәк бит, ә. Чит хатыннар кирәк. Минем аркада хатыным утырып чыкты.
Ана *(яшь аралаш)*. Ташласана!
Ата. Минем аркада! Әйе! *(Бераз эндәшми торганнан соң.)* Шулай шул. Бүген төшемдә мәче күргән идем.
Ана. Мәче?
Ата. Ата кара мәче! Күзен акайтып миңа караган да мыеклы паразит, мискидан ит урлый.
Ана *(авыр сулап)*. Урлый алдымы?
Ата. Алды.
Ана. Бөер! Совершенно верно — бөер! *(Барысы да айнып киткәндәй булалар.)*
Ата. Әйе, бу кадәр төшемнең туры хак килгәне юк иде әле. Сез мәчет турында сөйләшкән идегез бугай. Чыннан да, бәлки, үз гомеремдә бер генә тапкыр булса да мәрхүм әнкәм-әткәм, әби-бабаларым хөрмәтенә хәер биреп кайтырга кирәктер. Алай-болай китеп барсам.

Сәйфиеч керә. Билгеле, ул ишек артыннан тыңлап торган.

Ата. Ә хәзер барысына да нокта куярга вакыт җитте. *(Башын чайкап.)* Җитте! Хва-ати-ит! Кыскасы, хәзер янына барам да чын дөреслекне ачып салам. Һәм Җәмил алдына тезләнеп гафу үтенәм.

Сәйфиеч. Ә кызың? Кызың турында уйладыңмы соң син, Вахит әфәнде?

Ана. Әйе, кызың хакында...

Ата. Юк инде! Сезгә алдашырга да алдашырга, кемне дә булса төп башына утыртырга кирәк. Сездә минем кайгы юк! Юл бирегез миңа!

Наилә. Әти!

Ана. Вахит! Карткаем!

Ата. Юл! Юл бирегез!

Кыю атлап ишеккә атлый. Сәйфиеч аның башына суга. Вахит чайка-лып тора да егыла.

Ана. Син нәрсә?

Наилә. Әтием! Син үтердең аны!

Сәйфиеч. Миңгерәүләттем генә. Озакламас, аңына килер.

Ишектә звонок шылтырый.

Наилә *(ачуланган хәлдә)*. Кем инде анда тагын? Әни, әтине кара, ә мин хәзер... Кухнядан прихожийга чыга.

Үз бүлмәсеннән Җәмил чыга.

Кемнедер көтәсең?

Җәмил. Юк ла...

Ишекне ача. Эльмира керә.

О-о, Мәмдүдә Ханнановна!

Эльмира. Мең тапкыр гафу үтенәм. Сездә зажигалкамны калдырганмын бугай.

Җәмил. Ә-ә... Бер генә минут.

Эзли. Наилә, шикләнеп, Эльмираны күзәтә. Әмма ләкин ул аны танып җиткерми. Эльмира үзен танытмаска тырышып йөзен яшерә.

Җәмил. Менә ич ул.

Наилә. Шушы зажигалкамы? Карарга мөмкинме?

Эльмира. Рәхим итегез!

Наилә. Затлы...

Эльмира. Бик-бик тә. Ярый, мин йөгердем! *(Ашыгып чыгып китә.)*

Наилә. Шушы үзе буламы инде врач?

Җәмил. Нәкъ үзе.

Наилә. Димәк, этинең чирен ул тапты?

Җәмил. Әлбәттә, ул. Ә син, җүләрем, аңардан мине көнләгән булдың. Ну син, Наилә, борчылма. Мин синең этиеңнең операциясенә акча эзли башладым инде.

Наилә. Акча?! Операциягә?

Җәмил. Әлбәттә, әниеңә вәгъдә иткән биш мең евро!

Наилә. Нәрсә?! Син ул акчаларны әнигә бирәсең?..

Җәмил. Әйе. Әйтеп торам бит, операциягә кирәк.

Наилә. Йа Ходаем!

Җәмил *(сагая төшеп)*. Ә нәрсә? Әниең нәрсәдер, әллә...

Наилә. Ә? Юк ла... Нәрсәдер, нигәдер... Уйлавымча...

Җәмил. Мин үзем дә шулай уйладым. Ни өчен аңа мине алдарга? Дөресен генә әйткәндә, биш минуттан кияү буласы кешене.

Наилә. Сөйлисе юк.

Җәмил. Дөресен генә әйткәндә, авыру, операция хакында ул сиңа әйтмәскә кушкан иде дә. Ә мин, күрәсең, сүземдә тора алмадым.

Наилә. Зыян юк.

Җәмил. Ярый, мин шылтыратыйм әле.

Наилә. Кемгә?

Җәмил. Рәттән бөтен таныш-белешләремә. Кемнәндер акча алып торырга кирәк бит.

Наилә. Ә-ә... Син шуның өчен көне-төне шылтыратасыңмыни?

Җәмил. Билгеле. Ә син ничек уйладың?

Наилә. Менә хәзер аңладым.

Җәмил бүлмәсенә кереп китә. Наилә кухняга чыга. Әтисе идәндә башын

селкеп утыра.
Йә, аңыңа килдеңме.

Ата. Бераз.

Сәйфиеч. Бераз гына су бөркегән идем, тәртип.

Наилә. Котлыйм сине, әти. Синең үлемең кичерелә.

Ана. Нәрсә?

Ата. Ничек? Н-н-ни-чек кичерелә?

Наилә. Әйе, күрдем мин сезнең ул ялангач ботлы профессоршагызны.

Ата. Ханнановнанымы?

Ана. Шуннан нәрсә?

Наилә. Менә шул: син укытучы булган кебек, ул да бер медик. Менә бу минем әни кебек. Алар менә моның белән икесе бер калыптан. Ике кием — бер чабата! Бер шайкадан!

Ата. Һични аңламыйм. Нәрсә булып чыга соң бу?

Наилә. Нәрсә булып чыксын. Менә бу ике тутый кош, Җәмилнең башын бутап, янәсе, сиңа операция ясатабыз дип, биш мең евросын үзләштермәкче булалар.

Ана. Йа Ходаем!

Ата. Нәрсә?

Наилә. Әйе, әйе!

Ана. Менә сиңа мә!

Ата. Та-ак! Булды бу. Яхшы. Ә хәзер барыгыз да бу бәндәдән гайре күземнән югалыгыз.

Ана. Вахит!

Ата. Мин кемнәргә югалырга куштым? Мин хәзер бу сөекле әнкәй, әнекәччәй белән үземнең зөфаф кичемне үткәрәм!

Сәйфиеч. Но-но! Кулың белән кагыласы булма!

Ата. Әлбәттә! Ә син ничек уйладың!

Сәйфиеч. Туктагыз әле. Ә нәрсә булды соң? Сез миннән әниегез булуымны сорадыгыз, ә мин сезнең үтенечегезне үтәдем. Сезнең заказыгызны үтәп, туташ, мин үз алдыма куелган бурычымны намус белән үтәдем. Клиентым, гашыйк булып кына калмыйча, үземне әни дип атый башлады. Сезнең миңа карата бернинди дә претензиягез булырга тиеш түгел!

Наилә. Рәхмәт инде, сөендердең. Биш мең евро! Артык майлы булмасмы?! Үтең сытылмасмы?!

Сәйфиеч. Майлы? Беләсегез килсә, минем кебек тещалар урамда аунап ятмый. Бу бит тормыш-язмыш елмаюы! Бу бит бәһасез лотерея отышы. Барысыннан да иң зуры, иң мөһиме минем аркада, минем аналык хисем аркасында... сез, ниһаять, кияүгә чыгу бәхетенә ирештегез. Әйе! Әйе, сөеклем Наилә туташ! Заказыгыз үтәлде!

Наилә. Без бит өч мең урыс акчасына сөйләштек.

Сәйфиеч. Сезнең белән. Исключительно, именно сезнең белән. Ә менә мин ирләрдән күбрәк алам.

Ата. Профессор аламасы!

Сәйфиеч. Та-ак!.. Профессор аламасы дисез инде. Ә сез, калтыранып утыручы иптәш, авырыксынмый гына күптән түгел аякларыгызны болгап караватта хатыныгызга сөйләгән сөяркәләрегезне исегезгә төшерегез. Күпме евро белән котылырсыз икән?..

Ата. Ул барысын да белә!

Ана *(аптырап)*. Ничек? Каян?

Наилә. Каян-каян! Монда аптырарлык урын юк. Тыңлап торган.

Сәйфиеч. Үзегез бөтен йортка ишетелерлек итеп акырдыгыз.

Ата. Ну и ну, гад!

Сәйфиеч. Борынгы кытай теленә тәрҗемә итсәң, гад — это япона мать. Мине тыңлап калтырап утырган ир, хатыны төрмәдә чагында, әз-мәз генә чит хатыннар белән типтергән дигән сүз.

Ана. Ой, чыннан да шулай бит. Син мине шулай көткәнсең булып чыга түгелме, кәҗә тәкәсе! Сволочь! Фраер, имеш!

Ата. Ну, Галия! Син бит инде мине кичердең!

Ана. Әйе, әйе, сез барыгыз да ирләр — бабниклар. Барыгызны җыеп бер тәпәнгә салып болганчык суда агызырга.

Соңгы сүзен әйткәндә, Җәмил керә.

Җәмил *(югалып кала)*. Күрәм, мин вакытсыз кердем.

Сәйфиеч. Сез... сез нәрсә инде, Җәмил. Ә без монда... Без... Ә, әйе, Ания Хисмәтовна кызып-кызып үзенең бер беренче класста укыган укучысы турында сөйли иде.

Җәмил. Беренче сыйныф укучысы?

Сәйфиеч. Әйе! Үзе беренче сыйныф укучысы гына булса да, ә исеме борынгы — Гаптеләхәтгаптери.

Җәмил. Ә-ә, менә нәрсә икән. Мин сезнең янга идем, Галия ханым.
Сәйфиеч. Тыңлыйм сезне, Җәмил.
Җәмил *(куанычыннан кулларын уа-уа)*. Барып чыгарга охшаган. Алла боерса, барып чыгар төсле. Менә шул. Борчылыр урын юк, әни. Бөтенесе дә яхшы.
Сәйфиеч. Улыкаем!

Җәмил кереп китә.

Наилә. Тантана итәсез. Димәк, барысы да яхшы булачак.
Сәйфиеч. Өметләнәбез. Өметсез — шайтан гына, дигәннәр.
Наилә. Юкка өметләнәсез.
Сәйфиеч. Чынлапмы?
Наилә. Әйе, әйе, сез үзегез ул акчалардан баш тартачаксыз.
Сәйфиеч. Минме?!
Наилә. Ышандырып әйталам. Дөрес, миннән сезгә өч мең эләгәчәк. Ә менә калганы турында исегездән чыгарыгыз.
Сәйфиеч. Тагын нәрсә?
Наилә. Әйтегез әле, теге зажигалка, иптәшегездәге алтын йөгертелгән пистолет-зажигалка, каян килгән ул сезгә?
Сәйфиеч. Зажигалка? Ул хакта бернәрсә дә әйтә алмыйм.
Наилә. Неужели? Ә менә мин әйталам. Сез ул зажигалканы миңа каршы яшәгән фатирдан, тетя Дусядан, алдап, өч тиенлек өстәл сәгатенә алыштырып алгансыз.
Ата. Син боларны каян беләсең?
Наилә. Иртә белән безгә участковый кереп, пистолет-зажигалканың сурәтен күрсәтеп чыкты. Зажигалканың фотосурәте әбинең малаенда сакланган булган. Әгәр ул зажигалканы мин кайда да булса күрсәм, ул миңа шылтыратырга дип үз телефонын калдырды.
Ана. Кража. Өй басу — биш ел!
Наилә. Талау гына булса, бер хәл. Иң кызыгы да шул. Райсобес хезмәткәре булып кереп, әбинең чәенә нәрсә сиптегез, салдыгыз инде?
Сәйфиеч. Тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә! Чушь! Барысы да әкият.
Наилә. Әгәр дә сезнең өстә мәет булса... Моны ничек аңларга?
Сәйфиеч. Мәет?..
Наилә. Шулай килеп чыга шул. Талау, өстәвенә мәет. Групповой.
Ана. Унбиш ел гарантия!
Сәйфиеч. Ну без аның белән чәй генә эчтек.
Наилә. Ну, нәрсә белән инде?
Сәйфиеч. Вәринҗә белән.
Наилә. Шулай гына микән.
Сәйфиеч. Нигә? Ну «Аленка» дигән шоколад белән сыйладык.
Наилә. Диванага салышмагыз, монда дураклар юк. Мин сездән сорыйм, нәрсә салдыгыз? Клофелинмы, снотворныймы? Ну?
Сәйфиеч. Йоклаткыч.
Наилә. Ниһаять.
Сәйфиеч. Ул безгә йокысызлыктан зарланды. Ә без аңа йокы таблеткасын эчерттек. Рәхәтләнеп йокласын карт әби дип уйладык.
Наилә. Шуннан.
Сәйфиеч. Юк, юк. Мин сезгә ышанмыйм. Без бит аңа иң кечкенә дозаны бирдек!
Наилә. Шулай да булсын ди. Әгәр дә карт кешенең йөрәге авыру, слабый булса?
Ана. Кеше үтерүче!
Ата. Сволочь!
Сәйфиеч (*ни эшләргә белмичә башын ике кулы белән тотып)*. Кирәк бит, ә, кирәк бит! Черт!
Наилә. Кыскасы, менә шул. Мин сезгә шундый киңәш бирәм, сатулашмый гына биредән тиз арада үкчәләрегезне күтәрүегезне сорыйм. Әлегә мин участковыйга шылтыратмый торам. Ә соңыннан күз күрер. Сез мине аңладыгызмы?
Сәйфиеч *(паузадан соң, кычкырмыйча гына)*. Юк инде, рәхмәт!
Наилә *(аңлап җиткермичә)*. Нәрсә?
Сәйфиеч. Мине бугаздан алмакчы булдыңмы? Юк инде, сөеклем, ялгышасың. Синең кебекләрне күп күргән!
Наилә. Чынлапмы?
Сәйфиеч. Менә шул: зажигалканы без койма яныннан таптык, аңлашылдымы?
Наилә *(ирония белән)*. Сәгать яткан җирдәнме?

Сәйфиеч. Сәгать?! Нинди сәгать?
Наилә. Ябалак итеп ясалган өстәл сәгате.
Сәйфиеч. Беренче тапкыр ишетәм.
Наилә. Ташла! Яңа гына барысын да үзең сөйләп бирдең ләбаса.
Сәйфиеч. Болай гына. Кызык өчен.
Наилә. Ә сез ышанып әйтә аласызмы әби фатирында бармак эзләребез калмаган дип.
Сәйфиеч. Әйталабыз.
Наилә. Йөз процентмы?
Сәйфиеч. Ну, башкасына йөз процентка ышанам.
Наилә. Башкасы тагын нәрсә инде?
Сәйфиеч. Башкасымы? Башкасы шул: Җәмил синең газиз анаң турындагы чынбарлыкны белгәч, беләсеңме кая җибәрәчәк ул сине? Ул сине башка анаң янына җибәрәчәк. Һәм мин ышанам, йөз процент ышанам. Син бу яшеңдә бүтән кияү чырае күрмәячәксең.
Ата. Бәлки, үзен селкетеп алыргадыр?
Наилә. Кирәкми. *(Сәйфиечкә.)* Яхшы. Шулай да әгәр бармак эзләре калса... Ул чагында нәрсә?
Ана. Әйтәм бит, унбиш ел!
Сәйфиеч. Ярый, булды, туйдырдыгыз! Кемне-кемне, мине шантажировать итәсез. Көтеп торыгыз. Куркыталар, имеш. *(Паригын салып ташлый.)* Чакыртыгыз милициягезне! Киявегез белән бергә. Ниһаять, үз тещасын бөтен матурлыгы белән күрсен. Йә, кая, кая ул? Җәмил! Кияү!
Наилә *(куркынган тавыш белән пышылдый)*. Акылдан шашкан тиле! Кидерегез үзенә. Тиз булыгыз!
Сәйфиеч. Юк инде, төрмә икән төрмә! Күпме иртәрәк утырсаң, шулкадәр иртәрәк чыгасың!
Наилә. Ну ничек, ничек Җәмил ул акчаларны киредән хуҗаларына кайтарып бирә алачак.
Сәйфиеч. Ашыкмыйча. Иплэп кенә. Җайлап кына.
Наилә. Өстәвенә аның алимент!
Сәйфиеч. А-ли-мент? Кара син аны, нинди бозык! Күпме хатыннарның тормышын чәлпәрәмә китергән. Өстәвенә балаларын ташлаган. Вот ат чырай. Менә ул нинди икән. Өзегез, өзегез сез аның белән арагызны, Наилә туташ. Һәм тиз арада өзегез. Мин сезгә моны әниегез буларак түгел, ә хәзер этиегез буларак әйтәм.
Наилә. Ходаем! Зинһар, паригыгызны киегез!
Сәйфиеч. Теләмим. Эссе. Куркудан башым тирләде.
Наилә. Зинһар өчен!
Сәйфиеч. Юк, юк! Башымның тиресе рәхәтләнеп тын алсын әле. Ах, нинди рәхәт!
Наилә. Киегез инде!
Сәйфиеч. Бик кияр идем дә, чәчләремне кызганам. Рәхәтләнеп сулагыз, бәгырьләрем.
Наилә. Мин сездән үтенеп сорыйм.
Сәйфиеч. Шулай итеп, шулай. Итак. Әйтегез, мин үземнең еврикларыма хуҗа булачакмынмы?
Наилә. Әйе.
Сәйфиеч. Барлык биш меңгә дәме?
Наилә. Да!
Сәйфиеч. Ишетмим, кызым.
Наилә. Әйе, әйе... *(Ачулы.)* Мамуля!
Сәйфиеч. Күптәннән шулай диләр аны, бәгырькәем! *(Парикны кия.)*
Ата. Сез монда теләсә нәрсә эшләгез. Әмма ләкин мин үземне, йә булмаса, башка берәүне алдарга җыенмыйм.
Наилә. Нәрсә турында алдарга? Аңлап җиткермәдем.
Ата. Үземнең бөерем хакында.
Наилә. Йа Раббым бер Ходаем! Әти, син генә булса да дәшми торaласыңмы?
Ата. Әгәр алар сәламәт икән, нигә алдарга.
Ана. Вахит!
Ата. Әйттем, бетте. Мин үзсүзле.
Наилә. Әти дим...
Ата. Әйттем и все! Нокта!

Җәмил керә.

Җәмил *(шатланып)*. Галия ханым, тәртип! Мин таптым.
Ата. Әгәр дә син минем бөерем өчен тырышсаң, зря! Вакытыңны гына әрәм итәсең.
Җәмил *(югалып кала)*. Аңламадым.
Ата. Минем бөерләремә пычак та булмаган. Алар исән-сау, сәламәтләр.
Җәмил. Икесе дәме?
Ата. Бер-берсенең сәламәтлегеннән көнләшеп кабыргаларыма тибеп яшиләр.

Җәмил. Галия ханым, бәлки, сез миңа аңлатып бирерсез. Нигә сез дәшмисез?
Сәйфиеч. Ә нәрсәсен аңлатып торырга. Бөтенесе дә хак, Җәмил энем.
Җәмил. Дөрес?
Сәйфиеч. Әйе, Вахитка операция кирәкми.
Җәмил. Ничек?
Сәйфиеч. Шулай. Ул миңа кирәк, миңа!
Җәмил. С-сезгә?
Сәйфиеч. Әйе.
Җәмил. Алайса, нигә соң сез мине көне буе үгетләдегез? Ни өчен?
Сәйфиеч. Чын дөресен әйтимме?
Җәмил. Әлбәттә.
Сәйфиеч. Мин курыктым, Җәмил.
Җәмил. Нәрсәдән?
Сәйфиеч *(оялган булып)*. Үз-үземне эгоист итеп күрсәтмәс өчен. Үз сәламәтлеген генә кайгырта, үз сәламәтлеге өчен генә яши дип уйларсыз дип уйладым. Аннары Наиләнең дә сәламәтлеге әнисенекенә охшагандыр дип уйларсың, дидем. Ходай Наиләмне үземә охшатып тудырган. Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Кыскасы, үз баламның бәхете өчен көрәшеп, ялган юлга бастым. Сез мине гафу итәрсез дип ышанам.
Җәмил. Ә... ә... әлбәттә. Ә-ә, туктагыз әле, ә врач? Ул бит аны авырый диде.
Сәйфиеч. Әй Җәмил, Җәмил! Сез һаман да сабый! Билгеле, мин Мәмдүдә ханымнан минем файдага сөйләвен үтенеп сорадым.
Җәмил. Ә-ә...
Сәйфиеч. Ә хәзер, Җәмил улым, балакаем минем, без синең белән акча артыннан китәбез.
Җәмил. Юк ла! Юк, бернинди дә акча кирәкми!
Сәйфиеч. Ни-и-чек кирәкми?
Җәмил. Менә шулай. Күз алдына китерәсезме? Шылтыратам, шылтыратам... Көтмәгәндә менә сиңа мә! Минем бит бик якын таныш хирургым бар.
Сәйфиеч. Таныш хирург?
Җәмил. Таныш кынамы соң. Ун ел бер партада утырып укыдык. Классный хирург. Чит илдән кайтып кергәне юк. Ел башында гына Америкадан кайтып төште. Биш ел американецларны яргалады. Кыскасы, бушка операция ясарга риза булды, Галия ханым. Хәзер сезнең арттан керәчәк медсестраларга гына бер коньяклык акча ыргытам да, бөтенесе дә урынына утыра.
Сәйфиеч. Хәзер дисеңме? Минем арттан керәләр дисеңме? Ничек хәзер?..
Җәмил. Әйе, иртә белән ул бер айга Германиягә оча. Менә бүген бер буш киче калган. Менә шул. Әзерләнегез, Галия ханым. Ике сәгатьтән сезгә операция башлана. *(Сәйфиеч басып торган җиреннән селкенә башлый.)* Аның белән нәрсә? Аңа авыр? Приступ? Өянәк?
Сәйфиеч. Ю-ю-юк. Бетте.

Җәмил җайлап кына аны урындыкка утырта.

Җәмил. Шатланыгыз, шатланыгыз, Алла коллары! Галия ханым яши, яшәячәк Галия ханым!
Сәйфиеч *(авырлык белән йөзендә көлү чаткылары ясап, паузадан соң)*. Но... э-э... а, үтә, үтә.
Җәмил *(аңламыйча)*. Аңламыйм.
Сәйфиеч. Бөеремне әйтәм... Күрәсең... операциясез дә ничек тә төзәлер әле.
Җәмил *(югалып кала)*. Юк, мин тагын берни дә аңламыйм.
Наилә. Әни!
Ата. Алтыным! Операция! Бер нигә карамый, операция!
Ана. Галия ханым, ризалыгыгызны бирегез!
Сәйфиеч *(иплэп-иплэп ишек катына якынаеп)*. Ну... э... э... я...
Ата *(ишеккә аркылы басып)*. Галиям, үтенеп сорыйм!
Сәйфиеч. Мин... ни... Авыртудан куркам.
Ана. Борчылма, авыртмый ул. Наркоз белән ясыйлар.
Җәмил. Минем үземнең сукыр эчәгемне алып ташладылар, төкереп тә бирмәдем.
Сәйфиеч. Ну... мин...
Ата *(мәкерле тавыш белән)*. Хөрмәм!

«Ашыгыч ярдәм» машинасының сирена тавышы ишетелә. Бераздан
ул килеп туктый. Аяк тавышлары, ишек ябылган тавыш.

Җәмил *(шатланып)*. Алар! Алар! Шәфкать туташлары!

Пәрдә.

# ЭЧТӘЛЕК

Хиромантлар ............................................
Коткарыгыз, каравыл!!! ....................................
Таш сандык .............................................
Хөрмәткә кирәк хөрмәт ....................................
Әни буласым килә ........................................

**Тәрҗемәләр**

Яп тәрәзәң, бетте баш! .....................................
Булмас димә, дөнья бу ....................................

Литературно-художественное издание

**Салихов** Данил Хабибрахманович

КАМЕННЫЙ СУНДУК

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Салихов** Данил Хәбибрахман улы

ТАШ САНДЫК

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *С.Н.Галимуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.10.2008. Форматы 84г108 1/32.
Шартлы басма табагы 16,80. Шартлы буяу-оттиск 17,22.
Нәшер-хисап табагы 17,71. Тиражы 3000 д. Заказ Т-1390.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.